# Казан утлары

12 декабрь 1967

# Казан утлары



АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

**12**

ДЕКАБРЬ

1967

## Бу санда:

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ПОЭМА, ШИГЫРЬЛӘР

А. Расих. **Ямашев.** Роман . . . . . 3
Г. Хуҗиев. **Тәрәзәләр таңга карый.** Поэма . . . . . . . . . . 47
Н. Фәттах. **Мөдир Сәҗидә.** Повесть . . 54
Д. Сирай. **Яшьлек кебек. Наратлар талпына. Әй, сары яфрагым. Шифа бирә. Үз елгам бар. Алып кайтмас.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . 102

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ

Н. Юзиев. **Музалар туганлыгы.** . . . 104

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫННАН МАТЕРИАЛЛАР

А. П. Золина, Т. М. Насыйров. **Муса Җәлил биографиясенә яңа документлар** 113

ШАГЫЙРЬНЕҢ КУЕН ДӘФТӘРЕННӘН

З. Нури. **Чәчәкле этюд. Белсәм әгәр. Гыйшык уты. Кәләпүш. Ике башак. Бер кәрләгә. Ашыгуга каршы. Сүздә һәм эштә. Оптимист ялкау. Борчак белән ногыт. Актарыла урам. Шагыйрь шунда иде. Авызын бикләде. Эре белән вак. Масаю. Сүз остасы. Уңай тип. Яла ягучы. Тасма тел. Акыллы зат.** Шигырьләр . . . . . . . . . . 123

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. Харисов. **Юл өстендә кояш** . . . 127

ИСТӘЛЕКЛӘР

Л. Антов. **Артистның тормыш юлы** . . . 133

**Яңа китаплар** . . . . . . . . . . 148

**Укучы сүзе** . . . . . . . . . . . 150


**«Казан утлары» журналы битләрендә 1967 елда басылган әсәрләр исемлеге** . . 152

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

*Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*




*Атилла Расих*

*Роман*[1]

## Җәгъфәр

Җәгъфәр, аякларын чалган килеш, йомшак кәнәфидә утыра иде. Ул, гасабиланып, кулындагы газетаның соңгы битен ачты да көзге алдында көязләнеп торган Гөлҗиһанга төксе йөз белән текәлде.

— Буласыңмы инде син, тәмам алҗыттың!

Гөлҗиһан күпермә иңбашлы, тар билле, киң итәкле алсу асыл күлмәктән һәм яшел хәтфә камзулдан иде. Аның матур тулы йөзе дә алсуланып тора, күзләре уттай; бүлтәебрәк торган иреннәрендә үз-үзеннән канәгать булу, шатлыклы һәм сөйкемле бер елмаю балкый иде. Гөлҗиһанның елкылдап торган куе маңгай чәчләре өстендә генә — энҗеле хәтфә калфак. Барысы-барысы да бик матур һәм бик килешле. Хәтта биек үкчәле*читеге дә, итәк аша тоелып торган тыгыз балтырлы аяклары да...

Җәгъфәрнең җыерылган кашлары ихтыярсыздан язылып китте һәм иреннәренә саран гына булса да елмаю билгесе чыкты. Гөлҗиһан, ниһаять, керфек өстенә, күз кабагына хаҗ сөрмәсе сөртте. Ул, көзгегә якын ук килеп йөзен җентекләп тикшергәннән соң, түшәмгә тия язган трюмо тартмасыннан гатырша мае алды һәм энҗе муенса таккан ак муенына шуны сөртә башлады. Инде барысы да бетәргә тиеш иде. Йөзгә кершән сөртелде, иреннәргә, бит алмаларына чамасын белеп кенә иннек тә ягылды, кашлар караптылды, үзенең хуш исе белән бөтен өй эчен аңкыткан гатырша мае да эшкә китте — барысы да булды. Ләкин, Җәгъфәрнең шулай уйлап өлгерүе һәм урыныннан кузгала башлавы булды, Гөлҗиһан:

— Шырпы бирче, — диде. Җәгъфәр кесәсеннән шырпы чыгарды, аның ни өчен икәнлеген белеп, яндыра башлады.

---

[1] Ахыры. Башы 9—11 саннарда.

— Үзем, үзем, — диде Гөлҗиһан, кабаланып. — Үткән юлы да син яндырып мин сүндергән ием, талашуга булды.

Хатын, йөзек, балдаклар белән бизәлгән ап-ак тулы бармакларына кыстырып, чәнти бармагын тырпайткан килеш, ничектер игътибарсыз гына, шул ук вакытта бик нәзакәтле рәвештә шырпы кабыза башлады. Шырпы көеге белән уң як яңагына кечкенә генә кара миң ясап куйды.

Гөлҗиһан авызын очлайтып шырпы сүндергәндә Җәгъфәрнең бөтенләй диярлек хатынына ачуы сүрелгән иде инде, чөнки шулкадәр сөйкемле иде ул җен!

Хәлбуки, кәеф кырылырлык сәбәп бар иде. Бүген урамда очрап, Хөсәен Җәгъфәрне «Кәрвансарай» чәйханәсенә алып керде. Элекке дуслар арасында җитди сөйләшү булды. Хөсәеннең Җәгъфәргә бу кадәр каты бәрелгәне юк иде әле. Гомумән сабыр табигатьле, беркайчан да күтәрелеп бәрелми торган Хөсәенне мондый кискен сүзләр әйтә алыр дип уйламый иде Җәгъфәр. Чәй китерттеләр, ләкин чынаякка кул да тидермәделәр, бары бәхәсләштеләр генә.

Җәгъфәр үзен хаклы дип санады. Хөсәен нинди генә дәлилләр китермәсен, нинди генә авыр сүзләр әйтмәсен, барыбер Җәгъфәрне ышандыра алмады. Шулай да Җәгъфәрнең күңел төбендә нинди дер бер юшкын калды. Тоткан юлының дөреслегенә шикләнү иде бу. Акыл белән түгел, ә тойгы-хис белән үзенең начар, әшәке эшкә керешүен сизенде Җәгъфәр. Шулай ук, Хөсәен әйткәнчә, ул сатлык җан микәнни? Юк, юк, мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Ахыр чиктә кеше үзенә теләсә нинди юл сайларга хаклы. Ничек инде ул, Җәгъфәр, иптәшләрен сатучы булсын? Һич алай түгел! Киресенчә әле: Хөсәен үзе — ирек буучы, көчләп үз идеяләрен башкаларга тагучы. Ә бәлки, түгелдер? Җәгъфәрнең миен әнә шундый сораулар бораулый иде. Ул, түгел, түгел, дип кабатлады. Ләкин ничектер бу җавап нигезсез тоела, аны канәгатьләндерми иде.

Әле менә алар кунакка җыеналар. Казанның зур сәүдәгәрләреннән берсенә — Гөлҗиһанның ерак кардәшләренә. Гөлҗиһан диген, ә? Хөсәен аны да телгә алды бит. Имеш, Җәгъфәр халык чиккән нуҗаны чигәргә теләми, шуңа күрә, яратмаса да, бай тол хатынның аягына барып егылган. Монысы инде чеп-чи ялган. Бәлки, мин аны чын күңелемнән ярата торганмындыр?!

Ләкин бу очракта да эчке бер тавыш Җәгъфәргә, алай түгел бит, дип әйтеп тора иде. «Ә Рабига, Рабига соң?» — дип сорый иде. Авыр иде аңа. Кечкенә генә сәбәп тә аны ярсыта, ачуын китерә иде. Шуңа күрә Гөлҗиһанның артык озак маташуына җенләнеп, карасына бетеп утырды ул.

Ул шулай байтак вакыт, үзе киенгән-ясанган хәлдә, аяк чалып, «Голос» газетасын кыштырдатып, хатынының бизәнеп беткәнен көтеп утырды. Ләкин катырак итеп Гөлҗиһанга сүз әйтә алмады. Чөнки күзләре өй эчендәге нинди әйбергә генә төшмәсен, барысы да хатынныкы иде, хәтта Җәгъфәрнең өстендәге киемнәрен дә шушы бай хатын алып бирде бит. Барыннан да бигрәк гарьләндергәне шул иде: Гөлҗиһан аны үзенең сәүдә эшенә якын җибәрми, эшне үз кулыннан ычкындырмый. Әлбәттә, ул вәгъдә итә, барысы да синеке булачак, ди. Тик кайчан булыр әле ул? Җәгъфәр кайчан шул капиталдан бөек максатлары өчен файдалана алыр соң?

Әле генә Җәгъфәр хатынының матурлыгы белән мавыгып, күңел газапларыннан котылып торган иде. Ләкин Гөлҗиһан әйткән берничә сүз җитә калды.

Хатыны бармагы белән ымлап кына Җәгъфәрне үз янына чакырды.

— Кил әле, тәти егеткәем! — диде.

Җәгъфәр җенләнеп урыныннан торды. Гөлҗиһан исә, берни булма-

гандай, үз янына элепке-салынкы гына килгән Җәгъфәрнең яка асларына гатырша мае сөртте, бик житди бер төс белән Җәгъфәрнең ак якасындагы бантигын төзәтеп куйды, ул да булмады, энжеле хәтфә түбәтәен кырынрак итеп кидерде.

— Асыл кошым, менә шулай кияләр аны — кыйммәтле түбәтәйне!

Аллакай гынам! Әйтерсең лә, Җәгъфәр бер курчак инде! Әйтерсең лә, аның үзенең әз генә дә иреге юк. Түбәтәй, имеш.

Җәгъфәрнең ачудан битләре агарынып китте. Ул, сулышына буылып:

— Беләсеңме, Гөлжиһан, безгә ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк, — диде.

Хатынның күңеле күтәренке иде, ул матур кашларын уйнатып:

— Я, әйтеп бак, чибәрем, — диде.

— Мин артык булдыра алмыйм, юк, юк! — диде Җәгъфәр, хәлсезләнеп.

Гөлжиһан, асыл күлмәк итәкләрен чеметеп тоткан килеш, киң, иркен кәнәфигә барып утырды. Бередә хаким кеше үзе икәнлеген онытмыйча, житдиләнеп:

— Кил, утыр, сөйлә. Син өйгә кайтып кергәннән бирле нидер әйтергә кыжрыйсың, — диде.

Җәгъфәр дә кәнәфигә утырды.

— Безгә ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк...

— Сөйлә, сөйлә. Әллә, бәлкем, син жиңгәчәйләр кочагыннан туптуры өтермәгә эләгүең турында сөйләмәкче буласыңдыр?

— Син борма сүзне, Гөлжиһан! Ул турыда без бик күптән сөйләштек вә аңлаштык.

— Вә, вә, вә! Оятсыз кеше син! Мин сине кеше иттем, мин сине киендердем, рәтле адәм арасына керттем. Әгәр син намуслы булсаң, минем яхшылыкларымны аңлар идең, чукынмыш тәре!

— Мин анысын онытмыйм. Ләкин син дә мине аңларга тиеш, Гөлжиһан. Мин бит курчак түгел. Минем дә бит горурлыгым бар. Нигә син мине шулкадәр рәнҗетәсең, мине бала сымак күреп сөйләшәсең?

Җәгъфәр урыныннан торды.

— Мин иреңме синең, түгелме?

Күрәсең, Җәгъфәрнең дулап, сикереп аякка басуы һәм күзләрен беткәнче ачып карап торуы хатынга бик мәзәк тоелгандыр. Гөлжиһан өй эчен яңгыратып көлеп җибәрде. Бу хатын алдында Җәгъфәр үзенең көчсез икәнлеген бик ачык тойды. Ул инде аның канат астына шулкадәр тирән кереп сыенган, хәтта бу минутта аннан котыла алуына ышанычы да беткән иде.

Гөлжиһан сүз башлады.

— Сиңа нәрсә кирәк, карткаем? Өстең бөтен, ашыйм дисәң, алдыңда тәмле ашлар, инде иркәләним дисәң, куеныңда хур кызыдай яшь, чибәр хатын. Сиңа ни кирәк тагы? Син, бәлкем, сәүдә эшләренә идарә итәргә телисеңдер? Алла боерса, анысы да булыр. Теге чакны мин сиңа барысын да тапшырмак булган идем дә, үзең ич...

Җәгъфәр «һем» дип ачынып елмаеп куйды, ләкин җавап кайтармады.

— Бер дә «һем» түгел, — диде Гөлжиһан, — син минем бөтен өметемне юкка чыгардың, малай. Ничек инде сөйгән кешең әллә нинди бозык хатыннар белән чуалсын да, син тагы шуңа яшьлек исәбенә алынган мирасыңны бир?! Тот капчыгыңны, җәме?

— Мин бит сиңа моның сәбәбен аңлаттым! Анда бары музыка тыңлар өчен генә кердем, дидем. Миллэтебез шундый хәлгә куелган, музыкабызны тыңларлык рәтле урын да юк бит, ичмаса... Син...

— Туктасана, кеше сөйләгәндә бүлдермә, ичмасам, ачу китереп!

Инде минә туган этиең дә үзеңне кабул итмәгәч, забутта малайлыкта йөрү тешеңә тигәч, минем катыма килеп, аягыма ятып жыладыңмы, әйт син шуны?

— Алла хакына андый фажигале минутларны исемә төшермә! Алла хакына, дим!..

— Туктале, жанашым, жавап бир син миңа. Шул чакниләр вәгъдә иттең, ә? Моннан ары сүзеңә бер дә каршы килмәм, ни әйтсәң, шуңа күнәрмен, димәдеңме?

— Гөлжиһан!..

— Юк, юк, әйт, шулай димәденме?

— Әгәр минем шушы минутта ук өеңнән чыгып китүемне теләмәсәң, актарма минем йөрәк яраларымны!..

Хатын тагы да катырак тавыш белән көлеп жибәрде.

— Китсәң тагы! Әйләнеп кайтырсың әле. Әбәү, ходаем, куркыткан була!..

— Билләһи, китәм, — диде Жәгъфәр, үз-үзен тота алмыйча, тешләрен каты кысып.

— Әйдә, жүләрләнмә, — диде Гөлжиһан, кинәт дустанә тонга күчеп, — безне көтә торганнардыр.

Хатын торды да назлы гына итеп Жәгъфәрне кочаклап алды. Жәгъфәр хәзер үк аны үбәргә тотыныр дип уйлады, ахры, Гөлжиһан шунда ук кисәтеп куйды:

— Тик хәрәмләшүдән түгел, битемә кагыласы булма! Муеннымнан гына...

Шулай дигәч, үзе көткәнчә булмавына аптырый төшеп, Жәгъфәрнең йөзенә текәлде.

Таштай катып калган иде Жәгъфәрнең матур кара тутлы йөзе. Бу секундта ул үзенең бәхетсезлеге турында, Хөсәеннең ни дәрәжәдә хаклы булуы турында уйлана иде. Гөлжиһан белән аның арасында пәрәвез жебе чаклы гына бәйләнеш калган иде. Әгәр шул да өзелсә, тәгаен, Жәгъфәр, батырчылык итеп, бу, күзлекле еландай, үзен гипнозлап йотарга жыенган хатыннан китәчәк иде.

Һәм бу хәл булды да. Гөлжиһан, дорфалык күрсәтеп:

— Я, нәрсә, уклау йоткан кебек катып калдың? — дип әйтергә өлгермәде, Жәгъфәр элеге жепнең өзелеп китүен тойды.

Хатын:

— Әйт асрауга, Гомәр атны парадный турысына тарттырсын, — диде.

— Хәзер, хәзер. Кучерга үзем әйтәм, — диде Жәгъфәр.

Узышлый гына пальтосын, сай каракүл бүреген эләктерде, йөгерәатлый баскычтан төшеп китте. Бераздан ул, пальтосын төймәли-төймәли, урам буйлап йөгерә иде инде.

Жәгъфәр, чаттан борылып, беренче очраган капка алдындагы эскәмиягә утырды, яулыгын чыгарып, маңгаендагы тирләрен сөртте. Иреккә чыгу куанычы аның бөтен барлыгын чолгап алган кебек иде. Беравык бик рәхәт булып торды. Озак вакытлар урманда адашып йөргәннән соң бик таныш юлга килеп чыккандай тойды ул үзен. Ул Хөсәен белән булган бәхәсен, бу бәхәснең зур низаг, мәңгелеккә аерылышу белән беткәнлеген хәтерләде. Ләкин ходага мең-мең шөкер, бу аерылышу мәңгегә түгел икән! Жәгъфәр үзендә житәрлек көч тапты һәм хәзер ул күңелен әрнетеп торган зур хатасын төзәтәчәк.

Ул Хөсәенне эзләп табачак, сүзсез генә аның кулын кысачак. Дустының күзләренә карап торачак. «Рәхмәт, Хөсәен дус, — диячәк. — Рәхмәт, мине жәһәннәмнән йолып алуың өчен рәхмәт. Синең белән сөйләшкәннән соң мин барысын да аңладым. Мин яңадан сезнең янда, мин инде бу юлы гомерлеккә кайттым», — диячәк.

Җәгъфәр, шул хозур күренешне күз алдына китереп, эченнән елмаеп куйды. Чыннан да, нигә ул шушы тәрбиясез һәм комсыз хатынның кочагына алданып, бөтен яшьлеген бизәгән, аны канатландырган, йөрәксендергән идеалларын югалтсын! Юк, барысы да хәл ителде хәзер, ходага мең шөкер! Ул үзе утырган эскәмия тактасына кулын йодрыклап бер сукты да, торып, тәвәккәл адымнар белән атлап китте. Байтак вакыт ярсып, каударланып, ару-талуны тоймыйча барды ул. Тик юл шактый ерак иде әле. Ни әйтсәң дә, Хөсәеннәргә извозчикта гына тиз барып житеп була. Җәгъфәр тукталып тирә-ягына каранды. Бәхеткә каршы, чатлыкта торган извозчикны шәйләде. Кесәсен капшап карады, кинәт корт чаккандай булды аны. Каһәр суккан икән! Кунакка барам дип кием алыштырганда, бумажник казаки кесәсендә калган. Җәгъфәр, ашыгып, чалбар кесәләрен актаргалады һәм, вак-төяк бакыр-көмеш тапкач, бераз тынычлана төште.

Ләкин ул, Хөсәеннәргә житеп, хуҗаның өйдә юклыгын белгәч кенә, үзенең нинди ахмак бер хәлдә калганлыгын аңлады. Чалбар кесәсендәге акча бик аз иде. Ә бит алда яшисе бар әле. Хәерсез икән! Җәгъфәр иң беренче чиратта шул бумажнигына таянган иде бит. Инде син кем генә булма, барыбер ашамый-эчми яши алмыйсың. Җәгъфәр ул акчаны тиенләп жыйды, бумажнигын бер генә минутка да калдырмыйча әҗәл даруыдай саклап йөртте. Инде менә сиңа кирәк булса! Нишләргә?!

Шулай да ул Хөсәенне эзләргә карар кылды. Ни генә булмасын, хәзер чигенер урын юк. «Дусны күреп, әлеге теләгемне гамәлгә ашырыйм башта, аннары күз күрер», — дип уйлады. Ләкин шулай да күңелендә гаҗәп бер үзгәреш, ниндидер суыклык тойды. Хәзер Хөсәенне күреп сөйләшү иң әүвәл әлеге каһәр бумажник кайгысын онытыр өчен иде.

Җәгъфәр Хәдичәдән Хөсәеннең кайда булу ихтималын сорашты. Әлбәттә, туры гына әйтә алмады Хәдичә. Моны инде Җәгъфәр үзе дә аңлый. Шулай да ул юрап сорашырга тотынды. Бәлки, берәр танышындадыр, бәлки, «Кәрвансарай»дадыр? Бәлки... Ләкин, ни сәбәптәндер, бу төпченү Хәдичәгә бер дә ошамады. Җәгъфәрнең Хөсәен белән араны өзгәнен, башка лагерьга күчкәнен тәгаен белә иде ул. Ходай сакласын, шымчылык кылырга килгән дип уйламасын тагы! Моңа Җәгъфәрнең кәефе тагы да кырыла төште. Хәлбуки, Җәгъфәр белән сөйләшүдән соң Хөсәен чыгырыннан чыккан, өенә кайтып, Хәдичәгә: «Подлец, сатлык җан икән ул!» дигән иде. Җәгъфәр, әлбәттә, моны белмәде, ләкин Хәдичәнең күз карашыннан бәгырьне өшетә торган нәфрәт тойды.

Шулай да ул баштагы уйларыннан чигенмәде, болар барысы да, хәзер булмаса, бераздан ачыкланачак нәрсәләр дигән өмет белән Хөсәенне эзләп китте.

Кайларда гына булмады ул! Яушев, Рамазанов, Ибнеәминев, Биктимиров мосафирханәләрендә, «Кәрвансарай»да, Җамалый хәрчәүнәсендә. Әмма беркайда да Хөсәенне очрата алмады. Ниһаять, аны трамвай Бакыр бабай бакчасы тирәсенә илтеп ташлады. Күңелне үзенә тартып симфоник оркестр уйнаган музыка яңгырый иде. Биредә Казан буржуасы ял итә, кәеф-сафа чигә. «Туктале, — дип уйланды Җәгъфәр, — соңгы тапкыр булса да калган акчага шунда кереп, кымыз эчеп чыгыйм». Ул акчасын санап карады. Кымызлык кына бар иде әле.

Җәгъфәр музыка тавышлары ишетелгән якка юнәлде. Менә ул рәхәтлекләр кайда! Берсеннән-берсе матуррак киенгән дамалар, туташлар, берсеннән-берсе баерак, елкылдап торган крагалардан, котелок я цилиндрлы, а-ля франк киенгән, өфелдәтеп кенә үстерелгән купшы сакалмыеклы фырт кавалерлар бакча аллеяларын тутырып гөр килеп йөриләр. Читтәге павильоннарда сыра, кымыз саталар. Урталыкта — пыяла гөмбәзле ачык ресторан. Музыка тавышы шуннан килә, шуңа кушылып эчтән хатын-кыз көлүе, җыр авазлары ишетелеп китә. Фонтан сиптергән

сулар электр утларында җемелдәп уйнаклыйлар. Җәгъфәр бакчаның зиннәтле капкасыннан эчкә узды да халык агымына таба юнәлде.

Кемдер берәү, төркемнән аерылып, кискен адымнар белән Җәгъфәргә таба килә башлады. Башында котелок, аягында елтыр итек, кулында кыска гына жокейлар чыбыгы иде аның.

— Әй син, теплашка! Яле моннан ычкын! — дип кычкырды ул.

Җәгъфәр бу сүзләрнең үзенә әйтелгәнлеген әлеге кеше тәмам якынлашкач кына аңлады. Ә аңлагач, күз аллары караңгыланып китте. Гөлҗиһан, гөнаһ шомлыгына каршы, көчләп-көчләп, олы кешеләр алдында яхшы түгел дип, сай каракул бүрек кидерткән иде шул. Юкса, кермәгән урынымы соң инде бу бакча!

Җәгъфәр капкага язылган язуны хәтерләде. Анда: «Бу бакчага этләргә һәм татарларга керергә рөхсәт юк», — диелгән иде. Җәгъфәрнең йөзенә кан йөгерде, ләкин ул кул күтәрергә батырчылык итмәде. Тиз генә борылды да йөгерә-атлый бакчадан чыгып китте. Бераздан ул, гарьлегенә түзә алмыйча, Балык базары ягына таба атлый иде инде. Күңеле асты өскә килеп айкала иде. Ул бары әле генә үз алдына килеп баскан гаделсезлекнең дәһшәтен тойгандай булды. Болай да теткәләнгән нервылары өчен күтәрә алмаслык өстәмә авыр җәрәхәт иде бу. Җәгъфәр үзенең хәерчеләре белән дан тоткан Марусовка янына җиткәнче мыгырданып барды. Бары кыйшайган капка янында торган ниндидер бер марҗа эндәшкәч кенә айнып китте ул. Көя төшкән төлке гарҗетлы, ябык, котсыз шул фахишә:

— О, гүзәл егет, о, арслан! Әгәр бер сум акча бирсәң... басурман булсаң да риза, — дия иде. Бер кулына тузып беткән ридикюль, икенчесенә көйрәп торган арзанлы папирос тоткан хатынны Җәгъфәр терсәге белән авырттырырлык итеп этеп җибәрде.

— Кит чукынган марҗа! Оятсыз, хәшәрәт!..

Хатынның «басурман булсаң да» диюе уй-фикерләрнең ургылып, ярсып ага башлавына сәбәп булды. Җәгъфәрчә, хәзер бары рус кына иң зур түбәнлекләрне эшли ала торган халык иде. Ул барлык күрше тирәсендәге халыкларның җирләрен, суларын басып алган, ул аларны бетерү өчен барысын да эшли. Үз ата-бабаларың гомер сөргән җирдә дә бакчага кереп йөрерлек хокукың юк икән, — бу ни дигән сүз була инде?! «Мине бит фәкыйрь чагымда да татар бае бакчасыннан мәхрүм иткәне булмады», — дип уйланды ул.

Инде уй тезмәләрен тезеп, берәм-берәм, бер баскычыннан икенче баскычына атларга юл ачылды. Дөньядагы дөреслекнең очы тотылгандай булды. Бөтен бәла-каза руслардан. Ул үзенең әле менә бүген иртәнчәк шул турыда Хөсәен белән бәхәс алып барганлыгын хәтерләде. Хөсәен, рус халкы гаепле түгел, дип бара, рус халкының үзенең дә пролетариаты газап чигеп яши, ди, хикмәт, ди, байларда, эксплуататор сыйныфларда, ди. Ләкин бит безнең башыбызга төшкән иң зур бәла ул безнең байларыбыз түгел, ә рус игосы. Без анын табан астында инде өч йөз илле елдан артык вакыт җәфа чигәбез. Безне һәлакәттән саклап килгән нәрсә — ул да булса дин генә, диннең башка булуы гына. Халкыбызны диндар, диләр. Ни сәбәптән соң ул? Ул бит бары шул бетү, юкка чыгуга каршы ниндидер калкан эзләү аркасында. Ә Хөсәен, иң элек социализм, ди. Шуннан соң милләтләр чәчәк атачак, ди. Ул шулай ди, ләкин мин моңа ышанмыйм. Чөнки мин русларга ышанмыйм. Алар бик ишле, алар көчле, алар халыкларның тигезлегенә берничек тә юл куймаячаклар. Чөнки мин әле тарихта русның ниндидер башка, үз аяк астында калган берәр халыкка хәер-хаһлык кылганын белмим. Барысы да үзе өчен генә, барысы да. Баксаң-күрсәң, бу социал-демократларның социализм теорияләрен күкләргә ашырып йөрүләре дә барысы рус халкы файдасын күздә тотып кынадыр әле!

Җәгъфәр, шулай уйланып, юлын дәвам иттерде. Ул, үзе дә сизмәс-

тән, күңеленнән Хөсәен белән бәхәсләшеп барды. Хөсәен аны татар буржуазиясе лагерена күчүдә гаепли, аны сатылган бер кеше дип исәпли. Һа, алай әйтүе генә ансат ул! Җәгъфәр, теләсә, хәзер үк Хөсәеннең логик корылмаларын җимереп ташлый ала. Менә сиңа дәлил! Җәгъфәр үзенең җәберләнгән, изелгән халкына ярдәм күрсәтергә тели. Аңа ничек итеп нәтиҗәлерәк ярдәм күрсәтергә мөмкин соң? Әлбәттә инде, беренче чиратта, халыкны рус баскакларыннан азат итеп. Шул платформада торган хәлдә, патша самодержавиесе белән көрәшеп. Шуңа күрә татар буржуазиясе дип һич табаларга урын юк. Буржуазия дигәнең әле ул, чынлабрак карасаң, халкыбызның алдынгы зыялыларыдыр. Кем әйтә ала инде Рәшит казыйны буржуй дип?! Ул халыкны азат итү өчен чыңлап торган кыңгырау, дөньяның бер почмагыннан икенче почмагына очып йөрүче батыр йөрәкле фидакарь кеше. Мин һич буржуазия ягында түгел, мин халкыма бәхет теләүчеләр ягында.

Хәзер Хөсәен өеп киткән авыр йөк берәм-берәм Җәгъфәрнең өстеннән коела башлаган кебек иде. Җәгъфәр хәзер үзен бик-бик хаклы тоя иде. Юкка гына ул, Хөсәен белән сөйләшкәннән соң, ут йотып, газапланып йөргән икән. Аның күңеле тынычланып китте.

«Әйе, Хөсәеннең үз юлы бар, ә минем дә үз юлым», — дип уйланды ул. Хөсәен аны идеалларын аяк астына таптап, бай хатынга кол булып сатылуда гаепләгән иде. Җәгъфәрне хәзер бу нәрсә дә артык өркетми. «Туган халкым өчен көрәшәм, — дип уйланды ул. — Ләкин ул көрәш өчен миңа матди мөмкинлекләр кирәк. Туктале, ә бит социалистлар да, булсын эсеры, булсын социал-демократы, матди имканиятсез берни дә эшли алмыйлар. Алар да бит акча кирәгендә экспроприациядән баш тартмыйлар. Җәгъфәр дә, әгәр беләсегез килсә, Гөлҗиһанга кереп, үзенә күрә экспроприация эшли. Әлбәттә, аерма бар. Аерма шунда — социал-демократлар моны рәхимсез бер юл белән башкарсалар, Җәгъфәр бу эшне иң кешелекле бер ысул белән башкара. Бары шул гына!»

Җәгъфәргә хәзер бөтенләй җиңел булып китте. Юк, юк, ул әз генә дә ялгышмаган иде. Ул дөрес, хаклы юлдан бара. Хәзер аңа Гөлҗиһан янынннан дуамалланып чыгып качуы да ахмак бер эш булып тоела башлады. Бары бер нәрсә генә күңелне юата иде, — моны беркем дә белми иде бит әле.

Җәгъфәр яңадан Гөлҗиһан янына кайтып кергәч нинди сылтау табып акланырга тиешлеге турында уйлана башлады.

## Челлә якынлаша

Якынлашып килгән челлә һавасыннан калышмаска теләгәндәй, Казандагы революция хәрәкәте дә көннән-көн кыза барды. Иваново-Вознесенск тукучыларының стачкасы үзенең йогынтысын ясады: Казан завод-фабрикаларындагы эшчеләр бер-бер артлы эш ташлый башлады.

РСДРП комитеты канлы якшәмбенең ярты еллыгына аерата зур тырышлык белән әзерләнде. Утырышта күпчелек тавыш белән Алафузов предприятиеләрендә 9 нчы июльдә гомуми завод стачкасы башларга булдылар. Шуннан соң һәр көнне диярлек завод капка төбендә митинглар уздырыла торган булып китте.

Йөрәкләрдә якты өметләр ялкыны кабызган ашкынулы, дәртле көннәр иде бу.

Хөсәен урамга чыкты. Юлында очраган беренче извозчик арбасында пассажир китте. Анда «Волжский листок» редакциясендә иптәшләре белән очрашып сөйләшкәннән соң, алар Кулеша белән Алафузов фабрикасына юнәлделәр. Митингны оештырырга тиешле Лозовскийның анда киткәнлеген белгәннәр иде инде.

Алар патша һәйкәлен узып, Ташаяк ярминкәсе мәйданына төшкәндә, фабрикадагы вакыйгалар катлауланганнан катлаулана бара иде.

Сәгать кичке алтыны сугу белән колакларны тондырып свисток кычкыртты. Фабрика ишек алды тиз арада хәрәкәткә килде. Көне буе тынчу һәм шау-шулы цехларда эшләп алҗыган эшчеләр, станокларны туктатып, фабрика капкасына таба ашыктылар. Ишек алды кешеләр белән тулып китте. Садыйк та халык арасында. Тәгаен, Алексей килгән иде инде. Ашыгырга кирәк иде.

Садыйк контроль ишек аркылы узганда капка төбендә торган салам эшләпәле кешегә игътибар итми кала алмады. Сакчы үзен тентегәндә ул, тәрәзә аша күреп, салам эшләпәле кешенең комитет җибәргән Алексей икәнлеген аңлады. Атылып урамга чыкты һәм шунда таба китте. Бу вакытны Лозовскийны эшчеләр әйләндереп алган иде инде. Алексейга кемдер такта әрҗәгә менәргә ярдәм итте. Лозовский яңгыравык тавыш блән кычкырып үз янына эшчеләрне чакыра башлады.

Халык шактый җыелгач, ул сүз башлады. Аның җирән чәче тузган, йөзе ап-ак иде.

— Иптәшләр! — диде ул. — Безгә бөтен аһ-зарларыбызны уртага салып сөйләшергә кирәк. Без, Алафузов заводының барлык бүлекләрендәге эшчеләр, хуҗаның һәм завод администрациясенең изүенә артык түзеп торырга тиеш түгел. Без мохтаҗлыкның ахыргы чигенә җиткерелгәнбез, иптәшләр! Без дәшмичә калырга тиеш түгел. Бөтен Россия пролетариаты үзенең мәнфәгатьләре өчен көрәшкә күтәрелә. Без читтә калырга тиеш түгел, иптәшләр! Әйдәгез, җыелыгыз! Без хәзер шуның турында митинг ачыйк!

Садыйк барлык көченә: «Дөрес, дөрес!» — дип кычкырды. Губанов аның уң ягында тора иде. Ләкин ул ораторны тыңлау белән генә мавыкмый, үзенә тапшырылган эшне дә әйбәт үти. Кинәт Губановның күзләрендәге яктылык сүрелде. Ул Садыйкның янтыгына каты итеп терсәге белән төртеп куйды.

— Теге бәндәгә кара!

Ниндидер ят бер кеше тыңлау белән мавыккан эшчеләрне этә-төртә Алексей янына керергә маташа иде.

— Җибәрмә! Филер, — диде Губанов. Тирә-юньне халык сарып алган, хәзер башка урынга күчү җиңел түгел. Шулай да Садыйк җилкәсе белән юл ярып теге кешегә таба китте. Ул аның янына барып чыккач тукталып торды, бөтенләй күрмәмешкә салышты. Мәгәр күз төшерү белән Губановның хаклы икәнлеген аңлады. Җүнсез шымчы, никадәр генә гади эшчегә охшарга теләсә дә, Садыйкны алдый алмас! Сәгыев аның янына ук килде дә алга үтәргә теләгән булып терсәге белән тегенең күкрәгенә китереп төртте. Күрәсең, филер юкарак нәрсә иде. Ул агарынып өнсез калды.

— Што ты, господь с тобой, — дип мыгырданды ул. Садыйк аны, ай-ваена карамастан, артка этеп җибәрде, үзе аның алдына ук килеп басты. Инде тыгылып карасын!

Алексей һаман сөйли иде әле. Ул завод эшчеләренең хәлен, аларның адәм түзмәслек шартларда яшәвен, ачлык, наданлык аркасында бөтенләй кешелек сыйфатларын югалту мөмкинлекләрен, нигезләп, кызып аңлата иде.

— Ләкин бу хәлне төзәтү мөмкинлеге безнең үз кулыбызда. Безнең мондый эшкә кодрәтебез җитәрлек. Чөнки без — эшче сыйныфы, оешкан сыйныф, — диде Лозовский. Ул тугызынчы июльдә, канлы якшәмбе истәлеге итеп, Алафузов эшчеләрен гомуми стачка ясарга өнди башлады. Урам хәзер эшчеләр белән тулган иде. Алар ораторны әле хуплап, әле аңардан шикләнеп гүли, мәйдан шау-гөр килә иде.

Ләкин Алексей хуҗалар алдына нинди шартлар куярга кирәклеген әйтеп бетермәде, каяндыр килеп чыккан атлы полиция стражниклары, камчыларын селти-селти, атлары белән халыкны таптатырга тотынды-

лар. Кемдер ачы кычкырып сүгенеп җибәрде, хатын-кыз чәрелдәгәне ишетелде.

Садыйк хәзер аерата сизгерлек белән үз артында торган филерны сагалый иде. Ниһаять, ул түзмәде, шымчы Алексей янына үтәргә теләп тагы кыбырсый башлагач, аның җиңеннән эләктереп алып, үзе белән артка таба өстерәде. Бу минутта урамның икенче ягыннан җәяүле городовойларның свисток сызгыртып йөгерешкәне күренде. Эшчеләр хәзер һәр яктан камалып алынган иде. Ләкин алар бирешергә җыенмадылар. Атлылар һәм җәяүле городовойлар никадәр генә халыкны куркытып, таралырга әмер итмәсеннәр, эшчеләр кузгалмадылар. Төркемнең үзәге, бернигә бирешмичә, әле һаман ораторны куәтли, әле һаман аның сөйләвен сорый иде. Әмма халык төркеменең читләрендә хәзер чын мәгънәсендә сугышалар иде инде. Садыйк әлеге шымчыны өстерәп чыгарам дип чак кына ат астына барып кермәде. Башын югары күтәргән кара ат, күзләрен акайтып, авызыннан күбекләр чәчә-чәчә, күкрәге белән Садыйкка килеп бәрелде. Садыйк филерны кулыннан ычкындырды, көчкә читкә тайпылып өлгерде. Ләкин шулай да атлы полицейскийның нагайкасы аның сул як иңбашын утта көйдергәндәй ачыттырып алды. Ачуыннан тынына буыла башлаган Садыйк түзмәде, нелде дә аяк астында яткан ташны алып полицейскийга җибәрде. Читкә шылып, аңа күз ташлаганда полицейский атының муенына иелеп төшкән, кемдер теге яктан аның аягыннан сөйри иде.

Садыйкның таш атуы үзенә күрә бер сигнал кебек килеп чыкты. Чөнки тиздән халык полицейскийларга таш яудыра башлады. Заводның өлкән городовое зур корсаклы, акайган күзле Клементьев кынысыннан кылыч суырып чыгарды. Садыйкның күзләренә аның, кылыч белән селтәнеп, уртага юл ярып баруы чагылып калды. Садыйк үз янында торган эшченең ачынып: «Ах, җен!» — дип кычкыруына сискәнеп китте. Ни арада булды соң бу хәл, Садыйк аңгарып та өлгермәде. Ләкин ул урталыкка күз салганда, анда Алексей юк иде инде. Формалы һәм гражданский киемле кешеләр аны, кулларын каерып тоткан килеш, завод капкасына таба сөйрәп баралар иде. Аларга ташланган Миңнулла белән Губановны шундагы кешеләр бәреп аяктан ектылар. Садыйк аяк астына туры килгән әлеге әрҗәнең өстенә менеп басты.

— Иптәшләр! — дип кычкырды ул барлык көченә. — Күрмисезмени: безнең иптәшне алып киттеләр бит. Без барыбыз да бер булып...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, халык, болай да эшне аңлап, бердән үкерә башлады. Бөтен урам хәрәкәткә килде. Барлык кеше, бер көчкә буйсынгандай, завод капкасына таба ташланды. Юлда очраган полицейскийларны хәзер ул сытып-таптап кына узды. Бер-ике этү белән капка каерылып авып төште. Шашкын халык төркеме кулга алынган Лозовский артыннан аны коткару өчен һөҗүм башлады. Садыйкның күзенә үзенең цехташ иптәшләре очрап-очрап китте. Алга ыргылган халык арасында Шәрифулла абзыйның ачулы йөзе чагылып калды. Аның бер почмагына күзләрен зур итеп ачкан Тәгъзимә дә эләкте. Ниһаять, Садыйкка Фәрхетдин дә очрады. Егетнең авызы ачылган, күзләре түгәрәкләнгән. Ул, нидер әйтергә теләп, түбәтәен һавада селки иде. Халык ташкыны завод ишек алдын тутырды.

Хөсәеннәр завод капкасы төбенә җиткәндә, ишек алдыннан бик каты гүләү авазлары ишетелде. Ул хәлне аңлап өлгермәде, бер заман халык ябырылып кире урамга чыга башлады. Тирә-юньне меңләгән кешеләр тутырды. Кемнәрдер Лозовскийны өскә күтәргәннәр, каты кычкырып, урам уртасына киләләр. Хөсәен ачыграк күрү өчен тротуар читендә яткан ташка менеп басты. Эшчеләр: «Болынга, болынга!» — дип кычкырыша башладылар. Кемдер. «Иптәшләр, бүген үк стачка башларга! Бүген үк стачка, бүген үк стачка!» — дип акырды. Аның сүзләрен, эләп алып, кабатларга керештеләр.

Хөсәен хәлне аңлап тынычланып киткәндәй булды. Ул халык ташкынына нярде. Садыйкны очратып, аның чабуыннан эләктерде.

— Ни булды? — диде, тотлыга төшеп.

— Ябып куйганнар ие, — диде Садыйк, ачулы елмаеп. — Аналарын саткырылардан йолып алдык!

Халык үзенең барысыннан да көчле икәнлеген тойган хәлдә, урам тутырып, тантаналы рәвештә алга агыла башлады. Хөсәен, куанып, кызу-кызу адымнар белән аларга нярде.

## Ока елгасында

«Густав Струве» пароходының салоны халык белән шыгрым тулган иде. «Ниһаять, миңа да тарихи бер вакыйганың шаһите булырга насыйп икән», — дип уйланды Җәгъфәр. Ул арткы рәтләрнең берсендә тәрәзә янында урнашкан иде. Зур ачык тәрәзәдәге ефәк пәрдәләрне җилбердәтеп Ока суының сәрин сулышы шаяра. Вак дулкыннар өстендә кояш нурлары җемелди. Акчарлаклар, кычкыра-кычкыра, пароходны озата баралар.

Җәгъфәрнең шатлыктан йөрәге урыныннан кубардай булып тибә иде. Күп өметләр баглый иде Җәгъфәр шушы съездга. Әйтүе генә ансат: бөтен дөнья тарихында беренче тапкыр Россиядәге мөселман халыкларының съезды. Ниһаять, татар халкын колониаль изелүдән, түбәнлек-хурлыклардан азат итү өчен оешкан бер җирлек булачак. Ул барлык төеннәрне чишәчәк, барлык бәхәсләргә чик куячак.

«Иттифакы мөслимин»нең беренче съезды Нижний Новгород каласында узарга тиеш иде. Ләкин, шәһәребез болай да хәрби хәлдә, дигән сылтау табып, губернатор моңа рөхсәт бирмәде. Мәгәр оештыручы кешеләр аптырап калмадылар, өч йөз сумга шушы пароходны яллаган да Ока суында ял итеп йөрү исеме астында съездны уздырырга карар кылдылар. Берничә минуттан соң шул тарихи съезд башланырга тиеш иде.

Алгы рәтләрдәге хәрәкәткә карап, озакламый нидер буласын сизенгән Җәгъфәр башын күтәрде, игътибарын җикте. Төрле кәсеп иясе һәм төрле катлаулардан чыккан кешеләр утыра иде салонда. Арада европача киенгән җиту чәчле интеллигентлар да, зур корсаклы, көләпүшле, казакиле сәүдәгәрләр дә, фәсле, чалмалы, чапанлы дин әһелләре дә — барысы да бар. Биредә Җәгъфәрнең йөрешә торган таныш-белешләре дә, бөтенләй күз күрмәгән чит як кешеләре дә. Алда ап-ак сәлләләр, кызыл, яшел фәсләр, кара, я төсле, хәтта энҗеле түбәтәйләр тезелеп киткән. Кинәт алгы сафтагы кешеләр хәрәкәтләнә башлады. Җәгъфәр тынын кысты, әсәренеп күзләрен алга төбәде.

Хәрәкәт тагы кабатланды. Пенсне күзлек кигән җиту чәчле, бәләкәй сакаллы юантык кеше сафның уртасына утырган киң җилкәле, пеләш башлы таза кеше белән сөйләшеп алды. Пеләшнең аркасы һәм кызыл зур колаклары гына күренә. Пенснеле читкә китеп югалу белән, ул торды да өстенә яшел постау ябылган зал алдындагы өстәлгә таба китте. Бераздан ул халыкка йөз белән торып, таянган килеш, өстәл артына басты. Тәгаен, бу буйчан таза кеше Кавказ халыкларыннан иде. Аның карчыга борыны, зур кара күзләре шулай уйларга мәҗбүр итә иде.

— Үзебезнең бик могтәбәр мөселман әһелләреннән инде, — дип пышылдады Җәгъфәрнең күршесе. — Фрафисыр Әхмәтгәрәй әфәнде Төпчибашов. Бакудан.

Белдекле күрше әкрен генә әйтсә дә, алда утыручы шадра абзый, борылып, Җәгъфәрләргә кырыс бер караш ташлады. Янәсе, комачау-

лыйсыз. Төпчибашов залга текәлү белән моңарчы гөжләп торган халык бөтенләй тынып калды. Әгәр уң якта утыручылардан берәү гөлдерәтеп кикереп җибәрмәсә, бу тынлык аерата зур тантана төсен алачак иде.

— Кардәшләр, — диде Төпчибашов, — без бирегә егерме биш миллионнан артык булган Россия мөселманнарының вәкаләте белән җыелганбыз.

Ул «Иттифакы мөслимин»нең мөселманнар өчен әһәмияте турында сөйли башлады. Оратор әзербәйҗанча сөйли иде. Әлбәттә, халык, нотыкның нечкәлекләренә кермәстән, сүзнең гомумән ни турында барганлыгын төшенде. Шулай да Җәгъфәр бер нәрсәгә игътибар итмичә булдыра алмады. Үзенә аңлашылмаган телдәге сүз нинди мөкатдәс нәрсә турында бармасын, күңелгә үтеп керә алмый икән. Ул мәҗбүри рәвештә бу беренче тойгының ачысын йомшартырга тырышты. Әлбәттә инде, татар халкы җитәкче ролен башкарырга тиеш. Ләкин бит аңа карап башка милләтләрдән галимнәр бар икән, алардан файдаланмыйча булмый, дип үзен тынычландырды. Ә инде президиум сайланып, съездга рәис итеп Исмәгыйл бәк Гаспринский, сәркатиб итеп Муса Бигиев сайлангач, ул бөтенләй кәефләнеп үк китте.

Күршедәге бик белдекле, симез битле, елкылдап торган кара мыеклы кеше өстәл артына урнашкан һәрбер президиум члены белән Җәгъфәрне таныштыра барды. «Әнә күрденме, бу күзлеклесе — Йосыф Акчурин инде», я булмаса: «Игътибар белән карап кал, егет, әнә теге яшел фәс кигәне — Рәшит казый булыр, аның «Миръат»ын укыгансың булыр», — диде ул. Өстәл артындагы Садрый Максудыйны, Гаяз Исхакыйны, Фуат Туктаровны Җәгъфәр болай да таный иде инде.

Президиумны зал алкышлап каршы алды. Ораторлар берәм-берәм чыгып сөйли башладылар. Аларның кайберсе артык госманлы төрек телендә, я булмаса гарәп сүзләрен кыстырып, ислам тарихыннан, Мөхәммәт пәйгамбәр сүзләреннән үрнәкләр китереп, я кайберсе исә мишәр шивәсендә кирәккә дә, кирәкмәскә дә рус сүзләре кушып сөйли иде. Ләкин барысы да бер зарны куәтли. Сүз татар халкына тәрәкъкый итәргә ирек булмавы турында. Кадимче дин әһелләренә карата да каты-каты гына тел тидереп китүчеләр аз түгел. Дөньяви белемнәр бирә торган мәктәпләр кирәк. Алар яшьләргә Европа белемнәрен бирергә тиеш. Әлбәттә, динне дә онытырга ярамый, ләкин шулай да яшәү, тормыш итү, милләтне тәрәкъкый иттерү өчен заман кушканны өйрәнергә кирәк. Мәктәп бетергән кеше мөселман дөньясында гына түгел, гомумән Европа күләмендә алдынгы кеше булырга тиеш.

Бик күп тапкырлар уйланган һәм дөрес дип тапкан Җәгъфәр фикерләрен кабатлыйлар иде болар. Юк, Җәгъфәрнең булган хәлне күрү белән генә чикләнәсе килми иде шул. Аның нинди дә бер тәвәккәл чаралар тәкъдим иткәнне ишетәсе килә. Хәлбуки, чыгып сөйләүчеләрнең тел төбе һаман патшаһы әгъзәм хәзрәтләренә өмет баглауга кайтып кала иде. Янәсе, алтынчы августта игълан ителгән дума турындагы проект милләт өчен бик матур юллар ача. Җәгъфәр күңеленнән: «Ачар, көт», — дип куйды.

Аның тизрәк Гаспринскийны тыңлыйсы килә иде.Ниләр әйтер икән хәрәкәтнең башында торучы, остаз, мөхәррир, аксакал? Шул бит инде милләтне тәрәкъкый иттерү өчен беренче байрак күтәрүче. Җәгъфәр «Тәрҗеман» газетасын башыннан ахырына кадәр укып бара иде. Әле шәкерт чакны, күп нәрсәләрне белмәгән хәлдә дә, «Тәрҗеман»ның телен юньләп аңламаган килеш тә куанып, аны башыннан ахырынача укый иде. Кырым морзасы Исмәгыйл бәк Гаспринский, аның ышануынча, халык нәрергә тиешле бердәнбер лаеклы юлбашчы иде. «Нәрсә ул әлегәчә чыгып сөйләүчеләр, — дип уйланды Җәгъфәр эченнән генә, — бу либераллар белән эсерларның бәхәсен ишетеп туйган инде. Уң канат белән сул канат бәхәскә керә; тик алар икесе дә бер үк нәрсәне алга

сөрәләр бит. Чөнки тел төпләре бары бер үк көйне көйли, ниндидер могҗизага ышаналар, ниндидер ислах ясап максатка ирешергә телиләр. Әлбәттә, Гаспринский әфәнде үзенең тирән фикерле, барысын да ачыклый торган нотыгы белән изелгән төрки халыклар өчен файдалы, бәхет-сәгадәткә илтә торган юл күрсәтәчәк». Әйе, әйе, Җәгъфәр барысына да баштан ук риза. Ул, әгәр кирәк икән, үзенең туган халкы өчен утка-суга керергә дә әзер.

Ниһаять, рәис белән янәшә утыручы Йосыф Акчурин сүзнең Исмәгыйл бәк Гаспринскийга бирелүен әйтте. Бу минутларда Җәгъфәр киеренке бер эчке халәт кичерә, күңеле коштай ашкына, җилпенә иде. Ул ике күзен дүрт итеп морзага текәлде.

Калку җилкәле, буйчан Гаспринский, өстәл кырыендагы трибуна артына чыгып баскач, бераз тынып торырга мәҗбүр булды. Чөнки халык, аны алкышлап, гөж килеп кул чаба иде. Җәгъфәрдән дә катырак кул чабучы булмагандыр!

Гаспринский җыерчык баскан озынча соргылт йөзле кеше иде. Күрәсең, аның бүген кәефе хуш түгел — чырае артык төксе. Шулай да Җәгъфәргә бик ягымлы булып тоелды ул. Җәгъфәр хәтта Гаспринскийның күлмәк якасының аклыгына, соры костюмының өстендә килешле утыруына да сокланды. Менә морза, ашыкмыйча гына, үзенең йомшак калын тавышы белән сүз башлады. Оратор ярым кырымча, ярым төркичә сөйли иде. Җәгъфәр башта сүзнең эчтәлеген аңламыйча азапланды. Җаена төшенеп җиткәндә шактый күп фикерләр әйтелгән иде инде. Ләкин Җәгъфәр ораторны тыңлаган саен ничектер үзе көткәннәрдән ераклаша баргандай булды. Гаспринский:

— Тарихи зарурияттә үсеп килгән Русиягә Рязань, Казан, Астерхан, Сембер, Кырым патшалыклары, хәтта Кавказ арты ханлыклары, соңгы вакытта кайбер Урта Азия ханлыклары керде, — диган фикерне әйтә иде. — Ләкин Русия, безнеңчә, үзенең тарихи, табигый чикләренә барып җитмәде әле. Иртәме, соңмы, Русия чикләре үз эчләренә барлык төрек-татар кабиләләрен кертеп бетерәчәк дип уйлыйбыз без.

«Тукта, ничек инде болай», — дип уйланды Җәгъфәр. Ораторның бу сүзләрне тыныч кына әйтүе һәм тыңлап утыручыларның да әз генә дә борчылмыйча тыңлавы гаҗәпләндерде аны.

Ул, кашларын җыерып, һәрбер сүзне аңларга тырышты.

— Якын киләчәктә Русиягә, үзенең христиан державасы булу әһәмиятен киметмәгән хәлдә, иң зур мөселман дәүләтләренең берсе булырга язган, — диде оратор.

Җәгъфәр хәйран калып, әллә миңа гына шулай ишетеләме дигәндәй, маңгаен уа башлады. Ләкин ишеткәннәре нәкъ Гаспринский авызыннан чыккан сүзләр иде. Тукта, ничек инде? Моңарчы Җәгъфәр алладай күргән Гаспринский шулай сөйлиме? Димәк, ул Россиянең колониаль политикасын хуплый, димәк, «милләт, милләт» дип йөрүләр ул коры сүз генә. Я хода, бу нинди эш тагы?! Җәгъфәр тагы игътибарын ныграк җигеп нидер аңларга тырышты.

— Тәкъдир кушуы буенча Русия кул астына, аның хакимиятенә һәм канат астына үзләренең бай җирләре белән кушылган мөселман халыклары тапшырыла. Русия — Европа белән Азия, фән белән белемсезлек, хәрәкәт белән торгынлык арасындагы табигый арадаш.

Җәгъфәрнең артык тыңларлык та, аңларлык та көче калмаган иде. Ходавәндә! Мондый сүзләр көткән идеме соң ул Гаспринскийдан?! Ул үзенең тетрәнүен, эчендә утлар кайнаганлыгын сиздермәс өчен кулларын каты кысып йодрыклады, иренен тешләде. Күңел түрендә нәрсәдер гөрселдәп ишелгәндәй булды. Бу, тәгаен, аның салон башында кулларын кушырып тыныч кына сөйләп торган, озынча соры йөзле кешегә булган иманы, ышанычы иде.

Җәгъфәр, артык берни дә ишетмәскә тырышып, ачык тәрәзә аша Ока елгасына карады. Пароход ямь-яшел үлән белән өртелгән сөзәк яр буеннан бара иде. Яр өстендә киндер күлмәк-ыштанлы, ялан аяклы бер рус егете кулындагы картузын пароходка болгый. Бераз барганнан соң елгага су эчәргә төшкән сыерлар очрады. Алар корсак тиңентен суда койрыкларын селкеп рәхәтләнеп оеп торалар иде. Кояшта бик эссе булса кирәк. Җәгъфәрнең шушы минутта ук салоннан палубага чыгып, суга сикерәсе килде. Юк, эсселектән качып түгел, ә менә алдакчы, кабахәт дөньядан качып! Ул су астына төшеп ятар иде дә бер дә чыкмас иде. Җәгъфәр уй-хыяллары аша су асты патшалыгында байтак вакыт гизгәннән соң, уянып, тирә-юнендәге реаль тормышка кайтырга мәҗбүр булды. Бу вакытны оратор ниндидер халыкара мөнәсәбәтләр турында сөйли иде инде. Җәгъфәрнен колагына «Төркия, Иран» дигән сүзләр кагылып китте. Хәзер инде оратор нинди сүз әйтсә дә аны аптырашка төшермәячәк. Ул каты тетрәнүдән соң туган йокымсырау халәтендә, төшендә күргәндәй, Гаспринскийга текәлде.

— Төркия һәм Иранны кулында тоткан хәлдә, Русия барлык мөселман шәрыгының кардәшенә әвереләчәк һәм, мөселман халыкларының башында торып, аның мәдәниятын җитәкләячәк. Ак патшаның мөселман халифәсенә карата булган әйбәт мөнәсәбәте Һиндстан мөселманнарының фикерләрен тамырыннан үзгәртәчәк. Шуннан соң инде инглизләргә «урыс казагы мөселманнарны юк итәчәк» дигән әкиятне исбатлау җиңел булмас!

«Кызык бу, — дип уйланды Җәгъфәр, эченнән ачынып, — димәк, бу Кырым морзасы безнең белән генә чикләнми, әле тагы бик күп мөселман халыкларын ак патша җәберенә тапшырырга җыена. Тукта, бу бит, төптәнрәк уйласаң, бөтенләй сатлык җан. Бу бит рус патшасының көен көйли».

Җәгъфәр кинәт урыныннан торды да, янындагы әлеге белдекле мыекны этеп, рәт арасыннан чыга башлады. Ул ишеккә таба юнәлгәндә үзенә текәлгән усал карашларны тойды. Ләкин тукталмады, салон ишеге янында өелешеп торган кешеләрне эткәләп палубага чыкты. Монда һава саф, тын алулары иркен иде.

Хәзер ораторның әйткәннәре бик еракта гына ишетелә иде:

— Мөселман галәме белергә һәм ышанырга тиеш, — дия иде Гаспринский. — Русия ислам диненә һәм шул диндәге кешеләргә берниндидә дошманлык касты белән янмый. Русиядә мөселманнар, күчмә кыргызларны исәпкә алмаганда, көннән-көн баеafйлар. Минем күзәтүләрем, сәяхәтләрем миндә ышаныч тудыра: бер генә халык та җиңелгән һәм гомумән ят кабиләләргә безнең олы туганыбыз рус халкыдай шәфкать һәм кешелеклелек белән карамый.

Җәгъфәр түзмәде, палуба буйлап койрыкка таба китте. Монда шапыр-шопыр су ишеп пароход көпчәкләре әйләнә, машина залының гөрелтесе палубаны калтырата иде. Җәгъфәр байтак вакыт көпчәк калаклары астындагы суның ургылып-дулап күбекләнүенә карап торды. Аның алдында хәзер төпсез бушлык иде.

«Менә сиңа милләткә хезмәт! Менә сиңа гасырлар буе җәберләнгән һәм бетүгә юл тоткан халкыңа ярдәм итәргә теләвеңнең нәтиҗәсе». Ул берни дә күрмәгән караш белән һаман су өермәсен күзәтте. Өстә якчарлаклар ачы чыелдап ашарга сорыйлар, яр буенда бөдрә куаклыклар, балыкчы алачыклары, ерактарак чиркәүле авыллар кала иде.

Җәгъфәр, тәнәфес булып, халык шау-шуы палубаларны басып киткәнгә кадәр, урыныннан кузгала алмыйча торды. Кинәт ул янында гына таныш тавыш ишетте. Салонда әлеге белдекләнеп утыручы кара мыеклы кеше иде бу. Әле яңа гына Җәгъфәр аңа игътибар беләнрәк күз салды. Карасана! Йөзе бик таныш лабаса! Кайда күрде соң әле ул? Әйе, Печән базарында кызыл мал белән сату итә ич ул!

— Нигә чыгып киттең, агайне? — диде сәүдәгәр. — Коньяк-мазар эчеп харап булмагансыңдыр ич?

— Нинди коньяк? — диде Җәгъфәр, аптырап.

— Буфеттагыны әйтәм, — диде мыек, елмая төшеп, — мин дә, малай, бер бәләкәйне капкан ием, син чыгып киткәч, күңелне бөтенләй айкый башлады...

— Әйтә алмассыз микән, — диде Җәгъфәр, белдекленең сүзен бүлеп, — күреп булыр микән хәзер Исмәгыйл бәк Гаспринскийны?

— Һа, — дип куйды теге, мыегын бөтерә төшеп, — йомыш төште диген, ә?

— Миңа аны мотлак күреп сөйләшергә кирәк.

— Әнә ич, бар да сөйләш, — диде пароходның борын ягына таба борылып, — әле шунда күргән идем үзләрен.

Җәгъфәр палубадагы халык арасыннан пароходның алдына таба китте. Делегатларның рухы күтәренке, һәр төркемдә җанлылык сизелә иде. Алар әле генә булган чыгышлар турында үзара сүз алып баралар, тойгыларын уртаклашалар, артык кызмыйча бәхәсләшәләр. Күрәсең, канәгать хасил иткәннәр. Чапанлы, җөббәле, камзуллы һәм тройкалы юан-юан кешеләрне узып, Җәгъфәр алга таба баруында булды. Ниһаять, менә пароходның борыны. Алда Ока елгасы җәйрәп ята, өстә аяз күк йөзе, тирә-якта яшеллеккә өртелгән сөзәк ярлар. Гаспринский иркен камыш кәнәфидә утыра иде. Аның тирәсендә президиумда утырганнарның күпчелеге күренә. Ләкин алар гына да түгел, тагы алгы сафларда күренгән кешеләр дә бар. Җәгъфәр беравык кыймыйча читтән генә карап торды. Ниһаять, батырчылык итеп, кешеләр арасыннан эчкәрәк узды һәм Исмәгыйл бәкнең бәләкәй пауза ясавыннан файдаланып:

— Гафу итегез, Исмәгыйл әфәнде, — диде. Ничектер артык каты кычкырды, ахры. Барлык кеше, шул исәптән Гаспринский да, сискәнеп башларын Җәгъфәргә таба бордылар.

— Минем сезгә, әфәндем, әйтәсе сүзләрем бар, — диде Җәгъфәр, — сезнең сүзләрегезне тыңлаганнан соң туган фикерләрне әйтәсем бар. Минем мәзкүр җыелыш алдында чыгып сөйләрлек хәзерлегем юк, шуңа күрә кайбер фикерләрне сезгә монда әйтергә рөхсәт итегез.

— Мәрхәба, әйтеп ебәрең, егетем, — диде Исмәгыйл бәк.

— Сез, әфәндем, минем өметләремне акламадыгыз!

Исмәгыйл бәкнең сул як бите тартышып куйды, ләкин шулай да ул һаман елмая иде әле.

— Мин сезнең Гаррибальди булуыгызны теләгән идем. Мин шулай итеп сезне күз алдыма китергән идем. Ләкин...

Җәгъфәр тукталып калды. «Әйтергәме, юкмы?» дип икеләнеп торды.

— Сез минем яу торгызып мәмләкәткә каршы орышка чыгуымны теләдегезме? — дип сорады Гаспринский.

— Менә, менә, нәкъ шулай! — диде Җәгъфәр, җанлана төшеп.

— Пәс адәм икәнсез! — диде Гаспринский, ниндидер әшәке елмаю белән.

Тирә-юньдәге кешеләр, Җәгъфәрнең оятсызлыгына хәйран калып, тәнбиһ белән баш чайкап куйдылар.

— Без ак патша мәмләкәтеннән разый-бәхил. Безгә әйбәт законнар гына кирәк. Ә кемнәрдер дөньяны бутый икән, анда катнашыбыз юк, — диде берәү.

— Аллага мең шөкерана ит, егет, — диде икенче бер әфәнде, — без патшаһы әгъзәм хәзрәтләренең итагатьле мөселманнары, ул, алла боерса, тәгаен, безнең тавышыбызны ишетер.

Җәгъфәр артык берни дә әйтә алмады, башын иеп, тагы көпчәк шаулаган турыга китте. Теге белдекле сәүдәгәр һаман шунда тора иде әле.

— Я, сөйләштеңме? — диде ул.

— Сөйләштем, — диде Җәгъфәр. Аның хәзер кемгә булса да ачыласы килә, кемнең дә булса үзен хуплавын тели иде.

— Нәрсә әйтте соң? Син инде шул театр турындадыр?

— Нишләп театр булсын, — диде Җәгъфәр, ачулана төшеп, — мин яшәү, үзебезнең урыс патшасы аягы астында эт көнендә яшәвебез турында сөйләшмәкче идем.

— Нәрсә, сөйләшмиме, вакыт юк, диме? Олы кешене бимазалап йөрергә кирәкми шул.

Җәгъфәр өмет белән сәүдәгәргә текәлде.

— Абзый, сезнеңчә, ул олы кешеме? Ләкин дөресен генә әйтегез.

— Менә тагы! Нинди сорау инде бу! Гаспринский хәзрәтләре — бик олы кеше.

— Мин дә шулай дип уйлаган идем, — диде Җәгъфәр, — ләкин минем өметләрем акланмады.

Мыеклы һич көтелмәгәндә, мыегын бөтерә төшеп, кеткелдәп көлеп куйды. Җәгъфәр, карамаса да, күңеле белән аның әшәке итеп көлүен тоя иде.

— Сизәм мин синең эшеңне, егет, — диде сәүдәгәр, — синең күңеленә җәбриләр вәсвәсәсе кергән. Шулар аркасында бит инде дөньяның асты өскә килә. «Князь Потемкин Таврический» матросларының тинтәклеген ишеткәнсеңдер? Инде килеп Иваново-Вознесенск тукучыларының кыланышына ни әйтәсең? Барысы да шул аты коргыры җәбриләр...

Агай сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, арттан хатын-кыз тавышыдай нәзек бер тавыш ишетелде:

— Сез алай дисез дә, Шәмсетдин абзый, болар бит барысы да әллә кайдагы җиде диңгез артындагы случайлар. Менә үзегездәге хәлләргә, сезнең Казан хәлләренә күз салыгыз.

Җәгъфәр дә, Шәмсетдин дә теге нәзек тавышлы мишәргә борылдылар. Боларның сүзләрен ишетеп торган булса кирәк, фырт киемле, түгәрәк битле бу яшь кеше Алафузов заводындагы стачка, Казан тирәсендәге заводларда эш ташлаулар, крестьянның баш күтәрүе, имениеләр яндыруы турында сөйләп китте.

— Барысы да шул җәбриләр эше, — дип кабатлады Шәмсетдин, — барысы да.

Җәгъфәр эченнән генә: «Белләсең син пычагымны», — дип уйлады. Әле үзенең катыргы ак якасы, манжетлары белән кайдандыр ялтырап килеп чыккан нәзек тавышлы мишәр дә аның ачуын китерә иде. Бераздан соң ул Җәгъфәргә үзе артыннан барырга ымлады. Җәгъфәрнең теләр-теләмәс таптанып торуын күргәч:

— Мин сезне буфетка чакырырга телим, өлгерербез дип уйлыйм, — диде. Җәгъфәр эзләгәнен тапкандай булды. «Чыннан да», — дип уйланды ул. Буфет юатачак бит аны.

— Таныш булыйк, Ришат, — диде теге, кузгалып киткәч — Мин сезне, туганым, аңлыйм, — дип өстәде ул.

— Нәрсә аңлыйсыз?

— Мин бит сезнең Гаспринский әфәндегә әйткәннәрегезне ишетеп тордым.

Алар баскычтан аска таба төшә башладылар. Трюмдагы буфет янында ыгы-зыгы иде. Кечкенә генә зал сыман урында буш өстәлләрнең берсе тирәсенә урнаштылар. Җитез половой заказны үтәп китеп баргач, Ришат бокалларга салкын сыра коя-коя сүзгә керешге:

— Сез, Җәгъфәр әфәнде, юкка Гаспринскийның сүзләрен ахырынача тыңламадыгыз. Ул бит мәсьәләнең бер ягын гына сөйләргә өлгерде...

— Сүз бары милләтнең азатлыгы турында гына бара ала!

— Мин дә нәкъ сезнең кебек үк караштагы кеше. Ләкин мин сезгә бер кыйммәтле сүз әйтим: инде без халкыбыз өчен янып-көеп йөрибез икән, бераз алдын-артын уйлап эш итәргә дә тиеш булабыз...

— Сез нәрсә әйтмәкче буласыз?

— Менә нәрсә, — диде Ришат, официант житезлеге белән сыраны яңадан бокалларга коеп, — без сакланып эш итүебез өстенә, һәрбер мөмкинлектән файдаланырга тиешбез, әфәндем. Бу безнең тактик алымыбыз булырга тиеш.

Алар сыраны чөмереп куйдылар да, Җәгъфәр Ришатка каршы килеп:

— Әгәр инде без алай дип фикер йөртәбез икән, безгә, туган, иң кулае социал-демократларга ияру, — диде. — Чөнки аларда да милли мәсьәлә куела, алар хәтта милли автономия дип үк куялар.

Ришатның йөзе чытылып китте, кечкенә генә борыны бөтенләй җыерчыклар белән капланды.

— Алла сакласын, — диде ул, ниһаять, — большевиклар түгелме тагын!

Җәгъфәр Хөсәенне хәтерләде, аның милли мәсьәлә турындагы сүзләре ничектер колак төбендә яңгырап киткәндәй булды.

— Я, шулай булсын, ди, большевиклар, ди. Аларның да, минемчә, безгә уртак яклары бар.

— Аллам сакласын, — диде Ришат. Кинәт өстә кыңгырау чылтырады, кемдер муенын сузып:

— Әфәнделәр, керүегезне үтенәләр. Башлана, — дип кычкырды.

— Әйдә, булмаса, кермичә торыйк хәзергә, — диде Ришат, — бераз соңгарсак та зарар итмәс. — Ул кулын селтәп куйды. — Ни сөйләячәкләре билгеле инде, сыра да бетмәде.

Җәгъфәр дә моңа каршы түгел иде. Аңа хәзер җиңелрәк тә булып китте. Сөйләшерлек кеше бар иде, ичмаса. Буфет залы бушап, алар икәүдән икәү генә калгач, ул, ачылып, үзенең элекке дусты, ә хәзер бөтенләй дошманына әверелгән Хөсәен турында сөйли башлады. Ришат игътибар белән тыңлый иде. Җәгъфәр тынгач:

— Мин сезгә якын дустым итеп әйтим, — диде ул, — әгәр сезнең күзләрегез караңгы пәрдә белән томаланган икән, мин аларны ачарга ярдәм итим, бәлки, сез соңыннан миңа рәхмәт укырсыз.

— Я, әйтеп карагыз.

Ришат сырасына чеметеп кенә тоз салды да тагы борынын җыерып читкә карап торды.

— Менә нәрсә, әфәндем, безнең иң явыз дошманыбыз, әгәр беләсегез килсә, шул большевиклар.

— Ни өчен алай?

— Туктагыз, сабыр итегез, әйтермен. Безнең иң явыз дошманыбыз — әнә сез сөйләгән Хөсәеннәр. Уһ, мин ул кешене күрсә идем! Беләсезме, мин махсус шул явызны күрү өчен Казанга барып кайтырга әзер. Билләһи!

Ришатның яңак мускуллары калкып чыкты. Җәгъфәр тыела алмыйча көлеп җибәрде.

— Белмим, ни өчен сез большевикларга шулкадәр үчлек тотасыздыр?!

— Ни өченме? Сез шуны да аңламыйсызмы? Менә мин сезгә аңлатыйм алайса, туган. Әле генә югарыда Шәмсетдин абзый сөйләп тордымы?

— Сөйләп торды.

— Нәрсә диде ул, туганым? Тукта, тукта, үзем әйтәм. Ул бөтен гаепне еврейләргә сылтады. Җүләр ул! Чөнки кара надан ул, белми ул. Әгәр беләсегез килсә, дөньяны еврейләр бутамый, нәкъ менә социал-демократлар, аның да большевик фракциясендәгеләре бутый. Белдегезме?

— Белдем, тик бу бит безнең файдага.

— Һа-а, әйттегез, безнең файдага! Безнең файдага түгел ул. Безнең файдага булыр иде, әгәр аларга эшчеләр иярмәсә, безнең файдага булыр иде, әгәр авылдагы җыен йолкыш, бәдбәхет хәерче иярмәсә. Эшнең хәзер ничек торганын белдегезме? Инде ул большевикларның безнең татар арасындагыларына килик, алар бит халкыбызны менә безнең авызыбыздан ризыгыбызны алгандай өзеп алалар. Алар безгә юлны кисәләр, туганым. Патшасы белән дә чорт с ним, без вакытлыча килешә алабыз, кадеты, радикалы белән дә, тик менә большевигы белән тю-тю! Ах, мин ул сез сөйләгән кешене күрсәм!

Ришат йодрыкларын йомарлап күрсәтте. Һәм Җәгъфәр тагы көләргә мәҗбүр булды. Хәлбуки, көлүен көлсә дә, аныңча бу бәләкәй борынлы Ришатның сүзләрендә дә дөреслек бар иде. Моңа Җәгъфәр аның озакка сузылган аңлатуыннан соң ышанмый булдыра алмады. Әйе, чыннан да халыкның, татар халкының материаль байлыклар тудыруда хәлиткеч кешеләрен шул Хөсәеннәр аздыралар, шул Хөсәеннәр төрле хәйлә-мәкерләр корып Җәгъфәрләрдән аералар, үз мәсләктәшләре иттерәләр.

Бик озак тыңлап утырганнан соң, ул Ришатның сүзләрен бүлдерде.

— Нәрсә әйтмәкче буласыз инде? Бәлки, сез, әфәндем, миңа Хөсәен Ямашевны үтерергә боерасыздыр, ә?

Моңарчы җитдилекнең теге ягында булган Ришат кинәт пырхылдап көлеп җибәрде.

— Нинди сабыйдай беркатлы кеше соң сез, туганым?! — диде ул. — Әгәр мин аларны юк итәргә кирәк, алар безнең кан дошманыбыз дип әйтәм икән, моны туры мәгънәсендә аңларга ярамый. Без — гуманистлар. Ничек инде көпә-көндез үзеңнең милләттәшеңне... Мин аңламыйм.

— Ә ничек соң?

— Аларны морально үтерергә кирәк. Син, туганым, аңларга тиеш, алар белән көрәш, урыс әйтмешли, «не на жизнь, а на смерть» булырга тиеш!

— Тукта, ничек инде ул морально үтерергә? Мин бит сезнең кебек русча алай әйбәт сөйләшә белмим.

— Ну, рухи үтерергә. Аңлашылдымы?

— Ә, алай дисәгез. Ә нишләтергә соң?

Ришат башта ук эчкән булган, ахры, башын артка ташлап, исерекләрчә ялкау гына хахылдап куйды.

— Ә анысын мин белмим, Казаныгызга кайткач, мәсләктәшләрегез белән анысын ачыкларсыз.

Югарыдан кемдер иелеп:

— Ришат әфәнде! — дип кычкырды.

— Кем тия? — диде Ришат.

— Ришат әфәнде, сезне Сәйдәшев әфәнде чакыра.

Ришат урыныннан кузгалды.

— Күрешербез, — диде, — мин тагы төшәрмен әле.

Ул, чайкалмыйча, туп-туры өскә менеп китте.

Җәгъфәр тулы бокалына текәлде дә уйга калды. Кара әле, чыннан да бик тәвәккәл, бик батыр кешеләребез бар икән ләбаса! Ә бит дөрес сөйли. Кем дөньяны болгата? Кем безнең милләттәшләребезне икегә аерып, аларны иң изге юлдан тайпылдыра? Әлбәттә, шул Хөсәеннәр!

Бокалдагы сыра өстендә кызыл, күгелҗем төсләргә кереп бер күбек йөзеп йөри иде. Җәгъфәр: «Әгәр шул күбек бокалның теге ягына барып житсә, Хөсәен исән кала, юкса мин аны рухи үтерәм», — дип уйланды. Күбек һаман төрле төсләргә кереп әкрен генә бокалның каршы стенасына таба шуыша иде.

# Күңел күзе күрә

Хөсәен өч көн буена өенә кайта алмады. Ниһаять, бер буш ара табып, өйдәгеләрне күрү өчен генә, өенә кереп чыга алды.

Әнисе дә, Хәдичә дә, Нәкыя дә бик-бик шат иделәр. Мондый хәтәр көннәрдә хәвефнең нәкъ уртасында гизгән Хөсәеннең исән-сау кайтып керүе, житмәсә әле, ак тешләрен ялтыратып елмаеп куйгалавы, берни дә булмагандай тыныч сөйләшүе, хәтта мәзәк сүзләр әйтеп көлдерергә тырышуы, — үзенә бер могжиза кебек иде. Хөсәеннең өс-башы таушалган, күлмәкләре керләнгән, яңакларын куе кара сакал баскан. Нәкыя, Бибифатыйманың ымлавыннан ук аңлап, ишек алдындагы мунчага су ташый башлады. Бибифатыйма үзе, тизрәк аш өлгертү өчен, исән-саулык сорашылгач та, кухня якка чыгып китте. Хәдичә, аулактан файдаланып, иренең муенына сарылды. Алар бер-берсен бик сагынганнар иде. Ләкин менә вакыт кына бик тар, аннары Хөсәен бик алжыган, өстәвенә, аның Хәдичәгә дөнья кадәр яңалыклар сөйлисе бар.

Хөсәен хатынын үпте дә сак кына, иркәләп кенә кулларын ычкындырды. Урындыкка утырып сөйли башлады.

Казанда Идел буе һәм Урал большевикларының аграр конференциясе булып узган иде. Анда эшчеләр саны йөзәр меңләп исәпләнгән, революциянең алдынгы сафларында барган Мәскәү һәм Иваново-Вознесенскидан, ниһаять, үзәк комитетның үзеннән килгән вәкилләр белән күрешә Хөсәен. Менә ул шуларның берсе турында сөйли башлады.

— Арсенийны күрдем, — диде. — Япь-яшь егет үзе.

— Кем соң ул Арсений? Мин аны белмим бит.

— Ничек инде?! Мин бит сиңа Иваново-Вознесенск тукучыларының стачкасы турында сөйләгән идем. Теге, Талка елгасы буендагы вакыйгалар... Хәтерләденме?

— Ә, әйе, әйе, хәтерләдем. Шуннан?

— Мин аңардан Иваново-Вознесенскидагы вакыйгалар турында сораштым. Сөйләде. Афанасьев, Дунаевлар турында сөйләде. Ә үзе шундый ачык күңелле, сабыр табигатьле кеше икән ул Арсений. Политехника институтында укый. Мәскәүдә.

Хөсәен кинәт тынып күңелсезләнеп калды. Хәдичә моның сәбәбен ачык аңлый иде. Ул Хөсәеннең бик тә укыйсы килгәнлеген белә. Менә ничә тапкыр инде ул университетка керү өчен әзерләнә башлады. Кем-нәр белән генә киңәшмәде. Ләкин бу бик җиңел эш түгел иде шул.

— Ярар, тагы ниләр бар? — диде Хәдичә. — Син безнең ут йотып яшәгәнлегебезне, шәт, беләсеңдер. Ичмаса, әйтеп китәргә ярамыймыни? Мөмкин булмадымыни?

Хөсәен башын селкеп кенә куйды

— Һай, шулай булсачы, Хәдичә!

Хәдичә урыныннан торды да:

— Ярый алайса, мин дә сиңа яңалыклар сөйлим, — дип кечкенә бүлмәгә кереп китте.

Хөсәенгә ачык ишектән бүлмә эче күренеп тора иде. Хәдичә комод тартмасыннан нидер эзләп тапты. Хөсәен янына чыкканда аның йөзе борчулы иде.

— Нәрсә, әллә бер-бер күңелсезлекме? — диде Хөсәен, сагаеп.

Хәдичә кулындагы ике хатның берсен иренә сузды.

— Чистайдан. Мин юл араларындагыны үтүкләп чыгардым.

Хөсәен өчен бик көтелгән бер хат иде бу. Татарча текст арасына русча язылган сүзләрне җыеп укый башлады ул. Аның күңеле күтәрелгәннән күтәрелә, таныш рәхәт кичереш бөтен барлыгын били бара иде. Әйе, Хөсәеннәр кузгатып йөргән эш алга үрли. Тукта, тукта, монысы ни тагы? Талкышта яткан Трофим турында язылган. Конычев хатында

(ә хатның татарчасын энисе исеменнән Хәдичә билгеләгән чигүче кыз язган иде): «Сезнең остазыгыз белән соңгы бер атна эчендә бәйләнеш булмыйча торган иде. Әле кичә генә мәгълүм булды: ул үзе кунак булып яткан танышыгыздан киткән. Ничек киткән, кай тарафка киткән, — билгеле түгел. Ихтимал, аның эзенә төшкәннәрдер, бәлки, башка берәр хәл булгандыр. Ни булса шул, ләкин ул анда юк хәзер. Соңгы вакытларда остазыгызның кәефе чагыштырмача яхшырган иде. Үзе йөри башлаган иде. Ләкин мөнә бер атна көрешмичә тору сәбәпле мин аның турында берни дә әйтә алмыйм. Хуҗаның әйтүенә караганда, ул подвода яллап Чистайга киткән, ләкин хәзер кайда икәнлеге билгеле түгел» — диелгән иде.

Хөсәен, бу юлларны укыгач, хафага калды. Уен түгел бу. Революционер иптәше өчен җаваплылык аның өстендә. Комитетта да Завадский белән Хөсәен аркылы гына бәйләнеш тотыла. Ниләр булмас! Әллә берәр ашыгыч эш килеп чыгып... Юк, алай дисәң, Трофим бала түгел, үзенең югалуы белән иптәшләрен борчуга салмас иде ул.

— Хәдичә, бүген Чистайга хат язарга кирәк. Татарчасын язып куй, миңа, зинһар, кирәкле дәваларын да әзерлә, бүген үк, мөмкин булса хәтта хәзер үк, — диде Хөсәен.

Ул гасабиланып кесәсеннән сәгатен чыгарды, йөзен чытты, аннары кулын селтәп, урыныннан купты.

Ул энисеннән, ашарга юкмы? дип сорамакчы иде, ләкин аңа Хәдичә ирек бирмәде.

— Тукта әле, тагы берсе бар, — диде ул, икенче пакетны күрсәтеп.

— Анысы нәрсә тагы? — диде Хөсәен, аптырый төшеп.

— Монысын кайнар үтүк астында тотарга кирәкмәде, бу миңа гына атап язылган, хосусый хат.

Хөсәен җилкәләрен җыерып куйды.

— Алайса миңа бирмә, үзең укы.

— Ләкин бу хатта сүз синең турыда бара, Хөсәен.

— Минем турыда? — Хөсәен ихтыярсыздан хатка үрелде. Ләкин Хәдичә алай ашыгырга бик теләми иде.

— Үзем укыйм, сабыр гына тыңлап утыр.

— Я, укы, — диде Хөсәен.

— «Мөхтәрәмә Хәдичә ханым. Бу әманәтне сезгә яхшылык теләүче, сез белмәгән сезнең бер дустыгыз яза. Бу эшкә барырга миңа вөҗданым куша. Чөнки мин сезгә яхшылык вә бәхет теләп хәер догада калам. Ниһаять, мин сезнең дөреслеккә күзегез ачылуын телим. Белегез, ханым, сүз сезнең ышанычыгызга кереп, сезнең әти-әниегезнең байлыгын вә дә сезнең үзегезнең инсаниятегезне юкка чыгарып ятучы әдәм актыгы турында барачак. Ул сезнең яныгызда. Ул — сезнең ирегез Хөсәен Ямашевдыр. Нидән чыгып мин шундый, йөрәкләрегезне пара-пара итте-рәчәк хөкемнәр чыгарам соң? Моның сәбәбе Хөсәеннең фахишлегеннән. Ул сезгә өйләнгәннән бирле хыянәт кылып яшә».

— Җитте, — диде Хөсәен артык түзә алмыйча, — бир әле!

Аның йөзе кәгазьдәй агарган, күзләре ачудан ялтырыйлар иде. Ул хатка текәлде. Яла ягучы оятсыз рәвештә үзе уйлап чыгарган уйдырмалар язган иде. Хөсәен фәлән көнне фәлән җирдә булган, фәлән ханым белән очрашкан, фәлән көнне фәлән әфәндenең хатыны белән вакыт уздырган...

Хатның ахырында имза урынына «Сезнең дустыгыз» дип кенә куелган. Хөсәен укып чыкты да сорау белән Хәдичәгә карады. Хәдичә исә хәзер утыргыч аркасына уң кулын салып, сул учы белән маңгаен каплаган хәлдә, Хөсәенгә ярым борылган килеш күзләрен йомыбрак утыра иде. Шулай да ул Хөсәеннең каравын тойды һәм кузгалмыйча гына:

— Башыннан ахырынача ялган икәнлеген беләм, Хөсәен, ләкин шулай да миңа бик авыр, — диде.

— Авыр, чөнки кем язганы мәгълүм түгел.

— Әйе, кем язганын белмим. Ә кем язса да барыбер түгелмени?

— Юк, түгел.

Хәдичә һаман үзгәрешсез калды.

— Кем язса да барыбер, — диде ул. — Әгәр синең йөрәгеңне утта кыздыралар икән, кем кыздырса да, барыбер авырта.

Хөсәен җәһәт кенә урыныннан торды да хатны Хәдичәгә сузды:

— Мә, теләсәң нишләт, ул синеке!

Хәдичә хатны өстәлгә ташлап, Хөсәенгә сорау белән текәлде.

— Хәзер андый эшләр белән шөгыльләнергә вакыт юк, — диде Хөсәен.

Хәдичә барысын да аңлый иде. Тик шулай да аның күңеле сулкылдап сыкрана. Чөнки хат башыннан ахырынача ялганнан торса да, монарчы үзен артык сиздермичә, чак кына күңелне уңайсызлап торган сырхауларны да өскә калкытып чыгарды. Аны укыгач, хатын кинәт үзенең Хөсәеннән яшькә олырак булуын да, менә ничә елдан бирле көтсәләр дә һаман бәбиләре булмавын да хәтеренә төшерде. Ходаем, нинди җәфалар чигәргә язган тагы!

...Хәлбуки, бишенче елгы көз Казан урамнарына канлы бәрелешләр алып килде. Хөсәен шул вакыйгаларның уртасында кайный иде. Һәркайда аның тыныч, ләкин ышанычлы тавышы ишетелә иде.

7 нче октябрьда Мәскәү — Казан тимер юлчылары политик стачкага күтәрелде. Тиз арада бөтен Россиягә таралды бу. Бер-бер артлы илнең ундүрт тимер юлы эш ташлады. Тимер юлчылар артыннан ук тагы завод-фабрикалар күтәрелде, ул арада телеграф, телефон, почта эшчеләре кузгалды. Ниһаять, басмаханә эшчеләре, кием тегүчеләр, приказчиклар аякка бастылар. Казан РСДРП комитеты үзенең «Барлык кешегә» дип исемләнгән прокламациясендә Казан хезмәт ияләрен бөтен Россия политик стачкасына катнашырга, коралланырга, патша самодержавиесенә каршы сугышка чакырды.

Уналтынчы октябрьда көн җиләс, салкынча иде. Сәгать көндезге бер. Хөсәен, җирдәге сары яфракларны туздырып, ашыга-ашыга университетка таба юнәлде. Чаттан бик кызып сөйләшә-сөйләшә бер төркем яшь-җилкенчәк күренде. Шәкертләр, вак һөнәрчеләр, приказчиклар. Алар Хөсәенне күрү белән таныдылар. Университетта булачак халык митингысына ашыгалар икән. Ул да булмады, Печән базары турысында Хөсәеннәрне Крестовников эшчеләреннән бер төркем куып җитте. Күпчелеге рус эшчеләре иде болар. Алар арасында мыекларын бөтереп җибәргән Гыйльфан (ул хәзер мыек җибәргән иде) белән маевкада ораторлык иткән Мифтахетдин бабай да бар иде. Руслар да, татар егетләре дә шулай ук Хөсәенне күрү белән таныдылар. Чөнки Крестовников заводындагы эш ташлау вакыйгасы әле онытылмаган. Анда башлап йөрүче Тюнегин артында торган комитетчыларны, шул җөмләдән Хөсәенне, эшчеләр белми түгел иде.

Сүздән сүз чыгып, эшчеләр һәм яшьләр үзләренең бу митингка өмет баглауларын, анда бүген кызыклы сүз булырга тиешлеген әйттеләр. Хөсәен үзе дә шулай уйлый иде. Айга якын ябылып торганнан соң, университетта бертуктаусыз халык митинглары җыела башлады. Моның нәтиҗәсе, әлбәттә, бүген күренер. Кораллы восстаниегә хәзерлек... Ләкин бу ни хәл бу тагы? Хөсәеннәр төркеме, университет алдына килеп чыгу белән, тукталып калырга мәҗбүр булды. Бу бердәнбер тыныч урынны бүген көчәйтелгән полиция наряды камап алган иде. Университет алды халык белән тулган.

Хөсәен юлдашларыннан аерылды да халык арасына кереп китте. Аның исәбе, ничек булса да, капкага якынлашу. Комитетчылар шунда

булырга тиеш. Хөсәен капкага якынлаша торгач, нәкъ Саммерның янына ук барып чыкты. «Сакалбай», аны күрү белән, Лозовский турында сорады. Саммерның йөзе үтә житди, үзе әсәренгән бер хәлдә иде.

— Кертмиләрме? — диде Хөсәен. Саммер дәшмәде, бары йотлыгып капка ягына карап куйды. Анда юан полицейскийлар кылычларын кынылрыннан чыгарып селтәнәләр, капкага якын жибәрмиләр иде. Шулай да ишек алдында да халык юк түгел. Күрәсең, алар иртәдән үк кереп калганнар. «Менә сиңа университет автономиясе», — дип уйланды Хөсәен, ачынып.

Халык һаман гүли, сукрана, полицейскийларга хурлау сүзләре әйтә, капкага ташлана. Ләкин полиция аның саен кылыч елкылдатып халыкны чигенергә мәжбүр итә.

Халык дәрьясы ничектер уң якка таба чайкала башлады. Кемнәрдер Мало-Проломный ягына йөгерештеләр. Хөсәен халык арасыннан Накоряковны, аның күзлек пыялалары ялтыравын күреп калды.

— Мин киттем, — диде ул Саммерга, — тегендә юл тапкан булсалар кирәк.

Алар икесе дә, терсәкләрен кызу-кызу эшләтеп, Накоряков барган якка юнәлделәр.

Мало-Проломный тыкрыгында университет ишек алды стенасына егетләр баскыч китереп куйганнар иде. Хәзер җәһәт-җәһәт койма башына менеп, теге якка сикерәләр. Кара сакаллы бер сузан студент баскыч төбендә, шаярып, «оҗмахка» кергәндә тәртип кирәклеген әйтә иде. Хөсәен үз нәүбәтендә сыгылып торган баскычтан йөгереп өскә менеп китте. Ул ишек алдына төшкәндә халык анда шактый иде инде. Русы да, татары да, студенты да, эшчесе дә җыелган иде. Хөсәен хәтта үзенең берничә таныш шимбәчеләрен дә күрде.

Ләкин урамдагы ыгы-зыгы һәм аерата полициянең бинаны камап торуы халык арасында куркыныч һәм киеренкелек тудыра иде.

Ул да булмады, кинәт баскыч куелган койма турысыннан бик каты кычкырышу һәм команда тавышлары ишетелде. Накоряков:

— Полиция! — диде. Җыйнаулашып, әле койма башыннан төшә алмый маташкан кешеләргә ярдәмгә йөгерделәр. Койма башындагылар жиргә сикерде. Ләкин теге якта калганнарны, күрәсең, полицейскийлар өстерәп төшерә иде.

Койма башында торучы бер яшь студент нечкә ачы тавыш белән: «Казаклар, казаклар!» — дип кычкыра башлады. Урам яктан килгән гүләү авазы тагы да көчәйде. Ишек алдындагы халык, бердән кубып, университет капкасына баррикада кору өчен, күзенә ни күренсә, шуны ташырга тотынды. Атлы казакларның университет ишек алдына керүләре бар иде. Һәм, чыннан да, күп тә үтмәде, полицейскийлар капканың йозагын ачтылар. Ишек алдындагы халык бу вакытны туздырылган кырмыска оясыдай мәш килә, тизрәк юлны капларга ашкына, капканы ачтырмаска тырыша иде. Ләкин соң иде инде. Капка каерылып ачылды, юлдагы әрҗәләрне, мичкәләрне туздырып, полицейскийлар ишек алдына ташландылар.

Хөсәен капка янындагы коймага сыенды. Кылычларын уйнатып, котырынып халыкка һөҗүм иткән полиция алдында, әлбәттә, коралсыз кешеләр берни дә эшли алмыйлар иде. Әйе, оешмаган коралсыз кешеләр белән аларга эш итү ансат. Кылыч уйнатып эшчеләр төркеменә ташланган бер полицейский Хөсәеннең күзенә чалынды. Әйе, бу әлеге «бутышник» Гайнулла абзый иде. Ул да Хөсәенне күреп калды. Полицейскийның йөзе үзгәрмәде, ләкин шулай да:

— Кит, Хөсәен, чуалма монда! Хәзер атлы казаклар кереп турап ташлыйлар үзегезне, — диде. Хөсәенне этеп жибәрде дә үзе кылыч бе-

ләп селтәнеп алга бара бирде. Халык ташкыны Хөсәенне бөтереп алып, капкадан урамга чыгарып ташлады. Бу вакытта халык үкерешеп тарала, уң яктан атлы казаклар, сөңге һәм камчылар белән кешеләрне куркытып, капкага якынлашалар иде.

Кинәт Хөсәеннең колак төбендә каты шартлау тавышы ишетелде. Бер студент үзе ясаган самопалдан аткан икән. Әйе, нәкъ шул гына кирәк тә иде казакларга! Әйтерсең, бу шартлау сигнал булып яңгырады. Казаклар аркаларындагы мылтыкларын кулларына алдылар, дәһшәт эчендә төрле якка сибелгән халыкка ата башладылар. Тиз арада ишек алдындагы кешеләр чәбәләнә-чәбәләнә йөгерешергә тотынды. Үкерү, чәрелдәү авазларына кушылып, мылтыктан аткан тавышлар һәм тәрәзә пыялалары чылтырап ватылганы ишетелде. Каяндыр килеп эләккән бер бала акырып елый иде. Кешеләр үлем дәһшәтеннән качып ышыграк урыннарга йөгерәләр, баш түбәсеннән сызгырып пулялар оча, каядыр якында гына ат тоягы тупырдавы, казакның һай-һулап һәм сызгырып җибәрүе ишетелә иде.

Хөсәен, халыкка ияреп бераз чапканнан соң, университетка чатлаш торган шахмат клубының парадныена керде. Бирeдә Хөсәен кебекләр байтак иде. Башта караңгыда йөзләр ачык күренмәде. Бары кемнәрнеңдер сукрануы, ачы нәфрәтләрен кычкырып изһар итүе генә яңгырап торды. Әкренләп күзе ияләшә төшкәч, Хөсәен үзе янында ук басып торган Җәгъфәрне күрде. Һай, югалган иске дус! Хөсәенгә әле генә кичерелгән фаҗигадән соң ничектер җиңелрәк булып китте. Ул Җәгъфәрнең йөзенә игътибар белән кабат-кабат карады. Ләкин теге күрмәмешкә салыша иде. Кем белә, бәлки ул түгелдер, ярым караңгыда аермавың да мөмкин, — дип уйлады Хөсәен. Җәгъфәр дисәң, бу кеше ничектер артык шома, тулы, өс-башы да бик фәләнски. Тукта, Җәгъфәрме соң бу? Кара! Шул үзе ич! Ләкин ни өчен дәшми ул? Ул, шиксез, бирегә Хөсәеннән алда кергән, тәгаен, ул Хөсәенне күптән, килеп керү белән ук абайлагандыр. Ләкин ни өчен дәшми ул? Хөсәен, күзләрен алмыйча, һаман идәнгә карап торган Җәгъфәрне күзәтте. Ләкин элекке дус, «Җәгъфәр!» диюгә, сискәнеп, ерткыч тизлеге белән Хөсәенгә карап алды да һич уйламаганда, көтмәгәндә ишеккә ташланды. Кемдер аңа: «Сез кая, нишлисез?» — диде. Ләкин Җәгъфәрдән җилләр искән иде инде.

Атышлар тынгач, яшеренергә өлгергән кешеләр урамга чыктылар. Урамнарда дары исе аңкый. Тротуарларда һәм мостовойларда кан, үлгән һәм яраланган кешеләр ята. Хатын-кыз елавы, ирләр сыкрануы...

«Хәзер инде сезгә, патша ялчылары, халык тарафыннан мәрхәмәт, шәфкать булмаячак, — дип уйланды Хөсәен, — бу кадәр үк теш-тырнакларыгызның ялангач чагын Казан халкының әле күргәне юк иде».

Хөсәен тиздән кораллы кузгалыш булачагы турында уйланды. Әйе, бик житди рәвештә, чын-чынлап коралы сугышка хәзерләнергә кушып чаң сугылды. Казан кузгалачак, мотлакан кузгалачак! Ул шулай уйланды, ләкин ара-тирә ни өчендер зур уйлар-ашкынулар арасына Җәгъфәр турындагы фикерләр дә килеп кысыла иде. «Ни өчен ул миңа күтәрелеп карамады?» Шул чак Хәдичәгә килгән хат исенә төште. Гаҗәп бер тойгы кичерде Хөсәен. Күңеле аңа: «Ул хатны язучы кеше — шул Җәгъфәр, — дия иде, — шул, шул! Гаҗәп, — дип куйды Хөсәен, — нинди генә изге максатлар белән янма, әгәр син шул максатларны үтәү өчен ялгыш юлларга кереп китсәң, кабахәтлек баткагына кереп чумасың икән. Гаҗәп, гаҗәп!»

Хөсәен, үзенең иптәшләре белән берлектә, яралы кешеләргә ярдәм итәргә ашыкты.

# Давыллы көннәр турында

Завадскийдан хат килде. Хат Степановка дип язылган иде. Хөсәеннең аптыравына каршы, карт шул хатны күтәреп Чистайдан үзе килеп төште.

Хөсәенгә адресланмаган булса да, Степанов хатны аңа да укытты, чөнки аның Ямашевка турыдан-туры бәйләнеше бар иде. Трофим үзенең кыска гына хатында, сәламәтлеге бераз яхшыргач, үзенең, түзә алмыйча, Самарага китеп баруын хәбәр иткән. Ул Казандагы иптәшләрнең үзе өчен борчылганлыкларын белә, шуңа күрә тиз генә хәбәр итә алмавына бик үкенә, гафу үтенә. Инде бу хат аша ул Хөсәен дуска кайнар дуслык сәламе һәм рәхмәтен күндерә. Инде тагы бу хатны алу белән Степанов Хөсәен аша Казан РСДРП комитеты белән бәйләнешкә керергә тиеш икәнлеген әйтә, гомумән Самара белән Казан арасында элемтә урнаштыруда ярдәм кирәк, ди. Трофим Казан хәлләре турында хат көтә. Хатта әнә шулар язылган иде. Степанов хатны укытты да, иртәгә иртәнге алтыга сугылырмын, җавап әзер булсын дип, китеп барды.

Менә сәгать төнге бер, инде өйдәгеләр барысы да йоклый, ә Хөсәен үзенең бүлмәсендә хат язып утыра. Шәм уты әкрен генә тибрәнә, кәгазьгә төшкән каләм күләгәсе бер унга, бер сулга шуыша.

«Кадерле дус, синең хатыңа җавап итеп, комитет кушуы буенча, түбәндәге юлларны язам. Без бик кайнар вакыйгалар эчендә яшибез. Синең өчен Казанның ни дәрәҗәдә кадерле, якын икәнлеген аңлыйм, шуңа күрә, бу хатның фиргавеннәргә эләкмәячәгенә тәмам ышанган хәлдә, мөмкин кадәр тулы итеп язарга тырышачакмын. Безнең көннәр...»

Хөсәен, шушы җирдә тукталып, фикерен туплап торды. Аның күз алдыннан бер-бер артлы булып узган вакыйгалар үтте. Уналтынчы, аннары унҗиденче октябрь көннәре. Әйе, аларның барын да хатка язып бетерү мөмкин эш түгел, сайлап-сайлап кына, кирәген генә язарга була.

...Халык уналтысы көненнән айнып өлгерми, менә анысыннан да рәхимсезрәк унҗиденче октябрь көне килә. Кан өшеткеч, бәгыренне өзгеч ерткычлык тагы кабатлана. Берниндн коралсыз халыкны кыйныйлар, кылыч белән чабалар, аңа мылтыктан аталар. Күзләрдә дәһшәт һәм ләгънәт. Хәзер инде ул көнге вәхшилекләрнең вак-төяге дә мәгълүм. Унҗиденче октябрь көнне иртәнге якта ук халыктан үч алуны максат итеп куйган атлы һәм җәяүле городовойлар университет тирәсендә чуала башлаганнар. Алар шунда ук юлларына туры килгән студентларны һәм эшчеләрне камчылар белән ярганнар. Халык шулай да митингка җыелды. Ул Воскресенская урамын тутырып «Марсельеза»лар җырлый, патшага каршы төрле лозунглар кычкыра, мәгәр үзе һич сугышчан тотмый. Ә полициягә үч алу өчен нинди дә булса берәр сылтау гына кирәк. Сылтау тиз табыла. Бер студент, — Хөсәен аның эсер икәнен белә, — атлы полициягә ясалма бомба ыргыта. Бомба шартлый, ләкин беркемгә дә зыян китерми. Шуннан соң моңарчы качып торган атлы казаклар халык өстенә ташланалар, городовойлар һөҗүмгә күчә. Семинария бинасыннан, университеттан кемнәрнеңдер аларга револьвердан атканы ишетелә. Ләкин халыкның төп коралы — таш. Ә исерек казаклар һәм городовойлар исә винтовкалардан аталар. Ату тавышлары төнге унберләдә дә ишетелә. Пассажның ватылмаган бер генә тәрәзәсе дә калмый. Окружной суд, шахмат клубының тәрәзәләре чәрдәкләнеп бетә. «Франция» номеры утка тотыла. Исерек казаклар халыкны үтереп кенә калмыйлар, магазиннарны таларга керешәләр. Соңыннан алар, урамда очраган һәр кешегә ташланып, камчы белән ярып йөриләр. Хәзергә мәгълүм нәтиҗә шул: земский больницада биш үле,

егерме өче яралы килеш ята; Александровский больницада күкрәгенә утәли штык кадалган татар егетенең мәете һәм яралы биш кеше ята; семинария больницасында ике үле, бер яралы; университет клиникасында унөч яшьлек гимназист мәете һәм яралы биш кеше ята...

Хөсәен каләмен карага манып алды да: «16 нчы һәм 17 нче октябрь көнне» дип яза башлады.

Әйе, ул унҗиденче октябрь төнендә эшчеләр арасында булды. Хәзер алар ныклап коралланмыйча торып эш барып чыкмасын яхшы аңлыйлар иде. Корал табарга кирәк, корал белән эш итәргә өйрәнергә кирәк. Комитетта да төне буе шуның турында сүз барды. Иптәшләр агарып, суырылып калганнар. Ләкин хәзер инде алар барысына да әзер иде, хәлиткеч канлы көрәшнең бик якын икәнлеген ачык аңлыйлар иде.

Хөсәеннең күз алдыннан бер-бер артлы комитеттагы дуслары үтте. Әнә мәһабәт гәүдәле, ак чырайлы, ачык йөзле Саммер. Ул үзенең матур көрән сакалын һәрвакыт әйбәтләп тарап йөрүчән иде. Ә бүген аның сакалы учында йомарланып, киезләнеп беткән. Ул, кызып, нindирәк ысуллар белән Казан гарнизонындагы батальоннарны большевиклар ягына тартырга кирәклеген сөйли. Лозовскийның зур зәңгәр күзләре йокысызлыктан, алҗудан тоныкланган, ялтыратылган бакырдай җирән чәче маңгаена төшкән. Ләкин ул үзе тыныч, һәрбер сүзен гадәтенчә үлчәп сөйли. Аның хәзер эше күп: пропаганда активлыгы югары ноктасына җиткерелергә тиеш, шуның өчен ул партия каршында җаваплы. Әнә комитетның секретаре Дамперов, болай да ябык, сузан кеше, ул хәзер бөтенләй юкарып калган, болай да озын борыны бөтенләй зур булып күзгә ташлана.

Накоряков күзлеген теге көнне ваткан иде. Ансыз ул бөтенләй үзенә охшамый. Арада бары Кулеша гына үзен тәртипкә китерергә өлгергән. Хәер, моның сәбәбе дә бар: Кулешаның күлмәген ертканнар, шуңа күрә ул күлмәген алыштырырга мәҗбүр булган иде. Хәзер ул, бер үзе аерылып, якасы чигүле ап-ак күлмәктән бәйрәмдәгечә көяз булып, чәчсез чиста башын ялтыратып утыра иде.

Хөсәен язуын дәвам иттерде:

«Комитет членнарыннан син белгән иптәшләр барысы да диярлек исән. «Әткәй»дән хәбәр килеп тора. Соңгы вакытта хәрбиләр белән эшне көчәйтергә тырышабыз. Андрей бездә чакны күп ярдәм күрсәткән иде. Ләкин син болай да аңлыйсың инде, без ат кебек эшләсәк тә, әле эшнең очы-кырые күренми. Безгә бик күп кеше кирәк. Бик күп...

Син һәрвакыт минем үз халкым арасындагы эшнең барышы белән кызыксына идең. Мин һаман татар телендә большевистик газета чыгару дәрте белән янып йөрим».

Хөсәен тагы уйланып утырды. Вакыйгалар артык күп, тойгылар көчле иде. Ул сайлап-сайлап, иң кирәк дигәннәрен генә кәгазьгә төшерә башлады.

Хөсәеннең күз алдында шәһәр думасы алдындагы халык диңгезе җанланды. Хәзер инде халык акны карадан аерырга өйрәнгән иде. Шуңа күрә патша манифесты аркасында теләкләренә ирешкән кешеләр дәшмичә, посыбрак торуны артык таптылар. Соңыннан зур бер төркем дума гласныйлары янына юнәлде. Гласныйларның думада утырышлары иде. Алар, күрәсең, үзләре дә бу хәлне — халыкның манифестны болай өнәмичә каршылавын көтмәгәннәр, хәзер югала төшкәннәр. Башлыча большевиклардан торган делегация гласныйлардан унҗидесендәге вәхшилек өчен гаепле кешеләргә җаза таләп итте. Полиция коралсызландырылырга тиеш, хәрби көчләр казармаларыннан чыгарылмасын!

Хөсәен каләмен тагы карага манып алды. «Митингтан соң без, комитетчылар, һәм бер төркем халык вәкилләре шәһәр думасына кердек, — дип язды ул. — Алар алдына таләпләр куйдык. Мин дә делегациядә идем. Гласныйлар безнен таләпләрдән баш тарта алмадылар.

Менә шуннан соң инде Казанда чын мәгънәсендә революциянең тантанасы башланды. Минем мондый шатлыклы минутларны үз гомеремдә күргәнем юк иде әле».

Хөсәен комитет кушуы буенча Печән базарында уздырылган митинг турында уйланды. Митинг хас татар халкы өчен, татар телендә алып барылды. Анда да бөтен мәйдан шыгрым тулган иде. Хөсәен баштарак борчылган иде. Большевиклар куйган мәсьәләләр халыкка ят тоелыр кебек иде. Өстәвенә әле, кайбер катлауларга эсер һәм меньшевиклар йогынтысы да көчле. Тик әйбәтләп аңлату, ораторларның бер-бер артлы төшендерүе бушка китмәде. Митингка катнашучылар бер тавыштан сугышчан карар кабул иттеләр һәм кызыл әләмнәр күтәреп, революцион җырлар белән Екатеринская урамы буйлап Крестовников заводына таба юнәлделәр. Юлда халыкка завод эшчеләре дә кушылды. Завод капкасы төбендә митинг дәвам итте. Сүз ике телдә: русча һәм татарча барды. Митингтан соң Плэтән урамындагы 5 нче полиция участогына киттеләр. Приставтан корал таләп иттеләр. Башка вакыт булса, Хөсәеннең өендә тентү ясаган тәкәббер чиновник бик исәпләшеп тормас иде. Ләкин хәзер көч Хөсәен ягында иде. Әнә алар урамда, алар меңләгән. Приставның бармаклары чак сизелерлек булып дерелди башлады. Ул никадәр үзен батыр тотарга тырышмасын, коелып төште, буйсынды.

Полицейскийларның револьвер, кылычларын салдырып алдылар. Бутышник Гайнулла хәзер Хөсәеннең күзләренә туры карамый иде.

Полиция бүлекләреннән җыелган кораллар ул көнне университет клиникасы ишек алдына олаулап ташылды. Аннан соң халык милициясе һәм дружиналар оештырылды. Садыйклар, Миңнуллалар беренче булып дружинага керделәр. Язучы Галиәсгар Камал шәкертләрдән оешкан милиция отрядына үзе җитәкчелек итеп йөрде. Гаҗәп хәлләр булды!..

Хөсәеннең каләме тагы хәрәкәтләнә башлады. «Бездә хәзер тәртипне халык милициясе саклый. Хәзергә барысы да әйбәт кенә бара. Әле өченче көн генә туздырылган корт иледәй Казанда хәзер үрнәк булырдай тәртип».

Бүген, ягъни егерменче октябрьда, тагы бик зур митинг уздырылды, ә аннан алдагы төндә киңәйтелгән экстренный комитет утырышы булды. Башка революцион партияләр белән берлектә шәһәр коммунасы оештырырга карар кылынды. «Трофим дус,— дип язды Хөсәен,— власть хәзер революцион көчләр кулында. Мин шушы урында хатымны туктатырга мәҗбүр. Үзен аңлыйсың инде, бик катлаулы һәм тыгыз чак. Барлык комитет исеменнән кайнар сәлам. Хатларыңны хәзергә иптәш Степанов аша җибәрә тор. Кайнар революцион сәлам белән: Хөсәен.

P. S. Син үзеңнең сәламәтлегең турында берни дә язмыйсың диярлек. Бу хәл безне борчый. Яз. Аннан, үз тирәңдәге иптәшләргә бездән кайнар сәлам тапшыр. Х.»

Хөсәен каләмен карага манып алды да, языйммы, юкмы, дигәндәй икеләнеп торды. Ленин чыгара дигән «Пролетарий» газетасындагы мәкалә исенә төште. Аның 22 нче санында сүз Казан комитетының татарлар арасындагы эше турында әйтелгән иде. Хөсәен турында «бернинди дә милләтчелек чире белән азап чикмәүче ортодоксаль» диелгән иде. Хөсәен бер мәл уйланып утырды. Аннары моның турында язмаска булды. «Яхшы түгел, тыйнаксызлык», дип уйланды.

Ул хатны конвертка тыкты да, күзләрен йомып, беләгенә башын салды. Артык арылган иде. Ләкин хат турында да уйланмый булмый. Дөнья кадәр яңалык әйтелмичә калды. Хөсәен, барлык көчен куеп, үзен тәмам оета башлаган йокы исереклеген куарга тырышты. Ниһаять, хатның дәвамын бераз черем итеп алганнан соң язарга булып, ул шәмдәлне күтәргән хәлдә Хәдичә янына керде. Хәдичә йоклый иде. Әнә ул нәни балалар кебек авызын чапылдатып куйды. Хөсәен хатыны

янына килде. Менә ничә көн инде аның Хәдичәсе белән рәтләп, иркенләп сөйләшә алганы да юк. Тик, зарар юк, күп калмады инде. Инде төеннәр чишелүгә таба бара. Күп калмады, күп калмады. Менә-менә кораллы восстание күтәреләчәк. Бөтен Россия империясендә зур үзгәрешләр булачак!

Хөсәен, тыныч кына йоклаган хатынын яратып, үз алдына елмаеп куйды. Чыннан да, кайчаннан бирле инде иркенләп сөйләшкәне юк аның. «Ничек, теге ләгънәт хаин ясап киткән яралары төзәлгәнме икән? Зарар юк, зарар юк, — диде Хөсәен, үзен тынычландырып, — барысы да уңай хәл кылыныр. Иң олысы, иң бөеге хәл кылынсын, калганнары булыр».

Ул аяк очларына гына басып читкә китте, шәмне өстәлгә куеп, сүндерде, ярым чишенгән килеш урынга авып, шунда ук йокыга талды.

## Камалуда

Гафурның йөрәге ашкынып тибә, күңеле шатлык нурларында балкый иде. Ул эчтән генә үзенә әйтеп барды: шундый көннәрдә өеңдә сырхауланып ятма, туган! Бу бит инде адәм көлкесе, валлаһи. Башыңны югары күтәр, булдыра алганча каты басып шәһәр ягына таба юнәл.

Ә бит ярыйсы чыга иде. Гафур ашыгып алга атлады. Ак кар белән капланган урам якты, буп-буш иде. Чаттан борылуга, биткә ургылып искән ачы октябрь җиле килеп бәрелде. Гафур пальто якасын күтәреп, муенындагы шарфы белән иплән күкрәген каплады. Аны хәзер өметләре һәм уйлары гына җылыта иде. Нинди генә хыяллар тумады, гаҗәп иде; менә, ниһаять, шул зарыгып көткән көннәр дә житте. Тимер казык йолдызыдай янып, үзенә чакырып торган революция көннәре килеп житте диген, ә! Казан халык кулында. Казанның хуҗасы хәзер — эшчеләр, хезмәт ияләре. Шәһәр коммунасы диген, ә? Әйтүе генә ансат, билләһи. Париж Коммунасы турында укып хәйран калабыз, соң бит хәзер шундый зур вакыйгалар үзебезнең шәһәребездә, Казаныбызда!

Егерме беренче октябрьның иртәсе иде. Шәһәрдә тәртип менә өченче көн инде халык милициясе тарафыннан саклана. Шылт та иткән тавыш юк, бөтен җирдә тынлык. Әйтерсең лә, бернинди митинг та, стачкалар да булмаган. Кинәт каршыга өч кеше килеп чыкты. Карасана, менә шулар түгелме соң милиция вәкилләре?! Җиңнәрендә кызыл тасма, бил каешларына револьвер кыстырылган, ә өс-башлары гади, гражданский. Алар бик житди генә ни турындадыр сөйләшеп Гафур яныннан узып киттеләр. Әйе, болар бит Алафузов эшчеләре. Берсе татар әле аның, ничектер, кайчандыр Гафур аны очратмады микән әле. Гафур кызыксынып артларыннан карап калды. Тегеләр исә, Гафурга игътибар да итмәстән, һаман ни турындадыр кызып сөйләшәләр иде. Күрәсең, сүз артык житди, мәсьәлә артык мөһимдер.

Гафур кәефләнеп үз алдына елмаеп торды. «Ә Суфия мине чыгармаска маташты тагы. Мондый көннәрне бары шул кулына корал алган халык вәкилен күрү өчен генә дә ләхетеңнән сикереп торырсың».

Көзге җил усак яфракларын урам буенча бөтерә-бөтерә очыра иде. Арттан ат юрткан, арба тәгәрмәчләре дөбердәгән тавыш ишетелде. Кемнәрдер арбага төялеп киләләр. Гафур юл биреп читкәрәк чыкты. Ләкин арбадагылар, Гафур белән тигезләнгәч, атны каты тавышланып туктаттылар да:

— Гафур туган, учитель иптәш, әйдәгез арбага утырыгыз, — дип кычкырдылар.

Атта килүчеләр барысы да диярлек Гафурның танышлары булып чыкты: Шәрифулла абзый, аның кече улы Гыйззәтулла, аннан Садыйк, Садыйкның энеләре Зариф белән Гали. Гафур алтынчы кешене генә

танымады, анысы яшь чырайлы, коңгырт күзле, авылча киенгән бер егет иде. Атка болай да җиңел түгел, тик үзләре кысрыкланып булса да Гафурга да урын бирделәр. Гафур ат тотып барган Гыйззәтулла янына утырды.

Болай иртә таңнан кая баруларын сорау кирәксез иде. Сүзне Шәрифулла үзе башлады.

— Алай да үзең тынгысыз җан икәнсең, Гафур, — диде ул, — сине сырхауланып ята дип ишеткән идек. Түзмәгәнсең, мин әйтәм, чыгып киткәнсең.

— Мондый көннәрдә өйдә ятулары бик читен шул, — диде Гафур.— Ягез әле, сөйләп җибәрегез әле, ниләр бар дөньяда? Мин тәмам тормыштан артта калдым.

Җавапны Садыйк бирде, чөнки ул арбадагыларның барысыннан да күбрәк хәбәрдар иде. Ул шәһәрнең хәзер коммуна кулында икәнлеген, ләкин шул ук вакытта губернаторның да үз резиденциясендә яшәвен, инде хәзер заводларда дружиналар төзелүен, шәһәрдә халык милициясенең тәртипне тиешенчә урнаштырганлыгын сөйләде. Ләкин гарнизондагы хәрби көчләрнең әле һаман коммуна ягына күчмәгәнлеген, анда бик ышанычлы иптәшләр эш алып барса да, нәтиҗә ачык булмаганлыгын әйтте.

— Бер сүтелә башлагач, сүтелә инде ул, аллаһы боерса, — диде Шәрифулла, дилбегә кагып, — әллә кая китә алмас, салдаты да бит аның безнеңише кеше. Аны япон сугышы туйдырмаган дисеңмени?!

— Шулаен шулай да, — диде Садыйк. Тик әйтеп бетермәде, үзенең артык бәхәсләшергә теләмәгәнлеген сиздереп, елмаеп кына куйды.

— Шулай да, — диде Гафур, — хафаланырга урын бармыни әле?

— Хафаланмыйча да булмый шул, — диде Садыйк. — Менә кемнәрдән тора бит ул армия.

Садыйк үз янында утырып баручы әлеге авыл егетенә төртеп күрсәтте.

— Кем соң ул? — диде Гафур, Садыйкның шулай дорфа кылануына сәерсенеп.

— Бумы? Бу — авыл гыйбаты, Фәрхетдин дигән егет була. Хәзер безнең тимерчелектә чүкеч сугучы булып эшли. Эшче дип аталуы корысын! Мең бәла белән сәндерәсеннән өстерәп төшердек.

Мондый ачы көлүдән соң егет, әлбәттә, ни булса да әйтергә тиеш иде. Ләкин ул, Гафурның гаҗәпләнүенә каршы, дәшми-тынмый утыруында булды.

— Я, менә Гафур учитель алдында акланып бак инде, нигә авызыңны йомып утырасың? — диде Садыйк һаман дорфарак бер тон белән.

Фәрхетдин дәшмәде.

— Ничек соң, Фәрхетдин абый, — диде Садыйкның кече энесе Гали, шаян күзләрен уйнатып, — сыерга житәрлек кенә булса да җыелдымы әле?

— Җыелды, — дип куйды Фәрхетдин. — Сыерлык та булды, атның өч аягы да булды.

— Менә күрдеңме, Гафур, — диде Садыйк, үз сүзе дөрескә чыгуына куанып. — Ничек итеп шундый кешеләргә ышанырга була?

— Син, абый, арттырасың бераз, — диде Садыйкның уртанчы энесе Зариф. — Әллә Фәрхетдиннәрдән генә торамы авыл?! Авылларда алпут имениеләре янмыймыни хәзер? Кем эшли соң аны?

— Юк, әле Фәрхетдин барысын да күреп бетермәгән. Шуннан килә ул. Юкса без дә авылдан чыккан кемсәләр, — диде Шәрифулла.

Ул, бәхәсне куертмас өчен булса кирәк, үзенең башыннан кичкәннәрне сөйләргә керешге. Сөйләшеп бара торгач, юл кыскара төште. Тиздән

Ташаяк ярминкәсенә дә килеп җиттеләр. Гафур, рәхмәт әйтеп, арбадан төште, ә атлылар исә юлларын Проломный буйлап дәвам иттерделәр.

Иртә булуына карамастан, бу тирәдә халык ешрак күренә иде. Гафур, арбада килеп ойый төшкән ботларын бераз угалап, Иванов мәйданына менеп китте. Анда ялан башлы чуен патша, кремльгә мәгърур текәлгән килеш, һаман хакимлек итә иде әле. Дума ишеге төбенә кадәр ачык иде. Гади киемле кешеләр чыгып-кереп торалар. Барысының да кыяфәте җитди һәм эшчән. Кайберләрнең билендә револьвер, кайберләре хәтта мылтык белән коралланганнар. Гафур сакта торучы кешеләргә күз атты. Араларында Мөхәммәдия мәдрәсәсенең шәкерте Мостафинны таныды. Егет шәкерт җөббәсе өстеннән каеш буып, кылыч аскан, револьвер таккан иде.

— Киләсезме, Гафур әфәнде? — диде Мостафин. Аннары: — Бик шәп, хәерле сәгатьтә! — дип өстәде. Башка сакчылар руслар иде, алар сүз дәшмәделәр. Гафур тимер баскычларны янгыратып өскә менде, парадный ишегендәге язуны укырга тукталды.

«Теләүчеләр халык милициясенә биредә языла алалар», — диелгән иде анда. Әйе, Гафурга менә шул кирәк тә инде. Ул дулкынлана төшеп эчкә узды.

Күңеле шатлык хисләре белән тулган иде аның. Үзенең эчке омтылышларына, гомер буе ашкынган максатына ирешкәндәй булды ул. Тимер баскычны дөбер-шатыр китереп өстән бер төркем кеше төшә башлады. Гади халык вәкилләре. Шушы шәһәр думасы урнашкан чит-ят өй ике көн эчендә хезмәт халкының үз йортына әйләнде. Кара син ул кешеләрне! Үзләрен тулы хокуклы хуҗа итеп тоялар, рәхәтләнеп күкрәк киереп сөйләшеп төшеп киләләр. Гафур аларның үзе яныннан ук узып баручы берәүсенә мөрәҗәгать итте.

— Иптәш, кайсы бүлмәдә милициягә язылырга була?

Кыска пальто кигән картузлы эшче Гафурга күз ташлады. Аның аптырабрак калуы чагылып китте. Ләкин шулай да сорауга җавап бирде, өстә уң кул яктагы беренче бүлмәдә икәнлеген әйтте. Гафур баскычның борылышына кадәр менгән иде инде, кинәт аста нииндидер ят тавышлар ишетеп тукталып калды. Әле генә баскычтан төшкән һәм Гафурга ничәнче бүлмәдә милициягә язылырга мөмкин икәнлеген аңлаткан кешенең иптәшләре хәзер ишек янында тавышланалар иде. Гафур тыңлап торды, әмма сүзнең ни турыда барганын кинәт кенә аңламады. Урам яктан тагы нииндидер кешеләр килеп кушылды. Ярым ачык ишек аша халык тынып торган араларда ерактан, бик ерактан нииндидер гүләү тавышлары ишетелеп китә иде. Гафур бөтен игътибарын җигеп ишетергә тырышты, ләкин барыбер берни аңламады. Ул соңыннан артык тукталып торуны кирәк дип санамады. Нинди кызыклар булмас мондый көннәрдә! Ул берничә баскычка менү белән тагы тукталырга мәҗбүр булды. Аста халык ишәйгәннән-ишәя бара иде, тик хәзер аларның ярсып тавышланулары кырт киселде. Араларыннан, Гафурның аптыравына каршы, өч кеше ухылдап йөгерә-йөгерә өскә менә башладылар. Юк, болар әле генә төшеп килүче кешеләр түгел иде. Болар Гафур урамда күргән, җиңнәренә кызыл тасма таккан сакчылар иде. Менә алар Гафурны куып җиттеләр һәм тимер баскычларны дөбер-шатыр янгыратып узып киттеләр. Гафур Мостафинны чабуыннан диярлек эләктереп алды.

— Ни булды? — диде ул, тәмам хәйран калып.

— Манифестация! — диде сулышы капкан Мостафин. Ике-өч баскыч өскә менгәч кенә: — Чыгып карагыз! Бик сәер киләләр кара йөрәкләр! — дип өстәде.

Ул китеп күздән югалды. Ләкин Гафур әле дә берни аңламады. Бераз вакыт баскычта икеләнеп торганнан соң, аска төшеп китте.

Чыннан да, урамда манифестация иде. Тик бу манифестациянең башында алтынланган атлас ризалар кигән озын чәчле поплар килә иде. Аларга ияргән халык исә башлыча рус сәүдәгәрләре, итчеләр, маклерлар иде. Алда килүче ике егет алтынланган рамлы патша сурәте күтәргән. Өч япьле флаглар җилферди, чиркәүләрне генә бизи торган канатлы алтын фәрештәләр өстә чайкала. Колонна кремль эченнән чыгып әкрен генә, салмак кына дума өенә якынлашып килә. Бая тоныкгөрелте булып ишетелгән тавышның җыр икәнлеген Гафур әле генә аңлады. Килүчеләр: «Боже, царя храни», дип патшага озын гомер теләп, гимн җырлыйлар иде. Менә алар бөтенләй якынлаштылар инде. Арканы чымырдата торган ниндидер дәһшәтле күренеш иде бу. Дума алдындагы милиционерлар тирән тынлыкта манифестация колоннасындагы һәрбер хәрәкәтне сагаеп күзәтәләр. Милиционерлар турысыннан алгы сафлар тыныч кына узды. Менә колоннаның уртасы якынлашты. Кинәт исерек авазлар ишетелеп китте. Ниндидер кешеләр җикеренә, сызгырына башладылар. Болары исерекләр, йолкыш сукбайлар. Колонна алай зур түгел. Әлбәттә, милиция, чынлабрак керешсә, аларны авызлыклый да алыр иде. Гафур шуны көтте дә. Ләкин исерекләр төркеме дума каршында тәртип боза башлау белән, кремль капкасыннан гөрес-гөрес басып юнкерлар ротасы күренде. Өстән тимер баскычларны яңгыратып йөгерә-йөгерә тагы бер төркем кеше төште. Алар арасыннан Гафур таза гәүдәле Саммерны, җирән сакаллы Лозовскийны һәм сузан Дамперовны күрде. Алардан бераз соңгарак калып Хөсәен белән ниндидер күзлекле студент егет төште. Милициягә җитәкчелек итү Дамперовка йөкләтелгән иде. Ул юнкерларны күрү белән алгарак чыкты һәм револьверларын кулларына алган ачулы йөзле милиционерларга кычкырды:

— Иптәшләр, тыныч кына. Провокациягә бирелмик!

Ул арада урамны буып алган манифестчылар тагы да катырак кычкырырга, сызгырынырга тотындылар. Араларыннан берсе ямьсез ачы тавыш белән:

— Долой жидов! — дип кычкырды. — Яхшы чакта ташлагыз коралларыгызны!

Милиционерлар өстенә кар кисәкләре, буш шешәләр, таяклар, ташлар ява башлады.

— Тыныч булыгыз! — дип кабатлады Дамперов, йөзен кулы белән саклап. Ләкин коммуна сакчыларының нервылары җитәрлек киеренке иде инде. Гафур күңеле белән сизенеп торды: әгәр дә тегеләр тарафыннан тагы бер хәрәкәт ясалса, тәгаен револьверлар төзәләчәк иде. Халык төркеме милиционерлар каршында ишәйгәннән-ишәя барды. Милиция һәм коммуна яклылар исә бер-беренә тагы да ныграк сыендылар. Гафурның да бу минутта куллары йомарланган, тешләре кысылган, әгәр ул-бу була калса, ул да читтә калмаячак иде. Ләкин эш аңа барып җитмәде. Кинәт манифестчылар арасыннан алга бөтеренке мыеклы пристав чыкты.

— Әфәнделәр! — дип кычкырды ул карлыккан тавыш белән. — Мин сезнең хәзер үк милицияне таратып, коралны полиция кулына кайтаруыгызны таләп итәм!

— Кем соң син? — диде бер карт эшче.

— Мин алтынчы частьның приставы! Мин — вакытлыча полицмейстер вазифасын башкаручы.

Аның артында ук, җир астыннан калкып чыккандай, биш-алты полиция чины пәйда булды.

— Сезгә уйлану өчен биш минут вакыт, әфәнделәр, — дип кычкырды пристав.

— Үкчәгезне күтәрегез, ваше благородие, — диде Гафур янында торган яшь бер милиционер.

Пристав янап йодрык селкеде дә, барыбер үзенекен итәчәген кабатлап, манифестчылар арасына кереп югалды. Тагы ачы сызгыру, сүгенү авазлары ишетелде, тагы ниндидер хулиганнар таш, балчык, буш шешәләр ата башладылар. Ләкин Гафур сизеп торды: карагруһларның ниндидер кискен бәрелешкә барырга кулларыннан килми иде. Алар бераз котырынганнан соң тындылар, тукталган колонна тагы кузгалды һәм янадан «Боже, царя храни» гимны ишетелде.

— Әйдә, алдыгыздан артыгыз яхшы, үкчәгезне күтәрегез! — диде кемдер. Милиция вәкилләре ачу аша көлешеп калдылар. Тынычлык урнашты.

Колонна университет ягында күздән югалып, урам бушап калгач, Гафур янадан ишеккә таба юнәлде һәм шул чак Хөсәенне күрде. Хөсәен эчтә баскыч алдында Дамперов белән сөйләшеп тора иде. Милиция житәкчесе аңа ниндидер йомыш кушты булса кирәк, Хөсәен аңа: «Хәзер», — диде һәм борылганда Гафурны күреп аптырап китте.

— Бу нинди эш бу, Гафур? Кайдан ни арада килеп чыктың әле син?

— Бик табигый, — диде Гафур, Хөсәеннең кулын кысып.

— Соң бит сине авырый диделәр.

— Авыртмас сөяк булмас, Хөсәен.

Хөсәен Гафурның ябыгып каралган йөзенә, хәлсез моңсу күзләренә карап торды.

— Юк, син китәргә тиеш моннан, Гафур! Күргәнсеңдер бит. Кабахәтләр янадан котырына башладылар.

Гафур башын чайкады.

— Юк, мин бер кая да китмим. Мин китәр өчен килмәдем бирегә.

Хөсәен тагы Гафурның зур кара күзләренә карап торды. Бу юлы дусты өчен горурлык чагыла иде аның карашында. Ләкин ул тагы борчылып кашларын җыерды.

Китәргә тиеш идеме соң Гафур? Бәлки, ул киткән дә булыр иде, тик эшләр мондый төс алгач, ул китә алмый. Мондый хәлдә иптәшләренне ташлап китү коточкыч хыянәт. Әлбәттә, ул рәсми рәвештә партиядә тормый. Ләкин эш андамыни? Гомере буе гаделлек өчен көрәшеп тә, эшчеләргә ирек яулау турында хыялланып та шул эш инде хәвеф астында калганда, качса, кем булырга тиеш ул Гафур! Юк, андый нәрсә гомердә булмас, үләр, бетәр Гафур, мәгәр андый хыянәт ясамас!

— Син тегеләрнең янавын ишеттеңме? — диде Хөсәен.

— Ишеттем.

— Алар бит кире киләчәк, һәрхәлдә, алар кабахәтлек ясарга тырышачаклар, Гафур. Авыру килеш...

Кинәт Гафурның йөзе гарьләнүдән алсуланып китте.

— Син мине, Хөсәен, алла хакына, куркытма, — диде ул, текәлеп карап, — әгәр син минем дустым икәнсең, әйт, ничек итеп миңа милиция сафына язылырга да ничек итеп корал алырга?

— Корал юк, бөтен бәла дә шунда, — диде Хөсәен, күңелсезләнеп. — Ә син коралдан файдалана беләсеңме соң?

— Беләм, — диде Гафур.

Алар икесе дә тынып калдылар. Баскыч өстендә торган Саммерның тавышы ишетелде. Ул ни өчендер Хөсәенгә тиз генә өскә менәргә куша иде. Киңәшәләр, ахры, дип уйланды Гафур. Аның хәлсезлектән тез буыннары калтырый, тыны кысыла иде. Башка утырыр урын булмагач, тимер баскычка барып чүкте. Әйе, соңгарак калынган. Ни пычагыма шулай иркәләнеп, авырыйм-фәлән дип ятарга инде аңа. Барысы да әйбәт булган булыр иде. Гафур байтак вакыт салкын баскычта үз-үзен табалап утырды. Кешеләр әле төшәләр, әле меңәләр, бик кызып-кызып үзара сөйләшәләр, барысы да ашыгалар иде.

Гафур үзенең иңбашында кемнеңдер кулын тойды. Хөсәен ике иптәше белән төшеп килә икән. Тукталып:

— Әйдә тышка чыгыйк әле, — диде ул Гафурга. Гафур ихтыярсыздан аңа буйсынды. Ләкин алар, урамга чыккач, берни дә сөйләшә алмадылар диярлек. Чөнки әлеге көтелгән хәл якынлаша. Гостинодворская урамы буйлап Проломныйдан баягы манифестчылар күтәрелеп киләләр иде. Алар күренү белән, өстән, йөгерешеп, Дамперов һәм башка коммуна члennары төште.

— Тиз булыгыз! — диде Дамперов, гасабиланып.

— Әйдәгез теге яктан, — диде Хөсәеннең рус иптәше.

Мөгаен, аларга коммуна ниндидер йомыш кушкан иде. Гафур шулай уйлады. Хөсәен Гафурга бары:

— Кара аны, Гафур, үзеңне сакла! — дип әйтергә генә өлгерде. Өченче юлдашы аны, ачулана төшеп, Гафурдан аерды. Тиздән алар өчәүләшеп, бинага ышыкланган хәлдә, дума өенең артына китеп күздән югалдылар.

Бу арада инде манифестчылар дума йортына бөтенләй якынлашканнар, үзләренең гимннарын җырлап, әләмнәрен һәм фәрештәләрен өстә бер көйгә тибрәндерә-тибрәндерә кремльгә таба атлыйлар иде. Колоннаның урта өлеше бина турысына җиткәч, тагы туктадылар. Кая киткән теге атлас ризалы, озын яллы, ямьсез сакаллы поплар? Гафур төшенеп бетермәде, ләкин бөтен урамны тутырган халык арасында алар юк иде инде. Биредә бары баягы исерек сәүдәгәрләр һәм хулиганнар гына иде. Гафур аптыравына каршы, әле бая күзгә чалынмаган татар карагруһчыларын да хәзер абайлады. Алар колоннаның азагына кушылганнар. Барысы диярлек Печән базары әһелләре, араларында мәгълүм Галимҗан Баруди хәзрәт һәм каты реакционер Сәйдәшев бай да күренә иде. Гафурның тагы ачудан куллары кысылып йомарланды, йөзе ут булып яна башлады.

Шәһәр думасы йортында коммуна белән берлектә милициянең беренче бүлекчәсе дә урнашкан иде. Манифестчылар күренгәнгә кадәр үк инде милиционерлар барлык коралларын үзләре белән алып, барысы да ишек төбенә чыгып басканнар иде. Хәзер исә алар тыгыз койма ясап, колонналы дума йортын читләтеп узарга мәҗбүр иттеләр.

Манифестчылар баягыдан да ныграк акыра башладылар. Аларның күзләре тонган, ярсулары тәмам чигенә җиткән иде. Араларыннан берничәсе хәзер үк халык милициясенең корал ташлап таралуын таләп итә башлады. Ул да булмады, баягыдан да катырак итеп бу якка таш һәм каткан балчык кисәкләре атарга тотындылар. Дамперов милиционерлардан алгарак чыгып, кулын күтәрде.

— Гражданнар, гражданнар!.. Әгәр сез хулиганлануыгызны туктатмасагыз, халык милициясе тиешле чарасын күрергә тиеш булачак. Сез яхшы беләсез, полиция дума гласныйларының рөхсәте буенча коралсызландырылды. Шулай ук халык милициясе дә гласныйлар ризалыгы белән төзелде.

Ләкин Дамперовның сүзләренә манифестчылар колак салмадылар, аларның үкерүе тоташ бер гүләүгә әйләнде, коммунарлар ягына ташлар һәм башка нәрсәләр яңгыр кебек ява иде хәзер.

— Әйдәгез, һавага залп бирегез! — диде Дамперов. Милиционерлар бердән револьверлардан һавага атып җибәрделәр.

Моңарчы күкрәкләрен киереп җикеренгән манифестчылар тынып калдылар, аннан җан-фәрманга йөгерешеп таралыштылар. Мәйдан тиз арада бушады, анда бары чуен патша һәйкәле генә һаваланып, ә «мин курыкмыйм» дигәндәй, торып калды.

— Бик батырлардан түгел икән үзләре, — диде Дамперов, ачы көлемсерәп.

Лэкин моның белэн генэ бетэргэ тиеш түгел иде эле бу бэрелеш. Һэм чыннан да, монастырь ягыннан берэм-берэм солдатларның йөгерешүе күренде. Ул да булмады, чылтырап дума өенең өске каттагы бер тэрэзэсе коелып төште. Колак очыннан сызгырып пулялар оча башлады.

— Бинага! — дип кычкырды Дамперов. Булган барлык кеше бина эченэ ташланды. Ишеккэ терэк куйдылар, тиз арада шкафлардан, өстэллэрдэн баррикада ясадылар. Ул да булмады, барысы дэррэү кузгалып өске катка менделэр, тэрэзэ яннарына урнаштылар. Бу вакыт тэрэзэлэрнең барысы да диярлек ватылган иде инде. Гафур өскэ менгэндэ андагы салкын һава аның кызышкан битен сыйпап рэхэтлэндереп жибэргэндэй булды. Ул бер бүлмэдэн икенчесенэ ташланды, үзен кирэксез һэм файдасыз кеше итеп сизде. Чөнки кая кермэсен, барлык тэрэзэлэр турысында кешелэр урнашкан, барысының да кулларында корал иде. Алар жайлы вакыт сагалап торалар, аннан ара-тирэ кулларын сузып револьвердан аска, мэйданга, аталар.

Гафур, зур бүлмэдэ бер тэрэзэдэн икенчесенэ күчеп йөри торгач, Дамперов янына барып чыкты. Сузан студент хэзер ялан баш, аның чэчлэре тузган, йөзендэ ниндидер кырыс тэвэккэллек чагыла иде.

— Револьвер бирегез миңа, — диде Гафур. Урамнан кергэн пуля сызгырып баш очыннан үтте. Икесе дэ бердэн стенага ышыкландылар, Дамперов ялт итеп Гафурга карап алды.

— Корал юк, иптэш.

Дамперов жэһэт кенэ кулын урам якка сузды да, йөзен ямьсез чытып, револьверыннан атып жибэрде.

— Энэ, иптэшлэр яралансалар, ярдэм күрсэтегез! — диде ул Гафурга. Гафур башта яктырып китте. «Чыннан да», — дип уйланды. Лэкин тора-бара аның бу юанычы да кимеде. Нэрсэ эшли ала соң ул? Һич булмаса, чиста марлясы да юк бит.

Дамперов Гафур танымаган ак мыеклы бер эшчегэ:

— Белмим инде, булдырсалар ярый, — дип куйды, сукранып.

Мыеклы жавап кайтармады, аның бары зур тамак төере генэ күтэрелеп төште. Якынча гына булса да Гафур төшенде, болар кемнэндер ярдэм көтэлэр, нэрсэгэдер ышаналар иде.

Ул теге каршы як стена янында хэвефсезрэк икэнлеген, чөнки пулялярның түшэмгэ тиюен чамалап алды. Аннары ул яктан бөтен зал эче дэ ачык күренэ, өстэвенэ, ишек тэ якын, башка бүлмэлэргэ кереп йөрергэ дэ була иде.

Лэкин Гафурга бу бүлмэдэн чыгарга туры килмэде. Уң як кырый тэрэзэ янында тезлэнеп утырган гимназист егет йөрэк өзгеч тавыш белэн кычкырып жибэрде. Аның кулыннан револьверы төшеп китте, сул кулы белэн ул яралы белэген тотты. Гафур егет янына ташланды. Бала гына иде эле ул. Аның борын астында да мыек урынына бала йоннар, йөзе дэ алсу, түгэрэк. Егет кулын тоткан килеш чайкала-чайкала ыңгыраша башлады. Гафур кесэсеннэн чиста яулыгын чыгарды да ашыгып яраны бэйлэргэ керешге. Лэкин кып-кызыл кан һаман ага, егетнең өсбашын һэм идэнне чылата иде. Гафур, нишлэргэ белмичэ, муенындагы галстугын да салды, каты иттереп ярадан өстэрэк егетнең белэген бэйли башлады. Кан ургылып агуыннан туктады.

— Энэ теге якка чыгыгыз, — диде Гафур егеткэ, — тик пуляларыгызны, зинһар, миңа калдырыгыз.

Егет һаман эле ыңгырашып коридорга чыгып киткэч, Гафур кулына канлы револьверны алды. Кинэт аның күңеле чиксез горурлык белэн тулды. Ул бирегэ менэ шуның өчен, кулына корал тотып дошманнарга каршы көрэшү өчен, аның якын дуслары, иптэшлэре яулап алган ирекне яклар өчен килмэгэн идемени? Менэ ул, ниһаять, телэгенэ ирешге.

## Көпчәк күчәреннән чыкты

Чатлыкка җиткәч, Садыйк Гыйззәтуллага атны туктатырга кушты.

— Шундамыни? — диде Шәрифулла.

— Шунда, — диде Садыйк, җиргә сикереп. Фәрхетдин белән Гыйззәтулладан башкалары барысы да арбадан төштеләр. Шәрифулла улы янына килде.

— Улым, Гыйззәтулла, син бая сөйләшкәнчә, атны Сабирҗан абыйларыңа куй инде. Үзең берүк чыгып китәсе булма, берәребезнең килгәнен көт.

Гыйззәтулла борынын тартып кына куйды.

— Бар ышаныч синдә инде, — диде Шәрифулла, Фәрхетдингә борылып, — син, Фәрхетдин, берүк күз-колак була күр. Бала бит...

Күрәсең, Гыйззәтуллага үзе турында шулай кечерәйтеп сөйләү бөтенләй ошамый иде, ул, юрамалый ишетмәмешкә салышып, бик олы сымакланып, тик тормаган атына җикеренеп куйды.

— Борчылма, Шәрифулла абый, борчылма, әйткәнегезнең барысын да үтәрбез, алла боерса, — диде Фәрхетдин.

Садыйк та сүзгә кушылды:

— Фәрхетдин! Ат любой минутта җигеп чыгып китәргә әзер торсын. Арбаны да, сбруйны да ныклап тикшереп куй, төзәтәсе җирен төзәт, алай-болай ватылып, өзелеп калырлык булмасын.

— Була, була, ут йотма, Садыйк абый, барын да җайларбыз, алла боерса.

Ниһаять, әйтеләсе сүзләр әйтелеп, киңәшләр бирелеп бетте. Садыйк Шәрифулланы һәм үзенең энеләрен ияртеп вокзал ягына таба китеп барды. Гыйззәтулла атны кузгатты.

Иж заводыннан Алафузов фабрикасы өчен бер олау ниндидер йөк җибәргәннәр. Әле менә Шәрифуллаларның бистәдән калага килүләре шул әманәтне алып кайту өчен иде. Фәрхетдин күңеле белән үк Иж заводыннан киләчәк әйберләрнең фабрикага һич кирәкле нәрсә булмаганлыгын сизенә иде. Фабрика эшләми, аннан Садыйк үзенең энеләре белән ниемә дип бай малы өчен өтәләнеп йөрсен, ди. Ләкин шулай да Фәрхетдин бу юлы артык курыкмады. Чөнки ул хәзер вакыйгаларның ни рәвештә киткәнлеген бик ачык күрә, аннан башка чарасы да юк бит аның.

Ат Проломный урамының нәкъ уртасыннан бара иде. Йомры мостовой ташлары арбаны дыңгырдатып, барлык буын-сөякләреңне уйната. Ат бераз юыртып барды исә, эчеңә кату чыга. Нәгаләт кенә суксын инде бу кала җирен! Кайда ул гүзәл Зәй буйлары, андагы болыннар, үзәннәр! Кайда ул кошлар сайравы белән тулган чикләвекле куе урманнар!

Монда барысы да ямьсез, барысы да котсыз булып күренә иде Фәрхетдингә. Аны бары бер генә нәрсә юатып, шушы чит җирдә яшәтә. Фәрхетдин кайта-кайта шуның турында уйлый. Ул хәтта сыерның ниндирәк булуын да, аның төсен, мөгезләрен, зурлыгын, көрлеген дә күз алдына ап-ачык итеп китерә ала. Баштa ул ат иде, яшь кенә, ник кына туры байтал иде, аннан соң, акча аттан артып киткәч, ни өчендер, үзе дә белмәстән, Фәрхетдин гел сыер турында уйлана башлады. Ахры, Хафазаны артык нык сагынудандыр. Аның һәр көнне таң беленгәч сыер мөграү белән абзарга чыгуын күрәсе килә бит. Менә ул кызыл сыер мөгри башлады, Фәрхетдиннең Хафазасы иренең куеныннан шуып кына чыга да киенә башлый. Ул инде Фәрхетдинне йоклый дип белә. Йоклар синә Фәрхетдин! Ул барысын да тыңлап, хәтта керфекләре аша күзәтеп тә ята әле. Менә аның җанашы сыеры белән сөйләшә: «И бәгырькәем, и сөтлекәчем, кая, җиленнәреңне әйбәт иттереп җылы су белән җуыйм әле», — ди. Бераздан Хафаза чыжылдатып саварга тотына.

Иртәнге чәйгә ярып пешерелгән кайнар бәрәнге, аннан китереп, җылы куе сөт. Бик тәнгә сихәтле нәмәрсә инде шул яңа сауган сөт!

Инде тәмләп бөтен өй эчләре белән сәке йөзенә утырып чәй эчкәннән соң (ә чәй вакытында, әлбәттә, хуҗа буларак түрдә Фәрхетдин үзе утыра инде), ул туры атын җигеп чыгып китә. Нәдер белән Әлмәт арасындагы юл мондыймы соң, җүләр! Менә ул Фәрхетдинең үзенең туры байталында элдертеп кенә Әлмәт ягына таба бара. Син күр дә мин күр!

Урамда кеше бик сирәк күренә иде. Фәрхетдин белән Гыйззәтулла утырып барган атлы арба гына бөтен урамны яңгырата.

— Туктасана, Гыйззәтулла энем, атыңны кума, нәнәм, безнең алай ашыгыч эш юк ич, — диде Фәрхетдин. Гыйззәтулла, һаман әле олы кеше булырга тырышып, тамак төбе беләнрәк атына бер кычкыргач, Фәрхетдин тагы үзенең татлы уйларына бирелде. Хәзер алар, бер җайга тирбәлә-тирбәлә, атның дагалы тояклары чыгарган чалт-чолтны тыңлап, сүзсез генә баралар.

«Рәхмәт инде әйбәт кешеләргә, — дип уйлады Фәрхетдин нечкә күңелләләнеп китеп, — эшкә урнаштырдылар, ярдәм иттеләр». Әйе, әгәр шулай аңа яхшылык итмәгән булсалар, ул бу бәхетле минутларга ирешә алмас иде. Ләкин, ни әйтсәң дә, аның үзенең дә тырышлыгы булмады түгел. Ул остаының бер артына, биш алдына төште бит. Күзләренә гепә карап торды, барлык теләгән, әле теләк телгә күчкәнче үк, үтәде: эшкә алданрак килде, соңрак китте. Инде акча бетермәс өчен ул башта ипи, бәрәңге ашап кына җан асрады. Ләкин ярты потлы чүкеч белән унике сәгать кызган тимер табалау Фәрхетдиннең бугазын буып ит сорый иде. Башта акча кызганып, Фәрхетдин тартышып карады, тик чүкеченең тиешеннән йомшак бәрелүен остаының күзләренә карау белән үк тойгач, чигенергә мәҗбүр булды. Алай да хәйләсен тапты, итнең иң арзанлы сортларын, үпкә, бавыр, эчәк, баш-аяк, койрык, шуның ишесен алып туена башлады. Болай ярыйсы, һәрхәлдә, түзәрлек иде. Инде килеп, Фәрхетдин өс-башына да акча тотмады диярлек. Эш вакытында күлмәк кимәде; бердәнбер киндер ыштанга кызган тимер чаткысы тиеп көймәсен өчен, авыр күн алъяпкычны биленнән төшермәде. Барысын эшләде, күлмәк-ыштанын ямау өстенә ямау салып тутырды, тик чыгарып ташламады, чәй-шикәрне әҗәл даруы урынына чеметеп-чеметеп кенә тотты, һәрбер шырпыны икегә, хәтта өчкә телде. Әйе, ул үзенең бөек максатына ирешү өчен ниләр эшләмәде! Барысына барды, мәгәр ходай кушып, инде бер үрелсә, бәхет ишегенең бавыннан эләктереп алачак.

Хәзер көз ае, инде бәрәңгеләр дә казылган, авылда пычагым да эш калмады. Эти карт иртәдән кичкә хәтле чабата тукыр, чыпта ясар, я мич башына менеп кунаклар. Инде озакламый Хафаза белән әни төн ката җеп эрләп утырырлар. Ә миңа нинди эш булсын анда хәзер, шул атнасына бер урманга барып кайту да утын турап керту. Әйдә, булмаса, бу кышны да Казанда уздырыйк, белмәссең, әллә, бәлкем, тагы берәр сыерлык...

Фәрхетдин, кечкенә коңгырт күзләрен кыса төшеп, сәер татлы хыялларга бирелеп барды.

Кинәт арба янтайды, ат туктады. Фәрхетдин чак тотынып өлгерде, юкса мәтәләчәк икән. Арбаның арткы уң як тәгәрмәче күчәреннән чыккан иде. Икесе дә ашыгып арбадан төштеләр. Тәгәрәп китеп, читтә ауган көпчәкне Фәрхетдин алып килде. Тимер күчәрнең чәкүшкәсе сынып төшеп калган икән.

— Нишлибез инде, Фәрхетдин абый? — диде Гыйззәтулла, аптырап. Фәрхетдин, бөеренә таянган хәлдә, башын чайкап сызгырып торды.

— Берәр тимер кисәге тапмый булмый инде, малай.

— Мәле, дилбегәне тот алайса, — диде җитез малай һәм чатыр чабып каршыдагы таш капкадан кереп тә китте.

— Зуррак кадак булса да ярый, — дип кычкырып калды Фәрхетдин.

Гыйззәтулла ишек алдындагы чүплектә тимер кисәге эзләгән арада Фәрхетдин рәхәт гамьсезлектә авыз эченнән генә көй шыңшып, урам күзәтеп торды. Ул шул арада тагы бер Нәдергә кайтып килергә өлгерде, тагы үзенең атын, сыерын күз алдына китерде, үзе белән атка төялеп килгән өч агай-эне Сәгыевләр турында уйланды, инде юлда очрап арбага утырган Гафур белән дә булды, тагы кайтып чәкүшкә турында һәм инде көзнең тәмам килеп житүе, быел беренче карның аерата иртә явуы, авылдагы утын хәлләре турында уйланды, әтисен, әнисен, Хафазасын исенә төшерде...

Ләкин Гыйззәтулла һаман кире кайтмый иде әле. Китте дә батты ут борчасы. Инде булмаса, атны берәр яры бәйләп, тегенең артыннан керергә кирәк дигәндә, Гыйззәтулла ачык таш капкадан килеп чыкты. Ул бер кесә күгәргән тимер-томыр җыйган иде. Нәкъ шул вакытны бик ерактан шыңшуга охшаш сәер бер аваз ишетелде. Дикъкатьләрен жигеп озак кына вакыт тыңлап тордылар. Бик күп кеше җырлый идеме, әллә елый идеме, шайтан белсен! Мәгәр тавыш көчәйгәннән көчәя, димәк, бу якка таба киләләр. Бераздан инде Фәрхетдин ул тавышның җыр икәнлеген дә аңлады. Ниһаять, кызыксыну барын да җиңде. Фәрхетдин дә, Гыйззәтулла да күчәр кайгысын оныттылар.

Манифестчылар хәйран бер тамаша булып күренде аларга. Әнә алар Проломный буйлап урам тутырып бу якка таба киләләр. Гыйззәтулла исе-акылы китеп, арбага менеп басты.

— Нәрсә икән ул, Фәрхетдин абый?

— Шту-ты бик хикмәтле нәмәрсә бу, Гыйззәтулла, — диде Фәрхетдин.

— Карале, карале, теге өйнең тәрәзәләренә таш җибәрәләр.

— Таш?

— Әйе, таш, күреп торам ич.

Фәрхетдин ат алдына чыгып басты. Җыр шыңшуын ара-тирә ямьсез тавышлар, ачы итеп сызгырып җибәрүләр бүлгәли иде. Нидер сизенгәндәй, ат пошкырып куйды.

— Нәрсә икән бу? — диде Гыйззәтулла, тагы кабатлап. Аның кызыксынудан күзләре очкынлана, йөзе алсуланып киткән иде.

— Барып карап килимме, Фәрхетдин абый? — диде ул.

— Юк, — диде Фәрхетдин, — үзләре киләләр бит, күрербез. Бу эрвәлүтсияне шулай ясамый торганнардыр ич.

— Тукта, поплар да бар түгелме соң? Кара, Фәрхетдин абый дим, алар бит патша сурәте күтәргәннәр. Карале, карале, анда мулла абзый да бар.

Бераз шомлы, ләкин шулай да бик сәер иде. Фәрхетдин никадәр генә шүрләмәсен, кызыксыну аңа барыбер урыныннан кузгалырга ирек бирмәде.

Кинәт манифестчыларның берсе шартлатып һавага револьвердан атып җибәрде. Сискәнеп киттеләр. Ат колакларын шәмрәйтте, тагы да хәтәррәк итеп пошкырып куйды. Бу арада манифестчылар ташкыны бөтенләй аерым йөзләрне дә танырлык булып якынлашты. Хәзер акырыну, сызгыру тавышлары алда баручыларның «Боже, царя храни»ны җырлауларын бөтенләй күмеп киткән иде.

Колонна сул кул яктагы ике катлы таш йорт янына килеп житте дә тукталып калды. Араларыннан кемнәрдер тамак ертылырлык тавыш белән: «Бей жидов! Бей студентов!» — дип кычкырып җибәрде. Фәрхетдин белә иде: бу ике катлы таш өйнең астында ап-ак сакаллы карт яһүд сәүдә итә. Фәрхетдиннең шул кибеткә кереп, андагы искиткеч хикмәтле пирожныйларга, тортларга, аннан тагы әллә нинди тәмле сыйнигъмәтләргә төкәлеп, авызына сулар килгәнче йөргәне бар иде. Хәзер теге халык менә шул кибет янына тукталды. Ул да булмады, кибетнең

ишектән дә зуррак тәрәзәләре чалтырап ватыла башлады. Бер төркем кеше тәрәзә аша эчкә ташланды. Фәрхетдин тышка бәрея чыгардай итеп йөрәге тибүен тойды. Нишлиләр болар, нигә шулай итәләр? Беразлан тәрәзә уентысыннан кешеләр төянеп урамга чыга башладылар. Аларның кулында ниндидер төргәкләр, тартмалар, кесәләрендә шешәләр иде. «Әллә миңа да...» — дип уйланды Фәрхетдин. Ләкин телəген күңеленнән әйтеп бетерергә дә өлгермәде, кинәт тагы каты тавышлану башланды. Өске катның тәрәзәсенә таш җибәрде берсе. Котырынган кешеләр, йөгерешеп, ишек алдына ташландылар. Тәгаен, хәзер алар өске катка меңәләр иде. Чөнки ватык тәрәзә аша хатын-кыз чәрелдәве, үлем ачысы белән акырган бала тавышы ишетелде. Гыйззәтулла, куркуыннан нишләргә белмичә, арбадан төшеп, Фәрхетдингә сыенды. Хәзер урамга теге ватык тәрәзәдән актарылып ташланган мендәр мамыгы оча иде. Өйгә кергән кешеләрнең анданиләрдер җимерүе, кемнәрнедер кыйнавы, көчләве ачык иде. Ниһаять, аларның каты тавышланып чыгып килгәне күренде. Ап-ак сакаллы картны өстериләр иде алар. Фәрхетдин таныды. Кондитер магазинының хуҗасы карт яһүд үзе иде бу. Фәрхетдин аның кибет кассасында утырганын күргән иде. Ул бик мәһабәт, сакалны матур итеп икегә тарап җибәргән, алтын күзлек кигән һәм күргәч истә калырлык бер кыяфәттәге кеше иде. Хәзер ул эчке күлмәктән һәм ялан аяк. Фәрхетдин дә, Гыйззәтулла да бер-берсенә карашып алдылар. Гыйззәтулланың зур кара күзләренә әйтеп бетергесез дәһшәт тулды. Тынычландырырга теләгәндәй, Фәрхетдин малайны кочаклап алды.

Яһүд картын халык арасына этеп кертеп җибәрделәр, хәзер ул күренми иде. Аның тавышы да ишетелмәде. Бары кыргыйларча аңа сугу, типкәләү һәм ухылдау тавышлары гына бирегә килеп житә иде. Әйе, ул һушыннан язды булса кирәк. Бер мәл тукталып тордылар. Аннары колонна кузгалып бу якка килә башлады. Ат куркып чигенде. Ул, юл бирергә теләгәндәй, кинәт арбаны сөйрәп тротуарга ук чыкты. Тәгәрмәч тагы кучәреннән ычкынып җиргә ауды, ат тукталып тагы пошкыра башлады.

Ә колонна бөтенләй якынлашкан иде инде. Менә ул атлас ризалар кигән кара сакаллы поплар, пенснелы, котелоклы, затлы киенгән ниндидер әфәнделәр. Алар артыннан картузлы, бөрмә билле бишмәт кигән көрәк сакаллы сәүдәгәрләр, итчеләр, тиречеләр. Ә тагы да арттарак исерекләр. Менә шулар инде теге яһүд бабайны бернинди гаепсезгә изеп, үтереп киттеләр. Әнә алар баралар. Аларның атлаулары күңелгә шом сала. Әйтерсең лә, алар синең йөрәгеңне таптап узалар. Фәрхетдин никадәр батырланырга тырышмасын, тез буыннарының калтыравын тойды. Бик куркыныч иде. Кинәт Гыйззәтулла Фәрхетдиннән ычкынды да арба артына барып посты.

— Әй, татарчонок, нигә качасың? — диде якыннан узучы бер кеше. Икенчесе, ат турысына җиткәч:

— Җәмәгать! Карагыз әле, карагыз! — дип кычкырды. Ул кып-кызыл битле, тәгаен кызмача иде. — Бу бит миңа таныш! Менә ант итеп әйтәм, ялгышсам, кулым корысын! Менә шушы ат белән инде теге көнне полиция коралларын ташыдылар алар.

— Кем, кем ташыды? — диде берсе.

— Менә шушы малай, татарчонок ташыды. Шул ат, валлаһи газим, шул ат. Мин аның атасын да беләм әле.

Кешеләр, колоннадан чыгып, кычкырына-кычкырына атка таба килә башладылар. Күзләрен кан баскан иде аларның. Алар хәзер теләсә нинди ерткычлык ясарга әзер торалар иде.

— Ул берни дә эшләмәде, ул әле малинки, — диде Фәрхетдин. Ул туктатырга теләп төркемнең каршысына чыкты. Ләкин тротуар буйлап чаба башлаган Гыйззәтулланы котырынган кешеләр куып җиттеләр дә

күз ачып йомганчы урам ташына атып бәрделәр. Гыйззәтулланың кара матур күзләрендә хәзер үлем дәһшәте, ә йөзе кәгазьдәй агарган иде.

Фәрхетдин аны коткару өчен тагы төркем өстенә ташланды. Ләкин өлгермәде, ниндидер явыз, рәхимсез кеше җирдә яткан Гыйззәтулланың битенә тибеп җибәрде. Фәрхетдиннең шашынган күзләренә чагылып калды: Гыйззәтулланың төмрәеп торган тулы матур бите ертылып китте, шарлап кып-кызыл кан ага башлады. Фәрхетдин, үз-үзен белмәстән, җирдә аунап яткан көпчәккә иелде, аны алып төркем өстенә атты. Акырышып тирә-юньгә ташландылар. Ләкин тиз айнудылар. Кайсысыдыр арттан килеп Фәрхетдиннең башына таяк белән сукты. Фәрхетдин күзләрен йомды һәм хәлсезләнеп җиргә ауды. Ләкин ул һушыннан язмаган иде. Үз өстенә ябырылып ташланган кешеләрне ачык күрә иде. Алар хәзер Фәрхетдиннән үчләрен алалар, аның эчләренә, аякларына, күкрәгенә тибәләр иде. Фәрхетдин күреп ятты: аның тирәсендә халык ишәйгәннән ишәя барды. Гыйззәтулла хәзер кемнәрнеңдер аяк астында тапталып, изелеп ята иде. Фәрхетдин куллары белән йөзен капларга тырышты. Ләкин ирек бирмәделәр. «Чү, бу ни бу?! Әллә күземә күренәме?» — дип уйлады Фәрхетдин. Халык арасыннан аңа таныш йөз чагылып китте. Бу йөзне ул бик яхшы хәтерли ич. Бу бит теге, Фәрхетдин әле җиңгәчиләрдә бер тинтәк исерекне кыйнаганда афәрин дип үзен мактаган, аннан бергәләп полициягә эләккән кеше. Ялт итеп өмет чаткысы туды. Фәрхетдин, булган көчен җыеп, ялварып аңа кычкырды.

— Абый җаным, коткар безне, зинһар, алла хакы өчен коткар, син дә бит мөселман баласы!

Фәрхетдиннең таныган кешесе Җәгъфәр иде. Тиздән Фәрхетдин аңын җуйды.

Фәрхетдин больницада гына күзләрен ачты. Башта ни булганны, үзенең монда нинди сәбәпләр аркасында килеп эләккәнлеген аңламыйча ятты. Ләкин зиһене яктыргач, ул булган хәлләрнең барысын инәсеннән-җебенә кадәр хәтерләде.

«Гыйззәтулла!» — дигән сүз аның башына китереп суккандай булды. Ул кемне булса да күрергә һәм сорарга теләп башын борырга тырышты, ләкин бу мөмкин түгел иде, аның аяк-кул һәм башы бәйләүле иде. Ул үзен калып эченә тыгылып куелгандай сизә иде. Фәрхетдин күк гөмбәзе кебек биек түшәмгә күзләрен текәп кычкырырга тотынды. Әмма бусы да барып чыкмады. Кычкыру түгел, ә ниндидер ыңгырашу гына ишетелде.

— Абыйлар, апалар, әйтегезче, зинһар өчен,— диде Фәрхетдин, барлык көчен җыеп, — әйтегезче...

Ул җөмләсен тәгәлләп бетерә алмады, аның янына ак халатлы бер рус хатыны килде.

— Нихәл, нәрсә кирәк?

Фәрхетдин русча аңлатырга сүзләр эзләп ятты.

— Әйт, — диде ул, ниһаять, — малай, бәләкәй малай... Гыйззәтулла кая? Исәнме ул?

Ул арада теге санитарка янына икенчесе килеп җитте. Алар үзара нидер бик кызу-кызу сөйләшеп алдылар. Бераздан Фәрхетдин башта килгән хатынның сүзләрен ишетте.

— Малай үлгән, — диде хатын, — җанын ходайга биргән, теге дөньяга киткән.

Фәрхетдин кычкырып елап җибәрде. Аның бөтен битен яшь тутырды, күз яше авызына керә, марля астына үтә, биттәге, баштагы яраларны әчеттерә иде. Маржа байтак кына вакыт башын чайкап Фәрхетдингә карап торды.

Ә Фәрхетдиннең күз алдыннан Гыйззәтулла һаман китмәде. Шомырт күзле, житез, уңган, төмрәеп тора торган малай иде ул. Фәрхетдин баланың үлем алдыннан кичергән азапларын тойды, йөрәге телгәләнде.

тагы үксеп, тагы битендәге яраларын әчеттереп еларга тотынды. Әйе, ниндидер кабахәт кешеләр һич сәбәпсез-нисез Гыйззәтулланы үтерделәр. Ул жәл, ләкин аның атасы Шәрифулла да жәл. Фәрхетдин бит картның төпчеген ничек яратканын белә иде. Хәзер Шәрифулла абзый да, аның хатыны Маһитап апа да, тагы Гыйззәтулланың башка чыккан абыйлары да үксеп-үксеп елыйлардыр. Фәрхетдиннең күңеле тагы ташып китте, ул, тагы тыела алмыйча, бу юлы инде тавышсыз гына үксергә тотынды. Я хода, ни арада булды соң әле бу эш, төш кебек бит, төш кебек. Һай, Фәрхетдин хәзер үк үзенең Нәдеренә кайтып китәр иде. Бер генә минут та бу бәхетсез урында яшәмәс иде. Бер генә минут та мондагы гарьлекләргә түзеп тормас иде. Ләкин хәзергә мондый мөмкинлек юк иде, Фәрхетдин, биләүдәге бала кебек, хәрәкәтсез ята иде.

«Бер булмаса бер, ходай насыйп итсә, терелермен әле», дип юанды ул. Шушы минутта аның кинәт күкрәгеп капшап карыйсы килде. Бөтен кебек итеп беркайчан да үзеннән калдырмыйча муенына асып йөри торган акчаларын барлыйсы килде. Сул кулы аның авыр яралы, әмма сынмаган иде. Фәрхетдин, авыртуына йөзен чытып, марлялар арасыннан чыгып торган тупас бармакларын күкрәгенә якынлаштырды. Ул ыңгыраша-ыңгыраша бармакларын хәрәкәтләндереп, күкрәк турысын капмалый башлады. Ләкин анда авыртудан башка берни дә юк иде. Кинәт аның исенә акча тегелгән чүпрәкнең муенга асылынган икәнлеге төште. Тик бинт араларына бармак кертеп, никадәр эзләнмәсен, берни дә тапмады. Әле дәһшәт якынлашса да, өмет Фәрхетдинне алай ташлап ук бетермәгән иде. Аны чишендергәннәр бит, шул чагында акчасын да алып җыеп куйганнардыр. Фәрхетдин кычкырып тагы теге санитарканы чакыра башлады. Санитарка килгәч, ашыга-ашыга үзенең акчасы турында аңлата башлады. Үзе сөйләде, үзе марҗаның күзләренә карап, өметләнеп ятты. Бая хәвефкә төшергән дәһшәт хәзер котырып килгән паровоздай кызу якынлаша иде. Юантык, түм-түгәрәк битле санитарка кинәт катгый рәвештә башын селкеде дә:

— Юк, бернинди акчаң юк иде синең, — диде. — Сине арба белән китерделәр. Сине чишендереп, юындырып, операция өстәленә салганда мин дә бар идем. Тик, алла шаһит, синең бернинди акчаң юк иде.

— Кемнәр китерде соң мине? — диде Фәрхетдин, өметнең соңгы җепләренә ябышып.

— Полицейский чиннәр, — диде хатын.

Фәрхетдин күкрәгеннән ургылып чыккан сулышка «Аһ» дип куйды. Менә кайчан ул дәһшәт Фәрхетдинне шытырдатып изеп киткән иде! Егет бер мәл аңын югалтып өнсез ятты. Аның алдында хәзер төпсез бушлыктан башка берни дә юк иде.

## Юк, бетмәде әле

Төнге уннарда буран тына төште. Хөсәеннәр атка утырып Балык базарына таба юнәлгәндә тирә-якта гаҗәп тирән тынлык урнашкан, шәһәр тулган ай нурларында коена иде. Хөсәен сагаеп, дикъкать белән урамнарны күзәтеп барды. Кучерда утыручы Гыйльфан исә әледән-әле дилбегә кагып, я чөңгереп атны ашыктыра. Ул, чын извозчик кебек, башына зур кучер бүреге, өстенә кызыл кушаклы тун кигән. Хөсәен белән янәшә арка терәп утырган күзлекле рус студенты дәшми-тынмый нидер уйланып бара. Көн салкын булуга карамастан, ул бик җиңел киенгән. Ахры, җылырак киеме юктыр.

Менә алар Николаевский бакча яныннан да уздылар. Бакыр бабай бакчасына җитеп, Арча кырына таба борылу белән, каршыга искән ачы җил битләрне өшетеп җибәрде. Хөсәен яка ярыгыннан гына

абайлады: яннан алты олау печән йөге узды. Берәр алпавытныкы микән, әллә сатар өчен китерәләрме? Хөсәен якасын ача төшеп, күз салды. Татарлар икән. Алгы ат янында икәвесе бара. Колак чите белән генә Хөсәен:

— Безне куцдырыр микән... үләт кыргыры, — дигән сүзләрен ишетеп калды.

Ат зур печән олауларының күләгәләреннән өркә төште, ахры, озын аякларын еш-еш алга ташлап, бик кызу юырта башлады. Хөсәен, ат тоягыннан очкан кардан сакланып, тагы якасын күтәрде. Башкарылачак эш турында уйланып барды.

Үтә мөһим бер эш иде бу. Әле узган айның ахырында — 30 нчы ноябрьда — жандармнар РСДРПның Попова гора урамындагы типографиясен тар-мар иттеләр. Хәзер исә тиз генә ашыгыч чаралар күреп, аның урынына икенчесен оештырырга кирәк иде. Бернинә төркем хәрәкәт итә, шуларның берсе Хөсәен төркеме.

Типография эшчеләре белән күптән сөйләшенгән, шрифтлар алып чыгу мәсьәләсе күптән барлык ваклыкларына кадәр уйланылган иде инде. Бүген исә хәлиткеч көн, атна буена җыелган шрифтны бүген Хөсәен алып кайтырга тиеш.

— Полиция, — диде Гыйльфан, дилбегәне иплэбрәк тотып.

Хөсәен игътибарын җигә төште.

Атлы өч полицейский, аргамакларын юрттырып, яннан уздылар. Алар Хөсәен янындагы студентка күзләрен акайтып карадылар. Ләкин бик бай сыман киемле Хөсәен һәм җиренә җиткереп, формасын китереп барган кучер шик күзгатмады булса кирәк.

— Патруль, — диде студент, алар узгач.

— Нәгаләтләр, — дип куйды Гыйльфан.

Бераз тынып барганнан соң Гыйльфан тагы сүзгә килде:

— Кичә көн озын завод тирәсендә буталдылар.

— Боларымы, жандармнармы? — дип сорады студент.

— Шул охранкадан инде. Барысы да бер чыбыктан сөрелгән. Киемнәрне гражданскийны кигәннәр дә, танымыйлар дип уйлыйлар, ахры, сафсаталар!

Атны сулга борырга кушты студент.

— Туры барыргамы? — дип сорады Гыйльфан, борылгач.

— Туп-туры, — диде теге, — борыласы булса әйтермен.

Хөсәен бу яшь егетне якыннан белми иде. Аларны әле бүген генә Саммер таныштырды. Егет Хөсәенгә явка урынын күрсәтергә тиеш. Хөсәен белән Гыйльфанның бурычы — шрифтларны алып яшереп кую. Ат тая-тая Казан елгасына таба үрдән түбән төшә башлады, бер урында чак кына егылып китмәде.

— Дагасызмы әллә? — диде Хөсәен.

— Дагалы да, муены астына килгере, күрәсең, шомаргандыр, — дип куйды Гыйльфан.

Алай да үрдән исән-сау төшеп җиттеләр. Әле бит шуннан җанфәрманга чаптырып менәсе дә бар.

— Унга, — диде студент. — Мена шушы капка төбенә туктагыз.

Ул, ат туктар-туктамас, чанадан балалар җитезлеге белән сикереп төште дә, туңган җилкәләрен сикертә-сикертә, ике катлы иске агач өйнең кече капкасыннан кереп югалды. Бер минут вакыт узмагандыр, өйнең өске катыннан каударланып ике кеше төште. Аларның аркаларында авыр әйбер салынган капчыклар — шрифтлар иде. Алар, ни Хөсәенгә, ни Гыйльфанга юньләп карамастан, йөкләрен чанага ташладылар. Хөсәен чак шәйләп өлгерде: чыккан кешеләрнең берсе олы яшьтә, төптән юан, нык, таза һәм кыяфәте белән эшчегә охшаган бер агай иде. Йөген чанага салу белән ул тезгенне тотып торучы Хөсәенгә якынлашты. Кулын кысты да, бераз серлерәк тон белән:

— Бер генә минут та тоткарланмыйча, хәзер үк ычкыныгыз, — диде. — Берничә минуттан килеп җитәчәкләр.

— Шулаймы? — диде Хөсәен, тезгенне ычкындырып. Ат урынында тыныч кына тора торган хайван түгел иде. Ул шул ук минутта кузгалып та китте.

— Карагыз, тегендә дә сак булыгыз, — дип калды эшче.

Хөсәен барысын да аңлады. «Рәхмәт», диде, чанага ташланып. Димәк, хәвеф-хәтәр борын төбендә генә.

— Кайсы яктан, килгән юлданмы? — дип сорады Гыйльфан.

— Казанкага таба, Казанкага таба, — диде Хөсәен, шрифтларны козла астына яшереп. Ат та, сизенгән кебек, барлык көченә элдертеп үрдән аска төшеп китте. Колакка арттан кинәт ниндидер ят тавышлар ишетелә башлады.

— Кызулата төш, — диде Хөсәен.

Гыйльфан ачу белән атка сукты. Ату тавышы ишетелде. Хөсәеннәр кузгалып китү белән үк полиция килеп җиткәнлеге ачык иде. Ачы җил колакларны әчеттерә, изүгә, яка асларына кар керә. Хөсәен Гыйльфанның:

— Тот менә капчыгыңны! — дигән сүзләрен ишетеп калды. Иелгән килеш артына борылып карады. Алар инде хәзер Казан елгасы буйлап Арча кырына таба очалар иде. Тирә-юньдә күгелҗем-кара бушлыктан башка берни дә күренми. Иөрәк дөп-дөп тибә. Шулай да Хөсәен эшнең уңышлы чыгуына бик шат. Ул үзенә юл күрсәткән студент турында уйлап алды. Кулга эләкмәделәр микән? Хәер, эләкмәсләр, җинаятьне исбат итәрлек әйбер китте бит инде. Ул якаларын торгызып, тагы тирә-юньне яка ярыгыннан күзәтә башлады.

Алар юл буенча үзара сөйләшмәделәр диярлек. Болай да каршы искән ачы җил бит очларын, борынны әчеттерә иде. Гыйльфан кибәндәй зур бүреген батырып кигән, якасын күтәреп козлада яны белән утырган, Хөсәен дә кырын яткан.

Алар, семинария турысында атны борып, шәһәргә күтәрелә башладылар. Хөсәен кая барасын Гыйльфанга аңлатырга кереште. Тиздән алар ике катлы зур таш пулат янына җиттеләр. Хөсәен шунда атны туктатырга кушты.

— Тукта, бу генерал өе түгелме соң? — диде Гыйльфан, аптырып төшеп.

— Шаулама, — диде Хөсәен, мыек астыннан гына көлемсерәп, — атыңны парадный турысына тарттыр.

Хөсәен, төшеп, парадный звоногын шалтыратты. Күрәсең, аларның алдан ук сөйләшенгән билгеләре бар иде. Тиз арада парадный ишеге ачылып китте.

— Булыш, — диде Хөсәен, бер капчыкны үзе күтәреп. Капчыкның икенчесен Гыйльфан алды. Алар ашыгып ишектән керделәр. Капчыкларны баскыч алдына куйгач, Хөсәен: — Хәзер үк кайт инде син, — диде. — Хәерле юл!

Гыйльфан чыгып атына утырды. Ишек тагы ябылды. Болар шулкадәр тиз башкарылды, берничә секундтан соң зур таш йорт алды тагы тирән тынлыкта иде инде.

Хөсәен баскыч өстендә мех киемен җилкәсенә генә салган бер рус кызын очратты. Кызның кулында фонарь, ул Хөсәенне каршыларга чыккан иде. Хөсәен бу чибәр блондинка белән исәнләшеп аның кулын кысты. Әйе, бу отставкадагы генералның кече кызы Елизавета Ивановнаны Хөсәен күптән белә. Генерал хатыны белән Казанның салкын кышы узганны Италиядә көткән арада аларның кызлары шулай хәтәр эшләр белән шөгыльләнә иде.

Хөсәен:

— Кая куябыз? — дип сорады.

Тиздән ул кургашын шрифтлар тутырылган капчыкларны өскә ташый башлады. Борылмалы баскыч тар һәм, әле житмәсә, үтә вак иде. Елизавета Ивановнаның кулындагы фонаре юлны яктыртмаса, сөртенмичә менеп тә булмас иде. Шулай да алар өстәге өй алды сыман мәйданчыкка менеп життеләр һәм кыз стена буендагы сандыкны күрсәтте.

— Шушында салыгыз.

Хөсәен икенче капчыкны да алып менде, анысын да әйбәтләп сандыкка салды. Өстенә ниндидер иске киемнәр, тетелеп беткән китаплар салдылар. Хөсәен, тирән көрсенеп, өс-башын рәткә кертә башлады. Ул эшнең уңышлы тәгәлләнүенә чиксез шат иде. Киемнәрен каккалагач:

— Миңа китәргә дә була инде, эш башкарылды, — диде ул.

— Туктагыз, — диде Елизавета Ивановна, житдиләнеп, — минем сезгә әйтәсе бик мөһим сүзем бар әле.

Хөсәен, аптырый төшеп, кызның соры күзләренә, акябык йөзенә текәлде.

— Әле генә билгеле булды, Хөсәен иптәш, — диде Елизавета Ивановна, — барлык комитет членнарының өендә тентү бара.

Хөсәен кинәт житдиләнеп башын күтәрде.

— Ничек тентү? Димәк, барысы да жимерелде дигән сүз?

Кыз жавап кайтармады, бары әйтелгәннәрне икърар иткәндәй, күзләрен генә аска төбәде.

— Фу, шайтан алгыры, — диде Хөсәен, борчылып, — менә-менә кораллы восстание башланырга тиеш иде бит...

— Шулай шул! — кыз тагы бераз тынып торды, — менә нәрсә, Хөсәен иптәш, сезгә өегезгә кайтырга ярамый. Барлык комитет членнарында тентү. Димәк, сездә дә...

— Шулайдыр инде, — диде Хөсәен. Аның күз алдына өендәге яшерелмичә калдырылган китаплары килде. Әйе, әнисе һәм Хәдичә өчен авыр иде тагы. Хөсәен полиция чиннарының өйне астын өскә китерәчәкләрен, тупас мөгамәлә кылачакларын, әнисенең һичшиксез авыруга сабышачагын башыннан кичерде. Кабахәтләр, ничек көтмәгәндә... Менә ул хаин ак патшаның күз буяу өчен чыгарган манифестлары, матбугат иреге турындагы буш сүзләре. Хөсәен кызга карап алды. Кыз исә тәмам туңып беткән иде. Хөсәенне бу хәл уятып жибәргәндәй булды.

— Әйе, әйе, мин аңлыйм. Бу сатлык жаннарның эше булса кирәк. Ә бәлки, үзебезнең дә житәрлек сабак алмавыбыздандыр, — диде ул.

— Сез бүген төнегезне бирелә уздыра аласыз, — диде кыз.

— Юк, рәхмәт, — диде Хөсәен, — мин кунар жир табармын.

Хөсәен саубуллашырга жыенып кулын сузды. Ихтимал, бик озаккадыр. Ләкин кызның әйтәсе сүзләре бетмәгән иде әле. Ул Хөсәен белән саубуллашырга ашыкмады.

— Керик әле, — диде, елмая төшеп, — сезне минем бер кунагым күрергә тели.

Хөсәен сәерсенеп кыз артыннан өйгә керде. Колонналар һәм һәйкәлчекләр белән бизәлгән жиһазлы иркен бүлмәдә аны агара башлаган бөдрә чәчле, күкрәк авызына житкән куе сакаллы, кара сюртуклы таза бер кеше каршылады. Хөсәен аны күрү белән яктырып китте. Елизавета Ивановнаның кунак дигәне тукучы революционер Ефим Панкратьевич Табейкин булып чыкты. Аның Вологда якларында сөргендә икәнлеген Хөсәен яхшы белә иде. «Качып кайткан» дигән фикер башыннан узды.

— Кайттыңмы, «әткәй»? — диде ул, аңа таба атлап.

— Менә күргәнеңчә, — диде Табейкин, Хөсәенне кочып. Алар икесе дә елмаешып бер-беренә карап тордылар.

— Ах, сез таныш та икәнсез, — диде туташ.

— О, без күптәнге дуслар, — диде Табейкин. — Хөсәен Алафузов заводының үз кешесе бит инде дигәндәй....

Хөсәеннең Ефимны күрмәгәненә елдан ашкан иде инде. Ябыга төшкән, бөдрә куе чәчендә чал төкләре тагы да күбәйгән.

— Ничек соң, «эткәй», ни рәвештә? — дип сорады Хөсәен.

— Амнистия буенча, — диде Ефим. — Галиҗәнап патша хәзрәтләренең шәфкате аркасында.

Ефим яңгыратып көлеп җибәрде.

— Шәфкатьле булып кылануы да ярап куя икән, ә? — диде Хөсәен.

Табейкин җитдиләнеп:

— Мин кайттым, ә Василий белән Иванны алып киткәннәр, — диде.

Сүз Табейкинның уллары турында барганлыгын Хөсәен яхшы аңлый иде. Алар да әтиләре эзеннән баралар иде. Алар да тик ятмыйлар иде. Аларның шушы көннәрдә кулга алынуын ишеткән иде шул Хөсәен.

— Шулай шул, — диде ул, күңелсезләнеп, — кабахәтләр тагы котырына башладылар. Безнең Садыйк та, аның ике энесе дә кулда бит.

Алар йомшак кәнәфиләргә утырыштылар.

— Мин әле бүген генә иртәнге якта кайтып төштем, — диде Ефим,— әле менә Елизавета Ивановнага бәйләнешләр яңарту өчен килешем.

«Алай да, тынгысыз җан», — дип уйлап куйды Хөсәен.

— Әйдә, сөйлә, — диде Табейкин, — соңгы айларда булган хәлне мин белмим.

Хөсәен Казан партия оешмасының соңгы вакытларда нинди эшләр белән шөгыльләнүен, гомумән Казанның үзендәге һәм аның тирәягындагы вакыйгалар турында сөйли башлады. Унҗиденче октябрь манифестыннан соң либералларның, алар арасыннан аерым кешеләрнең, нишләвен, меньшевикларның төрлечә аяк чалуларын, алар арасыннан шәхсән кемнәрнең нилэр эшләгәнен Хөсәен тезеп китте. Табейкин белергә тиеш иде. Аның шушындый авыр көннәрдә мөмкин кадәр тизрәк эшкә җигелүе бик мөһим иде.

Хөсәен, ниһаять, «Черная сотня»нең инде менә егерме беренче октябрьдан бирле патша сатраплары белән берлектә котырынуын сөйләргә керешге. Егерме беренче октябрь вакыйгалары, дума бинасында коммунарларның патроннары беткәнче гаскәр белән атышуы, губернаторның, әгәр бирелмәсәләр, туплар белән янавы, инде бернечә комитет члeнының, шул җөмләдән Хөсәеннең, Иж заводыннан килергә тиешле корал алырга баруы, ләкин ул коралның меньшевиклар коткысы аркасында килмәве, Казан гарнизонындагы бер генә батальонны да коммунарлар ягына аударып булмавы күз алдыннан узды.

— Соң нишләделәр инде безнекеләр? — диде Ефим.

— Нишләсеннәр, бирелергә мәҗбүр булдылар, — диде Хөсәен, күңелсезләнеп.

— Һәм аларны...

— Дума бинасында комитетның күпчелек члены, бик күп милиция вәкилләре, аерым интеллигентлар, студентлар, эшчеләр булды. Аларның бәрысын да кулга алдылар. Тик бу вакыйга аркасында губернаторның адәм көлкесенә калуы артык ачык булды, күрәсең, аларның барысын да бер ай эчендә төрмәдән чыгарырга мәҗбүр булдылар.

Хөсәен шушы урында дусты Гафур Коләхметовны хәтерләде. Аның күз алдыннан аларның Гафур котылып чыккач очрашулары узды. Төрмә, ихтимал, Гафурның сәламәтлеген тагы да какшата төшкәндер. Ләкин аның каравы Коләхметовның революциягә хиреслеген ул тагы да арттырган иде. Гафур хәзер ныклап язу эшенә керешәчәк. Хөсәен Ефимга егерме беренче октябрь вакыйгаларыннан соң комитетның кораллы күтәрелешкә әзерләнүен, эшче дружиналары кораллландыруын, мастерскойларда, заводларда корал ясатуын сөйли башлады.

Казармаларда солдат арасында эшләүгә аерата күп көч куелган иде.

— Мәскәү комитетыннан корал килде, алар эшчеләргә өләшенде.

Инде менә без барысын да шушы көннәрдә тәгәлләп, хәлиткеч һөҗүмгә кучәргә тиеш идек. Менә, менә шушы көннәрдә,— диде Хөсәен, әрнеп. Аның йөзенә гарьләнү, чиксез ачыну билгеләре чыкты. Ефим, һичбер сүз дәшмәстән, борчылып, сакалын сыпырырга кереште. Әйе, хәл бик-бик авыр икән шул. Әгәр дә полициянең бүгенге һөҗүме җитәкче көчләрнең башына җитсә, тагы чигенергә, тагы хәзерлекне өр-яңадан башларга туры киләчәк. Хөсәен, вакыйгаларны берәм-берәм тезгән хәлдә, кайта-кайта карагруһларның ерткычлыгын сөйләп утырды. Алар һичбер гаепсез кешеләрнең канын койдылар. Вәхшилекнең чиге булмады. Татар белән русны талаштыру дисеңме, яһүд өйләренә погромнар оештырумы, интеллигенциягә каршы дошманлык тудырырга тырышу дисеңме — берсе дә калмады. Рус карагруһларына татар карагруһ вәкилләре иярде. Гөнаһсыз сабый балаларны үтерүгә барып җиттеләр бит. Балык базарында бер студентның эчен ярып, эчәгеләрен таякка чорнап селтәнеп йөрделәр. Тагы бик күп, бик күп кабахәтлекләр ясалды.

Хөсәен шуларны хәтерләде. Ниһаять, ул аякка басты, бирсдә хәвефсез булса да, аның күңеле ашкына, нинди дер яңалык ишетәсе килә, өйдәгеләрнең хәлен тизрәк беләсе килә иде. Алар Ефим белән очрашу урыны билгеләделәр дә Хөсәен китәргә җыенды. Табейкинның халәте шомлы, киеренке иде. Бик ихтимал, әгәр бүгенге һөҗүм комитетны таркатып ташлый калса, Табейкиннарга, Хөсәеннәргә үзәкне яңадан торгызырга туры киләчәк. Әлбәттә, көрәш никадәр авыр булмасын, бер генә минутка да тукталмаячак.

Ефим Хөсәеннең кулын кысты, сак булырга кушты. Хөсәен үз чиратында аңа уңыш теләде. Төнге кунаклар хуҗа кыз белән саубуллаштылар.

Хөсәен ул төнне өенә кайтмады. Яңа бистәдәге таныш приказчикларында кунды. Ә иртәгесен кораллы һөҗүмгә хәзерлек башында торган кешеләрнең барысының да диярлек кулга алынганлыгы мәгълүм булды.

Хәзер Хөсәеннәр капкасы яшерен сак астында. Көнен-төнен аны сагалыйлар. Ничәмә агент Хөсәенне эзли. Хөсәен, бер урыннан икенче урынга күчеп, Казанда һәм Казан тирәсендә көннәрен уздыра башлады. Күп тә узмады, РСДРПның кооптацияләү юлы белән торгызылган һәм тулыландырылган яңа комитеты эшли башлады. Монда инде барысы да яңа кешеләр иде. Комитет үзенең беренче яшерен утырышында ук Хөсәен Казаннан китәргә тиеш дигән карар чыгарды. Чөнки артык нык исәнәләр иде. Җандарм идарәсе һәм полиция Хөсәенне кулга төшерү өчен иң тәҗрибәле кешеләрен җиккән иде. Көннән-көн мәйдан тарайганнан тарая бара иде, башка мөмкинлек калмады.

...Декабрьның егерме тугызында Хәдичә ишек алдында япа-ялгызы яңа юылган керләр элеп йөри иде. Кичкырын чак иде. Капка төбенә пар ат җигелгән артлы чанада ниндидер кешеләр килеп туктады. Ул да булмады, чанадан бер рус төшеп, ишек алдына керде дә туп-туры Хәдичәгә таба килә башлады. Караңгы төшкән булса да, Хәдичә бу кешенең сакаллы бер рус карты икәнлеген абайлады. Аның өстендә иске кара толып, башында колакчынлы йонлач бүрек. Хәдичә кешенең шулай үзенә таба бик кыю якынлашуына аптырап, сагаеп торды. «Әллә Хөсәенемнән бер-бер хәбәр китерәме бу?» — дип уйланды. Тик әлеге кеше тәмам якынлашкач, Хәдичә хәйран калып, өнсез булды. Бу рус карты дип уйлаганы Хөсәен үзе иде. Ул сакал-мыек ябыштырган, парик кигән. Ниһаять, үзен кулга алып, хәзер шатлыгыннан Хөсәеннең муенына ташланырга җыенган Хәдичәгә ул күзләре белән генә елмаеп кисәтүле ишарә ясады.

— Сабыр, сабыр, Хәдичә,— диде әкрен генә.— Безнең күзәтү астында икәнлегебезне онытма.

Хәдичә көчкә тыелып калды. Хөсәенне карашы белән генә сөеп һәм иркәләп тыңлый башлады.

— Барыгыз да исән-саумы, әни исәнме? — дип сорады Хөсәен.
Хәдичә «исән» дигәнне аңлатып баш иде. Кинәт хәтерләп:
— Нәкыя китте, — диде.
— Кая китте?
— Аның егете бар иде бит. Шуның белән китте.
— Тегеләй әйбәт кенә аерылышкансыздыр ич?
— Әлбәттә, үз кызыбыз кебек озаттык.
— Теге көнне бик авыр булмадымы?
Хәдичә тирән итеп көрсенде дә:
— Әнинең йөрәге бик каты авыртты, — диде. Хөсәен көрсенеп аскы иренен тешләде.
— Сәлам әйт ана, — диде ул, башын күтәреп. — Аңлат. Ул бит барысын да төшенә. Ә мин китәргә мәҗбүр, Хәдичә. Эшләр шулайдан китте. Комитетны тар-мар иттеләр, кабахәтләр!
— Кая китәсең соң син, Хөсәен?
— Әле хәзергә Әлмәт ягына. Аннан күз күрер.
Хәдичәнең аскы ирене дерелдәп куйды.
— Ә озаккамы?
— Ничек әйтим, — Хөсәен уйланып торды, — һавалар ничегрәк булыр бит.
— Хөсәен, — диде Хәдичә, ялвару тоны белән, — зинһар дим, үзеңне сакла!
Хөсәен аның сүзен бүлде.
— Менә мин ни турында сөйләшмәкче идем, Хәдичә, — диде ул. — Әгәр миңа читтә озак торырга туры килсә, син яныма килерсеңме?
— Бу нинди сорау инде, Хөсәен!
— Юк, син уйлап әйт, кадерлем. Безнең тормыш бөтенләй башка рәвештә булачак анда. Без, бәлки, бик авыр шартларда яшәрбез. Мин моны сорамый китә алмыйм.
Хәдичәнең аскы ирене ныграк дерелди башлады.
— Ни сөйлисең, Хөсәен?! Мин, синең белән булсам, барысына да риза.
— Рәхмәт, Хәдичә. Мин шулай әйтерсең дип уйлаган да идем.
Хөсәен урыныннан кузгалды. Хәдичә:
— Хуш, җаным, — дип пышылдады.
— Тукта, онытa язганмын, — диде Хөсәен, яңадан борылып, — син Фәрхетдинне беләсеңме?
— Нинди Фәрхетдин?
Хөсәен саран гына елмаеп куйды.
— Әнә теге вакытны безгә керләр чәлдерергә кергән егет.
— Әйе, хәтерлим. Шуннан?
— Ул университет клиникасында ята. Зинһар, шуның хәлен белешсәнә. Әгәр мөмкинлегегез булса, ара-тирә ризык та илтер идең.
— Ярый, Хөсәен.
— Инде тагы бер сүз. Зинһар, сак бул. Аерата Җәгъфәрдән саклан. Ул әле хәзер кайдадыр юкка чыккан.
— Ярый, Хөсәен.
— Безнең бәйләнеш Гыйльфан аша булыр. Аңладыңмы? Син бит аны беләсең. Ул үзе сине очратыр.
Хәдичә баш иде.
— Менә алайса барысы да булды шикелле, — диде Хөсәен, иркен сулап. — Мине озата чыкма. Безне сагалыйлар. Хуш, кадерлем. Сәлам әйт.
Ул кискен рәвештә борылды да капкага юнәлде. Ә берничә минуттан соң аны кучер Лаеш тракты буйлап михнәтләр һәм хәвефләр тулып яткан, ләкин изге озын юлга алып чыгып китте.

*Беренче китап бетте.*

*Гали Хуҗиев*

# Тәрәзәләр таңга карый

*Поэма*

## Зәй өстендә салават күпере

Йөрәгемнән китми поход юлы,
Утлы кыры узган сугышның.
Онытмаска куша вөҗдан моны,
Иминлеге өчен тормышның.

Без — кичәге фронт кешеләре,
Ир башыннан ниләр кичмәгән...
Иманнарнең нинди ишләре соң
Җил-давыллар күреп үсмәгән?!

Кемне чын дус итсәң ут астында,
Ул аерылмас якын дус һаман.
Эссе елны, җәйнең уртасында,
Яңгыр юктан янып сусаган
Җирдәй сусый
Күңеле чын дустыңның
Синең олы күңел хисеңә.
Ерак юлда очар кошчык та бит
Мохтаҗ була үзенең ишенә.

Оча вакыт — сизеп булмаслык,
Якгылыкка илтеп юлдашлык.
Сугыш белән бу көн аралары
Ерак инде... Миңа әле дә
Дусларымның авыр яралары
Сызлый, гүя, күчеп тәнемә.

Узам менә язгы Зәй буеннан,
Бергә атлый солдат танышым.
Аз сүзле ул... Белмим, ни уенда,
Аңлаткандай вөҗдан тавышын, —
Шыгырдавы
Протез аягының
Кабатлана минем йөрәктә:
«Бутама син кабат дөньяларны,
Сугыш, утың тагын көйрәтмә...»

Зәй өстендә яна нур дугасы,
Сузылгандай ерак Иделдән.
«Бу — үзе бер яз һәм җыр дөньясы,
Нур алган ул күпме күңелдән, —
Ди Рахманов, җиргә нығрак басып, —
Ой, үткәннәр кире кайтмасын.
Гел салават күпере торсын ачып
Киләчәккә тормыш капкасын!»

Тоташкандай кырлар офыкларга,
Язгы җилләр иңләп киләләр;
Әйтерсең лә, җирдән орлыклар да
Болай диеп шытып бирәләр:
«Теләмибез, без дә теләмибез
Яшәү белән үлем тартышын.

Өстебездә һәрчак имин кояш
Сибеп торсын
Тормыш яктысын!»
Оча вакыт — сизеп булмаслык,
Яктылыкка итеп юлдашлык...

## Болай интегү үлемнән авыр...

Китмәс күңелдән, китмәс беркайчан
Утларга кергкән ул авыр юллар,
Һәркем йөрәген көйдереп үткән,
Яндырып үткән ул авыр еллар:
Фронтның әле иң кызган чагы,
Иөрәкләр аша гел узган чагы.

Юл ерак әле —
Тынарга түгел...
Кылычлар әле
Кыннарда түгел,
Волоколамск юллары буйлап
Чигенә дошман, зәһәр карышып.
Камалган утка туган туфракның
Һәрбер адымы, һәрбер карышы.

Январь иртәсе салкын томанлы,
Өермәле ут — тоташ ут ява.
Мина, снаряд кыра урманны,
Урталай сынып, наратлар ава.

Урман буенда егылган солдат,
Таңда һөҗүмгә барганда ярсып.
Яралы аның ике бот башы:
Берсендә — пуля,
Берсендә — ярчык.
Иң гадел юлдаш сугыш кырында —
Партбилет — аның йөрәк турында.
Җәелгән каны тирә-ягына,
Дәшә Рахманов, килеп аңына:
«Солдат дусларым, полкташларым,
Сезнең арада шәфкатьле кем бар?
Котылыйм тизрәк шушы бәладән,
Атыгыз мине, атыгыз, зинһар!..
Әйтсә берәрсе: «Юкка сыкрый», — дип,
Җанымны минем карасын ярып.
Яки булмаса, атакага ул
Бер генә тапкыр карасын барып...»
Узды ротасы, калды командир:
«Сезнең арада шәфкатьле кем бар?
Болай интегү
Үлемнән авыр,
Атыгыз мине,
Атыгыз, зинһар!»

## Агымың тирән, тынгысыз агым...

Госпитальдә ул күзләрен ача,
Хәйранга калып, нәкъ сабыйларча:
— Ялгышам бугай, төштер бу, — дисәм,
Шунысы гаҗәп: мин ничек исән?
Түзсә дә кеше түзә икән бит,
Калганмы тәндә канның яртысы?
Моннан соң инде кеше буламмы?
Бу — тормыш белән үлем тартышы.

Әйтә вөҗданым: «Кызганып җаның,
Калма атылып тормыштан читтә,
Иңгә-иң атла ишләрең белән.
Өзелсә әгәр аяк-кулларың,
Ябыш аңарга тешләрең белән.
Ябыш аңарга тешләрең белән;
— Мине тагын бер сынап бак, — диген.
Агымың — тирән,
Тынгысыз агым;
Мине дә берга
Алып ак, — диген.
Очрасын юлда меӊ төрле ташың,
Чоңгылларыңда әйләнмәс башым...»

## Башаклар шавы уята аны

Борчыла солдат, дусларын уйлап;
Узгандай үзе окоплар буйлап,
Тоя ул, гүя, дары исләрен,
Утлы җилләрнең ничек искәнен.
Көтәдер аны һәр полкташы,
Кергәндә тагын һөҗүмгә ярсып.
Яралы аның ике бот башы:
Берсендә — пуля,
Берсендә — ярчык.
Төшә исенә һәлак булганнар,
Чыккандай йөреп бөтен җир йөзен.
«Үләләр күзен терелер йома,
Үләләр ача терелар күзен...»

Тирән су асты чоңгылы аша
Узган агымдай, үтәләр көннәр,
Чыккандай агым өскә ургылып,
Тыелу белмәс тирән моң булып,
Солдат башларын уйга күмеп тә,
Моңга күмеп тә китәләр көннәр.
Хәтерли һади туган якларын,
Язгы Зәенең тулып акканын.
Башаклар шавы кера төшенә,
Моң-ялкын өстәп сагыну хисенә,

Ачып җиһанга тормыш капкасын,
Сызылып туа яңа көн таңы.
Һәр туган таңда, тизрәк савык, дип,
Башаклар шавы
Уята аны.
Уята аны башаклар шавы,
Һәм күңеле аның ямтырып китә.
Көтә еракта газиз уллары,
Еракта аны сөйгәне көтә.

Алты күз көтә... Яшьле алты күз,
Әйтерсең, һәр көн төбәлә аңа.
Очрашсын алар миндә дигәндәй,
Ерак офыкта таң чулпан яна...

Савыга солдат, баса аякка;
Оча хыялы ерак-еракка.
Күңел күзләрен имин тормышка
Беренче тапкыр ача кебек ул.
Туган җиренә, сабый баладай,
Беренче тапкыр баса кебек ул;

Беренче тапкыр баса кебек ул,
Ике күзенә яшьләре тулып:
«Их, тама алсам туган җиремә
Язгы болыттан бер тамчы булып...»

## Геркулес кебек

Инде ул менә Әлмәт ягында:
Кушылды тагын тынмас агымга.

Аяк астында — туган туфрагы;
«Калсын яңадан уелып эзең».
Һәм ул бүген дә җирдән аерылмас
Геркулес кебек хис итә үзен.

Авылдашлары әйтәләр аңа:
«Күрәсең, хәлләр җиңелдән түгел.
Тормыш арбасын тартыйк бергәләп,
Син, Һади туган, иң төпкә җигел!»
Таныш аларга кыен юл башы:
Яшь егет Һади — заман юлдашы
Авылның кая борылуын белгән;
Чабата сатып алган колыннын
Колхозга башлап җитәкләп килгән.
Җаныдай күреп туган туфрагын,
Сөргән ул, чәчкән, урган урагын...

«Мин хәзер, дуслар, тик ярты кеше,
Бирегез эшне хәлемә карап.
Колхоз, туганнар, тик арба түгел,
Колхоз, туганнар, ул — олы кораб».
«Шуның өчен дә сорыйбыз синнән,
Авыр елларда бергә юл ярыйк».
«Халык ышангач, райком да әйткәч,
Ярый алайса, тырышып карыйк»,

## Миңа кыен эш бирегез

Кыена авыл кырга чыгарга,
Уртак ышаныч һәм өмет белән.
Теләмим, диеп, мин дә соңларга,
Агач аяклы яшь егет килә.
Сугышта инде каиын коеп та,
Чыкмаган юньләп әле мыек та.
Рәис аңа ачык йөзле:
— Йомышың, туган, нидә?
— Һади абый, һич кенә дә
Ятасы килми өйдә.
Миңа кыен эш бирегез,
Миңа кыен эш кирәк.
Фронтта йөргән чактагыдай,
Тынгы белмәсен йөрәк.

Әйтә рәис, көлемсерәп:
— Бик әйбәт синең уйлар.
Болай булгач, синнән, энем,
Шагыйрь дә чыгып куяр...

Егет аңа тапмый җавап,
Оялып аска карый.
— Һади абый, шаяртмагыз!..
— Алайса — бетте, ярый...
Эш дигәндә — була анысы;
Хәзер бит авыр чаклар.
Солдат ирләр урынын алып,
Карарсың, туган, атлар...

## Кырларда булса—илдә дә булыр

Колхоз хәленә керде һәрбер йорт,
Орлыкка диеп бирде һәрбер йорт,
Үзе капмыйча, соңгы бөртеген.
«Ел тукландыра язның бер көне».

Башланды яздан чын урак өсте, —
Бөтен зур авыл басуга күчте.
Тәүге буразна, тәүге гектарлар...
Тукта, кем башлап буразна яра?
Рәис үзе ул... Протез аягы:
— Түз, түз! — дигәндәй,
Шыгырдап бара.
Тәүлекләр буе кайтмый ул кырдан;
«Үсмәсә кабаг әрем дә кылган,
Тиздән башаклар шау килеп торыр;
Кырларда булса —
Илдә дә булыр».

Карый яшь егет колхоз атларын.
(Һәркөнне шулай көч түгеп кара.)
Төннән ук — эшкә... Агач аягы,
— Түз, түз! — дигәндәй, шыгырдап бара.
Лапас башыннан төшкән салам да
Бетте тотылып... Инде сабанда
Атларга азык ничек табасы?
Һәр көн олаулап үләп чабасы.
Интегә егет... Ләкин җыенмый
Куак артында калырга посып.
«Күрдек сугышта моннан кыенны,
Сык кара тирең, түз тешең кысып.
Кара кан белән тулса да авызың,
Дошман сизмәсен, төкермә җиргә.
Белгәндәй кадерен икмәкнең-тозның,
Төкерегең белән йот аны бергә.
Эшем эш булсын: төпкә җигелеп,
Тартсын атларым бу еллар йөген.
Кырларда булса — илдә дә булыр,
Каерылып уңсын кырларда иген».

## Ил тотынса — тау күчерер

Әшли авыл кырда кунып,
Рәис тә буразнада.
«Мондый чакта булмас тынгы,
Булмас ул беразга да».
Мәйдан токкан көрәшчегә
Җиткәндәй сабан туе,
Кырлардан һәм җәйләүләрдән
Кайтмый ул көннәр буе;
Җыя авыл өлкәннәрен,
Яңа эш барлаганда,
Ике баш бит яхшырак, дип,
Бер башка караганда.
Шунда Зөһрә апа әйтә:
— Гозерем бар, — дип, — сезгә.
Һади туган, безнең хәлне
Беләсез үзегез дә.
Нәләт сугыш мине дә бит
Дөрләгән утка салды:
Фронтта калды газиз ирем,
Һәм ике балам калды.
Күрәсез бит, йортым иске,
Ишелә торган саен.
— Чәчү бетсен, Зөһрә апа,
Табарбыз берәр җаен.

Хәзер фронт эшеннән дә
Изгерәк эш юк сыман.
Ләкин һичкем калмас бездә
Оясыз кошчык сыман...

«Ил тотынса — тау күчерер»,
Һәм шулай булды да бу.
Сөенә ана: «Уңды эшем,
Бигрәк тә уңды ла бу».

Зөһрә апа йорт ишеген
Киң итеп ачып керә.
Әйтерсең лә, ил үзенең
Күңелендә урын бирә.
«Ил күңеле киң:
Юмарт бүлеп
Мәрхәмәт-шәфкать нурын,
Барлык ятим һәм толларга
Бертигез бирә урын».

## Аналар сабан сөрә

Зөһрә апа кырда һәр көн,
Кузгала таңнан.
Йөзе аның җил-кояшта
Бронзадай янган.
Сабан сөрә атлар белән;
Һәр буразнада
Йөзе буйлап, тамырланып,
Тозлы тир ага...
Күбәү алар — тол аналар;
Кырда башлап юл яралар.
«Ил кадерен белмәгән, ди,
Югалткан башын.
Җир кадерен белмәгән, ди,
Югалткан ашын».
Сусап-көеп янганда да,
Арып хәлдән тайганда да,
Сыза торган буразнада
Егылмый алар.
«Фронт көтә... Уңсын иген...»
Тормыш йөге, кайгы йөге
Басканда да таудай булып,
Сыгылмый алар.
«Мондый авыр, кырыс көннәрдә
Ил иңе бит безнең иңнәрдә».

## Орлыклар шытканда

Тынганнар инде язгы ташкыннар;
Күп сулы әле, — Зәй ага тулып,
Аяз төндәге йолдызлар юлы —
Киек каз юлы шикелле булып.
Таулары Зәйнең охшый Памирга,
Алар өстендә ак болыт йөзә, —
Сулышы җирнең дөньяны гизә.

Таулар өстендә йөзә ак болыт,
Аккош төркеме шикелле булып.

Килә Зәй буйлап, нилләрдер уйлап,
Һади Рахманов, ул — рәис кеше.
Иртә таң белән кая юл тоткан,
Кемгә дә булса төшкәнме эше?
Чыгарга теләп уйлар очына,
Дымлы туфракны ала учына:
«Орлыклар нинди тигез шытканнар,
Бу әйбәт инде, бу гаҗәеп шәп».
Бөтен авылның бөтен бер еллык
Ризыгын, гүя, карый ул үлчәп.

Аксый ул бераз; протез аягы,
— Түз, түз! — дигәндәй,
Шыгырдап бара.
Бердәй кыен эш: әйтерсең, солдат
Амбразурага
Башлап юл яра...

## Укырга китә егет

Алда яңадан юллар да юллар,
Туган авылы кала яңадан.
Бер узар, диеп, бу авыр еллар,
Ал-ял белмичә атлар караган
Агач аяклы таныш яшь егет
Казан вузына укырга китә.
Авыл аңардан яңа белгечен,
Үзенең яңа җырчысын көтә.
Кала озатып Чияле тавы,
Шау чәчәк атып, күренеп ерактан.
Кала озатып башаклар шавы,
Шыттың, дип, син дә
Безнең туфрактан...

## Фән һәм күңелләр кырларга күчкән

Иртә торганнар үкенмәс, диеп,
Соңлаган рәтле көн күрмәс, диеп,
Биредә бигрәк дөрес әйткәннәр
Һәм, раслап шуны, эш күрсәткәннәр:
Орлыклар башлап игенчеләрнең
Күңелендә шыткан;
Беренче яңа икмәкнең исе
Биредә чыккан.
Элеваторга тәүге олаулар
Кузгалган моннан.
Һәм бөтен авыл яңа үрләргә
Күз салган моннан.
Яңа үрләргә... Әйткән өлкәннәр —
Гашыйклар җиргә:
«Кысмастыр безне тормыш камыты,
Тартсак гел бергә».
Фән һәм күңелләр кырларга күчкән.
Бер уч орлыктан ничә уч үскән!
Инде һәр елны авыл өстендә
Райком байрагы тора җилфердәп, —
Намусы булып
Бөтен авылның,
Тирә-якларны хезмәткә өндәп.
Тора җилфердәп райком байрагы,
Еракка очкан
Ут кошы сыман,
Бөтен авылны иртә уятып,
Язгы таңнарның балкышы сыман...

## Зөһрә апа сөйли...

Юк, юк, онытмыйм... Ул көн яңадан
Алдыма баса:
Дуслык кулларын суздык Вьетнамга
Кыйтгалар аша.
Кысылды тешләр... Зал калды тынып.
Чал Зөһрә апа сүз алды торып:
— Андагы тол аналарның
Һәм меңнәрчә балаларның
Җаны бүген ничек әрнеп
Тетрәвен беләм.
Ә булдыра алсам бүген,
Каплар идем Вьетнам күген
Күкрәгем белән.
Анда искән утлы җилләр
Туган илем өстенә дә
Искәндәй була.
Анда төшкән һәрбер бомба
Монда минем өстемә дә
Төшкәндәй була.
Чөнки миллион йөрәкләрнең
Тетрәвен беләм.
Ә булдыра алсам бүген,
Каплар идем Вьетнам күген
Күкрәгем белән.
Һәм яктыртыр идем аны
Күңелебез кебек,
Гел кояшлы һәм гел зәңгәр
Күгебез кебек...

## Корый имән тамыры да туфрагыннан аерылса...

Әйттеләр аңа ничә тапкырлар:
— Колхозың инде гел үргә бара.
Инде бул, әйдә, райком кешесе,
Секретарь булып бер эшләп кара.

— Ә халык, белмим, нәрсә дияр бит,
Ярый, әйтсә ул: «Уйла һәр ягын, —
Партия кушкач, бар, эшләп кара,
Кайтырлык булсаң Нәдергә тагын.
Ул — синең газиз оян бит, туган,
Канатлар ярдың аңарда башлап.
Инде зур кеше булам, дип, туган,
Китмә син аны озакка ташлап.
Буразналарга кире кайт тагын,
Җылын аларның җылысы белән.
Сула, яшә син гомереӊ буена
Туган туфрагың
Сулышы белән».
«Сизәм, халык шулай дияр,
Борчый мине шушы тойгы,
Әйтерсең лә, бирми тынгы
Үз тәнемдә йөргән ярчык.
Авылдашлар белеп торсын,
Җавабым минем ачык:
Акласам бу ышанычны,
Тиз кайтырмын, җае булса.
Корый имән тамыры да
Туфрагыннан аерылса...»

## Гомер-гомергә калсын ул бездә

Авылдашлары әйтте райкомга:
«Колак салыгыз безнең хак сүзгә:
Күңеле бит аның безнең туфракта,
Гомер-гомергә калсын ул бездә».
Һәм калды Һади; узар юлында
Иркен офыклар ачылды аңа.
Һәм менә тагын Державабызның
Парламентыннан кайтты ул яңа.
Ул бит колхозның илчесе анда,
Халык илчесе — депутат кеше.
Давыл күрсәткән
Барометрдай,
Тынгысыз җаны,
Тынгысыз эше.
Тормыш чыгыры кирели кайчак,
Эштә мәшәкать гел чыгып тора:
Житешми анысы, житешми монысы;
Эш дисәң, кемдер йөз чытып тора.
Таңнан кузгал да — кырга юл ал син,
Поход тормышын кабатла һәр көн.
Ирнең сүзе бер: таш яр — кирәксә,
Әйтсә — эшли, — дип, инансын һәркем,
Шушы ышаныч гомер юлының
Маякларыдай яктырып янса,
Шушы маяклар, күңелләр аша,
Үрдән-үрләргә чакырып янса,
Тик шунда гына җиңел үтелә
Ташлы сукмаклар, бормалы юллар.
Әмма шунысы бар: чәчкә чал өсти
Тынгысыз эшләр, тынгысыз еллар.
Кара бөдрәләр чаллана һаман, —
Сала аларга эзләрен заман.
Хәер, моңардан зарар юк бер дә,
— Бирешмәм, — дисәң, — әле тиз генә.
Чәчтә чал булу — берни дә түгел,
Һәрвакыт чал бит
Диңгез үзе дә...
Күрше-күләндә шундый сүз йөри:
«Кайгыртмый рәтләп Һади үз йортын, —
Булмый күп вакыт ишек алдында
Терлеккә азык, ягарга утын».

## Чияле тау аны сагына

Килдем тагын Нәдер якларына,
Шагыйрь дусның туган ягына.
Шау чәчәккә тоташ капланган да,
Чияле тау аны сагына.
Колхозында атлар карап үскән,
Канын коеп, утны-суны кичкән
Үз җырчысын авылы көтә һаман.
Сызлаулары кискән аягының,
Шыгырдавы култык таягының
Йөрәгемдә тынмый кабатланган
Шагыйрь дуска күңелем гашыйк һаман,
Уртак гүя сулар сулышым.
Баскан саен туган туфрагына
Тоям кебек күңеле җылысын.
Әйе, бигрәк тәмле була икән
Җирдән күтәрелгән язгы пар,
Гүя, анда аның тормышының,
Яшәвенең җылы тыны бар...

## Тыкрыклар тар, урамнар тар...

«Җир кадере игендә, ди,
Ир кадере белемдә, ди.
Игә белсәң — мул бирә җир,
Иген уңа кырыбызда.
Кешеләрчә көн күрәбез,
Туклык бездә икмәк-тозга».
Баш-күз ала Нәдер халкы;
Яңа йортлар тора артып,
Күз карашын тирә-якның
Торган саен күбрәк тартып.
«Икмәк-тозга муллык бездә,
Болай булгач — тормыш ярый.

Якты булып күңелебездәй,
Тәрәзәләр таңга карый...»
Кырга күчә бөтен авыл,
Җәйге эшләр кызган чакта.
Тыкрыклар тар, урамнар тар,
Машиналар узган чакта.
Яшь авыл алга карап:
«Яңа үрләр үтәсе бар.
Бүгенгенең — иртәгесе,
Иртәгенең иртәсе бар».
Кырларда һәм җәйләүләрдә
Ишетәсең бер үк җырны.
Кышларын да, җәйләрен дә
Йөрәкләрдә аның урыны.
Инде сүзне җырга бирик,
Йорттан йортка бергә керик:

«Безнең авыл Зәй буенда,
Исемен Нәдер, диләр.
Эштә алтын куллыларга
Хөрмәт һәм кадер, — диләр.

Игенчеләр — җирнең гашыйк
Кызлары, уллары без.
Гел кояшлы үрләр аша
Узачак юлларыбыз.

Колхоз эше гөрләп барса,
Ял бирә җаннарыңа.
Тәрәзәләр таңга карый,
Тормышның таңнарына».

Ә иң биек тәрәзәләр —
Кешеләр күңелләре.
Яктыралар алар аша
Алдагы гомерләре.

## Аңлый дустым шавын башакларның

Май азагы бик эссе булды,
Тора кояш күктән яндырып.
Иген көя кырда, җир яна,
Рәис ут йоткан төсле булды:
Ул йокыга китә «их, яңгыр...» дип,
Шул ук хисләр белән уяна.
Һәм күз төби аяз күк йөзенә:
«Нигә яумый, шайтан алгыры.
Алыр иде тартып сулышын белән,
Килсә язның җылы яңгыры...»

Бу — яшәве аның:
Игеннәре
Тамыр җәйгән гүя күңеленә
«Кырларында әгәр булмый икән,
Ни бирерсең быел илеңә!»

Зәй өстендә бүген нур дугасы
Сузылгандай ерак Иделдән.
«Бу — үзе бер яз һәм җыр дөньясы,
Нур алган ул күпме күңелдән, —
Ди Рахманов, дымлы җиргә басып, —
Ой, үткәннәр кире кайтмасын.
Гел салават күпере торсын ачып,
Мең нәр күңеле аша торсын ачып
Киләчәккә тормыш капкасын!»

Риза күңел: «Алай булса — ярый»;
Әйтерсең лә, күңел —
Яз кошы.
Тәрәзәләр якты таңга карый,
Чагылгандай ил-көн язмышы.

Аңлый дустым шавын башакларның, —
Барысы таныш гомер-гомергә.
Иминлеге өчен башкаларның
Риза тагын утка керергә.

«Бутама син кабат заманнарны,
Сугыш, утың тагын көйрәтмә.
Планетаның азмы яралары
Болай да бит сызлый йөрәктә,
Болай да бит сызлый йөрәктә...»

*Әлмәт районының*
*«Зәй» колхозы. 1966.*



*Нурихан Фәттах*

*Повесть*[1]

# МӨДИР САҖИДӘ

*Өченче бүлек*

## I

Беркөнне мине Куштирәк авылыннан килеп алдылар. Биш-алты яшьләрдәге бер малай чирләгән. Сөйләүләренә караганда, хәле бик яманга охшый. Башы, тәне уттай яна, ди, коса, саташа, ди. Кайчагында аңын югалтып куйгалый, ди.

Бардым, карадым. Малай агач сәкедә ята. Нәкъ үлем түшәгендә яткан кебек. Астында иске тун, баш очында кызыл тышлы мендәр. Тирә-ягын чатыр кебек итеп кызыл чаршау белән әйләндереп алганнар. Йөзе кып-кызыл, күзләре ярым йомык. Градусник куеп караган идем — температурасы 39 чамасы.

— Нәрсә? — ди яшь кенә ана, эчке бер каушау белән.

— Хәзергә берни әйтеп булмый, — димен. — Әллә ни куркыныч нәрсә юк. Шулай да баланы өйдә калдырырга ярамый. Яңавылга хәбәр итәргә туры килер. Бәлки, больницага салырлар.

— Бүлнискә?! — ди хатын, коты алынып. — Юк, туганкаем, теләсән нәрсә әйт — анда илтеп бала үтертер хәлем юк! Үлсә өйдә үләр.

— Сезгә кем әйтте үләр дип?! — димен кырыс кына. — Әллә бала чирләми торамы?

— Әйтмә! Анда гына бала, ана гына кадерле! — ди абый кеше, хатынына ачуланып.

— Әллә мине күрми дисең? — ди хатын, еламсырап. — Бырачның әйтәсе килми. Бирмим баламны, үлсә өйдә үләр.

---

[1] Ахыры. Башы 10, 11 саннарда.

Белмим, әллә инде аны мин килгәнче берәрсе куркытып куйган, әллә чынлап та ул вакытта минем кыяфәтем бик шикле булган, — апа кеше тикмәгә генә сөйләнми иде, ахрысы. Бәлки, аның күңеле сизенгәндер?

Мин аны үземчә юатырга тырышам, берни юк, берни булмас димен. Күңелемнән исә һич тә алай уйламыйм. Минемчә, бу полиомиелит дигән авыру булырга тиеш.

Полиомиелит йогышлы авыру. Күбесенчә ул яшь балаларда була. Полиомиелит белән авырганда баланың арка мие зарарлана. Еш кына паралич суга. Тап-таза аяклар, куллар җансыз әйбер кебек салынып кала. Кеше гомер буена шулай хәрәкәтләнми торган, үсми торган аяк-куллар белән гарип калырга мөмкин.

Ул елларда Яңавыл районының кайбер авылларында менә шул куркыныч авыру калыккан иде. Шуңа күрә полиомиелит райондагы медицина халкының котын алган иде. Әгәр дә мәгәр берәр авылда шуңа охшаш берәр авыру булса, шундук районга хәбәр итәргә дип безгә алдан ук кисәтү ясап куелган иде.

Мин үземнең дөрес диагноз куюыма әз генә дә шикләнмәдем. Полиомиелит турында мин әле шушы арада гына китаптан укыган идем. Райздрав биргән күрсәтмәләрне истә тотып, мин, Мәсәгуткә кайткач та, Яңавылдагы тиешле урыннарга шалтыраттым.

Икенче көнне төшкә таба, «ашыгыч ярдәм» машинасына төялеп, Яңавылдан биш-алты кеше килеп төште. Алар арасында Соломон Моисеевич та бар иде.

## II

Алар башта безнең пунктка тукталдылар. Машинадан төштеләр дә, җыйнаулашып, тәрәзәләргә карана-карана, капкага юнәлделәр, капка алдында бераз җыелып торгач, ишегалга керделәр.

Мин әле авыруларны кабул итеп бетермәгән идем. Көтеп тору бүлмәсендә ике-өч кеше бар. Минем бүлмәдә, өстәл янында, шулай ук бер авыру утыра. Соломон Моисеевичны күреп алдым да куанычымнан елмаеп җибәрдем. Соңгы атнада бу минем беренче елмаюым булды, ахрысы. Көн ямьсез иде, болытлы иде. Иртәдән башлап яңгыр яварга җыена иде. Миңа кинәт кояш чыгып киткән төсле булды. Авыру янында Зөһрәне генә калдырдым да, ашыгып, ишекләрне орып-бәреп, кунакларны каршыларга чыгып киттем.

Мин аларны кайгырган-борчылган итеп күз алдына китергән идем. Беркемнең йөзендә борчылу билгесе күренми. Барысы да шат, көләч. Бигрәк тә Соломон Моисеевич. Аннары санэпидстанциянең баш врачы Ульяна Архипова.

Соломон Моисеевич, мине күргәч, юлдашларына нәрсәдер әйтеп алды. Барысы да шаркылдап көләргә тотындылар. Миңа карап көләләр. Мыскыл итеп көлмәгәнлекләрен күреп торам. Яратып, шаяртып көләләр. Ни өчен көлгәнлекләрен аңламасам да, мин дә көлгән булам, исәнмесез, димен, әйдәгез, түрдән узыгыз, димен.

Алар шулай шаулашып, көлешеп баскычтан менделәр, өйгә керделәр. Авырулар яныннан узганда артык шаулашмадылар. Безнең торак бүлмәгә кереп тулдылар да кем каян урын таба, шунда урнаштылар.

Мин аларны озата кердем, аннары, гафу үтенгәндәй:

— Мине авырулар көтеп тора бит әле, — дидем.

— Барыгыз, бар, карагыз, — диде Соломон Моисеевич.

Кая басканымны да белмичә, тулы ай кебек балкып, мин икенче якка килеп чыктым. Нишләптер кисәк кенә зиһенем чуалып китте. Өстәл янына утырдым да каршымдагы бабайга:

— Исемегез, фамилиягез? — дидем.

— Яздың бит инде, кызым, — ди бабай хәлсез генә.
— Яздым? Ә, язганмын икән! Кайсы авылдан?
— Кызыл Ярдан. Аңысын да яздың, кызым.
— Язганмын икән шул, — дигән булам мин, тынычланмакчы булып. Үзем һаман теге якка колак салам. Өзек-өзек булып Соломон Моисеевичның сүзләре ишетелеп китә. Аңа каршы тагын тыелып кына көлешеп куялар, пыш-пыш киләләр. Юлда, күрәсең, берәр кызык нәрсә турында сөйләшеп килгәннәр дә әле булса шуның тәэсиреннән котыла алмыйлар.
— Кай җирең авырта, бабай? — димен, соравымны дәвам итеп.
— Сорадың бит инде, кызым, — ди бабай тагын да, ризасызлык белән.
— Сорадыммыни? — дигән булам, исем китеп. — Кайчан сорадым? Сорадым бугай шул. Ничек әле?
— Тамактан үтмәй, кызым. Аш үтмәй. Эпине дә сөттә җебетеп кенә ашыйм. Әзрәк сөт эчәм дә чәй эчәм. Тамактан үтмәй. Ашамагач хәл юк. Шушы атна төшендә генә дә күзгә күренеп ябыктым. Куәт юк, кызым.

Ул әкрен генә сөйли, хәлсез тавыш белән генә. Мин аның йөзенә игътибар беләнрәк карап алам. Чыннан да, бик ябык. Яңак сөякләре, тиресен тишеп чыгардай булып, төртелеп тора. Күзләре эчкә баткан, нурсызланган. Чырае агарып-саргаеп калган.
— Җен кору зәхмәте диләр, кызым. Белмәм тагын. Менә сиңа килдем. Син ни әйтерсең. Кортка да, малайлар да сиңа күренеп карарга куштылар. Тамактан үтсә, башкасына кайгырмасыең. Тамактан үтмәй. Ни хикмәттер инде, кызым.

Мин бабайны бүлдерми генә тыңлап торам. Бичара, бу минутта ул мине алладан да артык күрәдер, бәлки. Аның ялварулы нурсыз күзләре, ябык чырае — бөтен кыяфәте шул турыда сөйли. Ләкин нишли алам мин? Нәрсә әйтергә аңа? Рентгеннан карамыйча, кирәкле анализлар алмыйча, каян беләсең аның нәрсә икәнлеген?!

Минем шунда күңелгә бер уй килде.
— Яңавылдан әнә олы докторлар килде, — димен бабайга. — Күрсәтеп карыйк әле сине шуларга.
— Бик әйбәт булыр, кызым, — ди бабай. — Үзем дә әйтмәкче булганыем, кыймадым.

### III

Кунаклар арасында «олы докторлар»дан ике генә кеше. Беренчесе, билгеле, Соломон Моисеевич. Медицина институтын ул Мәскәүдә бетергән. Моннан ике ел элек. Укуын бетергәч, аны Уфага җибәргәннәр, Уфа безгә җибәргән. Әйтүләренә караганда, укуын ул бик яхшы тәмамлаган. Килгәч тә аны район сәламәтлек саклау бүлеге мөдире итеп билгеләгәннәр.

Икенче «олы доктор» — Ульяна Архипова. Институтны ул Казанда бетергән. Кайберәүләр әйтә, имеш, алар Соломон Моисеевич белән йөриләр икән, ди. Ләкин мин моңа ышанмыйм. Тамчы да ышанмыйм. Булуы мөмкин түгел! Ульяна Архипова ямьсез. Үзе сары, үзе килбәтсез. Күзләре зәңгәрме, яшелме — аңламассың. Борыны зур. Бите бит түгел — кытыршы, тупас. Исең китәр, институт бетергән кеше дә шундый ямьсез булыр икән!

Югары белемле кешеләрдән бары шулар гына. Алар белән тагын дезинфектор Мәдинә апа килгән. Арада ул иң олысы. Яше белән. Аңа кырык, кырык бишләр чамасы булыр. Ул башкалар кебек юкка-барга көлми дә, шауламый да. Аннары санитария фельдшеры Соня. Яшь-яшь. Нечкә билле. Шәһәрчә матур. Тик тавышы гына тупасрак. Алардан кала тагын бер фельдшер кыз.

Шушы көннәрдә генә Мәсәгут пунктына керә торган авылларны икегә бүлеп, яңа пункт ачу турында сүз булган иде. Яңа пунктка өч авыл керәчәк: Куштирәк, Түбән Чат, Югары Чат. Медпункты Түбән Чатта булачак. Минем карамакта бары дүрт кенә авыл калачак: Мәсәгут, Алдар, Тау-авыл, Кызыл Яр.

Мин танымаган кызны менә шул яңа оештырылган пунктка мөдир итеп алып килгәннәр икән. Анысын соңыннан белдем.

Чыктым теге якка. Туп-туры Соломон Моисеевичка мөрәҗәгать итәргә ничектер кыюлык җитмәде. Санитария врачына ялынырга туры килде.

— Иптәш Архипова, — димен, — анда бер авыру бар. Чыгып кына карамассыз микән?

Архипова карышып тормады. Юл чемоданын ачып, чиста ак халатын киде дә минем белән кабул итү бүлмәсенә керде. Мин аңа бабай турында белгәннәремне кыскача гына тәрҗемә итеп бирдем. «Олы доктор» уйлангандай итеп торды да, бабайга, күлмәген салып, сәкегә ятарга кушты. Әчен капшап карады, суккалап карады. Капшаган саен, суккалаган саен, Таня кебегрәк итеп:

— Аорта? Аорта? — дип сорады.

Кай төше турында сорасаң да, бабай: авырта, кызым, авырта, ди. Кай җиренең авыртканын ул үзе дә ныклап аермый, күрәсең.

— Соломон Моисеевичка әйтеп карарга кирәк, — диде «олы доктор» бераздан.

Бабайга без киенми торырга куштык. Архипова теге якка чыгып китте. Койрык булып, аның артыннан мин дә тагылдым. Архипова түрдә өстәл янындагы урындыкта кырын-ярын утырып торган Соломон Моисеевич янына барды, бүтәннәр ишетмәсен дигән сыман, иплап кенә үзенсң йомышын әйтте.

— Ничего! Үзегез карагыз! — диде Соломон Моисеевич, кычкырып. — Мин сезгә ышанам.

Ул моны ничектер җиңел генә әйтте, шаярып, көлешеп сөйләшкәндәге кебек кенә итеп әйтте. Аннары, Ульяна Архипова турында да, аның йомышы турында да онытып, Соняга нәрсәдер эндәшеп куйды.

Бу миңа бераз гына гаҗәбрәк тоелды. Шулай да күңелемнән сөенеп куйдым. Димәк, Ульяна Архипованы ярата икән дигән сүзләр дөрес түгел! Яратса, билгеле, ул аның сүзләрен тыңлаган булыр иде.

— Саша, бәлки, карарсың, ә? — диде Архипова тагын да.

Монысында ул бик йомшак итеп, үзенчә бик ягымлы итеп эндәште.

— Улечка, мин бит сиңа тулысынча ышанам! — диде Соломон Моисеевич, елмаеп.

Аның бу елмаюында күрәләтә сангa сукмау сизелде. Күңелемнән мин пырхылдап җибәрдем: «Улечка! Шәп булды Улечкага!» дидем.

«Улечка»ның кәефе кырылгандай булды. Шулай да ул кеше алдында үзенең кәефсезләнгәнлеген күрсәтмәскә тырышты. Ясалма бер елмаю белән елмайгандай итте дә, без тагын кабул итү бүлмәсенә чыктык.

Бабайга мин киенергә куштым. Бабай киенде, янадан үз урынына утырды. Без экрен генә «Улечка» белән үзара сөйләшеп алдык, бабайга: Яңавылга барырга, рентгенда каралырга, хирургка күренергә кирәк дидек. Аннары, врач әйтүе буенча, мин рецепт яздым, Яңавыл поликлиникасына кәгазь яздым.

## IV

Авыруларны карап бетергәч, янадан үзебезнең бүлмәгә чыктым. Анда инде күптән мине көтеп утыралар.

Бүген төнлә яңгыр яуды. Яңгырлар бу арада ешаеп китте. Юллар пычрак, авыр. «Ашыгыч ярдәм» машинасы Ямадыдан Мәсәгуткә бик

авырлык белән килгән. Шофер Куштирәккә барудан баш тарткан. Машинаның болай да рәте юк, батып ятсак, бөтенләй Яңавылга кайта алмабыз дигән. Минем анда барганым бар — юл начар дигән. Кунаклар аптырабрак калганнар, нишләргә дә белмиләр.

— Тизрәк барып җитәсе иде, — ди Улечка, Соломон Моисеевичка караштырып. — Никтер күңел үз урынында түгел.

— Моңарчы нәрсә карадыгыз? Бирермен мин сезгә кирәгегезне! Минем районда — инфекция! — ди Соломон Моисеевич, шаяртып, кычкырынгалап.

Шуннан соң бу миңа борылды да, елмаеп:

— Менә иптәш Фәррахова ни әйтер бит әле! — диде. — Без аның карамагында. Теләсә нишләтсен.

Кызлар көлешеп миңа карыйлар. Аларга ияреп мин дә көлгән булам. Үзем көләм, үзем кызарам.

— Нишләргә — ат сорарга кирәк! — димен, җиңел генә.

— Әлбәттә, ат сорарга! — ди Соломон Моисеевич. — Безнең машинаны тартып алып барырдаен, көчләрәген...

— Чынлап та! — ди Улечка, сөенеп. — Акыллым, бар син сора. Тизрәк барып җитәргә кирәк. Ике ат сора. Икене, яхшыны!

Улечканың йомыш кушуы миңа бик үк ошап җитмәде. Шулай да ык-мык итеп тормадым — тиз генә икенче якка чыктым. Зөһрә шприцлар сөртеп маташа.

— Бар әле колхоз идарәсенә кереп ат сора. Куштирәккә барырга. Ике ат, — димен.

Зөһрәнең болай да чытык йөзе тагын да ныграк бозылып китте.

— Миңа бирәләрмени алар. Үзең сора! — ди бу.

Сатулашып тормадым. Чыннан да, аңа бирмәүләре мөмкин. Тоттым да үзем чыгып йөгердем.

Колхоз идарәсендә бухгалтердан башка беркем юк. Ат турында сүз чыгаргач: белмим дип кенә җавап бирде. Күп уйлап тормадым, туры председатель өенә йөгердем.

Мин барып кергәндә, председатель яңарак кына басудан кайтып кергән иде, ахрысы. Кәефе юк. Булмас та шул — колхозның эшләре шәптән түгел. Басуда җыелмый калган бик күп ашлык ята. Амбар алдында ашлык кыза. Киптереп өлгерә алмыйлар. Дәүләткә ашлык тапшыру буенча да колхоз артта бара.

Колхоз председателе белән без бик үк дус түгел. Ул безне күрми дә, белми дә. Беркадәр дәрәҗәдә ул безне эрәм тамаклар дип, эшлексезләр дип исәпли. Ул болай да тупас, кире кеше.

— Мирсәет абый, безгә яхшы гына ике ат бир әле... Тизрәк кирәк, — дидем мин килеп кергәч тә, тыным бетеп.

Мирсәет абый, аптырап, кашларын җыерып карады да:

— Кыз да булсын, буаз да булсын, — дип куйды. — Нәрсәгә? Кая барасыз?

Мин моңа аңлатып бирдем. Тизрәк кирәк димен, райздрав мөдире көтеп тора димен. Мин инде ничек тә Соломон Моисеевич исеме белән алдырмакчы булам. Үземчә бу тиешенчә тәэсир итәр дип уйлыйм, район начальнигы кушкач, берсүзсез ике атны безнең капка төбенә китереп туктатырга кушар дип уйлыйм.

Мирсәет абый эндәшмәде, тузгыган каты чәчләрен артка сыпырып куйды да, тәрәзә аша тышка, ялтырап яткан пычрак урамга карады.

— Ат юк. Ялга туктатылды барысы да, — диде.

— Минем үземә түгел бит, Мирсәет абый! — димен мин, мондый җавапка нәрсә әйтергә дә белмичә.

— Минем эшемә йөрмиләр әле, — ди председатель тупас кына. — Әнә Ходайбирдин калхузыннан сорагыз.

Ачудан, гарьләнүдән кып-кызыл булдым. Менә сөйләшеп кара син аның белән! Шундый да надан, шундый да аңсыз кеше булыр икән!

— Алар да үз эшләре белән йөрмиләр, — димен мин, кыза башлап. — Кеше анда үләргә ята, монда сезгә ике атыгыз да жәл.

— Ике? Ике түгел, берсе дә юк, сеңелем. Башымны катырма. Кирәк икән, җәяү барырлар. Тик ятып симереп беткәннәр, дуңгыз кебекләр. Бар, шулай дип әйтте диген.

Мин шаккаттым! Минем котым алынды! Ничек теле бара аның? Ничек теле әйләнә? Ничек оялмый ул?!

Мин аңа каршы бер генә сүз дә әйтә алмадым. Авызым йомылды, телем тотлыкты. Кырт кына борылдым да, үземчә бик усал итеп:

— Хушыгыз! — дидем.

Ишекләрен шапылдатып яптым да, чыктым да киттем.

## V

Авыл Советына киттем. Бәхеткә каршы, Галим абый шунда булып чыкты. Мин аңа үземнең хәлне сөйләп бирдем. Соломон Моисеевич турында тагын начар сүз ишетүдән куркып, монысында аны бөтенләй телгә дә алмадым. Күбрәк авыру балага, инфекция таралу куркынычына басым ясадым.

Галим абый сүзсез генә тыңлап торды да, өстәл читенә суккалап алды, беравык уйланып утыргандай итте.

— Ярар, минем атны алырсыз, — диде. — Алмаш-тилмәш утырып барырсыз. Сез, яшьләр, җәяү тәпиләсәгез дә таманга килер.

— Минем үземә ничек тә ярый, Галим абый! — димен, куанып. — Мин җәяү йөреп өйрәнгән.

— Шулайдыр, шулайдыр, — ди Галим абый. — Хәзер җигеп китерерләр. Әзерләнеп торыгыз.

Мин йөгереп пунктка кайттым. Кайтсам, чоланда Улечка көтеп тора.

— Менә нәрсә, акыллым, — ди бу миңа. — Хәзер төш җитә. Без барыбер төшкә кадәр барып җитә алмыйбыз. Аннан тагын кире әйләнеп тә кайтасы бар. Соломон Моисеевич төшке ашны ашамый булдыра алмый. Мин үзебез белән коры-сары алып чыктым чыгуын. Шулай да Соломон Моисеевич аңа гына канәгать булмас.

— Аш пешерербез! — димен мин. — Безнең зур чуен бар. Тутырабыз да шуны, пешерәбез. Итле аш!

— Тиз өлгермәс шул инде ул, — ди Улечка, үз-үзенә каршы килеп.

— Өлгерә, өлгерә! — димен мин.

— Ярар, алайса. Күп булса, ике сәгать көтәргә туры килер. Анда инде көнне дә ачып җибәрер, бәлки, — ди Улечка.

Менә бәхет! Мин Соломон Моисеевичны кунак итәм! Дөнья кинәт үзгәреп китте. Ямьсез Улечка искиткеч матур булып күренде. Әлерәк кенә көлке ишетелгән «Улечка» сүзе ягымлы булып тоелды.

Шулай да бераздан мине борчу биләп алды. Борчу да түгел инде, болай гына, уйлану гына... Зур чуенда итле аш пешерергә ризалык биргәндә мин кайбер нәрсәләрне уйлап житкермәгәнмен. Алар бит бишалты кеше, Таня белән мин генә түгел. Таня дигәннән, иртүк ул авылларга чыгып киткән иде. Төш вакытларына аның да кайтып житүе мөмкин. Шулай булгач, ашны биш-алты кешегә генә дә түгел, алтыжиде кешегә пешерергә туры киләчәк. Каян житкермәк кирәк аларга азыкны? Икмәк инде житәр. Житмәсә, күршеләрдән алып торырга була. Ә ит? Бозыла дип мин итне өйдән күп алып килмәдем. Авылда мал-туар суючы бөтенләй диярлек юк. Суйсалар да авылда сатмыйлар, Янавылга алып китәләр. Анда кыйбатрак. Нишләргә? Тагын колхоз председателенә барыргамыни? Әллә Галим абыйгамы?

Улечка шунда миңа күпмедер акча сузды. Мин, хурланып, акчаны

кире кактым. Шушы арада гына айлык эш хакы алган идем. Бу минем үз гомеремдә беренче эш хакым. Мин әле аны тотарга да кызгана идем. Үземә бераэр яхшырак күлмәк алырмын дип саклый идем.

Бүлмәгә кердем дә чемодан төбеннән шул акчаны алдым. Аннары икенче якка чыктым. Зөһрә әле кайтып китмәгән. Әллә ни эше булмаса да, эшем кешесе булып, һаман шул шприцлары белән, шкаф пыяласының тузанын сөртү белән булаша.

— Зөһрә! — димен мин моңа. — Хәзер үк безгә биш кило ит табарга кирәк. Хәзер үк!

Тегенең ике күзе дүрт булды.

— Биш кило! — ди бу, кычкырып.

— Кычкырма шулкадәр, — димен. — Хәзер үк аш пешерергә кирәк. Әйт, кемдә ит бар?

— Белмим, — ди бу сүлпән генә. — Шулкадәр мәшәкатьләнеп торганчы, чәй генә кайнатырга да бирергә.

— Син нәрсә! — димен. — Соломон Моисеевич чәй эчәмени? Ул бит синең белән мин түгел.

— Әллә кем дә түгел! — ди бу, кашларын җыерып. — Бераэр дистә йомырка пешерергә була...

— Ничек инде әллә кем булмасын! — димен мин. — Кыскасы, сатулашып тормыйбыз. Әйт, каян ит табарга?

— Каян табасың авылда юк итне? — ди бу.

— Ике бәясенә алабыз. Күпмегә булса да алабыз! — димен мин, йодрыктагы акчаны күрсәтеп.

— Туктале, алай булгач, — ди бу, уйланып. — Әллә колхоздан сорап карыйсыңмы? Аларның булмый булмас. Тракторчыларга суялар алар.

— Юк, булмый! — димен, кырт кисеп. — Әле генә председательдә булдым. Бирмәс.

— Гайшә апаларга кереп карале, ул белми микән, — ди бу.

## VI

Гайшә апалар безгә күрше йортта гына торалар. Без аларга әледәнәле йомыш белән кергәләп йөрибез. Кайчакларда Гайшә апа үзе дә керә. Кулы киселсә-нитсә, йод сөртterә, күзем кычыта дип, күзенә дару салдыра.

Кердем дә Гайшә апага бер-ике сүз белән үземнең йомышымны сөйләп бирдем.

— Ит булмас ул хәзер авылда, — ди Гайшә апа. — Йөрүең генә калыр. Үзем бераэр тавыгымны суйдырып бирерием дә, барысы да күкәй сала. Җәлрәк шул, апай. Быел тавык утыртмадым. Җәлрәк шул. Биш тавыкның берсен суйсаң, дүрт кала, дүртнең берсен суйсаң, өч кала.

— Бер тавык кына җитмәс, — димен мин. — Болай булгач, кимендә ике тавык кирәк. Минем акча бар. Артыгы белән түлим.

— Берсе дә җитеп торырые әле аның, — ди Гайшә апа. — Син инде ачуланма. Кара, ник Зөһрәләрнең үзләреннән сорап карамыйсың? Аларның тавыклары күптер. Ник тормышлы кешеләр бит алар.

Гайшә апаның сүзләре миңа бик дөрес булып тоела. Чыннан да, ник баш ватарга? Күптән шулай итәсе калган!

Гайшә апалардан чыктым да, пунктка кереп тә тормастан, чаптым Нәсимә апаларга. Чаптым дигәч тә, кая ул чабу! Аяк асты пычрак. Аякта тишек-мишек танкетка. Әледән-әле таеп китәм, егылмас өчен берәрсенең урам яктагы бакча коймасына тотынып-тотынып алам. Үземнең күзгә ак-кара күренми: кем белән очрашканымны да, кая барганымны да рәтләп белмим. Барам да барам.

Нәсимә апаларга барып кердем. Хисам абыйдан, Зөһрә белән

сеңелесе Сәлимәдән башкалары барысы да өйдә. Нәрсә булды икән дигән сыман, аптырашып карап торалар миңа. Мин еш-еш тын алам, тиз генә аңлатып сөйләп бирергә тырышам.

— Тавык кирәк, Нәсимә апа, — димен. — Итле аш пешерәбез, Нәсимә апа. Күпме сорасагыз да бирәм!

Шулай дигән булам да көлеп җибәргән булам, борынны тартып алам, маңгай чәчләрен төзәткәлим.

— Нинди тавык? — ди Нәсимә апа. — Зөһрә нишләп ята анда? Эшегез беткәндер иң?

— Рәйздрав килде, врачлар килде. Яңавылдан, — димен.

Аңлап алгач, Нәсимә апа кисәк кенә тынып калды. Күреп торам, бик үк риза буласы килми.

— Ярамаган кайнар су! — ди. — Кайнатыгыз да бирегез. Юкка мәшәкатьләнеп... Бетмәс андый килүче-китүче...

— Начальникка һыу эсерергә ярамас, — дигән була Рафика апа, юаш кына елмаеп.

— Үзем өчен түгел бит, Нәсимә апа, — димен, ялварып.

Минем кинәт үз-үземне кызгандырасым килеп китте, тыным кысылгандай булды. Шул ук вакытта котым алынып уйлап куйдым: «Болар да бирмәсә, кемгә барырмын? Берни барып чыкмаса, нинди хурлык!» димен.

— Бер тавыктан ни булган да ни калган, — диде шул чакны Фәгыйлә апа, сүзгә катышып. — Суйдырып бирергә кирәк, әнкәй.

— Минем тавыкларым симез, — ди Нәсимә апа, миңа карамыйча гына.

Фәгыйлә апа белән Рафика апа икесе берьюлы көлеп җибәрделәр. Мин, Нәсимә апаның ачуын китерүдән куркып, тыелып калдым.

— Күрше тавыгы гына симез була торганые, — ди Фәгыйлә апа, көлә-көлә.

— Ярар, авызыгызны җырмагыз! — ди Нәсимә апа, ачуланып. — Сезгә көлке. Карарга дигәндә, берсенең дә кузгаласы килми. Теге койрыкның өйгә кайтып кергәне дә юк.

Кем турында сүз барганын мин шундук аңлап алдым. Билгеле, Зөһрә турында. Сәлимәне әле телгә алмыйлар. Ул — укучы.

— Үзең өйрәтәсең, — ди Фәгыйлә апа. — Ул бит безнең сүзне тыңламый, синең сүзне генә тыңлый.

— Тынлайсыз сез! — ди Нәсимә апа, пыраннап. — Минем күзем йомылса, иркенләп калырыегыз да, күзем генә йомылмай.

— Миңа болай да иркен, — ди Фәгыйлә апа.

Ул моны тиргәшмичә генә әйтә. Җиңелчә шаяртып кына. Үзе шунда Рафика апага күз кысып ала.

— Кешене көттермә инде, әсәй, — ди Рафика апа кайнанасына юаш кына.

— Үзем өчен булса... миңа барыбер дә соң... — дигән булам мин, үз алдыма сөйләнеп.

Нәсимә апа кирелегән җиңде, өстенә иске бишмәтен киде дә тышка чыгарга җыена башлады.

— Аны әле тотасы да бар, — диде, сукранып.

— Әйдәгез әле тотып бирик мур кыргырыны! — диде Фәгыйлә апа, күңелләләнеп.

Без шаулашып тавык тотарга чыгып киттек.

## VII

Кычкыртып бер «симез» тавыкны тотып та алдык. Нәсимә апа тавыкның ике канатын каерып кулына тотты да, зур галошларын өстерәп, күрше картларга кереп китте. Бераздан күрше карты белән аның

аллы-артлы лапаска китеп барганнары күренде. Күп тә үтмәде, анда, лапас астында ак тавыкның тамак ярып бар көченә кычкырганы ишетелде. Озак кычкыра алмады — тавышы өзелеп, кисәк кенә тынып калды.

Нәсимә апа тавыкны эштер-өштер генә йолкып бирде. Кул очына гына тоттым да чаптым тагын урам буйлап.

Мин кайтып кергәндә, сәгать унике тулган, беренче китеп бара. Соломон Моисеевич белән хатын-кызлар һаман безнең бүлмәдә утыралар. Өстәл тирәсен әйләндереп алганнар да, дөньяларын онытып, рәхәтләнеп карта уйныйлар. Минем тавык күтәреп кайтып кергәнне күрделәр дә, дәррәү кубып шауларга, ура кычкырырга тотындылар.

— Молодец, Саҗидә! — ди Соломон Моисеевич, барысын да уздырып.

Мондый мактау сүзенә минем түбәм күккә тиде. Кыюланып Соломон Моисеевичның матур кара күзләренә карыйм, көләм, елмаям.

Чуендагы су инде кайнап чыккан. Тавыкны бер кат пешекләдек тә, шул көе чуенга салдык. Аннары тегесен-монысын әзерләргә тотындык. Бәрәнге әрчедек, Гайшә апалардан куна такта, уклау ише нәрсәләр алып чыгып, камыр җәйдек. Без дигәч тә, Зөһрә белән икәү эшлибез. Кунаклар һаман карта уйныйлар, көлешәләр, шаулашалар. Бары Мәдинә апа гына шауламый, уенга да катышмый. Безнең янга килеп булышкандай итә, тегесен-монысын сораштыра.

Шулай әзерләнеп ятканда, минем янга тагын Улечка килеп җиткән. Серле генә итеп бу мине икенче якка чакырып чыгарды да:

— Акыллым, — ди, пышылдап, — булгач булсын инде, тавык янына бер ярты куймый ярамас. Соломон Моисеевич кайчагында салырга ярата.

Нәрсә әйтәсең инде моңа? Мин бик шат. Соломон Моисеевич өчен булгач, икеләтә, өчләтә шат.

Тагын бу миңа акча сузды, бар әле, тиз генә кибеткә барып кил, ди.

— Сез минем кунаклар, мин — хуҗа, — димен эре генә, акчаны кире кагып.

Онга-камырга буялган кулларымны юдым да, кечкенә сумканы кулга эләктереп, чыгып киттем кибеткә. Аракы сорагач, сатучы миңа сәерсенеп карады.

— Начальство өчен. Яңавылдан килделәр, — дигән булам, никтер акланган сыман.

— Ярый торган эш, — ди сатучы. — Алар майлаганны ярата.

Ярты литр ак белән ярты литр кызылны алдым да кайтып та киттем.

Тиздән аш житеште. Аш җитешүгә генә диярлек Таня кайтып керде. Аны шаулашып каршы алдык. Шуннан соң Гайшә апалардан барыбызга да җитәрлек табак-савыт алып чыктык, бердәнбер өстәлне җайлап бордык та, кунакларга ике яклап утырырга куштык. Мин Таня белән аш бүлдем, табын әзерләдем, Улечка стаканнарга, йомырыларга аракы агызды.

— Хуҗаны түргә! Соломон Моисеевич янына! — диделәр кызлар, чыркылдап.

— Кил, кил монда! — ди Соломон Моисеевич, өстәл аша миңа кулын сузып.

Шатлыктан, дулкынланудан кисәк кенә башым әйләнеп китте. Үзем карышкан булам, ник карышамдыр — үзем дә аңламыйм. Мин карышкан саен кызлар ныграк кычкыралар, кыстыйлар. Кулдан тарткалап диярлек мине шулай да Соломон Моисеевич янына утырттылар. Улечка һәркемгә үз алдындагы стаканын, йомырысын алырга кушты. Соломон Моисеевич нииндидер тост әйтте, кызлар тагын көлештеләр. Улечка эчәргә кыстады.

Соломон Моисеевич яртылаш аракы салынган стаканны житез генә күтәрде дә авызына каплады. Эчкәндә аның ефәк галстук төене кыймылдап-кыймылдап куйды.

— Эч, Сажидә, берни булмас! — диде бу, минем аркадан сөеп. — Мин монда. Үзем рөхсәт итәм.

## VIII

Мәжлес бик күңелле узды. Барысы да бик канәгать булдылар, көлделәр, шаян сүзләр әйтештеләр. Күбрәк Соломон Моисеевич көлде. Без барыбыз да аның авызына гына карап утырабыз. Берәр сүз әйттеме, аны-моны карамыйча, шыркылдашырга гына торабыз.

Мин бөтенләй диярлек эчмәдем. Шулай да нишләптер исергәндәй булдым. Миңа кинәт бик кызык була башлады. «Соломон Моисеевич мине Улечкага караганда ныграк ярата», дип уйладым мин күңелемнән. Ул вакытта мин үземне әйтеп бетергесез дәрәҗәдә бәхетле итеп сиздем.

Ашап туяр алдыннан гына кемдер шоферны исенә төшерде.

— Их, алданрак әйтмәгәнсез! — дидем, өтәләнеп.

Плитә өстендә утырган зур чуенны аударып караган идем — ашның тамчысы да калмаган! Миннән шаулашып көләргә тотындылар.

— Улечка, берәр йөз грамм чыгарып бир, җылынсын, — диде Соломон Моисеевич.

Улечка урыныннан торды, стаканга яртыдан күбрәк аракы агызды. Бер кулына бер телем икмәк, икенче кулына стаканын тотып, тышка чыгып китте. Без, тын калып, кызыксынып, Улечканың кергәнен көтә башладык.

— Йоклап киткән, — диде Улечка, кергәч буш стаканын өстәлгә куеп. — Тагын яварга тора, нишләрбез икән, Саша?

— Икенче тавык суярга кушарбыз! — ди Соломон Моисеевич.

— Икенче тавык пешкәнче әллә барып кайтабызмы соң? — ди Улечка. — Сәгать өч тула. Бүген өлгермәвебез мөмкин.

— Мин һәрвакыт әзер! — ди Соломон Моисеевич.

Шулай диде дә бу, миңа карап алды. Мин аның нәрсә әйтергә теләгәнлеген сүзсез дә аңлап алдым. Табак-савытны Зөһрә белән Таняга юарга куштым да, авыл Советына кереп киттем.

Ат туарып куелган. Кештерт-кештерт китереп утлыктан печән ашап тора. Авыл Советы дежуры миңа мыгырданып алды: Куштирәккә барасы кеше шушы вакытка каламыни, диде, аннан әле әйләнеп тә кайтасы бар, диде. Шулай да атны җикте, дилбегәне миңа тоттырды да, фәлән вакыттан да соңга калмагыз дип, капка төбенә чаклы озата килде.

Минем ат тотып кайтканны күреп, пункттан бер-бер артлы кунаклар чыкты. Мин өйгә кереп, аягыма бота, өстемә плащ кидем.

Чыксам, тарантасны уратып алганнар да, нәрсә турындадыр сүз көрәштерәләр. Кемнәр иң әүвәл арбага утырып барырга тиеш диган мәсьәләне хәл итәләр икән.

Ат яхшы булса да, тарантас бәләкәй — алты кешене күтәрерлек түгел. Аннары, тарантаска алай төялеп тә йөрмиләр ләбаса.

Кызлар үзара сүз озайткан арада, Соломон Моисеевич беренче булып менеп тә утырды.

— Ярый, кызлар, сез сатулаша торыгыз, мин китә торыйм, — диде. Дилбегәне алды да, атка кагып та җибәрде. — Кем утырырга тиешлеген килеп әйтерсез! На-а!

Ат кузгалып китү белән, Соня бер яктан, Улечка икенче яктан тарантаска килеп утырмакчы булдылар. Соломон Моисеевич артына карап бер елмайды, кул болгады. Кызлар беркадәр җир йөгергәндәй иттеләр дә, көлә-көлә артка калдылар.

Шулай көлешеп-шаярып без юлга чыктык. Мин утыру турында уйламадым да. Җәяүләп мин хәзер әллә кайларга барырга әзер. Тик алдан Соломон Моисеевич кына барсын!

Авылны чыккач, ул безне көтеп алды, артына борылды да, елмаеп:

— Ягез, кызлар, кем куып җитә? — диде.

Соня кыланып йөгереп караган булды. Соломон Моисеевич шундук атын куарга тотынды. Бераз гына чаптырды да тагын атлатып бара башлады. Без, пычрак юлда ләпек ярып, шат, көр күңел белән, батырларча аның артыннан атладык.

## IX

Көн болытлы. Дымсу. Ике якта да сөрелгән кара җирләр җәелеп ята. Тракторлар юлны сөздереп киткәннәр. Юл әле тиешенчә тапталмаган. Тарантас тәгәрмәченә калын булып ләпек урала, аякларга балчык сылаша. Күтәрерлек тә түгел.

Соломон Моисеевич тарантаска кырын-ярын яткан. Әледән-әле безнең якка карап ала, елмаеп берәр нәрсә әйтеп куя. Аның шулай безгә бер елмаеп каравы була, тиленләр кебек без шундук көләргә тотынабыз. Ни өчен көлгәнлегебезне үзебез дә аңламыйбыз. Техникумда укыганда безгә бер укытучы әйткән иде: биш минут көлү ике сәгатьлек ялны алыштыра дигән иде. Күрәсең, дөрестер. Мин ул көнне уникe чакрым җир барып тамчы да арымадым.

Таш юлга чыккач, Соломон Моисеевич безне көтеп алды, Мәдинә апага үзе янына утырырга кушты. Мәдинә апа утырмады: рәхмәт, мин җәяү йөрергә яратам, диде. Соломон Моисеевич тагын берүзе кузгалып китте. Киткәндә артына борылды, уч төбен үпте дә, сау булыгыз дигән сыман, безгә кул болгады.

Атка үзе генә утырып ул, билгеле, дөрес эшләде. Әгәр дә мәгәр безнең берәребез утырса, икенчебез үпкәләр иде. Үпкәләмәсә дә, хәтере калыр иде. Ул әнә үзенең Улечкасын да утыртмады. Кем белә бит әле — үзенеке микән? Күрәсең, түгелдер. Кеше сүзе генәдер. Ул, ахрысы, чынлап та мине ярата. Ихластыр менә, шулай, ахрысы!

Шулай үз алдыма хыялланып, күзем маңгаема менеп бара идем, көтмәгәндә ниндидер чокырга батып киттем. Бу вакытта инде без, таш юлдан чыгып, ниндидер болынлыкка килеп кергән идек. Безнең юлны аркылы кисеп, ниндидер су агып ята. Су тирәсе баткак, сазлык. Башкалар җиңел генә чыгып китте, мин ничектер карамыйчарак калдым. Уң аяктагы бота сазга керде дә калды.

Тартам-тартам — һич алып булмый. Үзем көләм, үзем кычкырам. Барысы да миңа борылып караганнар. Алар да көләләр, шаярткан булалар. Гөнаһың күп, ахрысы, шуңа күрә баттың, диләр. Җир йота хәзер, васыятьләреңне әйтеп кал, диләр. Үзләре минем янга җыела башладылар. Соломон Моисеевич та атын туктатты, сикереп җиргә төште. Карасам, туп-туры минем янга килә! Аягында яхшы кызыл туфли. Шакмаклы чалбары әйбәт итеп үтүкләнгән. Пычракны уйлап та бирми — килүен белә! Килеп җитте дә, кулын сузып:

— Бир кулыңны! — диде.

Кулны сузарга да итәм, кыюлык та җитми. Суздым исә, никтер егылып китәрмен төсле.

Мин шулай икеләнеебрәк торган арада Соломон Моисеевич ике куллап минем билдән кысып тотты да, күз ачып йомганчы күтәреп тә алды. Мин кинәт хәлсезләнеп калдым. Беркайчан да булмаганча хәлсезләнеп, йомшап калдым. Мин аны шулкадәр көчледер, үземне шулкадәр җиңелдер дип һич тә уйламаган идем. Юан дип мин үз-үземне юкка гына кимсетәм, ахрысы. Чынында мин бик нечкә, бик җиңел бугай.

Шулай мине күтәрде дә, бер-ике адым читкәрәк алып куйды. Аягыма басыйм дигән идем, бота ләпектә торып калган! Китте чыр-чу, китте көлеш!

Соломон Моисеевич мине инде ычкындырып өлгергән иде. Мин аягымны югары күтәрдем, чайкалып киттем. Ярый әле янда гына Улечка бар иде — аңа тотынып калдым. Ул арада Соломон Моисеевич иелеп ләпектән сыңар ботаны тартып алды.

— Соломон Моисеевич Саҗидәне кул очында гына йөртә!

— Өрмәгән җиргә дә утыртмый!

— Тикмәгә генә түгел бу, нидер бар монда! — диештеләр кызлар, шаяртып.

Мин аларның уйнап сөйләгәннәрен бик яхшы аңлыйм, шулай да тиле күңел нишләргә белми: үсенә, җилкенә.

## X

Куштирәк — бәләкәй авыл. Бер генә урамлы. Тигез җиргә утырган. Урамында яшел чирәм. Тыныч, күңелле.

Килеп төшкәч тә бөтен көтүебез белән авыру бала яткан өйгә китмәдек. Куштирәктә медсестра бар иде. Иң элек без шуларга юнәлдек.

Урамнан узганда күреп барабыз: тәрәзәләргә кешеләр капланган. Кайберәүләр тавыш-тынсыз гына киртә-койма аша карап кала. Барысы да безгә исләре китеп карыйлар төсле. Мин шундук көлүдән туктадым, башны югарырак күтәрдем, әле һаман пырх-пырх килеп барган Соняга җиңелчә генә шелтә ясап алдым. Бит монда «минем авырулар» яши! Алар мине күреп торалар, сынап карыйлар. Алар алдында әдәпсезләнеп, авыз ерып бармассың лабаса!

Җыйнаулашып барып төштек медсестра тора торган йортка. Өйдән бер агай белән бер-ике хатын-кыз килеп чыкты. Яшьрәге — медсестра. Икенчесе аның әнисе. Килеп чыктылар да, елмаешып капка ачтылар, йөгәненнән тотып атны ишегалга алып керделәр, исәнләштеләр, хәл-әхвәл сораштырырга тотындылар.

Без тыныч кына ишегалга уздык, җыйнаулашып өйгә кердек, сәлам бирдек. Хуҗа хатын тыз-быз килеп самавыр куярга тотынды. Өй эче җылы, җыйнак. Идән ап-ак итеп юылган, тәрәзәләргә ап-ак кашагалар, пәрдәләр эленгән. Мендәрләр яхшы итеп кабартылган. Өстәлдә өр-яңа клеенка. Исләре килеп тора. Урындыкларда чуар чүпләмнәр. Мич ап-ак, мич алдына чаршау корылган. Бөтен җирдә чисталык, пөхтәлек.

Хуҗалар безгә: чәй өлгергәнче ял итеп алыгыз, диделәр. Без алай кыстатып тормадык, кайда урын бар — шунда утырыштык.

Минем утыруым булды, яныма Улечка килеп тә җиткән.

— Акыллым, җылы сулары юк микән, сора әле, — ди миңа русча пышылдап. — Соломон Моисеевич юынырга тели.

Мин, чаршау артына чыгып, Улечканың теләген белдердем.

— Юынгычта су җылы, юыныгыз, юыныгыз! — ди хуҗа хатын. — Сабыны да шундадыр. Халисә, карале, шундамы?

— Шунда, шунда! — ди Халисә, юынгач янына барып әйләнгәч.

Мин, олы якка чыгып, юынырга мөмкин икәнлеген әйттем. Соломон Моисеевич никтер кәефсез күренә. Ниндидер начар ис сизгән кебек, борынын тартып-тартып ала. Мин дә шикләнеп борынны тартып карадым, юк, андый-мондый ис сизелми.

Соломон Моисеевич юынган арада без Улечка белән нишләргә кирәклеге турында киңәшеп алдык. Иң элек авыру бала янына барып

кайтырга булдык. Шуннан соң, йортлар борынча йөреп, бөтен авылны карап, тикшереп чыгарга кирәк булыр, дидек.

Улечка тиз генә Соломон Моисеевич янына барып килде дә:

— Акыллым, сора әле, бирәр таска су әзерләп бирмәсләрме, — ди миңа. — Соломон Моисеевичның туфлиләрен юарга кирәк.

Мин тагын апага моның үтенечен белдердем. Апа, озак көттермичә, эмальле таска казаннан җылымса су салып бирде. Суны Мәдинә апа алды. Тышка чыгып китте. Сизеп торам, Соломон Моисеевичның туфлиләрен юарга аңа Улечка кушкан.

Шуннан соң мин ашыгып Мәдинә апа артыннан чыгып киттем. Чыксам, чыннан да Мәдинә апа, сукрана-сукрана, кызыл туфлиләрне юып ята!

— Хәшәрәт! — ди үртәлеп. — Барин булган, әрәм тамак!

— Мәдинә апа, каяле, үзем юыйм? — дидем мин иплән кенә.

## XI

Бераз торгач без Улечка белән, Гөлчирә белән авыру баланы карарга киттек. Соломон Моисеевич бармады, тагын да: мин сиңа ышанам, Улечка, диде. Соня белән Мәдинә апа урамның бер ягы буйлап өй борынча йөрергә тиеш булды. Медсестра Хәлисә безгә иярде.

Юлда килгәндә мин никадәр шат, гамьсез булмыйм, шулай да авыру бала янына барганда тынычсызлана башладым. Барыннан да элек мине: диагнозым дөрес микән? дигән сорау борчыды. Мин, билгеле, үзем куйган диагнозның дөрес булуын телим. Калганы турында бик үк кайгырмыйм да. Янында шулкадәр күп медиклар булганда, кайгырасың килсә дә кайгырмассың!

Барып җиттек. Хуҗалар безне борчулы, куркынган йөз белән каршы алдылар. Аяк киемнәрен чиста итеп юылган баскыч төбендә калдырдык та, өйгә кердек. Авыру бала янына килдек. Баланың баш өстенә аскан кызыл чаршау итәген кайтарып куйдык. Һаман шул ук хәл. Күзләре ярым йомык. Тын алуы авыр. Бите кып-кызыл. Тик бүген тәнендә үзгәрешләр күренә. Ясмык зурлыгындагы кызыл тимгелләр калкып чыккан. Температурасы кичәгечә: 39 чамасы.

Безнең янга шундук баланың әнисе белән әтисе килеп җитте. Барыбыз да, ни әйтер икән бу дип, Улечканың авызына карап катып калдык. Мин инде аңа авыру бала турында сөйләгән идем. Минем әйткәннәр белән генә канәгатьләнмичә, Улечка яңабаштан төпченеп сораштырырга тотынды. Кайчан авырый башлады, башта ничегрәк булды, диде; нинди балалар белән уйнады, диде; авылда шундый ук чир белән чирләүчеләр юкмы, диде. Хуҗаларның әйтүенә караганда, авылда чирләүче балалар юк икән. Димәк, инфекция таралырга өлгермәгән. Монысы инде куанычлы хәл.

Сораштырып бетергәч, Улечка баланың йөрәген, үпкәсен тыңлап карады.

— Куркырлык берни юк, — диде, ниһаять, ата белән анага карап. — Кызамык. Полиомиелит түгел.

Ата белән ана җиңеләеп көрсенеп куйдылар, бер-берсенә карашып алдылар да, бер-берсен бүлеп, такылдарга да керешеп киттеләр.

— Кызамык кына булгач ярый әле ул! — ди абый кеше. — Нәрсә ул кызамык!

— Чиратын үткәргәне яхшы инде, — ди хатыны да.

— Кызамыктан соң баланың үпкәсе шешәргә мөмкин, — диде Улечка. — Бу чүпрәкләрне алып куегыз. Битен капламагыз. Өйдәге һаваны алыштырып торыгыз.

Хуҗалар, рәхмәт әйтә-әйтә, безне озата чыктылар. Аларның хәзер сөйләшүләре дә, үз-үзләрен тотышлары да бөтенләй икенче. Күренеп

тора, кисәк кенә күңелләләнеп китәләр. Йөзләре ачык, ягымлы. Алар гына түгел, мин дә сөенәм. Чын күңелемнән сөенәм. Сөенмичә, уен эшмени ул сиңа полиомиелит!

## XII

Без, күңелле шаулашып, болардан чыгып киттек тә, күршеләргә юнәлдек. Ул көнне без барлык өйләргә кереп чыктык. Авыруларыгыз юкмы, дибез. Чисталык саклау мәсьәләсендә кайбер киңәшләр бирәбез.

Кайсы гына йортка барып кермә, безне ачык йөз белән каршылыйлар. Аннары шунысы куанычлы: һәркемнең ишегалды, абзар-лапас тирәсе чип-чиста итеп себерелгән, бернинди чүп-чар, тирес-салам күренми. Урам ягы, капка аллары да шулай ук чип-чиста, ямь-яшел. Баскычлар, өйалдары, идәннәр ап-ак итеп юылган, өйләр җыештырылган — кунак көтәләрмени! Түшәмнәрдә чебеннәргә каршы ябышкак кәгазьләр асылынып тора, тәрәзә төпләренә чебен даруы салынган тәлинкәләр куелган.

Минем инде авылларда йөргәнем бар. Авыл өенең ничек булганын беләм. Кешенең төрлесе була. Берсе аның бик чиста торырга ярата, икенчесе гамьсезрәк була яисә чисталык сакларга аның яшәү шартлары җитеп бетми. Шулай ук авылларның да төрлесе була. Мәсәгут ягындагы авыллар болай төзек, чиста. Шул авыллар арасында Куштирәк шулай да яхшы яктан ныграк күзгә ташланып тора шикелле.

«Ни булган боларга?» дип уйлыйм мин. Әллә безнең киләсене алдан белеп торганнармы? Менә ничек хөрмәт итәләр безне!

Ихтимал, ул көнне Улечка да, Гөлчирә дә, Соня белән Мәдинә апа да — барысы да шундыйрак нәрсә кичергәннәрдер.

Өйдән өйгә йөри торгач, көтмәгәндә Гөлчирә сорап куйды:

— Нишләп соң боларда бер дә бала-чага күренми? — диде.

Шулай диде дә миңа карап алды, әйтерсең, Куштирәк балаларын мин ашап бетергәнмен!

Мондый сорау миңа баштарак бик мәгънәсез булып тоелды. Ләкин шул ук вакытта мин Гөлчирәнең хаклы икәнлеген аңлап алдым. Чыннан да, баласыз авыл буламыни? Ә боларда укү яшендәге балалар да юк, яшь балалар да юк. Үзләре дә күренмиләр, тавышлары да ишетелми. Әллә ничек — үлеп беткәннәр диярсең! Кемгә кермә, барысы да олылар, барысы да тап-таза, ягымлы, ачык йөзле. Бераз гына киноны хәтерләтә. Ә бит кичәгенәк болай ук түгел иде шикелле.

Бер йортка кергәч, без шул турыда әйттек. Безнең үзебезнең балаларыбыз юк, калганнарны белмибез диделәр болар. Без шуның белән канәгать булгандай булдык. Мәсьәләнең сере миңа бары соңыннан гына беленде.

Былтыр Куштирәктә скарлатина инфекциясе таралган булган икән. Скарлатина авылдагы барлык балаларга диярлек йоккан. Шул турыда белгәч, Яңавылдан килгәннәр дә, авыру балаларны машинага төяп, больницага алып китканнәр. Ата-ана моңа каршы килгән, балаларыбызны үтерергә генә алып китәләр инде дип кайгырышып торганнар. Кичәгенәк мин: Яңавылга хәбәр итәргә кирәк булыр дигәч, авыл халкы шаулашып алган. Без килүгә алдан әзерләнеп торганнар һәм, быел да былтыргы кебек хәл кабатланудан куркып, балаларын кайсы кая качырып бетергәннәр.

Әйе, барысы да олы яшьтә, барысы да тап-таза... Бөтен авылда без бары бер генә авыру таптык. Безгә килеп әйттеләр: фәлән йортта фәлән кеше авырый, барып карамассыз микән, диделәр. Без, керәсе йортыбызга кереп тормыйча, төркемләшеп шунда юнәлдек.

Бу урта яшьләрдәге бер агай булып чыкты. Тимер караватта ята. Баш астында кат-кат мендәр. Аягында иске киез итек. Зур гәүдәле.

Сөякчел, ябык. Аяк-куллары йөрми икән. Сул кулы бөтенләй хәрәкәтләнми, уң кулын бераз кыймылдаштыра. Шулай ук аякларын да көчкә генә кузгата икән. Яздан бирле ята икән.

Улечка бик җентекләп карады, ләкин кистереп кенә бер нәрсә дә әйтә алмады.

— Соломон Моисеевичны чакырырга кирәк булыр, — диде бу, теләр-теләмәс кенә. — Миңа караганда ул нервы авыруларын яхшырак белә.

— Үзем генә чакырып килим! — дидем мин, чәчрәп торып.

— Сиңа гына килмәс, үзем барырмын, — ди Улечка.

Бер биш-алты минуттан ул Соломон Моисеевичны алып та килде. Соломон Моисеевич һаман күңелсез. Мин андагы һәрбер үзгәрешкә игътибар итәм. Минем әле беркайчан да аның болай күңелсез булганын күргәнем юк. Бүген әнә әллә нишләгән. Бүген дә түгел, менә монда гына, авылга килгәч кенә.

Авыруны ул теләмичә генә, эре генә, һавалы гына кыланып карады. Күрәсең, райздрав кешегә гади врач ролендә булу чыннан да күңелле эш түгелдер. Авыру агай берәр каты, тупас сүз ычкындырып ташламасын тагын дип мин чын-чынлап куркып куйдым. Ләкин авыруның үз хәле хәл. Соломон Моисеевичның салкынлыгына ул бөтенләй игътибар итмәде. Әллә шулай күренде генә микән?

Менә авыруны карау тәмам булды. Без барыбыз да җиңел сулап куйдык. Соломон Моисеевич, авыру кешенең тәненә тигән кулларын, резина чүкеч, әнә ише нәрсәләрен спиртлы мамык белән сөртте. Латинча үзенең диагнозын әйтте дә, киләчәктә нишләргә, нинди дарулар кулланырга кирәклеге турында киңәшләр бирде. Мин агайга аның кайбер сүзләрен тәрҗемә итеп тордым. Улечка рецептлар язды.

Авыру агайлардан чыгып барганда, мин Соломон Моисеевич белән Улечка арасында шундый сөйләшү ишетеп калдым:

— Авыл чиста, Саша, — диде Улечка.

— Әйе, идиллия, романтика! — диде Соломон Моисеевич, ирония белән. — Авыл авыл инде ул, нинди генә булмасын...

— Мин алай димәс идем, Саша. Әнә нинди күңелле монда: ямьяшел, бары да төзек, чиста.

— Авылның исемен ишетү белән миндә рефлекс эшли башлый. Авыл минем нервы системама начар тәэсир итә.

— Ләкин Бүә буена балыкка йөрү синең нервы системаңа уңай тәэсир итә! — диде Улечка, көлеп.

— Ул бит балыкка йөрү! — диде Соломон Моисеевич, үртәлеп.

Шуннан башкасын мин ишетмәдем. Ишетәсем дә килмәде. Миңа бик-бик кыен булып китте. Яраткан кешеңнең авызыннан яман сүз ишетү кайчакта бик кискен «рефлекс» тудырырга мөмкин. Ул минутта миндә дә шундыйрак нәрсә булды.

## XIII

Болай да болангыр көнне тиз арада караңгылык басты. Йортларны карап-тикшереп бетергәч, бөтенләй диярлек тоткарланмадык. Халисә колхоз утарыннан ат җигеп алып кайтты. Арбасы тарантас кына түгел, зур арба. Күп итеп арыш саламы салынган. Яхшырак урын алып калу өчен без шундук арбаны сарып алдык, чыр-чу килеп, салам кыштырдатып, урнаша да башладык.

— Кызлар, кем минем янга утыра? — диде шул чакны Соломон Моисеевич.

Аның ягымлы, ачык йөзен күреп, барыбыз да яңадан күңелләнеп киттек. Чәүкә балалары кебек: мин дә мин, дип кычкырырга тотындык.

Соня хәтта, барысыннан уздырмакчы булып, тарантаска барып ук утырды.

— Юк, — диде Соломон Моисеевич, — болай дөрес булмый. Шобагага тотыгыз кызлар, шобага!

Улечка безнең шау-шуга катышмады, уңайсыз елмаеп, үз-үзен кыен сизеп, бер читтәрәк басып тик торды. Мәдинә апаны әйтеп тә торасы юк. Ул инде күптән арбада саламга чумып утыра. Без өчәү: Соня, Гөлчирә, мин.

Мин утынлыктан озын гына чыбык алып килдем. Шуннан соң без көлешә-көлешә шобага тота башладык. Барысы да безгә карап торалар. Соломон Моисеевич елмайган, Халисә елмайган. Мәдинә апа ачулы. Хуҗа абзыйның йөзе берни аңлатмый. Тыныч кына тәмәке пошкырта. Мәсәгуткә чаклы ул ат тотып барачак. Аягына зур күн итек кигән, озын брезент плащ кигән, башында — бүрек, кулында — чыбыркы.

Минем өчен искиткеч бәхетле булды ул көн. Шобагада мин өскә чыктым! Кызлар шаулашып көләргә тотындылар. Гамьсез агай елмаеп куйды. Шатлыктан мин уттай кабынып киттем.

— Мин бик шат, — диде Соломон Моисеевич, елмаеп.

Бөтенесе алдында мине култыклап алды да, киноларда күрсәтелә торган аристократ кызлар кебек итеп, кыландырып мине тарантаска утыртты. Мин йомшак саламга кереп утырдым да аякларны сузып җибәрдем.

Хуҗа агай атны авызлыклады, ат өстендәге дилбегәне Соломон Моисеевичка алып бирде, аннары атны чиктерде, капка ягына борды. Агай бер читтәрәк сабыр гына көтеп торган үз аты янына китеп барды. Барса, арбада үзенә урын да калмаган!

— Әллә берәрегез күчеп утырасызмы, кызлар? — диде безнең якка карап. — Авыррак булмасмы. Бер атка биш кеше, бер атка ике кеше. Тигез түгел.

— Нәрсә сөйли ул? — диде Соломон Моисеевич, аның ризасыз тонын сизенеп.

Мин аңа агайның сүзләрен тәрҗемә итеп бирдем.

— Без икебез биш кешегә торабыз! — дип кычкырды Соломон Моисеевич, алдагыларга ишетелерлек итеп.

Кызлар көлештеләр. Агай көлмәде.

— Миңа ярый. Хайван хакы бар, — диде.

Шуннан ул арба кырыена гына урнашты да дилбегәсен кагып җибәрде. Майланган арба җиңел генә кузгалып китте. Соня бер дә юктан чыркылдап җибәргән булды, борылып безнең якка йодрык күрсәтте.

Беренче ат артыннан без дә кузгалдык.

## XIV

Авыл бик тиз артта калды. Авылдан чыккач та басу башланды. Тирә-як караңгы. Караңгылык аша якында гына булып болганчык күк йөзе күренә дә, беленер-беленмәс кенә җир өсте күренә. Бар яктан да сине нидер чолгап алган кебек, шулай да монда үзенә бер төрле киңлек-иркенлек сизелә. Кырлар-басулар иркенлеге генә түгел, күңел иркенлеге. Авылдан, шәһәрдән чыккач, мин һәрвакыт шундый күңел иркенлеге тоям. Мин үземне ниндидер тоткынлыктан котылгандай хис итәм. Минем бик борынгы ата-бабаларым бер урыннан икенче урынга күчеп йөргәннәр, бөтен гомерләрен киң далада, кырда-басуда үткәргәннәр. Күрәсең, миндә әле булса шул ата-баба каны кайныйдыр.

Куштирәктән чыгып бераз җир киткәнче шулай булды. Ләкин мондый иркенлек тойгысы шулай да озакка бармады. Күп тә үтмәде, мин

үземне яңадан тоткынлыкта итеп сизә башладым. Беренче исерткеч шатлык-куаныч тиз арада юкка чыкты. Көтмәгәндә мине тыелгысыз бер каушау-курку тойгысы, ни өчендер тартыну, газаплану тойгысы биләп алды. Мин тынып калдым, бөрешеп, йомылып калдым.

Мондый курку-каушауның ахмаклык икәнлеген мин үзем дә аңлыйм. Чуалган уй-фикерләремне, таркалган ихтыяр көчен бергә тупларга азапланам. Ләкин берни эшләп булмый. Мин дисәң мин түгел, әллә кем шунда. Куллар да минеке түгел, аяклар да, баш та, йөрәк тә...

Кичке һава салкын. Тирә-як тын. Бик тын. Җәйге вакыттагы кебек кошлар чыр-чуы да ишетелми, чикерткәләр сайравы да ишетелми. Юл пычрак, лыстыр-лыстыр ат тарта, тарантас тирбәлә, юлда сыек ләпек пычтырдый, тәгәрмәчләрдән ычкынган балчык кисәкләре шап та шоп артта төшеп калалар.

Мин тыңлыйм, юк-бар нәрсәгә колак салам, тояк тавышларына, артта чәчрәп калган балчык тавышларына игътибар иткән булам, ә күңелем бөтенләй икенче нәрсәдә. Минем уң ягымда утырып барган, мине чикләп-богаулап алган, шул ук вакытта мине магнит сыман үзенә тарткан зур, серле нәрсәдә...

Нишләргә, үз-үземне ничек тотарга? Нәрсә дияргә? Ничек сүз башларга? Ялгышмадыммы мин аның янына утырып? Менә ул мин теләгән кеше, мин хыялланган кеше. Караңгы басулар буйлап шушылай аның белән икәүдән-икәү тарантаста утырып баруны мин хәтта төшемдә дә күрмәдем. Минем өчен моннан да зур бәхетнең булуы мөмкинме? Ләкин нишләп соң куркам, нишләп газапланам, ни өчен мин бернинди шатлык, куаныч тоймыйм?

Күңелдә минем шундыйрак уйлар бутала. Мондый уйлар миңа бик катлаулы, бик авыр булып тоела. Күпмедер вакыт мин шундый каршылык эчендә барам.

— Карале, Сонечка, нинди гүзәллек! — ди минем уң яктагы кеше, әкрен генә пышылдап.

«Сонечка» дигән сүз мине чиркәндереп җибәрә. Сажидә башым белән нишләп мин «Сонечка» булыйм ди!

— Мин бит Сонечка түгел, — димен. — Сонечка алдан бара.

— Анысы — алдагы Сонечка, син — арттагы Сонечка.

— Мин алдагы Сонечка да түгел, арттагы Сонечка да түгел! — димен мин. — Мин — Сажидә.

— Әлбәттә, Сажидә! — ди Соломон Моисеевич, тиз генә минем белән килешеп.

Шулай диде дә бу, иплэп кенә кулын минем иңбашка салды. Миңа бу әллә ничек тәэсир итте. Ямьсез булып, тупас булып тоелды. Иңбаштагы авыр кулны минем читкә этәрәсем килә, ләкин берни эшли алмыйм. Тагын да ныграк тынып-йомылып калам.

— Төнлә нинди күңелле, Сажидә! — ди Соломон Моисеевич, әкрен генә, серле генә. — Менә без синең белән утырып барабыз. Әкияттәге кебек, ә?

Шулай сөйләнә-сөйләнә үзе һаман миңа елыша. Хәер, анда инде елышасы да юк. Без болай да бер-беребезгә терәлеп утырабыз. Ул бары башын гына миңа таба ия төшә дә, иңбаштагы кулын аскарак, бил турысынарак шуыштыра. Шуыштырып китерде дә бу, минем билдән кочып алмакчы булды.

— Кыен... — дидем мин кыюсыз гына, кымшангандай итеп.

— Кыен шул, — ди Соломон Моисеевич, бернинди каршылыксыз.

Бераз вакыт без тып-тын гына барабыз. Минем йөрәк дөп-дөп тибә, яңаклар кызыша. Соломон Моисеевич минем белән шундый үз итеп сөйләшә, минем алда үзен шундый ышанычлы итеп тота — аның белән үземнең арада мин кинәт туганнарча бер якынлык тойгандай булам. Курку-каушау юкка чыга, ихтыяр көче кире үземә кайта.

## XV

— Сез Мәскәүнең үзеннәнме, Соломон Моисеевич? — димен, сүз башлап.

— Әйе, Саҗидә! — ди Соломон Моисеевич җиңел генә, елмаеп.

Мин аның йөзен күрмим, ләкин елмайганлыгын бик яхшы сизәм. Тавышы буенча.

— Кайда торасыз соң сез анда?

— Кызыл Мәйданда, Кремльгә каршы, — ди Соломон Моисеевич.

Миңа ул шаярта шикелле тоела.

— Алдыйсыздыр әле, — дигән булам, көлеп.

— Нишләп алдыйм ди?! Чынлап, Саҗидә! — ди Соломон Моисеевич.

Ул моны ант итеп әйткәндәге кебек әйтә, ләкин бик җиңел генә, көлеп сөйләшкәндәге кебек кенә әйтә.

— Кызыл Мәйданда кеше торамыни! — димен мин, аның ялганын тотмакчы булып.

— Ник тормасын, тора! — ди бу.

— Алдыйсыз ла сез! — димен тагын да. — Анда теге рәсемнәргә төшерелә торган чиркәү белән мавзолей гына түгелмени?

— Анда кешеләр яши торган йортлар да бар. Зу-ур йортлар! — ди Соломон Моисеевич, өч яшьлек балалар белән сөйләшкән шикелле.

— Их, күңелледер анда! — димен мин, хыялга бирелеп.

— Синең Мәскәүне күргәнең юкмыни?

— Юк шул.

— Телисеңме, мин сине алып кайта алам Мәскәүгә.

— Мәскәүгә?! — димен мин, исем китеп.

— Әлбәттә, Мәскәүгә! Киләсе елга, җәй көне... отпуска вакытында.

Мин тагын тынып калам. Тагын йөрәк ешрак тибәргә тотына. Тагын күңелгә мең төрле уй-хыял килә. Мәскәүгә?! Соломон Моисеевич белән! Белмим... Мөмкин микән ул?

— Сез бит болай гына әйтәсез, — димен әкрен генә.

— Юк, Саҗидә... — ди бу, шулай ук әкрен генә, серле генә пышылдап.

Уң кулындагы дилбегәне тарантасның кәкре тимеренә эләктереп куйды да бу, яртылаш миңа таба борылып утырды. Бушап калган уң кулы белән минем кулны тотып алды. Карангыда тагын да нурлырак булып, серлерәк булып күренгән зур кара күзләрен төбәде дә:

— Әйе, чынлап әйтәм, Саҗидә, — диде елмаеп, пышылдап.

Мин эндәшмим. Эндәшә алмыйм. Телем кәрмәлә. Әйтер сүз дә табылмый. Минем ышанасым килә. Мин инде ышандым да кебек. Ләкин аңа ничек әйтәсең шул турыда? Аның мине җиңел акыллы дип, бик тиз ышанучан дип уйлавы мөмкин.

Күпмедер вакыт тавыш-тынсыз барганнан соң мин тагын беренче булып сүз башлыйм.

— Институтка керү сезгә авыр булдымы, Соломон Моисеевич? — димен.

— Юк, — ди Соломон Моисеевич. — Урта мәктәпне мин алтын медаль белән тәмамладым.

— Алтын медаль белән?!

— Әйе.

— Алайса, сез имтихансыз гына кергәнсез.

— Әйе. Аттестатны күрсәттем дә, кердем дә киттем... киногa кергән кебек.

— Нинди бәхетле кеше сез, Соломон Моисеевич! — димен мин, ихлас бер көнләшү белән.

— Юк, бәхетле түгел, — ди Соломон Моисеевич, чак-чак кына уйчанланып.

— Бәхетле түгел?! Ник, Соломон Моисеевич?

— Институтны бетергәч, мин аспирантурага керергә тиеш идем. Алмадылар. Көчләп менә монда авылга җибәрделәр.

— Әллә сезгә чынлап та ошамый бездә? — димен мин.

— Юк, ошый, Саҗидә! — ди Соломон Моисеевич, шат күңел белән.

— Бездә күңелле! — димен мин, аның шул шаяртып әйткән «ошый» сүзенә дә куанып. — Бүә буе үзе ни тора! Урманнар, болыннар!

— Идиллия! Романтика!

— Чынлап, Соломон Моисеевич!

— Аспирантура тагын да күңеллерәк, Саҗидә.

— Институтка керүен керсәм, аспирантуралар турында баш ватып тормасыем әле.

— Бик керәсең киләме институтка?

— Бик килә, Соломон Моисеевич. Мин барыбер керәчәкмен. Кайчан да булса керәчәкмен! — димен мин, батыраеп.

— Мин сиңа булыша алам, Саҗидә, — ди бу тагын әкрен генә, серле генә пышылдап.

— Ничек? Нәрсәгә?

— Институтка керергә. Мәскәүдә минем дуслар, танышлар җитәрлек. Аннары әти минем профессор.

— Профессор?! Менә белмәгәнием...

Борылгандай иттем дә, карап барам күзләремне зур ачып.

— Әйе, профессор, — ди Соломон Моисеевич, елмаеп.

«Нәрсә, мине сынап карамакчы була микәнни?» дип уйлап алдым шунда үз алдыма.

— Юк, мин алай кермәячәкмен, — димен мин нык итеп.

— Шәп кыз син, Саҗидә! — ди Соломон Моисеевич, мактап.

Шулай диде дә бу, искәрмәстән үпте дә алды.

## XVI

Бу бөтенләй көтмәгәндә булды, кинәт кенә булды. Мин ни әйтергә дә белми калдым. Минем әле моңарчы беркемнән дә үптергәнем булмады. Үбешүне мин, гомумән, начар нәрсә дип исәплим. Минем карашымча, бары киноларда гына, романнарда гына үбешәләр. Аннары аерылышканда вокзалда үбешәләр икән әле. И, яратмыйм да шул картаеп беткән кешеләрнең ярдай халык алдында чут та чут үбешүләрен! Ә тормышта... чын тормышта минем беркайчан да үбешкәнне күргәнем юк.

Китапларда язылганча мин бернинди ләззәт тә, рәхәт тә тоймадым. Бу үбешү ничектер чиркәнгеч, җирәнгеч үбешү булды. Янымда утырган кешене олылау, хөрмәтләү хисе кинәт кенә юкка чыкты. Минем күз алдында ул кечерәеп, гадиләнеп калды. Шулай да ул вакытта мин аңа ачулана да алмадым, каршылык та күрсәтмәдем. Ул тагын кочты, тагын үпте.

Ат әкрен генә юыртуында булды. Колакка шул чакны алдагы арбада утырып барган кызлар тавышы чалынып калды. «Күрделәр микәнни?» дип уйладым мин, куркып. Таштай катып калган авыр гәүдәмне кузгаткандай иттем дә, чәчне, яулыкны төзәткәләп куйган булдым.

Икебез дә тынып калдык. Бер-беребез янында икебезгә дә кыен, уңайсыз кебек. Ләкин беркая бара алмыйбыз. Арба тар, урын тар. Җәяүләп китеп барыр идең, булмый, мөмкин түгел. Телисеңме, теләмисеңме — барырга туры килә шулай парлашып.

— Сез бит мине яратмыйсыз, Соломон Моисеевич, — димен мин беркадәр тынычлангандай иткәч, үпкәләп.

Соломон Моисеевич эндәшми. Минем моңа хәтер калгандай булды. Минем ничек тә аннан «яратам» сүзен әйттерәсем килә башлады.

— Сез бит болай гына... — димен тагын да.

Монысында инде «яратмыйсыз» дигән сүзне әйтергә телем бармый. Шул ук вакытта күңелгә: «Әллә елап җибәрим микән?» дигән бер уй килә. Елап җибәрдем исә, Соломон Моисеевич мине юата башлар, иркәләр, яратам, кадерлем дияр шикелле тоела. Бит театрда һәрвакыт шулай итәләр!

Шулай да мин еларга өлгерми калдым. Шып итеп кинәт ат туктады. Кызлар чыр-чуы якында гына ишетелә башлады. Күрәсең, туктаганнар да безнең килеп җиткәнне көтеп торалар.

— Соломон Моисеевич, ә, Соломон Моисеевич! — дип кычкыра Улечка. — Түбән Чатка керәбезме, юкмы?

Икебез дә, саңгырау кешеләр кебек, берни эндәшмибез. Улечка бераз тынып торгандай итә дә, соравын тагын кабатлый. Аның сүзен бүлеп Соня кычкыра, Гөлчирә кычкыра. Үлеп беттегезме әллә, диләр; арбадан төшеп калдыгызмы әллә, диләр. Үзләре көлгән булалар.

— Нәрсә, Улечка? — диде, ниһаять, Соломон Моисеевич, тавыш биреп.

Аның шулай «Улечка» дип үз итеп эндәшүе миндә көнләшү шикелле бер нәрсә кузгатып куйды. Атны туктатып, бөтенләй кирәкмәгән нәрсә турында сорашуы өчен Улечкага ачуым килде.

— Исәннәр икән, исәннәр! — дип кычкыра Соня, кыланып.

— Сажидә андамы, төшеп калмадымы? — дигән була Гөлчирә.

— Монда, — димен көттереп кенә.

Улечка, караңгыда пычрак ярып, безнең янга килә.

— Түбән Чатка кереп торабызмы, Саша? — ди.

— Кермәбез, — ди Соломон Моисеевич. — Бу караңгыда нәрсә калган анда!

— Ә Гөлчирә нишләр?

Сизеп торам: Улечка юри сүз озайтып маташа, безнең янда озаграк торасы киләдер инде.

— Нишләсен, менә Сажидәләрдә кунар да, кирәкле медикаментларын алып, иртәгә үз пунктына китәр, — ди Соломон Моисеевич. — Авыл Советы белән сөйләшенгән, бүлмәсе бар. Кирәк икән, Сажидә булышыр. Шулай ич, Сажидә?

— Булышырмын, Соломон Моисеевич, — димен мин.

— Ярый, киттек, — ди Соломон Моисеевич коры гына. — Вакыт тар.

Улечка тавыш-тынсыз гына үз арбасына юнәлде. Без яңадан кузгалып киттек.

«Барыбер «яратам» дип әйтмәде!» дип уйлыйм мин, бүленгән уйларыма кире кайтып. Ник әйтми ул? Юри генә әйткәнме, әллә чынлапмы? Ничек әйттерергә аннан ул сүзне?

## XVII

Соломон Моисеевич мин көткән сүзне барыбер әйтмәде. Мәсәгуткә кайтып җиткәнче без рәтләп берни сөйләшмәдек. Әллә сөйләштек микән соң? Никтер хәтердә калмаган...

Ә Мәсәгуткә без бик тиз кайтып җиттек. Кайтып җиттек тә пункт турысында арбадан төштек. Авыл Советы дежуры көтеп торган икән — атны шундук алып китте. Куштирәк агае да, үз бурычын үтәгәч тә, үзләре ягына борылды. Безнең каршыга йөгереп Таня чыкты.

— Чәй кайнаган, эчәсезме? — диде.

Соломон Моисеевич тизрәк кайтып китәргә ашыкты. Безне көтә-көтә ялыгып беткән шофер машинасын кабызды. Соломон Моисеевич, Улечка, Соня, Мәдинә апа безнең белән саубуллаштылар да машинага кереп утырдылар. Таня капка ачты. «Ашыгыч ярдәм» машинасы иплән кенә капкадан чыкты, юлга борылды, як-якка чайкалгалап, урам буй-

лап китеп барды. Без өчәүләшеп капка төбендә торып калдык. Озаттык та, капканы ябып, өйгә кердек.

Миңа күңелсез. Никтер елыйсы килә. Ләкин Гөлчирә бар — аның алдында еларга ярамый. Минем ни өчен елаганымны сизенүе мөмкин. Болай да әллә нәрсәләр уйлыйдыр әле.

— Сиңа хат бар, — диде Таня, өйгә кергәч.

Өстәлдә чыннан да хат ята. Кемнән дисәң, Галиядән икән. Ачтым да укый башладым.

«Минем, дигән, күптәнге хыялым тормышка ашты, дигән. Мин институтта укый башладым, мин — студент! дигән. Медтехникум укучысы гына түгел, студент, дигән. «Студент» сүзен зур итеп язган. Безнең группада яртысы кызлар, яртысы жегетләр, дигән. Көн дә лекция тыңлыйбыз, анда чабабыз, монда чабабыз — ашарга да вакыт юк, аяк өсте генә ашыйбыз, дигән. Лекцияләрне атаклы профессорлар укый, бер аудиториядә өчәр йөз кеше була», дигән.

Шулай үзе турында әз-мәз генә язган да мине тәнкыйтьләргә тотынган. Мин аңа авылга килгәч тә нишләвем, кемнәр белән танышуым, вакытны ничек уздыруым турында язган идем инде. Галиягә минем бер нәрсәм дә ошамаган.

«Әһә, дигән, авыл жегетләре белән таныштыңмы, дигән. Хәзер инде авыл хатыннары белән ызгышып йөри башлагансың икән, дигән. Сиңа инде кияүгә генә чыгасы да, бала табасы, мал-туар үрчетәсе генә калган, дигән. Үрчет әйдә, үрчет, мин сине бик яхшы беләм — күрәсең, син инде мәңгегә шунда күмелеп калырсың, дигән. Бака тавышы тыңлап, сыер савып, бала күлмәкләре юып гомерең үтәр», дигән.

Шулай да хатының азагында миңа ярдәм кулы сузмакчы булган бу. «Кулыңа китап тотып караганың бармы берәр вакыт, дигән. Искә төшерәсеңме безнең бергә укыган чакларны, искә төшерәсеңме безнең берберебезгә биргән антларны, дигән. Кеше булырга омтылу, дәрт, ялкын бармы әле синдә әз генә булса да», дигән.

Хат мине бик нык уйга калдырды. Юлда булган нәрсәләр шундук онытылды. Нишләптер мин хәзер Галиягә сукырларча табына алмадым. Аның сүзләрендә миңа ниндидер хаксызлык бар сыман тоелды. Мин әле аны гаепләргә дә жыенмадым, аннан баш тартырга да уйламадым. Шулай да күңел түрендә ниндидер үзгәреш барлыкка килде. Мин үземнең кайсыдыр мәсьәләдә аннан өстенрәк икәнлегемне аңладым.

Бит ул минем мондагы тормышны тулысынча белми. Ул бары хатлар буенча гына фикер йөртә. Ярар, кайбер нәрсәдә ул хаклы да булсын... Ә инде «күмелеп калу» мәсьәләсендә, эш, уку мәсьәләсендә... Юк, анысында ул ялгыша, бик нык ялгыша! Дөрес, минем әле ул әйткән китапларны — физика, химия дәреслекләрен кулыма да алганым юк. Ләкин дөньяда бит андый дәреслекләрдән башка да китаплар житәрлек! Мин инде аларның күбесен укып та чыктым. Тик әле укып кына бетерә алмадым. Күрәсең, беркайчан да укып та бетерә алмам. Мин монда бөтенләй икенче китаплардан өйрәнәм, тормыш китабын өйрәнәм. Әйе, минем хәзер күзем ачыла башлады кебек. Мин моны бик яхшы сизенәм.

Юк, Галия жаным, син хаклы түгел. Мин әле күмелмәгән. Күмелү алай булмый. Киресенчә, күмелүдән азат була бару түгел микән әле бу!

## XVIII

Икенче көнне авыруларны мин аерата игътибар белән карадым. Кичәге уйлардан соң минем үз-үземә ышанычым арта төшкән кебек булды. Ләкин бу инде элеккечә масаю түгел. Бу — күңелдә жаваплылык хисе арттыра торган нык, төпле ышаныч.

Төшкә кадәр вакытым шулай авырулар карап үтте. Төштән соң мәктәпкә киттем. Мәктәпкә барганда юл буенча Галия белән сүз көрәштереп бардым. Уйлый торгач, күп кенә нәрсәдә мин тагын да үземнең хаклы икәнлегемне күрдем. Мәктәпкә мин күтәренке күңел белән барып кердем.

Мәктәп авылның иң очына урнашкан. Якында гына Гәрә елгасы ага. Елга аръягында әрәмәлек, әрәмәлек артында иркен кырлар-басулар җәелеп ята.

Мәктәпкә әле минем беренче килүем. Укытучы халкыннан мин әлегә беркемне белмим. Күрше Кәрим абыйны исәпләмәгәндә, билгеле. Күрше дигәннән, мин хәзер алар белән татулаштым. Заһирә апа элеккечә ал-ял белми эшли дә эшли: мал-туар карый, утын кисә, утын кертә. Кәрим абый көн дә Тау-авылга укытырга барып кайта. Алар үзара болай әйбәт кенә яшиләр. Тик менә Кәрим абый салырга ярата, аннары балалары гына чорсызрак: сугышалар, елыйлар, кычкыралар. Хәер, балалар барысы да шулайдыр инде...

Менә хәзер дә, мәктәп капкасыннан килеп кергәч тә, иң элек чыр-чу килгән бала-чага тавышы ишетелде. Тәнәфес вакыты бугай. Укытучылар дәрескә кереп киткәнче киракле кешеләрне очратырга теләп, кызурак атларга тотындым. Ләкин барыбер өлгерә алмадым. Мин укытучылар бүлмәсенә барып кергәндә звонок булды. Мин бары исәнләшә генә алдым. Укытучылар, кулларына дәфтәр-журнал тотып, урыннарыннан кузгалдылар, бер-бер артлы чыга башладылар.

Бүлмәдә бер яшь кыз гына утырып калды. Чибәр генә. Түгәрәк битле. Гәүдәгә миннән бәләкәйрәк. Өстенә укучылар кия торган көрән йон күлмәк кигән. Чәче кыска. Укучы дисәң укучы түгел. Мәсәгуттә жидееллык мәктәп. Андый зур укучылар монда булмас.

Мин кыю гына аның янына бардым, исәнләштем, үземнең кем икәнлегемне, ни өчен килүемне әйттем. Мәктәп күлмәге кигән кызый башланмаган дәфтәргә ниндидер исемлек шикелле нәрсә язып утыра иде. Мине күргәч бу эшеннән туктады, оялчан гына елмайды да:

— Таныш булыйк алайса, — диде. — Мин монда пионер вожатые булып эшлим. Исемем Лилия.

— Шулаймыни? — дигән булдым мин.

Без сөйләшеп киттек. Башта бер-беребез турында сораштык: кайсы авылныкы, кайда укыдың, ничәне бетердең, дидек. Лилия Мәсәгутнеке икән. Быел җәй Ямадыда унны бетергән.

— Нишләптер мин сезне белмим, — дидем мин, Мәсәгутне бик яхшы белгән кеше кебек.

— Сез эшли башлаганда мин өйдә булмадым, — диде Лилия.

Шулай диде дә никтер кызарынып китте. Мин аның ни өчен кызарганын сизеп алдым.

— Уфада булдыңмы? — дидем.

— Юк, Казанда, — диде Лилия, тагын да ныграк кызарынып.

— Нинди институтка?

— Университетка...

— «Балл» житмәдеме?

— «Балл» житмәде.

«Менә тагын миңа иптәш артты», дип уйлап алдым мин. Миңа аның кызарынуы да, оялуы да — барысы да таныш. Мин инде аларны кичергән. Институтка керергә итеп тә керә алмый калган һәркем миңа таныш, һәркем якын. Алай гына да түгел, андый һәрбер кеше минем иң якын сердәшем, иң якын туганым. Без — бер сыйныф кешеләре.

Лилия белән якыннан танышкач, мин аның кебек үк икенче бер «туганымны» исемә төшердем. Миңа моңсу булып китте. Үзем дә сизмәстән, көрсенеп куйдым. Минем көрсенүне Лилия үз кайгысын уртаклашу дип белде, ахрысы.

— Мин алай кайгырмыйм! — диде бу, шат күңелле булып күренергә тырышып. — Минем анда бик үк барасым да килмәде. Монда миңа ныграк ошый. Балалар белән күңелле. Берәр ел эшлим дә, пединститутка бирен карыйм.

—, Дөрес, — дидем мин олыларча. — Нәрсә әле монда мүкләнеп ятарга!

Ләкин «мүкләнеп яту» хәзер минем үзем өчеп дә ышандыргысыз булып ишетелде. Галиянең «күмелеп калу»ын хәтерләтте. Мин тынып калдым. Институт турында, «күмелү», «мүкләнү» турында сөйләшү хәзер миңа урынсыз булып, кызыксыз булып тоелды.

## XIX

Лилия яңадан үзенең дәфтәренә иелгәндәй итте дә:

— Нишләп син бер дә дөньяга чыкмыйсың? — дип куйды.

— Вакыт юк, — дигән булдым мин. — Эш күп. Авылларга йөрергә кирәк.

— Шулайдыр инде, — диде Лилия.

— Арып-алҗып кайтасың. Анда сиңа дөнья кайгылары калмый. Буш вакытың калды исә, укырга тотынасың, — дигән булдым мин, зарлангандай итеп. — Медицина бит ул! Анда бөтенесен яттан белергә кирәк.

— Шулайдыр инде, — диде Лилия тагын да.

Ләкин миңа бүген әллә нәрсә булды. Мин тагын тынып калдым. Зарланасы да килми. Кызыгы юк. Мине бүген бер нәрсә дә тулысынча мавыктыра да, кызыктыра да алмый кебек. Мин үземнең һәрбер сүземдә, һәрбер фикеремдә хата күрәм, мәгънәсезлек күрәм шикелле. Аннары бер генә нәрсә турында уйлап булмый. Әле кичәге кич турында уйлыйм, әле «сыйныфташ туганым» турында уйлыйм. Борчылып, газапланып уйламыйм. Бераз гына олы булып, хәтта бераз гына чит кеше булып уйлыйм. Ник алай икән бу? Нәрсә сәбәпче булды соң моңа? Галия хатымы, әллә Лилияме? Лилия дисәң, сәбәпче булыр нәрсәсе дә юк. Бары тик иске яраны гына кузгатты.

Бүлмә уртасында озын, зур өстәл. Өстәлгә кызыл сатин җәелгән. Өстәлнең икенче ягында Лилия. Мин тын гына утырам. Тышта, тәрәзә башында чыпчыклар чыркылдаша. Бүлмәдә салкынча. Тәмәке исе, кәгазь, акбур исе килә.

— Карале, Сәҗидә, — диде Лилия, башын калкытып. — Октябрь бәйрәменә без пьеса әзерлибез. Кешеләребез җитми. Әллә катнашасыңмы?

Мин, урындыкны шыгырдатып, аңа табарак борылып утырдым. Ни әйтергә белмичә, беравык тынып тордым да:

— Кемнәр әзерли? — дидем.

— Мәктәп коллективы. «Зәңгәр шәл»не куймакчы булабыз, — диде Лилия.

Мондый тәкъдимгә мин бернинди икеләнүсез риза булырга әзер. Тик шулай да нидер тотып тора шикелле. Нәрсә соң ул «нидер?» Минем авылда клубка йөрмәскә, теләсә кем белән аралашмаска дип үз-үземә биргән сүземме, Галиядән шүрләүме, әллә соң бөтенләй башка нәрсәме?

Мин сораштыра башладым: нинди рольләргә кеше җитми, дидем, син үзең уйныйсыңмы, дидем. Минем каршы килмәүне күреп, Лилия елмаеп җибәрде.

— Мөслим абыйны куандырыйм әле! — диде бу, иң элек үзе куанып. — Без синең үзеңә дә бармакчы булганыек та... Менә үзең килдең. Яхшы булды әле. Кеше белән аралашмый, авыл яшьләрен яратмый, диделәр, шуңа да бармадык.

Күзгә карап әйтелгән мондый «мактау» сүзләреннән соң мин сизелерлек дәрәҗәдә уңайсызланып киттем. «Минем турыда әнә тагын нәрсәләр сөйлиләр икән әле!» дип уйлап алдым.

— Моннан соң мин сезгә гел килеп йөрермен әле, — дигән булдым үзем Лилиягә.

— Миңа Зәһирә ролен бирделәр, — диде Лилия. — Беләсеңме, Булатның сеңелесе? Бер репетиция булды. Бүген тагын җыелабыз. Кичке җидегә.

— Миңа нинди роль бирмәкче буласыз инде? — дидем мин.

— Сиңамы? — диде Лилия, тотлыккандай итеп. — Белмим. Анда бераз тавыш булып алды. Мөслим абый әйтер әле.

## XX

Күп тә үтмәде, кыңгырау тавышы ишетелде. Бүлмәгә укытучылар керә башлады. Менә ишектә директор да күренде. Мин аның белән таныш түгел, шулай да аның турында ишеткәнем бар. Кыскарак буйлы, киң җилкәле. Юан, таза бер агай. Зур башлы, зур битле. Салмак кына атлап килде дә түргә, өстәлгә таба узды. Узышлый миңа таба карап алды. Мин урынымнан тордым, беренче булып сәлам бирдем, үземнең кем икәнлегемне әйттем.

— Ярый торган эш, — диде Мөслим абый салмак кына, ашыкмыйча гына. — Медиклар белән без моңарчы тату яшәдек. Көз көне, яз көне томау төшүләрне исәпкә алмаганда, авыручыларыбыз булмады. Медицинаның ярдәме гел тиеп тора.

— Балалар ничек? — дидем мин җитди генә.

Директорны мин чынлап сөйләшә дип уйладым. Үзенә игътибар беләнрәк караган идем, кысылган күзләрендә елмаю чаткылары күреп алдым. Чыннан да, минем «җитди» сорауга ул җавап биреп тормады, шулай күзләре белән генә елмайгандай итеп, баштагыча салмак кына үз сүзен сөйләвендә булды.

— Асыл кошны аягыннан эләгә, диләр, әй! — диде. — Болай булгач, сез асыл кош булып чыктыгыз инде, Сажидә.

— Асыл кош читлектә яши. Иптәш Фәррахованы читлеккә ябып куярга туры килә, — дигән булды шунда кемдер, шаяртып.

— Үземнең нинди кош икәнлегемне белсәм, бөтенләй килеп йөрмәгән булырыем, — дидем мин, алардан калышмаска тырышып.

— Без аны читлеккә япмабыз, — диде Мөслим абый, — аягына җеп бәйләп җибәрербез дә кирәк чакта тарттырып кына алырбыз.

Укытучылар күңелле генә көлешеп алдылар. Мин дә аларга кушылган булдым. Көлешү басылганын көтеп тордым да, үз йомышымны ачыкламакчы булып:

— Мөслим абый, мин сезгә эш белән килгәнием, — дидем.

— Сөйләп кара, — диде директор.

Папирос кабызды да тәрәзә янынарак китеп барды. Ачык форточкадан өрә-өрә тартырга тотынды.

— Балаларның тазалыгын тикшерергә кирәк, — дидем мин. — Аннан соң минем балалар белән гигиена турында, чисталык турында әңгәмә уздырырга да исәбем бар. Менә шул хакта сөйләшәсе иде. Тәнәфес вакытында эшләрбез микән, дәрестән соңмы?

— Ярар, булыр, — диде директор.

Аннары, тәрәзә яныннан аерылып, өстәлгә якынрак килде.

— Без медикларга каршы килә алмыйбыз. Ләкин бер шарт бар, — диде.

— Нинди шарт?

— Ул инде белә, Мөслим абый! — диде Лилия.

— Белә? Син алып килдеңмени? — диде директор, Лилиягә карап.

— Юк, үзе килде.

— Ярый торган эш! Кыскасы, Сажидә сеңелкәш, «Зәңгәр шәл»дә уйнарга безнең кешеләребез житми, — диде директор. — Шунда катнашырга без сине чакырмакчы булганыек.

— Шулмы шартыгыз? — дидем мин.

— Шул. Ризамы?

— Белмим шул, — дигән булдым мин.

— Бүрегегез белән киңәшеп карагыз.

— Бүрегем юк шул.

— Эх, хатын-кызның менә шунысы яман да инде анын! — диде Мөслим абый. — Шәһәрдә әнә бүрек кия башлаганнар бугай, инша алла, дөньялар иминләнер болай барса.

Укытучылар тагын көлешеп алдылар. Мин дә көлгән булдым. Тавыш басылганны түземсезлек белән көтеп тордым да:

— Нинди рольгә кеше житми соң? — дидем.

— Дипломатик сөйләшүләрне менә шуннан башлыйк та без, — диде директор, елмаеп. — Мәйсәрәгә сез соңга калдыгыз. Мәйсәрә безнең бар. Шулай ук Заһирә дә бар. Безгә хәзер ишан хатыннары житми. Мин үзем ишан булачакмын. Ике хатыным булды, өченчесен менә һич таба алмыйбыз. Коткарыгыз безне, Сажидә сеңелкәш!

Соңгы сүзләрен ул театрдагычарак итеп, ялварып, ике кулын сузып әйтте. Безнең сөйләшүне тыңлап, безгә карап торган укытучылар күңелле генә гөрелдәшеп алдылар.

— Ярар, килеп карармын, — дидем мин, риза икәнлегемне белдереп.

— Юк, карарга килмәгез, уйнарга килегез, — диде Мөслим абый.

— Ярар, уйнарга килермен, — дидем мин, сүземне төзәтеп. — Эш мәсьәләсендә ничек?

— Эш мәсьәләсендәме? Бүген булмас. Озын тәнәфес үтте. Алдан билгеле булмагач, кыенрак булыр. Иртәгә! Килерсез, җаныгыз ни тели, барысын да эшләрсез. Бүген менә таныштык-белештек, житеп торыр. Кич тагын килегез. Сәгать төп-төгәл жидедә.

— Ул инде белә, Мөслим абый! — диде Лилия.

— Беләмени? Ярый торган эш. Алайса, киләсез?

— Килермен! — дидем мин.

## *Дүртенче бүлек*

### I

Шулай итеп, минем тормыш икенче эзгә кереп китте. Мин репетициягә йөри башладым.

Бәйрәмгә инде күп калмады, шуңа күрә без көн дә әзерләнәбез. Үзем белән мин Таняны да алып барам. Ул үзе катнашмый, безнең кыланышларны карап кына утыра, әледән-әле үз алдына елмаеп куйган була. Ялыктыра башлады исә, рәсемле журналлар карарга тотына. Ә без кычкырабыз, жырлыйбыз, чыр-чу киләбез.

Безнең «баш режиссер» — Мөслим абый. Үзе уйнамаганда ул безне читтән генә күзәтеп тора, өйрәтә, кабатларга куша, кайчагында әйткәләп тә ала. Аның әйтүе безнең өчен закон. Билгеле, аның бернинди театраль белеме юк. Ләкин ул яшьтән үк спектакльләрдә уйнап йөргән. Аннары, үзе әйтүенә караганда, укытучылар институтында укыганда драмтүгәрәктә катнашкан. Ә ул драмтүгәрәкнең житәкчесе нинди дер атаклы артист булган, имеш.

Үз ролем миңа бик ошый. Мин яратып, бирелеп уйныйм. Бер карчыктан миңа борынгы күлмәк табып китерделәр. Күлмәк зур, ләкин миңа таман гына. Шул күлмәкне кидемме, Таня тыела алмыйча көләр-

гә тотына. Бүтәннәр дә көләләр. Шаяртҡан булып: Сажидә, сиңа гел ишан хатыны гына буласы калган икән, диләр.

Көн дә шулай репетициягә йөрү, балалар белән, укытучылар белән аралашу мине кинәт үзгәртеп җибәрде. Моңсулык, юкка-барга эч пошу, аннан да бигрәк, минем турыда нәрсә сөйлиләр икән, тагын берәр гайбәт таратмадылар микән дип шикләнеп яшәү үзеннән-үзе юкка чыкты. Ул гына да түгел, хәтта Соломон Моисеевич та, аның белән булган оятлы, үкенечле үбешү дә онытылгандай булды. Минем өчен, әйтерсең, икенче дөнья ачылды. Мине бөтенләй яңа дәрт, яңа хис биләп алды. Мин хәзер өмет белән, киләчәктә, бик якын киләчәктә нindидер яхшы, куанычлы нәрсә булыр дигән бер өмет белән яши башладым.

Ул көннәрдә мин очынып кына йөрдем. Нәрсә әйтсәләр, шуңа килешәм, нәрсә кушсалар, шуңа риза булам. Ә миңа кем куша ала? Я Галим абый, я Вәзир. Алар минем турыдан-туры начальникларым. Ләкин минем бу арада авыл Советына бөтенләй кергәнем юк. Минем өчен хәзергә иң зур начальник — Мөслим абый. Үзеңнән олырак, тәҗрибәлерәк кешегә буйсыну кайчагында куаныч хисе тудыра. Ул вакытта мин дә шундыйрак нәрсә тойдым. Репетиция буенча гына түгел, башка мәсьәләләрдә дә Мөслим абыйның сүзе минем өчен авторитет булып әверелде.

## II

Бер көнне Мөслим абый белән минем арада шундыйрак сөйләшү булып алды.

— Карале, Сажидә, сине картайган дигәннәрие, дөрес булып чыкты бит әле бу, әй! — ди Мөслим абый.

— Ник? — димен мин.

— Карт хатыннарны бик килештереп уйныйсың. Үзе карт булмаган кеше алай бик үк булдыра алмаган булыры димен шул.

Мин моңа көләргә дә, үпкәләргә дә белмәдем. Көлсәм, үземнән үзем көләрмен шикелле, үпкәләсәм, үпкәләр нәрсәсе дә юк сыман. Аннары, Мөслим абый мыскыллап та әйтми, шаяртып кына әйтә.

— Белмим тагын, — димен, тотлыгып. — Картлар роле булгач, картларча кирәктер инде. Шулай да аңламыйм: кем мине картайган, ди?

— Егетләр әйтә! — диде Мөслим абый. — Миңа жалоба белән кергәннәр.

— Жалоба? Кемнәр? — дидем мин, сискәнеп.

Шул чакны Равил белән Тимерҗанны күз алдына китереп, кызарынып киттем.

— Әһә! — ди Мөслим абый, күзләре белән генә елмаеп. — Кемнәр икәнлеге кызыксындыра, алайса? Анысын әйтмим. Егетләр булгач егетләр. Син, Мөслим абый, колхозның парторгы буларак, Сажидәгә тәэсир ит әле, диләр, кичләрен уенга чыксын, клубка барсын, безнең белән аралашсын, диләр. Югыйсә, ул чирлеләрне генә ярата, безне санга сукмый, диләр. Сажидәнең нурлы йөзен күрү өчен генә аяк-кулны имгәтеп булмый лабаса инде, диләр. Чын, әй, шулай диләр!

— Сез нәрсә дидегез соң? — дигән була шунда бер укытучы.

— Нәрсә дисең, әй! Мин яшь кеше түгел, минем сүзне тыңламас ул, дидем. Шулай да сөйләшеп карармын үзе белән, дидем.

Мөслим абый әле миңа, әле теге укытучыга карап ала. Укытучыга караганда күз дә кыскалап куя. Мин инде барысын да күреп торам. Мөслим абыйның шаяртып сөйләвен дә аңлыйм. Шулай да оят. Ни өчен оят булуын үзем дә төшенмим.

— Вакыт юк бит, Мөслим абый, — дигән булам, акланмакчы булып.

— Вакыт ул, сеңелем, безнең һәммәбезгә дә тәүлегенә 24 сәгать бирелгән. Бәлки, синеке 23 кенә сәгатьтер?

Укытучылар елмаешып алдылар.

— Болай сөйләвем өчен үпкәләмә, сеңелем, — диде Мөслим абый, житди итеп. — Син бит яшь кеше. Яшь чакта яшьләрчә булырга кирәк. Яшьлек кайда да бер — авылда да, шәһәрдә дә. Гел шәһәр турында гына уйлап йөрсәң, бик тиз картаерсың. Чын, әй! Гомер ул искән җил кебек. Уза да китә.

— Нишлим мин анда чыгып? — дидем мин, үземнең гадәттәге фәлсәфәмә тотынып.

Мөслим абый тынып калды. Аптырагандай итеп беравык карап торды да:

— Алай кызык булмагач булмый инде, — диде. — Ә мин сиңа бер нәрсә тәкъдим итмәкче булганыем.

— Нәрсә?

— Нәрсәме? Халык алдында лекция укырга кирәк. Медицина темасына. Клубта.

— Безгә дә әйтәләр ул турыда, — дидем мин, сер тотмас бала-чага кебек.

— Әйткәч, бик яхшы! Тот та әзерлән. Һәр айның унында, уникеләрендә кино килә. Кино башланыр алдыннан сөйләргә була. Белдерү язып, аерым җыярга да була халыкны.

— Юк, белдерүсез генә! — дидем мин.

Мәктәптән кайтканда мин юл буена Мөслим абыйның тәкъдиме турында уйлап кайттым. Нинди темага сөйлим икән дидем. Ул көзне бөтен илдә, хәтта бөтен дөньяда вируслы грипп авыруы таралды. Мәсәгуттә әле ул сизелми иде, ләкин районда инде ишетелә башлаган иде. Мин шул турыда сөйләргә булдым. Кайттым да кул астында булган барлык материалны барлап чыктым, әзерләнергә дә тотындым.

Минем өчен бу тагын бер яңалык булды. «Чынлап та, нишләп әле миңа тумас борын картаерга?!» дип уйладым. Техникумда укыганда безгә әйттеләр ич: авылның җәмәгать тормышында актив катнашыгыз, халык арасында аңлату эшләре алып барыгыз, медицина темасына лекцияләр укыгыз, диделәр. Соломон Моисеевич та әйтмәде микән әле? Әллә әйтмәде микән соң? Әйтмәсә, аның әйтүе генә иммени?

Үземдәге материал гына миңа әз булып тоелды. Икенче көнне кабул итүдән соң уку өенә кердем. Беренче мәртәбә. Бары урам аша гына чыктым. Бик озак газета-журналлар карап утырдым. Ә кичен тагын мәктәпкә киттем.

Әйе, ул көннәрдә мин гел нәрсәдер көтеп яшәдем. Уку өендә утырганда репетиция башланыр сәгатьне көттем. Репетиция беткәч тизрәк икенче көн тууын, тизрәк авырулар белән очрашуны көтә башладым. Икенче көнне тагын шул ук хәл кабатланды. Болай гына әйткәндә, мин тизрәк бәйрәм җитүен, тизрәк спектакль куелуын көттем. Аннары бәйрәмнән соң тизрәк кино килүен, үземнең тизрәк лекция укуымны көттем.

Тагын нәрсә көттем икән соң? Тагын мин бәйрәмнәрдән дә, спектакльдән, лекциядән дә зуррак икенче бер нәрсәне көттем. Мин Тимерҗанны сагындым.

## III

Бишенче ноябрь иде. Ул көнне авырулар күп булмады. Кабул итеп бетердем дә үземнең эшемә тотындым. Зөһрә тиз-тиз генә идәнне юып чыкты. Аннары, эш сәгате беткәнне дә көтеп тормастан, өйләренә кайтып китте. Мин каршы килмәдем.

Зөһрә дигәннән, аның белән минем арада соңгы көннәрдә сәер мөнәсәбәт урнашты. Без хәзер бер-беребезне элеккегә караганда да ныграк яратмыйбыз. Яратмау гына да түгел — дошман күрәбез! Без инде бер-беребезнең күңелен шактый белеп өлгердек. Шуның өстенә,

озын колак аша мин Зөһрә турында кайбер бүтән нәрсәләр дә ишеттем. Аулак өй турындагы, авырулардан май-күкәй алу турындагы гайбәтләрнең барысын да ул тараткан. Элекке фельдшерлар турында да ул шулай юк-бар сөйләп йөри торган булган. Гайшә апа: «Сак бул, сеңлем. Астан кисеп, өстән ямай торган кыз ул», диде аның турында. Мин башта ачуымнан, нәфрәтемнән нишләргә дә белмәдем. Шундук Галим абыйга барып бөтенесен сөйләп бирергә, Зөһрәне бер көн торгызмый эштән куарга уйладым. Ләкин шулай да вакытында тыелып калдым. Гайбәт сөйли, дип әләкләшүнең үзенең гайбәт булуын чамаларга ничектер баш җитте. Чыннан да, ничек исбат итәсең аның гайбәт сөйләгәнлеген?! Үз эшен ул яхшы башкара. Ничек, кайсы яктан бәйләнәсең аңа? Аннан соң, гомумән минем хәзер беркем белән дә тавышланып йөрисем килмәде. Ни генә булмасын, хәзергә мин эчтән тынарга булдым.

Ул да, күрәсең, эчтән тына. Ул да минем белән ачыктан-ачык бозылышмаска тырыша. Ул бераз гына койрыгын кысарга мәҗбүр. Мин инде дәрәҗә саклыйм. Билгеле, болай бик кыен. Ләкин берни эшләп булмый. Бер очы чыгар әле кайчан да булса...

Зөһрә кайтып киткәч, Таня белән без икәүләп күлмәкләрне үтүкләдек, ашарга пешердек. Ашагач, Таня авылларына, төрле җирләрдәге таныш-белешләренә хат язарга утырды. Ул инде көн дә яза. Үзе һаман бәйрәм хаты язам дип сөйләнә. Минем Галиядән башка язар кешем юк. Ләкин минем аңа хәзер берни язасым килми. Чит, ят ул миңа хәзер.

Ашадым-эчтем дә китап укырга утырдым. Нишләптер китап та укыйсы килми. Бер нәрсәгә кул бармый. Бит бүген соңгы репетиция. Генераль репетиция. Иртәгә, алтысында, мин сәхнәгә чыгачакмын. Тизрәк вакытны уздырасы килә, тизрәк мәктәпкә китәсе килә. Күңел түзми, җан түзми.

Мин инде үземнең сүзләрне күптән ятладым. Биш бармагым кебек беләм. Сүзе аның әллә ни күп тә түгел. Эш юктан тагын шуны кабатларга керештем. Кызларның күмәк җырында җырланачак җырларны җырладым. Кычкырам бөтен бүлмәгә. Үзем төрлечә кыланган булам. Ярый әле Таня ачуланмый.

Шулай ничек кирәк алай берничә сәгать узып китте. Иң яхшы дигән киемнәремне кидем дә ашыгып урамга чыктым. Таня кер юарга тотынды, мәктәпкә соңыннан барырмын, диде.

Тышта салкын гына. Һава коры, тын алуы рәхәт. Аяк асты туңган — баскан саен шакылдап-шакылдап кала. Күзге көн инде кечкә авышкан. Урамда беркем күренми. Барам шулай ашыгып йортлар, коймалар буйлап. Алга да карамыйм, артка да карамыйм.

Шулай бара торгач, каршымда кемдер барлыгын шәйләп, кинәт туктап калдым. Карасам — Тимерҗан! Күзләрне зур иттереп ачканмын да торам карап тавыш-тынсыз гына. Ул да миңа караган. Ул да аптыраган. Торабыз карашып ни алга, ни артка китмичә.

— Сажидә! — диде бу, телгә килеп.

— Тимерҗан! — дидем мин дә.

— Исәнме, — диде бу.

— Исәнме, — дидем мин.

Икебез дә бер үк вакытта сөйлибез, шуңа күрә бер-беребезнең сүзен рәтләп аңламыйбыз да шикелле. Мин моңа күтәрелеп карагандай иттем. Өстендә эш киеме түгел. Клубка бара микән, идарәгәме? Ул да минем турыда шулайрак уйлады, ахрысы.

— Кая барасың? — диде.

— Менә... мәктәпкә, — дидем мин.

— Әллә фельдшерлыкны ташладың? — дигән булды бу.

— Йомыш белән барам, — дидем.
— Анда хәзер нинди йомыш? Балалар кайтып беткәндер.
— Балалары булмаса, олылары бардыр, — диган булдым мин.
— Шулай микән...
— Шулайрак шул...
Шулай дидем дә урынымнан кузгалып куйдым, саубуллашып:
— Ярый, хуш...ыгыз, — дидем.
— Әгәр мин сине озата барсам? — диде Тимерҗан.
— Рәхмәт, юлны беләм, — дидем, сер сынатасым килмичә.
— Беләсеңдер дә, юлында бүреләр очравы бар бит әле.
— Очраганнары да житәр инде!
— Очраганы анын бүре түгелдер.
— Бүре булмаса, төлкедер.
Мин кузгалып киттем. Тимерҗан да кире борылды. Минем яннан атлап килә бу.
— Безнең халык турында син гел шулай уйлыйсың икән, — ди ясалма бер үпкә белән.
— Ничек?
— Бүре дә төлке.
— Син шаяртканны аңламыйсың икән, — димен мин, жиңелчә шелтә белән.
— Анлаштырам.
Шулай диде дә бу, күрәсең, бу турыда сөйләшәсе килмичә, тәмәке кабызырга азаплана башлады.

## IV

Без урам уртасына чыктык. Монда иркенрәк булып китте. Ләкин сүз барыбер ялганмады. Мәктәпкә барып житкәнче берни сөйләшмәдек.
Репетиция башланырга әле иртә. Мәктәпкә беркем килмәгән булырга тиеш, чөнки тәрәзәләрдә ут күренми.
— Китереп куюың өчен рәхмәт, — дидем мин, мәктәп капкасы алдына килеп житкәч.
— Сау бул, — диде Тимерҗан.
Мин капканы ачтым, эчкә кердем. Бу да минем арттан иярде.
— Ишек төбенә кадәр илтеп куйыйм әле булмаса, — диган булды.
Мин эндәшмәдем. Ишек төбенә житкәч борылдым да, көлеп:
— Життек. Рәхмәт, — дидем.
— Ике рәхмәт алдым. Өч булсын инде — әйдә класска кадәр озатып куйыйм, — диде бу.
— Юк, житте, — дидем мин.
Ә үзем күңелдән: «Китмәсә ярар иде!» дип уйлыйм.
Караңгы коридорга килеп кердек икәүләп. Мин үзебезнең репетиция була торган класска барам. Класс ачык. Килеп керү белән борынга бераз тынчурак жылы һава бәрелде. Тәрәзә янына бардым да, партага басып, форточканы ачып жибәрдем.
— Кешенең медик икәнлеге әллә каян күренеп тора, — диде Тимерҗан.
Мин жавап кайтармадым. Партадан төшеп, аяк белән баскан жирне сөртеп куйдым, кысылыштырып шундагы парта арасына кереп утырдым. Ник утырганмындыр — үзем дә белмим. Гомумән нишләргә дә, нәрсә уйларга да белмим. Икәүдән-икәү генә бер бүлмәдә булу, караңгы бүлмәдә булу шомлы да, сәер дә. Күңелдә шулай ук нинди дер вәсвәсә бар, куаныч-шатлык бар.
Тимерҗан да минем янга утырды. Кесәсеннән папирос чыгарды.
— Класста тартырга ярамый, — дидем мин.
— Укытучы күрмәгәндә ярый ул, — диде Тимерҗан.

— Фельдшер күргәндә ярамый.
— Алар үзләре дә тарта, — диде бу.
Шулай да папиросын кесәсенә салып куйды. Тик торганда тарту-тартмау мәсьәләсендә ике арада сүз ялганып китте.
— Алар фельдшер булганчы тарта башлаганнардыр, — дидем мин, «тартучы» фельдшерларны яклаган булып.
— Ничек кенә булмасын, фельдшер халкына барыбер ышанып булмый.
— Нишләп алай?
— Алар әнә эчмәскә дә кушалар да үзләре эчәләр.
Миңа кинәт кайнар булып китте. Ярый әле карангы — ул минем йөзне күрми. «Димәк, теге көнне кибеттән аракы алып кайтканны күргән», дип уйладым мин. Алып кайтканны гына түгел, Соломон Моисеевич белән эчкәнне дә белә торгандыр әле. Әллә соң болай гына сөйләнәме?
Мин, гаепле кеше сыман, тып-тын калдым.
— Чынлап та, нигә алай икән ул? — диде Тимерҗан, миннән киңәш сораган кебек. — Кеше бер төрле сөйли, икенче төрле эшли. Ул сиңа тәртипле булырга куша, үзе тәртип боза. Тартмаска куша, үзе тарта, эчмәскә куша, үзе эчә. Яхшы булырга куша, үзе начарлык эшли. Нигә алай соң ул?
— Каян белим мин аны? — дидем мин.
— Син бик тиз ачуланасың икән, Сажидә, — диде бу.
— Әллә тагын, — дидем мин.
— Син һаман да миңа ачу саклап йөрисеңме?
— Ни өчен?
— Теге сүзләр өчен соң...
— Кайсы сүзләр өчен? — дидем мин, гаҗәпләнеп.
— Ярар инде, белмәмешкә салынма.
— Юк, чынлап белмим! — дидем мин ихлас күңелдән.
Тимерҗан тынып калды. Минем чыннан да ялганламаганны белергә теләгән кебек, сынап, миңа карап тора башлады.
— Мин сине ачулангансыңдыр дип уйлаганыем, — диде бераздан.
— Юк, мин сиңа ачуланмадым, — дидем мин.
— Минем сине гел күрәсем килде, — диде бу әкрен генә.
— Шулаймыни?
— Әллә ышанмыйсың?
— Ышанам, — дидем мин, пышылдап.
Нәкъ шул чакта тышкы ишек ачылган тавыш ишетелде. Без икебез дә, тынны кысып, көтә башладык. «Безне шушы килеш күрсәләр, нинди оят!» дип уйлап алдым мин шул ук секундта.
— Репетиция бетүгә мин сине көтеп торырмын, яме? — диде Тимерҗан, ашыгып, пышылдап.
Мин эндәшмәдем.
— Шушында, мәктәп янында, яме? — диде бу, чыгып китәргә җыенып.
— Ярар, — дидем мин, көчкә тын алып.

## V

Ишектән керүче туп-туры безнең класска килде. Тимерҗан чыгып китәргә өлгермәде. Белмим, нәрсә уйлаптыр, класста качып калмакчы булды. Бу тиз генә караңгы почмакка йөгерде.
Менә ишек ачылып китте. Ярым карангыда мин Таняны танып алдым.
— Ә-э, Та-аня! — дидем, куанып.
Мин моны шундый итеп әйттем, әйтерсең, бер ел күрешми торганбыз.

— Син мондамыни? — диде Таня, тыныч кына.
— Монда, монда! — дидем мин, тагын да ныграк куанып.
— Син, нәрсә, спектакль уйныйсыңмыни монда бер үзең?
— Без икәү! — диде Тимерҗан, караңгыдан чыгып.
Таня, куркып, «а!» дип кычкырып җибәрде. Өчебез дә көләргә тотындык.
— Менә нәрсә икән! — дигән булды Таня.
— Качышлы уйныйбыз. Уйныйсыңмы син дә? — диде Тимерҗан татарча.
Таня инде татарча ярыйсы гына пупына. Шулай да Тимерҗан әйткәнне тулысынча аңлап җитмәде.
— Нәрсә ул «качышлы?» — диде Тимерҗанга карап. Аннары русча өстәп куйды: — Мин, бәлки, сезгә комачаулаганмындыр?
Мин Таняга «качышлы»ны тәрҗемә итеп бирдем.
— А-а, шулаймы качышлы уйныйлар?! — дигән булды Таня татарча.
— Шулай, шулай! — диде Тимерҗан. — Сажидә апагыз белән без әнә гел качышлы уйныйбыз.
— Алдый, алдый! — дидем мин.
— Белмим, кайсыгыз алдый, — дигән булды Таня.
— Карале, син бит каядыр барырга чыкканыең бугай? — дидем мин Тимерҗанга.
— Дөрес, — диде Тимерҗан. — Мин дә бит репетициягә барасы кеше.
— Репетициягә?!
— Әйе, мин гармунда уйныйм. Минсез анда... клубта берни барып чыкмаячак.
— Гармунда уйныйсың?! — дидем мин, никтер ышанасым килмичә. — Нишләп соң минем бер дә ишеткәнем юк?
— Гармун уйнаганны ишетү түгел, минем белән рәтләп сөйләшкәнең дә юк синең.
— Ләкин синең урамда уйнап узганың да юк.
— Урамда хәзер гармун уйнау, авыз күтәреп җырлау тыела.
— Тыела?! — дидем мин, аптырап.
Тимерҗанның сүзләре миңа көлке булып тоелды. Ләкин шул ук вакытта күңелгә: «Чыннан да, урамда гармун уйнаганны, җырлаганны ишеткәнем юк бит!» дигән уй килеп китте.
— Әйе, тыела, — диде Тимерҗан.
— Теге элек муллалар тыйган кебекме? Алар да таяк белән куалап йөргәннәр ди ич җырлаган, гармун уйнаган яшьләрне.
— Мулла нәрсә ул! Хәзер алай таяк белән кумыйлар — телефоннан гына шалтыраталар!
— Кем тыя соң аны шулай да?
— Районнан кушалар. Янәсе, культурасызлык... тәртип бозу...
— Кичә үлсәм, бүген ишетмәгән булырыем, — дидем мин.
— Бик зур яңалык белмичә үлә язгансың икән, — диде Тимерҗан.
Шулай диде дә, ашыгып ишеккә таба китеп барды. Чыгып китәр алдыннан тагын баягы сөйләшү-килешү турында искә төшерде, Таняга: сау бул, Таня, диде.
Ул китеп күп тә үтмәде, караңгы бүлмәгә Фәгыйлә апа килеп керде.
— Абау, әллә кеше бар? — диде, безне шәйләп.
— Без бу, Фәгыйлә апа, килегез монда, — дидем мин, кычкырып.
— Сезмени әле? — диде Фәгыйлә апа. — Ишәй белән Кушай килеп тә җиттегезмени әле?
— Җиттек шул, — дигән булдым мин. — Утыра торыгыз, хәзер лампа алып киләм.

— Йөрмә, үзләре кертерлер әле, — диде Фәгыйлә апа. — Караңгыда күңеллерәк.

Фәгыйлә апа Мәйсәрә ролен уйный. Аның тавышы искиткеч. Уфа, Казан артистларында да аныкы кебек тавыш юктыр. Чынлап. Минем инде тыңлаганым гына бар артистларны. Уфада ике ел торган кеше лә мин. Артистның тавышы аның икенче төрлерәк була. Ясалмарак диимме, шомартылганрак диимме... Музыкаль белемең булмагач, дөресен генә әйтеп тә булмый. Ә Фәгыйлә апаның тавышы саф, көчле. Чын-чынлап табигый тавыш.

Фәгыйлә апалар өендә бер ул гына түгел, барысы да җырчы. Әниләре дә, абыйлары да, сеңелләре дә. Рафика апа гына җырчы түгел. Барысыннан да яхшырак җырлаучы, әлбәттә, Фәгыйлә апа. Шуңа да Мөслим абый аны Мәйсәрә роленә алган. Булат роленә Хисам абыйны алмакчы булганнар икән дә, чын исеме Булат булган бер укытучы каршы төшкән. Үзе җырлый. Тавышы әллә ни көчле түгел, шулай да ярый инде. Үзе теләгәч, көчәнә шунда.

Ә Фәгыйлә апага беркем каршы төшәрлек түгел. Ул инде күптән шулай авыл сәхнәсендә җырлап килә икән. Ел саен Яңавылга смотрга бара икән, ел саен мактау кәгазьләре алып кайта икән. Ул кәгазьләрне мин үзем дә күрдем. Стенага «кәртичкәләр» куелган рамнар янына ябыштырылган. Бервакыт Башкортстан филармония артистлары Фәгыйлә апаны үзләре белән алып китәргә дә иткәннәр, укытырбыз, өйрәтербез, дигәннәр. Фәгыйлә апа, дивана, риза булмаган. Ул нәкъ теге гәзитләрдә мактала торган кеше: үзе фермада бозау карый, үзе алдынгы. Үзе чибәр, үзе җырчы. Бар яктан да килгән инде менә.

Болай ул мине якын күрә, хәтта бераз гына ярата да бугай әле. Сөйләшкәндә гел үз итеп сөйләшә. Бүген эштән бик арып кайткан, ахрысы. Әллә ничек тик кенә утыра. Аның киеменнән ислемай исе, җылы өй исе килгән сыман. Ул эндәшмәгәч, без дә тынып калдык.

— Тимерҗан нишләп йөри монда? — диде бу шулай тып-тын гына утыра торгач.

Мин дерт итеп киттем. Фәгыйлә апа авызыннан мондый сүз ишетү мине әллә нишләтеп җибәрде. Тимерҗан белән булган әлеге очрашудан, сөйләшүдән соң күңелдә шатлык-куаныч тойгысы саклана иде. Мин, әйтерсең, класста түгел, кайдадыр биектә, җиденче кат күктә утыра идем. Фәгыйлә апаның сүзләре шундук Зөһрәне күз алдына китереп бастырды. Мин бөрешеп калдым. Үземнең Тимерҗан мәсьәләсендә дә икеле-микеле хәлемә, җебегәнлегемә ачуым килеп куйды. Нишләп соң мин бер дә горур түгел, нишләп минем үз фикерем, ихтыяр көчем юк?! Нишләп соң әле мин бүген тагын аның алдында җебеп төштем? Зөһрәсе була торып, ник борчый ул мине? Алар барысы да шул: бер көнне берсе белән, икенче көнне икенчесе белән... Алар шулай. Ләкин ник соң мин дә алар кебек?!

Бик кыска гына вакыт эчендә минем күңелгә шундый сораулар килде.

— Таняда йомышы булган бугай,— дидем Фәгыйлә апага, ялганлап.

— Нярся Таня? — диде кызый, үз исемен ишетеп.

— Юк, бернәрсә дә юк, — дидем мин.

— Син мине алдый, — диде Таня, татарча җөмлә төзеп.

— Што син, разве сине алдарга ярый! — дидем мин.

— Карале, бу Танә дигәнегез көннән-көн ачыла бара бит, — дип куйды Фәгыйлә апа.

Ул моны болай гына, тынычсыз икәнлегеп сиздермәс өчен генә әйтте. Шуннан соң тагын тынып калды.

Коридорда аяк тавышлары ишетелде. Ишек ачылды. Мәктәп караучы апа лампа күтәреп керде. Аның артыннан Мөслим абый, хатыны, тагын бер-ике укытучы күренде.

## VI

Репетициядэн соң мин Таня белэн, укытучылар белэн кайтып киттем. Як-ягыма әйләнеп тә карамадым. Пунктка җиткәнче без бер төркем булып кайттык. Үзебезнең турыга җиткәч тә туктап тормадым — кердем дә киттем. Таня белән икәүләп.

Өйгә кергәч, шулай да бераз гына кыен булды. Бит мин вәгъдәмдә тормадым! Менә бер төрле сөйләдем, икенче төрле эшләдем. Ә бит мин үзем болай намуслы гына кеше.

Вакыт соң булса да, Таня белән чәй кайнатырга куйдык. Таня ут яндырмакчы булды. Мин яндыртмадым. Тәрәзә янына килдем дә карыйм урам якка. Күп тә үтмәде, урам уртасында Тимерҗан күренде. Йөрәк кысылып куйды.

Мәктәп ягыннан килә. Әкрен генә килә. Безнең турыга җиткәч, туктагандай итте, тәрәзәгә карады. Нәкъ мин капланган тәрәзәгә. Мин читкәрәк киттем. Карап торды-торды да өйгә таба атлап куйды. Тагын карап тора башлады. Тәмәке тартырга кереште. Шактый озак басып торды. Аннары теләр-теләмәс кенә кузгалып китте.

Баягынак мәктәптә чакта уйлаган шелтәле, ачулы уйларым кинәт юкка чыкты. Сүземдә тормавым өчен тагын бик-бик кыен булып куйды. «Җүләр!» дидем, үз-үземне тиргәп. Яратмаган кеше шулай йөримени? Бәлки, ул Зөһрә турында уйлап та карамыйдыр әле. Зөһрә үзе генә ялынып йөридер!

Мин шундый фикергә килдем. Ул төнне мин бик тыныч йокладым. Иртән, гадәттәгечә, бик иртә тордым. Күңелдә — шатлык, тәндә — җиңеллек. Бәйрәм шатлыгы гына түгел. Аннан да зуррак шатлык-куаныч. Бөтен дөньяны ямьле итеп күрсәтә торган шатлык-куаныч. Беренчедән, бүген спектакль. Икенчедән, бүген мин беренче тапкыр халык арасына чыгачакмын. Чынын гына әйткәндә, пунктта ятып мин инде ялыгып беттем. Өченчедән, әлбәттә, мин аны күрәчәкмен! Мин инде очрашкач аңа әйтәчәк сүземне алдан ук әзерләп куйдым. Төркемнән аерылып булмады диярмен.

Бүген авырулар бөтенләй диярлек булмады. Бер-ике кешегә укол кададым да бер кызның кайнар суда пешкән кулын бәйләдем. Эштән соң Таня белән икәүләп пункт капкасына кызыл байрак чыгарып кадакладык. Шуннан соң кичәгә әзерләнергә керештек.

Алдан исәпләп куйган план буенча мин бәйрәм көнне Яңавылга кайтып китәргә тиеш идем. Җидесен дә исәпләгәндә, өч көн ял булачак бит. Үз урыныма Таняны калдырырга уйлаган идем. Яңавылга киткәндә мин гел шулай итәм. Бүген баштагы фикеремне үзгәртергә булдым. Бәйрәмне Мәсәгуттә уздырырга кирәк дигән фикергә килдем. Шул турыда әйткәч, сөенеченнән Таня елмаеп җибәрде, мине кочаклап алды, күтәрергә итеп караган булды — күтәрә алмады. Без икебез дә рәхәтләнеп көләргә тотындык.

Сөенми, сөенерлек тә шул. Бер үзенә аңа өч көн буена бик үк күңелле булмас иде. Икәү булгач, без ничек тә бирешмәбез. Кая ул бирешү! Менә дигән иттереп үткәрербез бәйрәмне! Бүген кичне клубта уздырырбыз. Иртәгә дә клубка барырга була. Анда бармасак, мәктәпкә барырга була. Укытучылар үзара мәҗлес ясамакчылар. Шунда безне дә чакырдылар.

Монда мәсьәләнең икенче ягы да бар. Таня Равилгә чын-чынлап гашыйк, ахрысы. Миңа сиздермәскә тырышкан була. Тапкан сиздермәс кеше! Әйтерсең, мин инде берни аңламыйм. Вәзир белән әйтешкән теге көннән соң Таняның да эшләре чуалып китте. Равил пунктка килми башлады. Шулай да алар бер-ике мәртәбә кинога бардылар. Кино булмаган көннәрдә мин Таняны беркая җибәрмәдем. Чынлап. Усал бианалар кебек тегене уч төбендә йомарлап тоттым.

Ә бүген... иртәгә... берсекөнгә без икәүләп барачакбыз! Килен белән бианә. Ха-ха-ха! «Трам-та-там, трам-та-там, бүген театрга барам!»

## VII

Клубка без бик иртә кердек. Халык жыела башлаганчы беренче рәттә утырып тордык. Бездән соң төркемләшеп бала-чагалар керде. Аннары яшьләр күренде. Соңгарак берән-сәрән олылар да килә башлады. Клуб эче әкренләп халык белән тулды.

Бер заман таягына таянып Шәйхаттәр бабай килеп керде. Башында бүрек, өстендә сырма, аягында күн итек. Нәкъ теге каравылда торган чагындагы кебек. Килеп керде дә, ишек төбендә туктап, халыкка карап алды, кычкырып сәлам бирде.

— Исәнмесез, җәмәгать! — диде.

— Бик исәнбез, Шәйхаттәр абзый!

— Әйдә, түрдән уз! — диештеләр кешеләр.

Шәйхаттәр бабай, көлештереп, таягын тукылдатып, алгарак узды. Туп-туры безнең янга килде. Ләкин безнең арттагы кемдер аны үз янына чакырды.

— Бабагыз килде, башларга була, — дигән булды Шәйхаттәр бабай, арттагы утыргычка урнашып.

Таня белән мине танып алды да, табактай бите белән елмаеп:

— Иске танышлар икән ләбаса! — диде.

— Исәнме, бабай, — дидем мин.

— Исәнме, кызым, исәнме, — диде Шәйхаттәр бабай. — Исәнлеккә ис киткән, печәнлеккә ут киткән дигәндәй... йөрәк авырта әле, кызым, менә шуңа килдем... Әйдә утырып булмый. Кызлар янына тарта күңел.

Шул чакны кеше арасында Равил күренеп китте. Таня күрде дә авызын ерып җибәрде. Житмәсә, үзе минем артка яшеренгән була. Янәсе «качышлы» уйный. Тапкан качар җир!

Равил дә безне күреп алды. Килә кешеләрне ерып-җырып.

— Исәннәрмесез, апалары! — диде бу, бөтен залга кычкырып.

— Равил, кил монда, кил! — дидем мин, кул болгап.

— Каягыз әле, кереп утырыйм әле шунда, — дип кычкыра Равил безнең рәттәге кешеләргә. — Әнә бит көтеп утыралар. Зарыгып беткәннәрдер.

Кысылыштырып бу минем янга килеп житте, утырды. Мин Таня белән аның уртасында торып калдым. Урыннарны алыштыру өчен кузгала гына башлаган идек, халык арасыннан Мөслим абый килеп чыкты. Аның янында тагын хатыны белән берничә «артист» бар. Сәхнәгә баралар. Равил белән Таняның икесен генә калдырып, мин дә алар артыннан иярдем.

— Убыр китте, урыны калды! — диде Равил минем арттан.

Ишетеп торам — шундук Таняга тәрҗемә итәргә дә тотынды. Таняга инде житә калды. Көлә мысмылдап. Аңа кушылып Равил көлә. Кеше артыннан көлеп калмасалар ярамагандыр! Бу кадәр әдәпсез булгач та булыр икән бу халык!

Сәхнәгә менгәндә мин, чак-чак кына башны борып, залдагы шаулашкан халык өстенә карап алдым. Беркемнә аерырлык түгел. Кешеләрнең йөзләре барысы да бер төсле булып күренә. Барысы да кызгылт-сары, барысы да бер якка — сәхнә ягына төбәлгән.

Без жыйнаулашып сәхнәгә менгәч, тавыш басыла төште. Ә бераздан пәрдә ачылды. Мөслим абый, трибуна алдына чыгып, Октябрь революциясе турында доклад укырга керешге. Халык шып булды.

Мөслим абый доклад укыган арада без киемнәрне алыштырдык, төзәндек-бизәндек, грим сөрттек. Доклад озак булмады. Докладтан соң пәрдә ябылды. Озын күлмәкләрне өстерәп, җилбер-җилбер килеп без

барыбыз да сәхнәгә чыгып җыелдык. Мөслим абый, папкасын кул очына тотып, ашыгып, сәхнә артына узды.

Күп тә үтмәде, тиешле декорацияләр эленде, кое «образын» чагылдырырга тиеш булган бура сыман нәрсә сәхнә уртасына чыгарып куелды. Кылдавына бау бәйләнгән чын чиләк тотып, Мәйсәрә — Фәгыйлә апа кое янына барып басты. Ишан киемендәге Мөслим абый янадан сәхнәгә килеп чыкты да, пышылдап, ләкин сәхнәдәге һәркем ишетерлек итеп:

— Башладык! — диде.

Без — сәхнә уртасында, яктыда буталып йөргән хатын-кызлар, су сипкәндәй, сәхнә артына кереп яшерендек. Бер җиргә җыелдык та тынып калдык. Без — хор. Хорда мин дә катнашам.

Кемдер чыгып халыкка спектакль башлануын белдерде. Пәрдә ачылды. Бөтен зал бер ноктага — кое янында су алып торган Мәйсәрәгә — Фәгыйлә апага текәлде. Мөслим абыйның югары күтәрелгән кулы кинәт аска төште. Авызларны зур ачып без җырлап җибәрдек:

Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз,
Елама, калдырмам ялгыз.

## VIII

Спектакльне халык бик яратып карый. Тын да алмый утыралар. Фәгыйлә апа җырларга тотынгач шундук дәртле бер җанлану сизелә башлады. Кайберәүләр ишеттереп көрсенеп куя, кайберәүләр борынын тарткалый. Пәрдә беткәч шаулатып кул чаптылар, кычкырдылар, аяк типтеләр. Шунда берсе торып тәртипкә өндәгән булды. Ләкин халык барыбер тыңламый, күңелләре тулган — җенләнүен белә. Бары пәрдә ябылгач кына кул чабу, шаулашу кимегәндәй булды. Аннары инде күңелле гөрләшү башланды.

Пәрдә артыннан пәрдә алышына торды. Безнең һәммәбездә искиткеч күтәренкелек. Сәхнә артында тыз-быз чабышып йөрибез, ашыгып сөйләшәбез, кайчагында исә бер-беребезгә ачуланып алабыз. Мөслим абый тыныч, җитди, киеренке. Без аның авызына гына карап торабыз. Күңелләрдә горурлык хисе. Беркайчан да булмаганча үзеңне бәхетле итеп тоясың. Үзеннән-үзе көләсе килә...

Көлү дигәннән, ул көнне мин сәхнәдә бик күп көлдем. Беренче пәрдәдә әле ярый. Ул-бу булмады. Ә менә бишенче пәрдәдә үземнең чамадан тыш көлүем белән чак-чак кына эшне бозып ташламадым.

Минем төп ролем — Сабира роле, ягъни ишанның өченче хатыны. Яшьрәк хатыны. Ишанның карт хатыны ролендә Мөслим абый бичәсе Нәфига апа уйный. Алар нәкъ тормыштагыча, тик исемнәре генә алышынган да киемнәре генә алышынган. Алар икесе дә менә дигән итеп уйныйлар. Аларның килмәгән җирләре юк. Ишан — Мөслим абый салмак, мәкерле, хәйләкәр. Хәдичә, ягъни ишанның карт хатыны — усал, явыз.

Хәдичәнең — Нәфига апаның сәхнәгә чыгуы булды, Мәйсәрәгә кычкырына башлавы булды, залдагы халык тыела алмый көләргә тотынды. Болай караганда, бер дә көләр җире юк инде. Киресенчә, тып-тын гына утырырга кирәк. Чөнки көчләп ишанга дүртенче хатынлыкка бирелгән Мәйсәрә, уйлавымча, иң таш күңелләрдә дә кызгану хисе уятырга тиеш. Аның пәрдә ачылганда җырлаган җыры гына да нинди кызганыч! Халык исә уйлап та бирми, көлепме көлә!

Хәдичәдән соң Мәйсәрә янына ишанның икенче хатыны чыга. Талаш-кычкырыш башлана. Дөресе, талаш-кычкырыш дәвам итә. Ишанның карт хатыннары талаша. Аларны аермакчы булып, хатыннар арасына Мәйсәрә дә килеп кысыла. Сәхнәдә хатыннар талашын күреп, халык һаман буынсыз булып көлә. Хәзер инде чыннан да көлке.

Нәфига апа — Хәдичә сәхнәдә әле берсенә, әле икенчесенә очып куна. Теле телгә йокмый, кулы кулга йокмый. Шундый шәп уйный! Атказанган артисткаларың бер читтә торсын. Репетиция вакытында ул алай ук уйнамаган иде шикелле. Монда аны, әйтерсең, алыштырып куйганнар.

Мин бары соңыннан гына аңладым — халык бигрәк тә Нәфига апаның кыланышыннан көлә икән. Ул тормышта да нәкъ спектакльдәгечә усал, явыз икән. Усаллыгы аның бөтен тирә-якка таралган икән. Ул вакытта мин берни белмәдем. Шуңа күрә, залдагыларга ияреп, көләм тыела алмыйча!

Менә миңа да чыгар вакыт җитте. Чыктым да, ишан хатыннарының талашуын күреп:

— «Бу ни эшегез, җир битләр, хәзрәткә йокларга ирек бирмисез!» — дип кычкырып җибәрдем.

Мин моны бик усал итеп, җикеренеп әйтергә тиеш. Ләкин минем кычкыруда бернинди җикерену ишетелми. Мин ничектер көлә-көлә әйттем бугай.

Мин шулай «җикеренгәч» тә, карт хатыннар миңа ябырылдылар, мине мыскылларга тотындылар. Мин инде, ишанның яшьрәк хатыны буларак, алардан да арттырып җибәрергә тиеш. Ләкин, үтерәсеңмени, булмый гына бит! Һаман көләсе килә. Тиешле сүземне әйтәм дә читкә борылып көлеп алам, тиешле сүземне әйтәм дә тагын көләргә керешеп китәм. Залдагылар күреп алдылар, менә хәзер минем көлүдән көләләр! Мин инде болай ярамаганлыгын бик яхшы аңлыйм, шулай да берничек тә тыелып булмый.

Сизеп торам — сәхнәдә дә, залда да ниндидер үзгәреш башланды. Сәхнә артындагы Мөслим абый ачуланып миңа нидер пышылдарга тотынды. Нәрсә пышылдаганлыгын аңламыйм — пышылдавын гына ишетәм. Ул арада без — ишан хатыннары үзара сугыша башлыйбыз. Безне бары Мәйсәрә генә аерырга тырыша. Бераз гына аерылгандай итәбез дә тагын әләгешеп китәбез. Мин әле һаман чын-чынлап ачулана алмыйм. Үзем сугышам, акырам, җикеренәм, ә үземнең авыз ерыла! Аптырадым бит менә.

Шуннан бер вакыт ыгы-зыгы арасында Нәфига апа ана каздай миңа очып кунды да, күзләрен акайтып:

— Көлмә! — дип ыжгырды.

Шул ук секундта бар көченә минем беләктән борып та алды. Авыртудан чак-чак кына кычкырып җибәрмәдем. Көләсе килү шундук юкка чыкты. Күңелдә ташып ярсу кузгалды. Ләкин ул вакытта инде ишан хатыннарының талашы бетеп килә иде.

## IX

Спектакль беткәч, без залга төшеп утырдык. Спектакльдән соң авыл яшьләре концерт башлап җибәрделәр.

Концертка мин әллә ни игътибар итә алмадым. Спектакль тәэсире тиз генә бетеп җитмәде. Мин ничектер кыйнап ташлагандай булганмын. Бөтен бит яна, колак очлары яна. Үзем сәхнәгә караганмын, үземнең күз бер нәрсә дә күрми. Әле Таня, әле Равил нидер әйткән була, мактаган була — берни аңламыйм. Арттагы халык тавышы шулай ук ерактан килгән тонык гөрелдек кенә булып ишетелә.

Шундый хәлдә мин шактый озак утырдым, ахрысы. Менә бер заман конферансье күмәк җыр башкарылачагы турында белдерде. Сәхнәгә җыйнаулашып дүрт-биш кеше чыкты. Күзләремне ныграк ачып карасам — Зөһрә, Фәгыйлә апалар! Хисам абый да алар белән, сеңелләре дә... Бөтен өй әһелләре белән чыкканнар. Нәсимә апа гына юк.

Тезелделәр болар сәхнә уртасына. Иң алга Зөһрә белән Сәлимә бас-

ты, артка Фэгыйлэ апа белэн Хисам абый басты. Э алардан алга, урындыкка, кулыңа гармун тотып... Тимержан утырды!

Мин айнып киттем. Күзлэр тагын да ныграк ачылды, колаклар үрэ торды.

Зөhрэ мине күреп алды да эре генэ читкэ карады, башын югарырак күтэрде. «Спектакль уйнап шаккатырдым дип уйлыйсың инде? Бик исләре китте! Күр менә хәзер безне!» дигән кебек булды аның бу тәкәббер кыланышы.

Тимержан бөтенлэй карамады да. Хурланудан, оятымнан нишлэргэ белмэдем. Тимержаннан бигрэк Зөhрэ ачуны китерде.

Ул инде баядан бирле минем күнелне кытыклады. Клубка беренче мэртэбэ килеп кергэч тэ без аны очраттык. Безгэ карамады да, эндэшмэде дэ. Эчтэн генэ ул миңа: пунктта син хужа булсаң, монда мин хужа! дигэн кебек булды. Туктаусыз ул безнең күз алдында чуалып йөрде. Әле сэхнэ артына узып киткэн була, эле лампаның утын калкыта, эле трибунага графин белэн су китереп куя.

Күмэк җырны халык бик яратты. Шаулатып кул чаптылар.

Концерт номерлары алышына торды. Берэүлэр биеделэр, җырладылар, икенче берэүлэр чыгып шигырь укыдылар. Берсе дэ ныклап торып хэтердэ калмаган. Хэтердэ бары бер генэ «номер» калган. Бик нык калган.

— Аерым җыр! — диде эйтеп торучы.

Сэхнэгэ Зөhрэ чыгып басты. Аның янындагы урындыкка Тимержан килеп утырды. Мин инде моңа артык гажэплэнмэдем. Шулай кирэктер дип уйладым. Соң, гармунчылары ул булгач, ул уйнамый кем уйнасын!

Үзе генэ басып торган Зөhрэ миңа тагын да матуррак, тагын да тэкэбберрэк булып күренде. Өстендэ кыска итэкле йон күлмэк. Алсу төстэ. Итэге тар, биле нечкэ. Нэкъ шэhэрчэ. Күкрэклэре калку, муены ачык. Аягында биек үкчэле туфли. Капрон оек. Шатлыктан йөзе алсуланган, күзлэре уттай яна. Сокланмасаң да сокланырсың дошманга!

Чыннан да, сэхнэгэ бу чыгып баскач та, тирэ-якта чыш-пыш тавышлар ишетелэ башлады. Берсе эйтте: курчакмыни! диде, икенчесе эйтте: бер кашык су белэн йотарлык, диде. Кайсыдыр көлеп куйган булды: сыйрагы нечкэрэк шул, авыр эшкэ ярамас дигэн булды. Аңа каршы тагын берсе эйтте: белэге дэ нечкэ — сэнэк тота алмый бу, диде. Билгеле, көнлэшеп сөйлэнэлэр. Тишек авыз ни эйтмэс.

Шундый чыш-пыш арасында колакка кинэт икенче төрле сүзлэр чалынып калды.

— Нинди пар килгэннэр! — диде бер яшьрэк хатын, пышылдап.

— Аларны бит өйлэнешергэ йөри дигэннэрие, — диде янындагы ир кеше.

— Тимержаны кирелэгэн түгелме соң? — диде хатын кеше.

— Эллэ тегесе микэн соң? Бик чибэр бит, анасын!.. — диде ире.

— Ярар, шаулама, тик кенэ утыр! — диде хатыны.

## X

Шуннан башка мин берни ишетмэдем. Мин бөтенлэй ишетмэс булдым. Ишетмэдем дэ, күрмэдем дэ. Залда бик кызу була башлады, дөнья тараеп калды. Бөтен халык арасында мин үземне кирэксез итеп сиздем.

Мин көчкэ утырдым.

Концерттан соң халык тарала башлады.

— Кайтабызмы? — диде Таня.

— Кайтабыз, — дидем мин.

Равил безнең юлга аркылы төште.

— Юк, апалары, мин сезне кайтармыймын бүген! — диде, бик яман

кычкырып. — Без сезнең уйнаганны карадык, хәзер сез безнең уйнаганны карагыз.

— Нәрсә сүлисен? — диде Таня.

— Шуны сүлим, маржа апасы, — дип кычкырды Равил, — кайтмайсыз өйгә. Ни пайдет дамуй! Аңлашылдымы?

— Аңлашылдым, — диде Таня.

— Аңлашылдым түгел, аңлашылды!

— Аңлашылды, — диде Таня, төзәтеп. Аннары миңа карап алды да: — Таңга кадәр вакыт җитәрлек, калыйк, яме? — диде.

— Калыйк, — дидем мин.

Минем өчен барыбер — кайтсак ни дә, кайтмасак ни. Миңа хәзер бер нәрсәнең дә кызыгы юк. Мин төштәге кебек. Шулай ук Таня да, Равил дә миңа төш кешеләре кебек тоела. Алар гына түгел, барысы да, барлык кешеләр дә, зал да, клуб та, сәхнә дә... Әйе, төштәге кебек.

Равил каядыр китеп барган иде, Таняга борылдым да:

— Син үзең кайтырсың... Минем баш авырта, — дидем.

Таняның берүзен калдырып, чыктым да киттем. Таня аптырап калды. Иярмәде. Калсын. Алар икәү...

Тышка чыккач йөгердем генә. Ишекне ачып өйгә кердем. Кергәч эчтән бикләп куйдым, үзебезнең бүлмәгә уздым. Үзебезнең бүлмә ишеген дә эчтән бикләп куйдым. Ашыкмадым, кабаланмадым. Бик җентекләп эшләдем. Шуннан соң өс-баш, аяк киемнәрен салып куйдым.

Бүлмә салкынчарак тоелды. Бернинди кайгым юк сыман, әкрен генә кыланып, мичкә ягарга керештем. Лампага ут яндырып тормадым. Мискидә көндездән калган аш бар иде. Мич яна башлагач та шуны плитә өстенә утырттым. Аннары өстәл өстендә җыештырылмый калган табак-савытларны җыештырырга тотындым. «Боларны бит юарга да кирәк але», дип уйладым. Барып чиләккә тотынган идем, чиләк буш. «Су беткән икән», дидем.

Яңадан аякка киендем, өскә, башка киендем, кулга чиләк алып суга киттем.

Клуб янында тавышлар тынмаган. Кычкырып сөйләшәләр, кемдер гармун уйный, кемдер җырларга азаплана. Клубы да, тавышлар да бик еракта, әллә кайда еракта булып тоела. Аларда бернинди катнашым юк. Мин читтә, бөтенләй чит дөньяда.

Ашыкмый гына тыкрыктан төшеп киттем. Коедан су алдым. Шулай ук ашыкмыйча гына өйгә кайттым. Яңадан ишекләрне бикләп куйдым. Плитә өстенә җылынырга су утырттым. Мискидәге аш кайнарланып беткән. Өстәл янына килеп, ашарга утырдым. Бер-ике кашык кына каптым да тәмсез ашны кире этеп куйдым. Төш күрү өзелмәде. Табак-савытларны юып бетердем дә, «Тагын нишлисем бар икән?» дип уйладым. Ә, мичнең янып беткәнен көтәсе бар икән әле!

Утырдым да мичнең янып беткәнен көтә башладым. Озак утыра алмадым. Бернинди хәрәкәтсез утыру никтер куркыныч, бик куркыныч булып тоелды. Тышка чыгып киттем... Таня кайтмый микән дип...

«Ул кайтканчы ятып торыйм әле булмаса», дип уйладым. Шуннан соң чишенмичә генә караватка сузылып яттым. Күп тә ятмадым, күңелгә: «Әллә йоклап китәрмен, ишекләрне ачып керим әле», дигән уй килде. Тордым да ишекләрне ачып кердем.

Төш күрү дәвам итте. Өнне хәтерләтә торган бар нәрсәне куалап җибәрергә тырыштым. Әгәр дә мәгәр уянып киттем исә, әгәр дә мәгәр хакыйкать турында нык уйлап торып уйлана башладым исә, искәрмәстән харап булырмын шикелле тоелды. Ә минем әле яшисем килә. Төш күреп булса да яшисем килә!

Шулай аңгы-миңге ята торгач, чын-чынлап йокыга киткәнлегемне сизми дә калганмын.

## XI

Кайткач Таня, күрәсең, мине уятып тормаган. Мин берни белмичә йоклаганмын. Мин уянып киткәндә әле караңгы иде. Шулай да таң аткан бугай. Сәгать бишенче ярты чамасы. Бер уянгач ятасы килмәде. Иплэп кенә тордым. Юындым. Киендем. Кайбер нәрсәләрне сумкага салып, шүрлектән бер телем икмәк алдым. Ашана-ашана ишеккә юнәлдем.

«Таняга язу язып калдырырга кирәк», дип уйладым кинәт. Кире борылып өстәл янына килдем. Башланмаган бер дәфтәр бите ертып алып: «Таня, мин Яңавылга кайтып китәм. Минем урынга син каласың», дип язып куйдым. Йоклап яткан Таняга бер карап алдым да, тыныч кына, ашыкмыйча гына чыгып киттем.

Тышта салкын. Ләкин минем өстә җылы. Иртәнге һаваның салкын булуы миңа хәтта ошап куйды. Урамда беркем юк. Яктырып килә. Мин урам уртасыннан барам.

Менә басуга да килеп чыктым. Авыл артта калды. Таш юлга кадәр нибарысы чакрым ярым. Бүген машиналар очравы шиклерәк. Очрап та куюы бар. «Трах»та беркайчан да машина өзелеп тормый.

Кичәге төш әле булса бетеп җитмәгән. Шулай да иртәнге саф һава, иртәнге салкынлык һәм җәяү бару үзенекен итә. Томанлы төш әкрен генә тарала бара, йокымсыраган йөрәк һәм баш миенең хәтер учаклары уяна бара. Күз алдына бер үк нәрсәләр килә башлый, күңелдә бер үк уйлар, чишелмәгән һәм, күрәсең, беркайчан да чишелмәячәк уйлар тыпырчына башлый.

Алайса, алар чынлап та яратышалар? Өйләнешергә йөргәч, билгеле яратышалар... Ә мин алар арасына кергәнмен. Үз санитаркамның сөйгән ярын тартып алмакчы булганмын. Мин — әхлаксыз...

Туктале, әллә соң санитарканың сөйгән яры әхлаксызмы? Мин аны белмәдем. Мин аны чакырмадым. Мәктәпкә үзе ияреп барды. Класска үзе керде. Көтеп торырмын дип үзе сүз куйды. Чыннан да, бәлки, ул үзе әхлаксыздыр? Нинди әхлак ул! Авыл малаенда әхлак буламыни! Бер көнне күрешәләр, икенче көнне өйләнешәләр, өченче көнне аерылышалар. Бармыни аларда чын ярату? Юк, билгеле. Хәтта җырда да җырлыйлар: яшь чагында типтереп кал, үкенерсең картлыкта, диләр. Менә шулай типтереп йөриләр дә инде алар.

Хәзер инде минем өчен барыбер. Кирәкми берсе дә. Санитаркасы да, сөйгән яры да. Яшн бирсеннәр сөешеп. Минем үз-үземә: егетләр белән йөрмәскә дигән сүзем бар. Галия хаклы. Мең мәртәбә хаклы.

Чыннан да, нинди ахмаклык эшләдем мин! Юк, эшләп үк житкермәдем әле. Чак-чак кына харап булмадым, чак-чак кына «күмелеп» калмадым. Менә шулай «күмелеп» калуың бик тиз. Нәкъ Галия әйткәнчә. Башта шулай ихахай-михахай йөрерсең, аннары сизмәенчә генә чыгып куярсың, йортың булыр, балаң булыр, мал-туар дип кайгыра башларсың, печән, салам дип, балаларга күлмәк-ыштан дип кайгыра башларсың... Фу! Яшь кеше шул турыда уйлыймыни? Бит минем бөтен тормышым алда. Бит минем рәтләп яши дә башлаганым юк!

Болай булуы аның яхшы да булды әле. Икенче мин анда кайтмаячакмын. Бармыйм. Соломон Моисеевич белән сөйләшәм дә район больницасына урнашам.

Соломон Моисеевичны искә төшерү белән, минем уй җепләрем чуалып китте. Күңелдә кинәт яшен кебек булып өмет чаткысы кабынып алды. Уйлар, теләгемә буйсынмыйча, берәм-сәрәм икенче якка йөгерешә башладылар. Күңел шатланып куйды. Менә бит ул нинди күңел! Нишләтәсең аны? Оят юк, намус юк. Бары үз кайгысын гына кайгырта. Чынлап. Мин инде аны берни эшләтә алмыйм. Күрәсең, аның үз законнары бардыр. Әллә берниндн законы да юкмы соң? Каян белим мин аны. Миндә хәзер аның кайгысымыни?!

Таш юлга чыгып бер-ике чакрым киткәч, мине бер машина куып житте. «Победа». Ниндидер начальник Яңавылга демонстрациягә барып житәргә ашыга, ахрысы. Бәлки кунакка барадыр янсә өенә кайтадыр. Мин инде сорашып тормадым. Минем анда эшем юк. Мине бары Яңавылга гына кайтарып ташласыннар.

Утырттылар. Бер ярты сәгатьтән кайтып та төштем.

## XII

Мин беркая чыкмадым. Өйдә генә яттым. Җидесендә өйдә аш-су булды. Кунакка әтинең-әнинең туганнары килде. Мәҗлес ярыйсы гына узды. Мин туйганчы ит, бәлеш кебек нәрсәләр ашадым да, кунаклар таралганчы йокларга яттым. Икенче көнне төшкә кадәр йокладым. Кичкә чаклы йокларга да исәп бар иде, булмады — йокы туйган булып чыкты. Барыбер урыннан тормадым. Торасы килмәде. Уяу килеш ята бирдем.

Күңелгә тагын кичәге, өченче көнге хәлләр килде. Хәзер инде икенче төрлерәк итеп уйладым. Әрнеп, сызланып уйладым. Әледән-әле көрсенеп куйдым. Үземне үзем кызганып юрган астында гына балавыз да сыгып алдым. Ярату шулай була торгандыр инде ул. Чынлап та, балавыз сыга белмәгән кеше ярата да белмидер ул. Яратмаган кешең өчен ник күз яше әрәм итеп торырга?

Ә бит мин аны чын-чынлап яратам бугай! Бер нәрсәгә карамыйча яратам бугай. Ул мине ярата микән соң? Минеме, Зөһрәнеме? Белмим. Белмим булгач, белмим!

«Туктале, нишләп яратмасын?» дип уйладым бераздан, үз күңелемне үзем күтәреп. Яратмагач, минем арттан килер идемени? Очрашырга вәгъдә куяр идемени?!

Яшь аралаш мин елмаеп җибәрдем. Чак-чак кына сикереп тормадым. Нәрсәдер тотып калды. Күңелгә тагын каяндыр шик төште. Дөнья тагын караңгыланып, күңелсезләнеп калды.

Нишләп әле мин аларның арасына керергә тиеш?! Юк, беркайчан да! Миңа әле табылыр үземә дигәне. Мин әле барыбер бәхетле булырмын. Барыбер!

Уйлый-уйлый минем баш авыртып бетте. Әллә күп йоклаганга микән соң? Ни булса да булгандыр, әмма әни килеп юрганны тартып алгач, шундук аягыма торып бастым. Ашагач, эчкәч, сеңелем белән энемне ияртеп, урамга чыгып киттем.

Өйдән чыкканда мин: урам күрергә барабыз, дидем. Чынында исә күңелдә икенче уй. Бик яшерен уй. Мин Соломон Моисеевичны күрергә өметләнәм. Урамда. Бер үзен. «Бәлки, киногa чакырыр», дип уйлыйм. Кич хәтта озатып куюы да мөмкин димен. Шунда, бәлки, Яңавылга күчү турында да сүз чыгарып куярга булыр димен.

Шундыйрак уйлар уйланып барам урам уртасыннан. Райздрав турысыннан узып киттем. Бакчага кереп чыктым. Клубта бүген кич нинди кино булуын белештем, аннары үзебезнең мәктәпкә бардым. Аннан арырак та узып киттем. Арырак — аптека, больница. Анда — авырулар һәм медицина дөньясы. Соломон Моисеевичның кайда торганлыгын гына белмим. Белгән булсам, бер карамый барып чыккан булыр идем.

Ләкин, күпме генә йөрсәм дә, барыбер очратмадым. Күңелсез була башлады. Энекәш белән сеңелкәш тә: кайтабыз! дип теңкәне корытып бетерделәр. Тоттым да кайту ягына борылдым. Никтер кайтасы да килми. Анда кайтып нишләргә?

Шулай да кайттык. Өйдә бер-ике сәгать чамасы гына тордым да, киенеп яңадан урамга чыгып киттем. Әйтерсең, тоз сипкәннәр! Клубка бардым, киногa кердем. Кинодан үземә генә кайтырга туры килде. Бик ямансу булды.

Нәрсә белән булса да юанмакчы булып, күңелдән грипп турындагы лекцияне кабатлап чыктым. Уннарында бит кино килергә тиеш дигән иде Мөслим абый! Мин аңа сүз бирдем, лекциянең темасын да әйттем. Бармасаң, сөйләмәсәң, алдау була лабаса. Тагын сүзеңдә тормау була. Мөслим абыйны ничек алдамак кирәк? Атаң кебек кешене...

Тугызында эш көне иде. Иртүк тордым да Яңавылның Җобанай ягына юнәлдем.

## XIII

Зөһрә белән бөтенләй сөйләшмәдем. Шулай ук Таня белән дә сөйләшәсе килмәде. Мин киткәч ниләр булуы турында да, Таняның кичләрен ничек уздыруы турында да — бер нәрсә турында да сорашмадым. Таня үзе дә сөйләмәде.

Тугызы шулай моңсу гына, күңелсез генә узып китте. Кич йокларга ятар алдыннан Таня шулай да әйтеп куйды:

— Җидесендә Тимерҗан килде, — диде.

— Шулаймыни? — дидем мин гамьсез генә.

— Сине сорады. Кызмача. Син яшергәнсең аны, кая куйдың, ди...

— Яратмыйм исерекләрне! — дидем мин.

— Ул исерек түгел иде, — диде Таня, Тимерҗанны яклап.

— Барыбер! — дидем, кырт кисеп. — Бүген әнә берәү килгән. Эчәргә ярамый үзенә. Эчкән дә, кан басымы күтәрелгән. Нишләргә белми. Эчкечеләрнең барысы да гипертоник та неврастеник. Әйткәнне тыңламыйлар, эчмә дисәң, кырык сүзгә житешәләр, акыллы булган булалар. Эчмәгәч тә ни кызыгы бар бу дөньяның диләр. Шәп фәлсәфә — әйтәсе дә түгел!

Үзем дә аңламыйм, никтер үртәлеп сөйлим. Ни өчендер кыерсытылган кеше кебек сөйлим. Аракының зарары турында Таня, билгеле, минем кадәр генә белә булырга тиеш. Ләкин минем анда эшем юк — күзгә күренмәгән нинди дер эчкечене тиргәвемне беләм.

Таня эндәшми. Ул эндәшмәгәч, мин дә тынып калдым.

Икенче көнне көткән кино килде. Белдерүне мин төштән соң күрдем. Кулдан язылган лекцияне эшем беткәч яңадан бер кат укып чыктым. Аннары, дәфтәргә карамыйча гына, үз-үземә сөйләп карадым. Таня иртән Кызыл Ярга китте. Ул әле кино килгәнне белми. Аңа әйтмичә генә чыгып китүне килештермәдем. Аның кайтып житкәнен көтеп тордым да:

— Бүген кино килгән бит, — дидем.

— Барабыз, алайса! — диде бу, сикергәләп. — Лекцияңне онытмадыңмы соң?

— Юк, — дидем. — Үз вакытың белән керерсең. Мин алдан киномеханикны күреп сөйләшәм.

Чыгып киттем. Клубта киномеханикны эзләп таптым. Кино башланыр алдыннан медицина темасына лекция укырга исәпләвемне әйттем. Киномеханик берсүзсез риза булды. Күңел тынычланып калды. «Халык жыелганчы Таня янына кереп чыгыйм булмаса», дип уйладым.

Клубтан чыктым да яңадан үзебезгә кереп киттем. Шул чакны күзгә Тимерҗан чалынып калды. Идарә турында туктап тора. Янында кемнәрдер бар. Бу да мине күреп алды. Күрде дә, урыныннан кузгалды. Миңа таба килә. Үзе кычкыра:

— Сажидә, туктале! — ди.

Аның шулай урам бетереп кычкыруы миңа әдәпсезлек булып тоелды. Шул чагында миңа, бәлки, йөгерергә кирәк булгандыр. Ләкин мин йөгермәдем дә, ашыкмадым да.

Ул арада Тимерҗан килеп тә житте, минем юлга аркылы да төште.

— Сажидә! Сажидә! — ди кабаланып, — артыннан куа киләләрмени!

— Сезгә нәрсә кирәк? — дидем тыныч кына.
— Син кирәк, Сажидә!
— Кабул итү сәгате бетте, иртәгә килерсез. — дидем.
Мин моны чынлап әйттем шикелле, ләкин бу теге шаяртып сөйләшкәндәге кебегрәк килеп чыкты.
— Әллә нинди син, Сажидә, валлаһи! — диде бу, ачыргаланып. — Качасың, сүзендә тормыйсың. Ник теге көнне калмадың?
— Гафу итегез, вакытым юк, — дидем, китеп бармакчы булып.
— Туктале! Бераз гына... — диде бу.
Үзе никтер ашыга, юлга аркылы төшә, хәтта минем кулдан тотып алмакчы була.
— Туктап торырга вакытым юк! — дидем мин тагын да, нык кына итеп.
— Бер генә сүз! Бер генә сүз сөйләшәсе бар синең белән, Сажидә! — диде бу. — Ныгытып сөйләшәсе бар, аңлыйсыңмы?!
— Сөйләш әнә Зөһрәң белән! — дидем усал итеп.
Әйе, бик усал итеп әйттем. Барысын да — үпкәсен дә, ачуын да, нәфрәтен дә бергә җыеп әйттем. Кырт кына читкә тайпылдым да киттем дә бардым.
— Менә шул турыда, Сажидә! Шул турыда, аңлыйсыңмы?! — диде бу, өзгәләнеп.
Юк, туктамадым. Арттан килергә батырчылык итмәде. Урамда, капка төбендә туктап калды.

## XIV

Без Таня белән клубка барып кергәндә, халык җыела башлаган иде инде. Тимерҗан да шунда кергән, нинди дер егетләр арасында күренә.
Кердек тә алгарак уздык. Безнең утыруыбыз булды, янылызга Тимерҗан килеп җитте. Таняга карап:
— Исәнме, Таня, — диде.
— Исянме, Тимерзян, — диде Таня.
Мин читкә борылдым. Кыймыйча гына Тимерҗан урынга утырды. Сүз башларга итеп карады, ләкин сүз ялганмады.
Утырабыз шулай өчебез дә ни өчендер үпкәләшкән кешеләр сыман. Таня әледән-әле ишек ягына караштыра, үзенең Равилен көтә. Тапкан көтәр кеше! Анысы да шундый ук Донжуандыр әле. Йөрсен әле әйдә ышанып. Татарча өйрәнә, имеш! Әйтерсең, мин аны кытайча өйрәтәм. Мин өйрәткән ярамаган. Өйрәтерләр әле сине татарча!
Безнең янга акрен генә атлап киномеханик килеп җитте.
— Әллә лекцияңне башлап җибәрәсеңме? — диде миңа. — Кино соңга кала. Халык җитәрлек җыелды.
— Ярар, — дидем мин, урынымнан кузгалып.
— Хәзер утны кабызам, — диде киномеханик.
Ашыкмыйча гына тышка чыгып китте. Озакламый урамда дөп-дөп мотор эшли башлады. Клуб эче гөлт итеп китте. Мин, лекция язылган дәфтәрне кулыма тотып, сәхнәгә таба атладым.
Ләкин шул вакыт көтелмәгән бер нәрсә булды. Мин сәхнәгә менеп житә алмый калдым — алгы рәтләрнең берсендә утырган Мирсәет абый — колхоз председателе басты да:
— Иптәшләр, тавышланмагыз, — диде. — Хәзер, кино башланганчы, районнан килгән лектор иптәш Кашапов сезнең алда район партия комитетенең чираттагы пленум карарлары хакында бисида ясаячак.
Мин тукталып калдым. Залга борылдым да, аны-моны уйлап тормыйча:
— Юк, хәзер мин лекция укыйм! — дидем.
Бик ышанып әйттем, үземнең хаклыгыма, укыячак лекциямә ыша-

нып әйттем. Барысы да миңа күтәрелеп карадылар. Клуб эче тып-тын калды.

— Өченче көн генә доклад булды лабаса! — дип кычкырды кемдер.

— Лекторлар күбәйгәч, харап икән эшләр, малай! — диде икенчесе.

— Мин медицина темасына укыйм, — дидем мин, кычкыручыларга җавап итеп.

Председатель кулын күтәрде дә халыкка тагын тавышланмаска кушты. Аннары, сөзәргә җыенган үгез төсле, миңа карады.

— Нәрсә сез, иптәш Фәррахова? — диде. — Сезгә кем кушты?

— Бүген мин әзерләндем, — дидем мин. — Грипнкә каршы көрәш турында. Безгә районнан куштылар, Мөслим абый кушты. Киномеханик әнә утны минем өчен яндырды.

Залдагылар көлешергә тотындылар.

— Тавышка куярга! — дип кычкырды кемдер.

Председатель яңадан халыкны тынычландырды да, ике төрле уйларга урын калдырмыйча:

— Бик яхшы алай әзерләнгән булгач, — диде. — Сез мондагы кеше. Икенче кино килгәч укырсыз.

Шулай диде дә үзе янындагы ят кешегә:

— Рәхим итегез, иптәш Кашапов, — диде.

Кашапов дигән кеше сәхнәгә атлады. Баскычтан менде. Минем яннан үткәндә илтифатсыз гына миңа кагылып, орынып китте. Хурлыгымнан җир тишегенә керердәй булдым. Хурланмаслык та түгел шул — никадәр тырышып әзерлән-әзерлән дә, кисәк кенә, җиңел генә синең өметеңне киссеннәр, имеш! Берниндн сораусыз-нисез, берниндн сөйләшүсез! Бөтен халык алдында адәм көлкесе итсеннәр, имеш! Юри эшләгәннәр дип торырсың.

Минем күңел тулды. Тамак төбенә ачы төер килеп тыгылды.

Ул арада лектор сөйләргә дә керешеп китте. Кисәк кенә урынымнан купгым да, кызарынып-бүртенеп, бөтен зал аша ишеккә йөгердем.

Бүлмәгә кергәч, чишенеп тә тормыйча, мендәргә капландым, еларга тотындым. Туйганчы еладым. Авылда бер көн торасым килмәде. Авылда гына түгел, дөньяда торасым килмәде. Беркем кадереңне белми икән, адым саен кыерсыталар икән, ник торырга, ник яшәргә?!

## XV

Үз алдыма тузынып мин тагын Яңавылга кайтып киттем. Монысында инде бөтенләйгә. Чын-чынлап. Берниндн икеләнүсез, берниндн үкенүсез.

Яңавылда үзебезнең өйгә дә кайтып тормадым — туп-туры райздравка киттем. Соломон Моисеевичның мине аңлаячагына, миңа ярдәм итәчәгенә мин әз генә дә шикләнмәдем.

Күземә ак-кара күренмичә, әле һаман ярсып, тәвәккәл бер кыяфәт белән ишек шакыдым. Җавап та көтеп тормастан, ишекне иңeләй ачып җибәрдем. Кердем дә кычкырып:

— Рөхсәтме? — дидем.

Рөхсәт бирделәрме, юкмы — хәтерләмим. Кыю гына түргә уздым. Бүлмәдә ике кеше күренгәндәй булды. Берсе Соломон Моисеевич булырга охшый, икенчесе әллә секретарь хатын, әллә бүтән хатын-кыз. Үзе бераз таныш кебек. Мин ишектән килеп кергәндә алар бер-берсенә бик якын торалар иде шикелле. Мин кергәч бер-берсеннән аерылып киттеләр. Күңелдә шундук: «Әллә үбешеп торалар инде?» дигән бер шикле уй туды. Чынлап та, шулай булды, ахрысы.

— Ә, иптәш Фәррахова! Сажидә! — диде Соломон Моисеевич, чамадан тыш ягымлы елмаеп. — Әйдә, әйдә, түрдән уз!

Соломон Моисеевич күлмәк якасын, галстугын төзәткәләп алды да үзенең кресло сыман итеп ясалган урындыгына килеп утырды. Мин дә

утырдым. Аның каршысына. Мин тынычсыз. Иреннәр кысылган, йодрыклар йомарланган. Сугышка ташланырга җыенган яшь этәч кебек. Соломон Моисеевич та бик үк тыныч түгел шикелле. Күз кырые белән генә тәрәзә ягына карап-карап ала. Караганын миңа күрсәтмәскә иткән була, ләкин ничек күрмисең — каршыда гына утыра лабаса! Артта, тәрәзә янында теге хатын-кыз басып тора, ахрысы.

— Сөйләп җибәр — эшләр ничек бара? — ди Соломон Моисеевич, миңа эндәшеп.

Мин нәрсә сөйләргә дә белмим, каткан агач кебек тик утырам. Сүз башларга нәрсәдер комачаулый шикелле. Күңелдәге уйлар түгел, мондагы ниндидер серлелек, аннары минем арттагы ят хатын-кыз комачаулый шикелле.

Нәрсәдән сүз башларга белми аптырап утырганда, минем арттагы хатын-кыз телгә килде.

— Ярый, мин китим, Саша, — диде.

Тавышы моның калтыранып чыкты. Бик таныш тоелды бу миңа. Чак-чак кына артыма борылгандай иттем. Соня! Безнең белән Куштирәккә барган фельдшер Соня. Кызарынган, күз карашы томанлы. «Чынлап та үбешteләр микәнни?» дип уйладым тагын да.

— Ярый, ярый, рәхим ит! — диде Соломон Моисеевич, Соняга баш иеп, елмаеп.

Соня мине күрде, таныды. Шулай да танымаганга салынды. Мин дә аны танымаганга салыштым, тиз генә башымны бордым да, иреннәремне тагын да ныграк кысып, үртәлеп, өстәлдәге кара савытларына карап утыра башладым. Соня, биек үкчәле туфлиләре белән шак-шок басып, ишеккә юнәлде.

— Туктале! — дигән булды Соломон Моисеевич, урыныннан торып.

Ниндидер бик кирәкле сүзе калган кеше сыман ул Соня артыннан кузгалды, аны ишеккә кадәр озата барды. Ишекне ачып, коридордагы Соня белән тагын пышылдап кына нидер сөйләнеп алды.

Мин барысын сизеп, ишетеп утырдым. Мин үземне утлы табадагы кебек хис иттем. Юл буена ташып килгән ярсу, тәвәккәллек — барысы да юкка чыга барды.

Соломон Моисеевич, Соняны озатып куйгач, кире үз урынына килеп утырды. Ул минем яннан узып китте. Шул чакны корсагы күзгә ташланды. Бәләкәй генә тау кебек булып, чалбар каешын төртеп тора. Ияк асты да салынып төшкән. Мин аны элек күреп житкермәгәнмен, ахрысы. Баксаң, ул да симез кеше икән лабаса!

— Я, тыңлыйм, — диде бу, матур кара күзләрен янадан миңа төбәп.

«Нәрсә әйтергә соң?» дидем мин кинәт үз-үземә. Чынлап. Барысын да оныттым. Миндә хәзер икенче нәрсә башланды. Әллә күңел кайту, әллә ышанмау, әллә җирәнү...

— Нәрсә булды? Нишләптер борчулы күренәсең, Сажидә, — диде райздрав мөдире.

Ул моны бик ягымлы итеп, күңелгә кереп әйтте. Ләкин сизеп торам — чын күңелдән түгел. Шулай булса да, аның бу ягымлылыгы күңелдәге кире тойгыларны юкка чыгара алды. Күз ачып йомганчы мин яңадан элекке Сажидәгә әйләндем.

— Китәм мин Мәсәгуттән, Соломон Моисеевич! — дидем, телгә килеп. — Мин анда эшли алмыйм. Күчерегез мине районга.

— Нишләп алай? Нәрсәсе ошамый Мәсәгутнең?

— Тынычлап эшләргә ирек бирмиләр. Адым саен аяк чалалар. Бигрәк тә колхоз житәкчеләре. Булмый, эшләмим! Теләсәгез нишләтегез.

Бөтенләй кирәкмәгән чакта Кәрим абый күз алдына килеп китте. Ул да бит башта ук, очрашкач та миңа колхоз, авыл житәкчеләрен хурлаган иде. Ул вакытта аның да, күрәсең, шулай тузынган чагы булгандыр,

— Эшләп булмый, алайса? — дип куйды Соломон Моисеевич, уйлангандай итеп. — Син бит институтка керергә хыялланасың?
— Әйе.
— Җәй көне дә әйткән идең, ахрысы?
— Әйе, — дидем мин, теләр-теләмәс кенә.
— Ярар, булыр, Сажидә! — диде кинәт Соломон Моисеевич, кутәренкелек белән. — Район больницасында бер урын бар. Мин сине шунда күчерермен. Ризамы?
— Риза, — дидем мин әкрен генә.
Тик нишләптер мин моңа чын-чынлап шатлана алмадым.
— Иртәгә килерсең, — диде Соломон Моисеевич. — Секретарь чирләп киткән. Иртәгә эшкә чыга. Приказны да шунда язарбыз. Ә хәзер, бар, тынычлан, ял ит.

## XVI

Ул мине шулай юатып, юмалап чыгарып җибәрде. Миңа ул каядыр ашыга, шуңа күрә мине тизрәк чыгарып җибәрергә тырыша кебек күренде. «Коридорда Соня көтеп тора микәнни?» дип уйладым мин. Коридорга чыккач, Соняны күрмәкче булып, як-ягыма карандым. Соня күренмәде.

Әкрен генә атлап үзебезгә кайтып киттем. «Дөрес, үбешеп торалар иде», дигән уй килде күңелгә. Янадан барысын да күз алдыннан үткәреп чыктым. Мин кергәндә үбешеп торуларына тамчы да шигем калмады.

«Үбешсәләр әллә!» дидем үз-үземә, бераз баргач. Бер дә исем китмичкелле тоелды. Бары тик икенче урындагы үбешү генә күңелне тырнап, ачыттырып алды. Аякларым ирексездән кызурак атларга тотынды. Эх, бөтенесе буталды, бөтенесе баш-аяк килде...

Кайтканда базарга сугылдым. Кесә тутырып көнбагыш алдым. Энекәш белән сеңелкәшкә. Алар бит күчтәнәч алып кайтканны яраталар. Күчтәнәчне кем дә ярата. Ә теге вакытта мин алмадым. Әгәр алган булсам? Күрәсең, күчтәнәч белән күчтәнәч арасында аерма бар.

Тимер юлны чыктым да үзебезнең якка бара торган юлга борылдым. Озакламый таш юлга җиттем. Таш юл дигәч тә, яландагы таш юл түгел, урам уртасындагы таш юл. Ике якта йортлар. Мин юл читеннән барам. Алдан да, арттан да машиналар килә. Тыз да быз чабып кына торалар.

Менә бер заман таныш автомашина тавышы ишетелеп китте. Шундук артыма борылып карадым. Борылмадан маңгаена кызыл хач билгесе куелган «ашыгыч ярдәм» машинасы килеп чыкты. Килеп чыкты да, җилләнеп, тузан туздырып, минем яннан узып та китте.

Шофер янына Соломон Моисеевич утырган. Шофер белән аның арасына авызы колагына җиткән Соня кысылган. Соломон Моисеевич та көлә. Күрәсең, бик кызыктыр.

Әйе, алар. Узып киттеләр. Мин карап калдым...

Кая баралар алар?

Кая барсалар да минем өчен барыбер түгелмени? Барсыннар. Кирәгем исә Каф-тау артына китсеннәр. Әллә кая олаксыннар. Миңа хәзер барыбер.

## XVII

Кайттым. Эти гәзит укып утыра. Минем эти бик кызык кеше. Гәзитне ул баштанаяк укып чыга. Беренче битендәге беренче хәрефтән алып соңгы битнең соңгы хәрефенә кадәр укый. Укып чыга да күзгә күренмәгән берәр бюрократны сүгә, каракларны я булмаса американнарны сүгә. Ул да булмаса, үз-үзе белән бәхәсләшә башлый. Әле укып чыкмаган, тып-тын утыра.

Энекәш белән сеңелкәш уенда. Әни казан тирәсендә. Мине күргәч болар аптырап киттеләр. Әти гәзит укуыннан туктады да:

— Ни булды, кызым? — диде. — Ни шимбә, ни җомга дигәндәй, әле генә кайтып киттең ич!

— Кайтсани! — дидем мин.

Чишендем дә түргә уздым. Эш юктан эш булсын дигән сыман, ипи ашарга тотындым. Эш юктан гына түгел инде — ашыйсы да килә.

— Аш өлгерә, сабыр ит, — диде әни.

— Өлгерсә! — дидем каты гына.

Аш өлгергәнне көтеп торасым килмәде, тундым әле дидем дә, түрене урынга яттым.

— Нәрсә, башыңа бер-бер кайгы төштеме әллә? — диде әти.

— Төшмәде, — дидем.

— Нишләп алай караңа көйдең соң?

Эндәшмәдем. Шулай тып-тын гына яттым да, өйдәгеләрне сөендермәкче булып:

— Мәсәгуткә бармыйм, — дидем. — Район больницасына күчәм. Иртәгә приказ язылачак.

— Ни булды? — диде әти. — Ошамадымыни? Әллә кешеләр белән килешмәдеңме?

Нишлисең, барысын да сөйләп бирдем этигә. Дөресрәге, кичәге күңелсезлекләрне. Үземне хаклырак итеп күрсәтү өчен колхоз председателен юри ныграк яманладым. Аннары Вәзирне дә искә төшердем. Моңарчы әле мин әти-әнигә берни әйтмәгән идем.

Әти тыныч кына тыңлап утырды да көлемсерәп куйды.

— И, кызым, кызым! — диде, башын селкеп. — Нигә аны башта ук әйтмәдең? Мин әллә Мәсәгутнең берәр чите кителгәнме дип торам! Мәсәгут үз урынында калгандыр ич?

— Сиңа көлке! — дидем, үпкәләп.

Ләкин сизеп ятам, чынлап торып үпкәләп булмый. Киресенчә, ничектер җиңелрәк булып киткән сыман булды. Бөтенесе ап-ачык, гап-гади булып калды. Нәрсәнең ап-ачык булганын мин әле үзем дә аңламыйм, шулай да инде авыр йөк — күңел газабы — кире кайтмаслык булып артка ташланды.

— Нәрсә, әллә җыларгамы? — ди әти. — Шуның өчен раюн больницасына күчәсеңме? Сине тыңлаган Саламуныгызны әйтерием инде! Һай, җегетләр! Нинди нәрсә соң ул? Шуның өчен кешене эшеннән күчерәләрмени? Ә синең урынга кем кала? Танямы? Таня урынына кем? Чирлеләр нәрсә дияр... авыл халкы?.. Уйладыңмы шул турыда? И, кызым, кызым. Чебен тимәс, чер итәр — менә шул була инде ул!

Мин тып-тын ятам. Әтинең шелтәле сүзләре йөрәкне чәнчеп-чәнчеп ала. Авырттырып-авырттырып ала. Карале, нишләдем соң әле мин? Нәрсә кыланып йөрим соң мин? Үпкәләгән булып, ачуланган булып... Кемгә үпкәләп? Колхоз председателенәме, Вәзиргәме? Кемгә? Тимерҗан белән Зөһрәгәме югыйсә? Вәзирләрдән, колхоз председательләреннән башка анда бит әле тагын Галим абыйлар, Мөслим абыйлар бар. Шәйхаттәр бабайлар, Фәгыйлә апалар... Бөтен бер авыл! Алай гына да түгел, Кызыл Яр, Алдар, Тау-авыл бар. Мин бит Сажидә генә түгел, мөдир Сажидә. Минем өстә никадәр бурыч, никадәр җаваплылык. Шуларның барысын да ташла да, оныт та... шуларның барысына да төкер дә... кемнәндер куркып... җиңелеп... качып кит, имеш!

Менә сиңа кирәк булса, малайкай! Ничек баш җитмәгән шуны уйларга? Нәрсә, иртәгә тагын райздравка барыргамыни? Инде кире уйладым, район больницасына керәсем килми диярргәмени? Юк инде, ике аягымның берсен дә атламаячакмын!

Шул чакны әни өстәлгә кайнар аш китереп утыртты.

— Әйдә, тор, ятма анда көпә-көндез иркәләнеп! — диде ачу белән. — Бала-чага уены дип белдеңме әллә аны бер кайтып, бер килеп йөрергә! Килешмәгәнне...

Мин кинәт сикереп тордым. Юындым да ашарга утырдым. «Әллә бүген үк китәргә инде?» дидем үз-үземә. Әйе шул, китәргә кирәк. Әле соң түгел. Кеше-кара сизенгәнче тизрәк таярга кирәк моннан.

Ашап туйгач, беркемгә бер сүз әйтмичә, киенә дә башладым.

— Кая җыенасың тагын? — диде әни.

— Җыенам әле, — дидем. — Авылга китәм. Мәсәгуткә.

— Китәсең?! Әллә тагын ут капканмы? — диде әни, ачуланасы килеп.

— Мәсәгуткә ут капмаган. Миңа капты, миңа! — дидем мин.

— Син нәрсә эндәшмисең? — диде әни әтигә. — Минем сүзне колагына да элми инә синең унган кызың. Үзең әйт. Иртәгә китәр. Кайчан барып җитә ул... Төнгә калса...

## XVIII

Әти җавап бирергә өлгермәде, — урамда, безнең турыдан гына бик каты үкереп, тирә-якны дер селкетеп ниндидер машина узганы ишетелде. Без барыбыз да никтер тынып калдык. Машина исә ары китмәде, безнең капка турысында шып туктады. Кабинадан, кузовтан ниндидер кешеләр төште.

Мин аптырап тәрәзәгә якынрак килдем. Карыйм... кемнәр соң болар? Безгә керәләр түгелме соң? Аһ аллам, харап кыналар булдым, мине алырга килделәр микәнни?

Тәрәзәгә карана-карана керделәр болар капкадан. Баскыч төбендәге тимер сыртына күн итекләрен кырдылар, текә баскычтан менә башладылар. Иң элек Кәрим абый килеп керде. Күзем күренәме әллә дип торам! Теге безнең күршедәге укытучы. Аның артыннан... Равил, аннан шофер...

— Исәннәрмесез әле, — диде Кәрим абый.

Аның янындагылар да тыелып кына гөрелдәшеп алдылар, исәнмесез-саумысыз, диделәр. Равил, мине күрде дә, бер дә юктан авызын ерып җибәрде, үз кеше булып миңа каш сикертеп алган булды. Мин ни: торам нишләргә белмичә, үз өемдә үземне чит санап.

— Бик исәнбез. Әйдәгез, түрдән узыгыз, — диде әти, кунакларга каршы атлап.

— Узып тормабыз, — диде Кәрим абый.

Үзе шундагы урындыкка иркенләп утырды да, сүзсез генә миңа карап алды, аннары әтигә, әнигә карады.

— Менә... — диде, чигәсен кашыштырып. — Сажидә күршене алырга кердек. Мәсәгутнекеләр без. Яңавылда икәнен белдек тә, сугылып чыгыйк әле, дидек. Илебатырга ашлык китергәниек. Якын гына торасыз икән шул монда.

— Мин үзем дә китәргә җыенып ятадырыем әле, — дидем мин, ашыгып.

— Ә? Шулаймыни? — диде Кәрим абый. — Әйдә, алайса, сеңнем. Сине көтәләр анда. Синсез эш бармай.

— Кая, нинди китү әле ул? Менә чәй кайнады, чәй эчеп китәрсез, — диде әни, кунакларның кемнәр икәнлеген шәйләп.

— Рәхмәт, килен, эчеп тормабыз, — диде Кәрим абый, аягүрә басып.

Әти дә кабалана башлады, нишләп алай бик тиз генә диде, әзер ашны ташлап китү килешми инде ул, диде. Мин кыстап-нитеп тормадым, чөйдәге плащымны кулга элдердем дә, өйдән тизрәк чыгып китү

ягын карадым. Кәрим абый әллә минем турыда сүз куерта башлар тагы... әни алдында, әти алдында юкны-барны искә төшерә башлар...

Чыктым да баскыч төбенә, көтеп торам нишләргә белмичә. Менә күп тә үтмәде, ишек ачкан тавыш ишетелде. Чыгалар, ахрысы! Һай, рәхмәт төшкере Кәрим абый! Өстән тау-таш ишелеп төшкәндәй булды. Сөенеп, көлә-көлә шундук капкага йөгердем.

Кузовта берничә ир кеше, хатын-кыз күренә. Мәсәгутнекеләр. Төсләрне аера алмыйм, шулай да үзебезнекеләр икәнлеген ерактан ук күреп киләм.

— Сажидә, кил монда! — диде ниндидер кызый, кулын болгап.

— Апасы, кабинага утырасыңмы, безнен беләнме? — дип кычкыра арттан Равил.

— Сезнең белән. Кабинага Кәрим абый утырыр, — димен, артыма борылгандай итеп.

Сузылган кулларга үрелдем дә, тәгәрмәчләргә бастым да... тукта... авызы ерылганы Лилия... Икенчесе Тимерҗан лабаса! Кулдан нгыгып тоткан, елмайган...

Кинәт йөрәгем кысылып куйды. Хәл бетте. Үзем көлгән булам, елмайган булам. Алар да елмая. Никтер барысы да чамадан тыш шат, күңелле кебек күренә.

Менә Равил дә менеп утырды. Машина кузгалып китте. Әти белән әни нәрсәдер кычкырып калдылар — рәтләп ишетмәдем дә. Аяк астында машина тирбәлә, каршыга җил исә. Кайнар җил. Юк, җиле кайнар түгел, чигәләр кайнар. Якында гына Тимерҗан, Равил... Алда, киләчәктә — киңлек-иркенлек, билгесезлек һәм... бәхет. Бәхет? Алда микән, артта микән ул? Әллә янында гына микән соң?

*1962 ел, Казан*

—□—

*Дифгать Сирай*

## Яшьлек кебек

Малай чакта ташу карарга дип
Җыела идек күпер янына.
...Бозлар акты, елга актарылды,
Сулар чыкты сикереп ярына.
Алар китте иңләп болыннарны,
Үзәннәрне күмде, каплады.
Яшьлек кебек ярсып акты алар,
Ерак акты, кире кайтмады.

## Наратлар талпына

Урманның югалган тынлыгы,
Гөж килеп талпына наратлар,
Әйтерсең, иңенә аларның
Элгәннәр баһадир канатлар.
Наратлар талпына, шау-шуы
Гасырлар буена тыналмый.
Тормышның үзе бит ул урман,
Шуңадыр шауламый торалмый.

## Әй, сары яфрагым

Әй, сары яфрагым,
Җәй үтте бит инде.
Назлап бер сөйимче
Сипкелле битеңне.
Сипкелле яфрагым,
Сөйкемлем, кадерлем, —
Шулай дим, белгәнгә
Әнкәмнең кадерен.
Йөзендә сагыш-моң
Булгандыр аның да,
Мин читтә йөргәндә,
Еракта чагында.

●

Шифа бирә җиргә яңгырлары,
Шуңа килә болыт буласы,
Килми лакин аяз көннәрне
Аның кебек каплап торасы.

## Үз елгам бар

Юктыр, дустым, синең тыңлаганың
Бужай [1] дулкыннары тавышын.
Үргә таба һаман омтылам күк,
Текә ярларына ябышып.
Чабак кебек уйнап йөргән идем,
Чума-чума дулкын эчендә.
Ярларының соры комы гүя
Табанымны әле дә пешерә...
Юктыр, дустым, синең тыңлаганың
Бужай дулкыннары тавышын.
Тик һәркемнең була үз елгасы
Түгәр өчен шатлык, кайгысын.

## Алып кайтмас

Күпме чакрымнарны үттем икән
Төпи басып киткән язымнан?
Һәр адымнан туган туфрагымда
Азмы-күпме эзләр язылган.
Эз калмаса?
Үткән юлга кире
Алып кайтмас нинди еллар да.
Кешеләрнең күңелендә генә
Мөмкин чөнки кабат туарга.

[1] Елга исеме.

——□——

Нил Юзиев

# МУЗАЛАР ТУГАНЛЫГЫ

## II. Әдипнең эрудициясе һәм сәер остазлары

Әдәбиятның үсүе, баюы, беренче чиратта, аның иҗатчылары — язучыларга бәйле. Язучының халык тормышы белән бәйләнеше, заман һәм укучылар таләбен тоюы, таланты, культура дәрәҗәсе, эрудициясе — болар барысы да әдәбиятның хәрәкәт итү тизлеген, аның эстетик сыйфатын билгелиләр.

Әдипнең уй-хисләр дөньясын, сурәтләр палитрасын баету юллары гадәттән тыш күп. Шул мөмкинлекләрнең берсе — үзенә чиктәш сәнгать төрләрен яхшы белү, аларның казанышларын өйрәнү.

Татар язучыларының эстетик карашларын тикшергәндә дә аларның матурлык тойгыларын тәрбияләүдә башка сәнгать төрләренең әһәмиятле роль уйнавы ачык күренә. «Музыканы мин иҗатымны баетырга, тирәнәйтергә ярдәм итә торган бер эзләнү алымы, үземне тәрбияләү чарасы итеп карыйм», — дип сөйли Сибгат Хәким. Язучыларның иҗтимагый һәм тәнкыйть эшчәнлекләренә дә шушы бердәмлек тирән эз салган. Мәсәлән, Г. Ибраһимов үзенең әдәбият теориясенә караган хезмәтләрен яки шул чордагы татар әдәбияты турындагы мәкаләләрен язганда бөтен дөнья сәнгать тарихы казанышларыннан мул файдалана, театр һәм музыка тарихына да, рәсем һәм һәйкәлчелек өлкәләрендәге ачышларга да таяна. Ул әдәбиятның үз канунннарын гына түгел, әдәбият һәм сәнгать арасындагы уртаклыкларны да ачарга омтыла.

Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Гафури кебек язучылар сәнгатьнең башка төрләрен пропагандалауда, аларга нигез салуда якыннан торып катнаштылар. Алар артистларның, җырчыларның, яңа туып, күтәрелеп килгән театрның иң якын дуслары, булышчылары, таянычлары булдылар. Г. Камалның, тормыш соравына буйсынып, үзенең үк драматург, артист, рәссам булу факты да күп нәрсә сөйли.

Халыкны уятуда, аны тәрбияләүдә сәнгатьнең гаять зур көчкә ия булуын алар ачык төшенделәр. Тукай милләтне уятыр өчен «җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын», дип язды. [Тукай. Әсәрләр. 4 томда. 3 том. 13 бит.]

Сәнгать өлкәсендә киң эрудицияле булу аларга әдәбият канунннарына тирәнрәк төшенергә ярдәм иткән. Милли сәнгать төрләренең башка илләр белән чагыштырганда арттылыгын күрү аларда көрәшче-трибун сыйфатларын үстергән.

Г. Ибраһимов та татарда рәссамлык сәнгатенең юклыгына пошынып, «тәрсим вә тасвир сәнгатен» үстерергә чакырды, «Рәсемнәрнең махсус бер мәсләк вә бер идеягә хезмәт җәһәте дә бардыр» дип, рәсем сәнгатен дә «халык ихтыяҗына хезмәт» итәргә өндәде. Бу уңайдан Л. Толстойның «фәкыйрь вә ач булган авыл крестьяннарының аяныч хәлен тәрсим кыйлырга» өндәвенә тулысынча кушылып, рәссамнарның халык алдындагы югары миссиясен дә билгеләде. [Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 1960 ел. 29 бит.]

XX йөздә татарның милли сәнгать төрләре баеп китүе әдәбиятның сәнгать белән тагы да тыгызрак бәйләнеше туууга сәбәп булуын алда язып үткән идек. Шунысын да әйтергә кирәк, бу дәвердә татар әдәбиятына рәсем яки музыка сәнгате йогынты ясауга караганда, сәнгатьнең ул төрләренә әдәбиятның йогынтысы күп көчлерәк булды. Татар профессиональ музыкасы, мәсәлән, бер яктан халык моңына һәм классик рус, көнбатыш Европа музыкаларына нигезләнеп туса, икенчедән, татар шигъриятенә, иң беренче чиратта Г. Тукай поэзиясенә, халык күңелендә ул ачкан рухи байлыкка һәм шул байлыкны сурәтләү алымнарына таянып туды. Һәвәскәр композитор Заһидулла Яруллинның Тукай вафаты уңае белән язылган «Тукай маршы» бу яктан бик тә мәгънәле ишарә. Бу әсәр Тукайның бөеклеген һәм халыкка якынлыгын музыка теле белән әйтеп бирергә омтылуның беренче тәҗрибәсе иде.

Тукай шигърияте үзе бер дөнья, халык күңеленә гаять тирән үтеп кергән, халык белән шагыйрь арасында аерылгысыз бердәмлек урнаштырган, шуның белән халык-

ның эстетик фикерләвенең яңа югары баскычын төзегән тылсымлы сәнгать дөньясы иде.

Менә шунда без сәнгать төрләре һәм аерым жанрларның кушылырга омтылуы һәм үзара тәэсир итешүләре нигезендә яткан кайбер сәбәпләр белән очрашабыз. Бу — сәнгать төрләре һәм формаларының үзенчәлеге, иҗтимагый тормышта башкарган вазифалары белән аңлатыла. Аларның (сәнгать формаларының) закончалыкларында бердәмлек бар. Төрле форма, жанрларны берләштерә торган уртак законнарның яшәве бу туганлыкның нигезендә ята. Кино гына түгел, әдәбият та, хәтта музыка үзе дә өлешчә синтетик сәнгать.

Г. Ибраһимов язганча, «сәнгатькәрнең — теләсә шагыйрь вә әдип булсын, теләсә рәссам вә композитор булсын — халыкка мөнәсәбәтенең, халыкның аны үз итүенең, йөрәгенә якын алуының сере иштә шул ике йөрәк арасындагы уртак тәэсирнең шул әсәрдә, шул рәсемдә, шул көйдә табигый вә ачык рәвештә тәҗәссем итүендә, — сүз беләнме, рәсем беләнме, — шуның гәүдәләнә алуында, тагы ачыграк әйткәндә, сәнгатькәр йөрәгеннән халык йөрәгенә турыдан-туры юл салуындадыр» (Альбом. Казан. 1915. 13 бит).

Г. Тукайның да халык титаны булып күтәрелүе, шагыйрьләргә генә түгел, ә гомумән рәссам, композитор, драматург — һәр өлкәдәге сәнгатькәрләргә юл күрсәтүче йолдыз буларак мәгърифәт дөньясында балкуы әнә шул ике йөрәк арасында уртак тәэсирнең урнашуында, шагыйрьнең халык йөрәгенә турыдан-туры иң кыска юлны таба алуында. Менә шул юлны табуы һәм шул юлдан тайпылмыйча атларга өйрәтүе белән Тукай шагыйрьгә дә, композиторга да, драматургка да кадерле, якын. Тукайның дөнья әдәбияты һәм сәнгате казанышларының байлыгын үзләштерү нигезендә формалашкан реалистик сурәтле фикерләве татар композиторларына гаять дәрәҗәдә нык йогынты ясады. Тагын шунысы әһәмиятле һәм кызык: бу йогынты татар музыкасы үскән саен тирәнәя һәм катлаулырак төс ала бара. Тукай бүгенге көндә дә композиторларга остаз, укытучы булып кала. Бүгенге композиторлар да Тукай шигърияте белән рухланалар, Тукайның халыкчанлыгыннан, халык һәм кеше йөрәгенә иң туры юлны табу осталыгыннан өйрәнәләр.

Тукай иҗаты үзенең темалары, образлары белән дә композиторлар өчен бетмәстәкәнмәс чишмә булды. Тукай авырлык кичермичә, бик табигый гына поэзиядән музыкага күчте. Тукайның музыка дөньясына күчүе Тукай заманында ук башланды, аеруча совет чорында киң колач җәйде. Татар композиторларының шагыйрь сүзләренә 60 лап җыр, романс иҗат итүләре дә күп нәрсә сөйли.

Тукай композиторларга җыр музыкасын, татар романсын үстерергә ничек булышса, аның башка жанрларга да шундый ук ярдәме тиде. Беренче татар балеты — Ф. Яруллинның «Шүрәле»се Тукайның «Шүрәле» балладасына нигезләнеп туды һәм бөтен дөньяны диярлек әйләнеп чыкты. З. Хәбибуллинның «Раушан», Ә. Бакировның «Алтын тарак», Р. Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балетларында, Н. Җиһановның «Кырлай» поэмасында да Тукай иҗат иткән образлар белән очрашабыз, аның фикерләвен, дөньяны кабул итүен тоябыз. Шагыйрь хыялы белән туган образлар, җанлы күренешләр, музыка дөньясына күчеп, яшәүләрен яңача дәвам иттерәләр, яңа эмоцияләр, буяулар белән баетылалар.

Салих Сәйдәшевның композитор буларак формалашуында Тукайның роле, шөбһәсез, зур. Г. Тукайның шигъри фикерләве һәм С. Сәйдәшевның музыкаль фикерләве арасында гаҗәп тирән охшашлык һәм уртаклык бар. Һәр икесенең иҗаты халык рухы белән, халык моңы белән тирән сугарылган, һәр икесенең иҗаты халык йөрәгенә күзгә күренмәстәй мәңләгән нечкә җепләр белән тоташкан. Тукайның поэзия күгендә балкуы музыкада Сәйдәшев кебек гаҗәп халыкчан композиторның тууына этәрүче күп сәбәпләрнең берсе булды.

Тукайның татар музыкасын үстерүдәге күп яклы хезмәтен өйрәнүне музыка белгечләренә калдырып, тик шуны гына әйтәсе килә: рус музыкасын үстерүдә Пушкинның роле ничек булса, Тукайның да татар музыкасын үстерүдәге хезмәте, урыны шулай.

Тукайны тик гел үзеннән генә нур чәчүче шигърият кояшы итеп күзалларга күнеккәнбез. Такташны да, Җәлилне дә, Ибраһимовны да. Хакыйкатән ул шулай. Ләкин ул нурлар бит юктан бар булмыйлар. Төрле атомнарның кушылулары нәтиҗәсендә әнә шундый энергия, көчле нурлар туа. Тукай да, Такташ та, Ибраһимовлар да әдәбият һәм сәнгатьнең башка төрләре, жанрлары чәчкән нурларны, байлыкны үзләренә җыйнадылар.

Шушы уңайдан америка язучысы Эрнест Хемингуэйга хәбәрчеләр биргән бер сорауны китереп үтәсе килә. «Сезнең укытучыларыгыз кемнәр!» дигән сорау белән мөрәҗәгать иткәч, ул болай дип җавап бирә: «Марк Твен, Флобер, Стендаль, Бах, Тургенев, Толстой, Достоевский, Чехов, Эндрю Марвелл, Джон Донн, Мопассан, Киплинг, Торо, капитан Марриэт, Шекспир, Моцарт, Кеведо, Данте, Вергилий, Тинторетто, Иероним Босх, Брейгель, Патенье, Гойя, Джотто, Сезанн, Ван-Гог, Гоген, Сан Хуан де ла Крус, Гонгора. Берсен дә онытып калдырмыйча санар өчен миңа тулы бер көн кирәк булыр иде. Ә аннан соң бу минем тормышка һәм иҗатка йогынты ясаганнарның барысын да искә төшерергә тырышуга караганда үземнең юк эрудициям белән мактану кебек нәрсә килеп чыгар иде» (Э. Хемингуэй әдәби осталык турында. «Иностранная литература» журналы. 1962 ел. 1 сан).

Хемингуэйның үз элгәрләре һәм остазлары итеп бөтен дөньяга танылган проза осталарын атавы бик тә табигый. Әмма шушы ук җавапта беренче карашка сәер тоелган исемнәр дә очрый. Шекспир — прозаик түгел, драматург. Эндрю Марвелл,

Джон Донн, Кеведо, Вергилий, Гонгора — болары төрле заманның, төрле илләрнең шагыйрьләре. Әдәбият вәкилләреннән тыш бу исемлектә Бах, Моцарт кебек атаклы композиторларның исемнәре бар. Ул гына түгел, Хемингуэйның укытучылары исемлегендә атаклы испан художнигы Франсиско Хосе де Гойяны, бөек итальян рәссамнары Джотто һәм Тинтореттоны, атаклы нидерланд художниклары Иероним Босх Ван Акенны һәм Брейгель Старшийны, француз рәссамы Поль Гогенны очратабыз.

Композитор, әдип яки рәссамнарның шундый «сәер» укытучылары булуы беренче карашка гаҗәбрәк тоелса да — табигый күренеш. Аерым шагыйрьләр Салих Сәйдәшевны Тукай белән янәшә куеп, аңа багышлап шигырьләр язалар икән, Сәйдәшевны да үзләренең укытучылары санныйлар икән — бу гадәти хәл. Һәйкәлче Урманчега Кол Гали, Тукай, Дәрдмәнд, Җәлил сынналарын оста башкарырга рәссамнар гына түгел, үзләренең шигырьләре белән шул ук шагыйрьләр дә ярдәм иткәннәр, өйрәткәннәр. Бакый аганың Тукай яки Дәрдмәнд шигырьләрен яттан белүе, фарсы, төрек яки инглиз шагыйрьләрен оригиналда укуы очраклы түгелдер. Аның мастерской стеналарын да Сәгъди шигырьләре бизәгән.

Г. Ибраһимовның остазлары итеп без гадәттә Горький, Толстой шикелле прозаикларны атыйбыз. Минемчә, аның укытучылары күбрәк һәм төрлерәктер. Укытучылары Пушкин, Лермонтов, Байрон кебек шагыйрьләр арасында да, Шекспир, Островский кебек драматурглар арасында да булгандыр. Хемингуэйга биргән сорауны Ибраһимовка биргәндә, ихтимал, ул укытучылары арасында Репинны да, Верещагинны да, Шишкинны да, антик сәнгать осталарын да атар иде. Гөлсем Мөхәммәдева үзенең истәлекләрендә Ибраһимовның сынлы сәнгатьне гаҗәп тирән аңлавын, мәшһүр сурәтчеләрнең иҗатын яхшы белүен язып үтә.

Тукайны күп татар прозаиклары үзләренең укытучылары итеп санныйлар. Гомәр ага Бәширов университет студентларына сөйләгән бер лекциясендә үз иҗатына Тукайның көчле йогынты ясавын, сүзне урынлы куллану, фразаның аһәңен табу буенча шагыйрьдән күп өйрәнүен әйтеп үткән иде.

Шулай ук Тукайның остазлары да без уйлаганга караганда күбрәктер. Тукай поэзиясенең татар әдәбиятында яңа дәвер ачуын, гаҗәп күп төрле интонацияләрдә яңгыравын, искиткеч сыгылмалы формаларга, күп төрле жанр үзенчәлекләренә ия булуын аның тик халык авыз иҗатыннан, рус һәм бөтен дөнья поэзиясе казанышларыннан өйрәнүенә генә кайтарып калдыру тулы һәм төгәл булмас иде. Аның остазлары — шагыйрьләр генә түгел.

Без еш кына «Тукай Пушкиннан өйрәнгән» дибез. Пушкин дигәннән аны шагыйрь буларак кына күз алдында тотабыз. Тукай исә Пушкин-шагыйрь белән Пушкин-прозаикны аерылгысыз шәхес итеп караган, бөек шагыйрьнең проза әсәрләреннән дә өйрәнгән. «Пушкинга» шигырендә ул үзе бу турыда ачык итеп әйтә:

«Мәрамым — матлабым анчак сәнең мәнзум вә мәнсурең» (ягъни «Минем бар теләгем, максатым — синең тезмә һәм чәчмәләрең», ди).

Шагыйрь үзе әйтмешли: «бөтен җаннарның җаны вә бөтен инсаннар вөҗданы кадерле вә бәһалы Толстой җәнапларыннан» һәм башка атаклы прозаиклардан (шул исәптән З. Бигиев, Ф. Әмирханнар иҗатыннан) Тукай шигърияте күп нәрсәләр белән тукланган.

Реалистик прозаның казанышларын өйрәнү һәм файдалану Тукайга үз чорын тарихи, милли, социаль, политик сыйфатлары белән конкрет һәм тирән итеп ачарга ярдәм иткән. Шагыйрь үзенең игътибарын хикәя яки повесть кануннарына түгел, ә прозаның кешене һәм җәмгыятьне тикшерү буенча ачкан яңа сыйфатларына юнәлтә. Ул сәнгатьнең һәм әдәбиятның үсешен билгели торган, поэзиянең дә казанышы булып әверелердәй әнә шул гомуми сыйфатларны өйрәнә.

Тукайга XX гасыр проза казанышлары гына түгел, театр, драматургия, музыка да тәэсир иткән. Тукай дәверендә аеруча театр аякка баса, зур казанышларга ирешә. Шуңа да Тукайга театрның көчле йогынты ясавы бик тә табигый.

Г. Тукайның 1907 елны «Әльислах»та басылган «Театр» шигыре шагыйрьнең театр сәнгатенә көчле мәхәббәте турында, бу сәнгать төренең көче турында сөйләде. Әмма шигырьнең әһәмияте моның белән генә чикләнми, ул татар театрының, артистларының тууына да тәэсир иткән. Сәхнә ветераны Касыйм Шамил: «...иске мәдрәсәне ташлап чыккан Кулалайларның, чапанчадрасын ташлаган Сәхипҗамалларның һәм шулар кебек башка бик күпләрнең артист вә артистка булып китүләренә бу шигырьнең тәэсире бик зур булды», — дип күрсәтә. («Совет әдәбияты» журналы. 1946. 4 сан. 124 бит.)

Г. Тукай атаклы артист Габдулла Кариев белән дә якын дус булган. Хәтта аның сәхнәгә менүендә дә Тукайның билгеле бер роле барлыгын сөйлиләр. Г. Тукай 1907 елны Уральскидагы әдәби кичәдә үзенең «Теләнче» шигырен, бер шәкерт белән бергә, сәхнәдә инсценировка итеп уйнаган. Менә шушы уенны күрү яшь Кариевтә сәхнәгә менү теләге уяткан. Артист булгач та ул Тукай белән дуслыгын дәвам итә, «шагыйрьнең киңәшләрен тыңлау белән үзенең уенын үстерә». («Совет әдәбияты» журналы. 1946 ел. 4 сан. 124 бит.)

Тукайның сәхнә һәм театр белән дуслыгы аның поэзиясенә дә билгеле бер тәэсир ясаган. Моңа бер яктан, диалог формасында язылган шигырьләрнең Тукай поэзиясендә активлашып китүе дә мисал була ала. Тукайның «Бала белән күбәләк», «Яңгыр илә кояш», «Казан мулласы һәм булачак депутат», «Өйләнү — түгел сөйләнү», «Ике иптәш арасында», «Ник! Нигә!», «Шайтанның муенына» кебек шигырьләре диалогка нигезләнеп төзелгәннәр. Кемгә дә яки нәрсәгә дә булса атап эндәшүнең, кем беләндер сөйләшү, монолог рәвешендә язылган шигырьләрнең Тукай поэзиясендә гаҗәп

зур урын алуын искәртмичә булмый. Поэзия өчен бик табигый булган мондый форманың активлашуында да театрның йогынтысы булмый калмаган. Театр поэзиянең элек-электән хас үзгәлекләрен тирәнрәк тоярга, яшәп килгән сәнгать алымнарының рольләрен ачыграк сиземләргә, шигырьнең үз функциясен ныграк аңларга ярдәм иткән.

Сөйләү, хәрәкәт, драматизм, картиналылык — театрның бу сыйфатлары элекке чор поэзиягә караганда Тукай шигыренә дә үзгәрәк бер төс бирә, Тукай шигыренә дә үзенә күрә сыйфат яңалыгы өсти. Менә, мәсәлән, «Китмибез» шигыре:

Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр:
— Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! — диләр.
Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:
Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион.

Күрәсез, шигырь көйләүгә түгел, ә сөйләүгә корылган. Бу үз чиратында бөтенләй яңа интонацион-ритмик төсмерләр туугa сәбәпче булган. Хис-фикер драматизмы ягыннан караганда да шигырь үзенчәлекле: киеренке фикер, фикернең энергияле агышы... Шигырь үзе бер драматик театраль күренешне хәтерләтә. «Эштән чыгарылган татар кызына» җырында да без шушы драматик киеренкелекне ачык тоябыз.

«Шүрәле», «Таз», «Эш беткәч уйнарга ярый», «Теләнче», «Печән базары яхут яңа Кисекбаш», «Су анасы», «Япон хикәясе», «Кәҗә белән сарык әкияте» әсәрләрендә исә нинди бай театраль картиналылык! Хәрәкәт аларда шулкадәр оста оештырылган — үзләре үк инсценировкага, сәхнәгә, тамашага сорап торалар.

Тукай әсәрләренең балалар бакчасында, мәктәпләрдә театраль күренеш буларак куелып, уйналып йөрүләре, «Таз» сюжетына балетмейстерларның бию куюлары һич тә очраклы түгел. Болар барысы да татар поэзиясендә, шигырь поэтикасында туган яңа үзгәрешләр турында, Тукайның укуга гына түгел, ә тыңлауга, күрүгә дә нигезләп иҗат итүе, музыкаль шагыйрь генә түгел, театраль һәм драматик шагыйрь дә булуы турында сөйлиләр.

Тамашага корылган шигъри әсәрләр, билгеле, халык авыз иҗатында татар театры туганчы ук яши иде (Н. Исәнбәт. «Балалар фольклоры». К., 1940). Диалог формасы шулай ук үткән чор әдәбиятының аерым әсәрләрендә очрый иде. Әмма театр тууы халык иҗатында һәм язма поэзиядә яшәп килгән ярапгыларны тагы да ныграк үстереп җибәрде, ул формаларны активлаштырды, аларның шигъри төзелешендә яңарак эстетик функцияләрен ачты. Менә шуңа Тукайда бу алымнар халыкның сурәтле фикерләвенә шулкадәр якын да, шул ук вакытта яңа эчтәлекне ачарга җайлашкан сәнгатьчә табигыйлекләре һәм яңалыклары белән үткән чорлардан аерылып та торалар.

Сәнгать төрләренең йогынтысы башка әдипләрдә дә чагылмый калмады (М. Гафури, С. Рәмиев, Ш. Бабич, Дәрдмәнд, С. Сүнчәләй һ. б.). Әмма Тукайда бу «керешү» көчлерәк, тирәнрәк булды һәм уңышлырак нәтиҗәләргә китерде. Тукайның бу яктан да олы таланты, гаҗәп сизгер шигъри интуициясе күзгә ташлана. Ул поэзияне тагы да киңрәк, олырак мәйданга алып чыкты, аның үсеше өчен күп төрле юллар күрсәтте. Сурәтле фикерләүдә Тукай ачкан яңалыкларны, шул исәптән сәнгатьнең төрле төрләре, жанрлары арасындагы тыгыз бәйләнеш традициясе татар совет поэзиясендә тагы да үстерелде.

20 елларның ахырында, 30 елларда поэзиянең театр белән бәйләнешендә яңа күренешләр, яңа процесслар туа. Татар совет культурасының киң колач белән үсүе арадашлыкны, иҗади бәйләнешләрне тагы да көчәйтте, театр һәм музыкага бәйләнешле, яңа жанр үзенчәлекләренә ия булган әсәрләрнең туына сәбәпче булды.

Язучы һәм сәнгатькәрләрнең иҗади дуслыгын, бергә, кулга-кул тотынышып иҗат итүләрен тормыш үзе көн тәртибенә куйды. Монументаль, синтезлы сәнгать төрләрен тудыру шагыйрь, композитор, рәссамнарның уртак иҗатыннан башка мөмкин түгел иде инде. Опера, балет, кино кебек сәнгать төрләренең туу шушы иҗади бергәлек, арадашлык бурычын да куйды. Шагыйрьләр дә, композиторлар да, рәссамнар да тар «үз цех»ларыннан чыгып, әмма шул цехларындагы байлыкка, тәҗрибәгә таянып, татар сәнгате өчен бөтенләй яңа күренеш булган әсәрләр иҗат иттеләр. Балет һәм опера татар сәнгатендә менә шундый зур яңалык һәм үзгәреш тудырган күренеш иде. Шагыйрьләрнең опера-балетка тартылулары поэзиядә дә, шагыйрьләрнең үз иҗатларында да яңа традицияләр ачты. Опера драматургиясен аякка бастыру өчен М. Гафури «Эшче» драматик поэмасын яза, С. Габәши, В. Виноградов кебек композиторлар, Г. Әлмөхәммәдев кебек җырчылар белән дуслаша, классик музыканы, опера жанрын өйрәнә. Тукай чоры белән чагыштырганда, 30 елларда сәнгать төрләренең синтезы, шул рәвешчә, үзгәрәк күренеш буларак аерылып тора.

20—30 елларда шигырьнең музыка, кино, театр белән якынаюы поэзияне яңа ачышлар белән баета. Бу синтезның үрнәге аеруча Такташ иҗатында чагылды. Татар поэзиясендә симфонизм күренеше белән без Такташ иҗатында очраштык. Такташ «шагыйрь композитор булырга тиеш» дип санады һәм, шигырьнең бөтен искергән кануннарын җимереп, хиснең табигый, иркен, күп тавышлы яңгыравына иреште. Аның театр, кинодан өйрәнүе татар шигырен драматизм белән баетты, шагыйрь күзенең кинематограф күзе кебек хәрәкәтчән булуына китерде. 30 елларда бу традиция үстерелде, Ә. Фәйзинең «Качкын», «Золхәбирә», М. Җәлилнең «Алтынчәч», М. Максудның «Кара йөзләр» кебек, яңа жанр үзенчәлекләренә (либретто) ия булган уңышлы әсәрләр иҗат ителде.

Арадашлыкның көчәюе укытучы-остазларның да санын бермә-бер арттырды. Җәлилнең остазларын Дәрдмәнд, Тукай, Такташ, Шевченко, Гейне, Шиллерлар белән генә чикләү тулы булмас иде. Б. Асафьев, С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, Җ. Фәйзи, Л. Хәмиди кебек композиторлар аның якын дуслары да, музыка өлкәсендәге укытучылары да булдылар. Бу исемлекне Җәлил, бәлки, Бах, Моцарт, Бетховен, Брамс, Гендель исемнәре белән дә тулыландырыр иде. Әминә ханым үзенең истәлекләрендә Мусаның бу композиторларны ның яратуын һәм аларның әсәрләрен яхшы белүен яза.

Бездә язучыларның публицистик мирасы тиешенчә өйрәнелмәгән. Әгәр, мәсәлән, Г. Кутуй, М. Җәлил, Ә. Фәйзиләрнең сәнгать турындагы мәкаләләрен тулы итеп туплап чыгарсак, аларның татар сәнгатен үстерү өчен гаҗәп күп көч куйганлыкларын, театрны да, музыканы да, рәсем сәнгатен дә тирән аңлап эш итүләрен, киң культуралы, тирән эрудицияле әдип булуларын күреп тагын бер кат сокланыр идек. Алар яңа туып килә торган опера һәм балет театрына әсәрләре белән дә ярдәм итәләр, мәкалә-рецензияләр аша да җәмәгатьчелекнең игътибарын туплыйлар. Рәсем күргәзмәләре, җырчыларның яңа концерт программалары турында да язарга вакыт табалар. Алар сәнгатьнең әдәбият белән чиктәш өлкәләрендәге закончалыкларын зур тырышлык һәм комсызлык белән өйрәнергә тырышалар.

Шушы уңайдан академик Б. В. Асафьевның «Алтынчәч» операсы уңае белән Җәлилгә язган түбәндәге хатыннан бер өзек китереп үтәсе килә: «Бөтен йөрәктән Сезгә тагын бер тапкыр либреттогыз өчен, булган бөтен игътибарыгыз өчен, минем белән сезгер эшегез өчен, безнең бөтен иҗат эшенә — сәнгатьчә принципиаль мөнәсәбәтегез өчен рәхмәт укыйм... һәм мин бу иҗат дуслыгыбызның дәвам итүен генә теләр идем, чөнки мин Сездә культуралы белән миңа якын булган сезгер либреттист-шагыйрьне таптым».

Шундый атаклы композитор, академик татар шагыйре белән, аның таланты, кешелеклелеге, культурасы белән сокланган икән — бу инде бер дә юктан гына түгел!

Әхмәт Фәйзине якыннан белгән язучылар, композиторлар, артистлар һәм художниклар шулай ук шагыйрьнең сәнгатьнең башка тармакларын гаҗәп тирән белүе, аңлавы, төшенүе, киң культуралы, эрудицияле булуы турында сөйлиләр. Ә. Фәйзинең архивтагы әлегәчә басылмаган бай публицистикасы да шушы фикерне тулысынча раслап тора.

* * *

Үзара тәэсир һәм йогынтыларны билгеле бер калыпка салып күрсәтүе ифрат авыр. Алар төрле язучыда, төрле сәнгать төрендә, хәтта сәнгатькәрнең төрле әсәрләрендә төрлечә чагылалар.

Сәнгатьнең аерым төрләренә мәхәббәт, шул өлкәдә кайнау, шул өлкә кешеләренең тормышларын өйрәнү әдипнең тормыш тәҗрибәсен тулыландыра, әдәбиятны темә һәм образлар ягыннан да баета. Сәнгать дөньясында кайнаган Г. Кутуйның повесть, хикәя, пьесаларына артист образларының килеп керүе һәм аларның җанлы сыйфатларында ачылуы һич тә очраклы түгел. Н. Исәнбәтнең беренче татар артистлары тормышыннан алып язылган «Гөлҗамал» драмасының тууы шулай ук Нәкый аганың театр белән озак еллар дәвамлы дуслыгының бер нәтиҗәсе ул.

Нинди дә булса композиторга, рәссамга яки артисткага багышлап язылган әсәрләр турында да сүз элып барырга мөмкин булыр иде. Поэзиядә андый шигырьләр дә (С. Сәйдәшев, Ф. Кудашева, Ф. Ильская, Ә. Афзалова, И. Шакиров һ. б. турында) бик табигый рәвештә туа торалар һәм, алар да әдәбият һәм сәнгать кешеләре арасындагы дуслык җепләре турында сөйли торган фактлар буларак карала ала. Фәридә Кудашеваның халык моңы белән сугарылган җырларын тыңлау Хәсән Туфанны «Башкортстан сандугачына» багышлап махсус шигырь иҗат итәргә этәргән. Аккош күлендә үткәрелгән бер әдәби җомгага һәвәскәр композитор Фәтхерахман Әхмәдиев тә килгән иде. Хәсән ага аның баянда уйнавын сокланып тыңлап утырды да, бер мәлне югалып торды. Бу арада ул музыкадан тәэсирләнеп шигырь язган икән, шул кәгазьне алып килеп, ул аны мәҗлестәгеләргә укып та чыкты...

1938 елны Сибгат Хәким Мәскәүдә шагыйрьләрнең бер айлык семинарында укыган вакытта Третьяков галлереясендә була һәм Венера Милосская сынын карау тәэсирендә соңыннан «Теләк» шигыре языла. Шул ук елны ул Мәскәүдә атаклы һәйкәлче Меркуров мастерскоен карый, художник һәм аның бай иҗаты белән таныша. Бу кызыклы очрашу истәлеге буларак «Скульптор мастерскоенда» шигыре туа. С. Хәким һәйкәлче Бакый Урманченың мастерскоенда хәзер дә шактый еш була. Бакый аганың һәр яңа эше белән беренчеләрдән булып танышып бара. Шагыйрьнең Урманчега багышлап язылган махсус шигыре дә бар икән.

Шагыйрьләрнең опера театры һәм музыка белән тыгыз контактка керүләре яңа жанр — либреттолар тууына сәбәпче булуы турында язып үткән идек. Биредә сәнгать төрләренең «керешү»ләре, йогынтылары артык дәлил сорамый, үз алдына сөйләп тора. Әмма турыдан-туры икенче сәнгать төренә кучми торган, шулай ук әдәбиятны баета торган йогынты-тәэсирләр дә яшь. Андый тәэсирләр үзләре күп төрле характерда булырга мөмкин. Боларын дәлилләве һәм аерып алуы күп кыенрак. Ярый лә, язучы үзе исән чакта ул турыда язып калдырса! Ләкин татар әдәбиятында иҗат психологиясен һәм иҗат процессын ачуга, тикшерүгә тиешле әһәмият бирмәгәнгә, язучыларның истәлекләрендә ул күтәрелмәгән чирәм булып калуында дәвам итә. Кайвакытта хәтта исән язучылар да башка сәнгать төрләре тәэсиренең ничек булуын билгеләргә кыенсыналар. Мәсәлән, Антанас Венцлова (Вильнюс) үзенә киноның тәэсир ясавын кире кага. Ә менә худож-

никларның — француз импрессионистларының һәм Чюрленис, Шклерюс, Сарьян кебек рәссамнарның үзенә көчле тәэсир итүләрен ачыктан-ачык әйтә. «Ләкин миңа язучы буларак алар нинди тәэсир ясыйлар — әйтергә кыенсынам», — ди ул үзе дә. Сынлы сәнгатькә карата шушыңа охшаш фикерне миңа С. Хәкимнән дә ишетергә туры килде.

Үзара тәэсирләрнең көчен, чикләрен билгеләү, әлбәттә, гаять авыр эш һәм аерым очракларда булган тәэсирне дә аерып алып күрсәтүе кыендыр, хәтта мөмкин дә түгелдер. Чөнки иҗат процессында сәнгать төрләре арасындагы көчләр генә хәрәкәт итмиләр, бу көчләр әдәби традицияләр, халык иҗаты традицияләре белән кушылып, тагы да катлаулы «капма-каршы көчләр хәрәкәте» тудыралар. Шулай да сәнгать төрләре һәм жанрларның үзара тәэсирләрен бөтенләй танып һәм билгеләп булмый торган бер нәрсә итеп карау да дөрес булмас иде. Әсгать Мөхтар үзенә үзбәк рәсем сәнгатенең, бигрәк тә Үзбәкстанның халык художнигы Урал Тансыкбаевның тәэсир итүе турында сөйли: «Урал Тансыкбаевның Үзбәкстан табигате турында зур сериясе бар. Ул картиналарда — Үзбәкстан нәкъ үзе... Бөтен тулылыгы, байлыгы белән ачыла. Рәссам аерым оста детальләр аша башкалар күрә алмаган матурлыкны, үзгәлекне сурәтләп бирә, күзгә якын иңләшкән нәрсәләрнең дә яңалыгын, тирән мәгънәлеген ача. Миңа шигырьдә пейзаж лирикасын язганда Тансыкбаев кайсы яклары беләндер ярдәм итте. Аеруча аның ярдәмен мин прозада («Дәвер минем тәкъдиремдә» романын язганда) табигатьне сурәтләгән чакта тойдым». (Малеевкада 25 январь, 1967 елдагы сөйләшүдән.)

Әхмәт Фәйзинең дә атаклы дөнья рәссамнарыннан күп нәрсәләргә өйрәнүе турында сөйләргә мөмкин булыр иде («Кара таш ник дәшми»). Бу юлы тик аның бер драмасын антик сәнгатьнең атаклы әсәре исеме белән — «Лаокоон» дип атавы белән чикләнәбез. (Бу әсәр шагыйрь архивында саклана.) 1942 елгы Ватан сугышы вакыйгаларын, Ленинград оборонасы вакыйгаларын сурәтләгән бу әсәрендә совет кешеләренең каһарманлыкларын ачуда борынгы грек скульптурасы да ярдәмгә килә. Әсәрнең идея эчтәлеген ачуда Лаокоонның билгеле бер әһәмияте бар: ирекле кешеләрне буарга омтылган кара еланнар фашистлар белән эчке бер тыгыз бәйләнеш ората.

Җәлилнең 30 елларда музыканы өйрәнүе аның бөтен иҗатына — жанрлар төрлелегенә дә, шигырьләрнең аһәңлегенә дә тирән тәэсир ясады. Мәсәлән, «Хат ташучы» поэмасының музыкаль, эмоциональ, лирик стилен тудыруда шагыйрьнең үзенең җырлар һәм романслар язу буенча туплаган бай тәҗрибәсе дә, рус һәм көнбатыш шагыйрьләренең җырларын, либреттоларын тәрҗемә итүе дә нык кына ярдәм иткән. Мәскәү консерваториясе янындагы татар студиясендә эшләгән чагында 1935 елның апрель-май аенда гына да ул 19 җыр һәм романс тәрҗемә итә. 1937 елны татар теленә Пушкинның 20 җыры һәм романсы күчерелсә, шуның яртысын Җәлил үзе эшли. Шушы ук елны ул русча 10 операдан өзекләр тәрҗемә итә. Болар барысы да аңа классик җыр һәм романслар поэтикасы белән якыннан танышырга, алардан өйрәнергә мөмкинлек биргән. Чыннан да, шушы елларда Җәлил иҗатында лирик тирәнлеккә, эмоциональ тулылыкка, гармониягә омтылыш көчәя.

Музыка белән шигырь бәйләнешен тикшергәндә, аерым язучыларда музыканың әсәр структурасына, сюжет-композициясенә дә нык кына йогынты ясавын күрергә мөмкин булыр иде. Бер төр поэмаларны хәтта музыкаль поэмалар дип атарга мөмкин. Андый әсәрләрдә җыр, көй, моң әсәрнең төзелешендә, сюжетында әһәмиятле роль уйнаган күренешкә әверелеп китә. Фәрит Ибраһимовның «Гармонь тавышы» — әнә шундый поэмаларның беренчеләреннән берсе. Әсәрнең идея-художество системасында гармонь тавышы зур роль уйный. Ул әсәрнең бөтенлеген тудырырга ярдәм итә, авторның фикерен үстерүче, аны ачучы топ чарага әверелеп китә. Гармонь моңы шагыйрьдә лирик ассоциацияләр уята, аның уен төрле тормыш күренешләре белән бәйли.

Шушындый ук күренеш белән Ә. Фәйзинең « Флейталар» һәм Ф. Кәримнең «Кыңгырау лы яшел гармонь» поэмаларында да очрашабыз. Биредә дә музыкаль төшенчәләр — флейталар иңрәве, саратский кыңгыраулы яшел гармонь моңы образларны ачуда әһәмиятле чараларга әверелеп китәләр. Менә «Флейталар». Башта флейталар сурәте нигездә музыкаль пландарак кабул ителә: флейталар уйный. Әмма тиз арада автор флейталарны җанландырып җибәрә:

алар сорый яшьлек хикәямне...

Флейталарның көйләвенә кушылып әсәрнең лирик герое үзенең үткәнен сөйли башлый.

Геройның үткәне һәм флейталар көйләве... Хикәяләү барышында бу ике пландагы күренешләр бер-берсенә якыная бара. Флейталар безгә геройның үткән тормышы турында көйлиләр, геройның «йөрәк грузовигын исерек шофер шикелле кууын», «ялгыз бунтарьлыгы диңгезне түгел, ә үзен яндыруын» сөйлиләр. Абыйсының гражданнар сугышында батырларча үлүе, абыйсы кулыннан төшкән байракны эстафета итеп алып киткән сугышчан дусларының хатлары — барысы да егеткә көрәш логикасын һәм революция романтикасын тирәнрәк аңларга ярдәм итәләр. Яшь егеттә яңа тойгылар уяна, ул үзенең «яңа нәсел эчендә тутык» икәнен, ниһаять, аңлый.

Мин шат... Бүген үлүемне түгел,
Туууымны җырлыйм.

Флейталар иңрәвен флейталар гүләве алыштыра. Алар егетнең авыр бала чагын, әтисен, әнисен күз алдына бастыра. Әмма егет өчен беренче тапкыр тууы түгел, ә икенче тапкыр — гражданин-көрәшче буларак тууы әһәмиятле. Бу турыда язганда

инде флейталарның моңлы тавышы ишетелми, ул — югала, киң күкрәк тавышы белән җырлаучы солист-җырчы образы килеп баса:

Бөек кеше түгел мин, шулай да
Бөек чор кешесе!
Мин масаям, «бүген» һавасында
Чыңлый минем җырлар.

Шундый даулы йөрәк хисләрен флейта тавышы яки ялгыз җырчы гына ишеттерә аламы соң!

Флейталар иңрәп тына, узган
Гомер кебек чыңлап,
Алар тына минем даулы йөрәгем
Симфониясен тыңлап.

Йөрәгендә туган хисләр ялкынын шагыйрь инде симфония образында сурәтли. Симфониянең соңгы өлеше яшьлеккә дан җырлаган көчле аккорд белән тәмамлана.

Симфония образы белән Такташның «Давылдан соң» шигырендә дә очрашкан идек. Шагыйрь бу образны Октябрьдан соң булган чынбарлыкны — тормыш катлаулылыгын, каршылыгын, яңа тормыш идеяләренең көчен сурәтләр өчен куллана. Бу әсәр хәтта үзенең интонацион-ритмик рәсеменең катлаулыгы белән музыкаль фикерләүгә аналогия рәвешендәрәк төзелгән. Симфонизмның тәэсире әсәрнең бөтен тукымасында сизелеп тора. Музыкаль фикерләү тәэсире башка шагыйрьләрдә дә бар. Ш. Мөдәррис «Үлемсезлек» әсәренең жанрын симфония дип билгеләгән. Д. Фәтхинең «Алтын тайга трагедиясеннән» поэмасында композиция сонатаның циклик формасы белән охшаш.

И. Юзеевнең «Таныш моңнар», «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмаларында шагыйрь фикерен ачуда музыканың роле шулай ук кечкенә түгел. «Таныш моңнар»дагы аерым шигырьләргә җыр язылып, поэманың музыкаль радиопоэма булып китүе һич тә очраклы түгел.

«Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасында музыкаль фикерләүнең тәэсире тагы да көчлерәк. Биредә файдаланылган аерым халык көйләре поэманың идеясенә, андагы образларның язмышларына барып тоташалар. Көй, җыр, моң үзе эчке мәгънәгә ия булган образлы бер системаны төзи. Икенче яктан, шигырь төзелешендә дә, интонациядә дә халык җырларының төрле һәм бай ритмикасын хәтерләтә торган яңгыраш бар. Хис, фикер үзгәрешенә мөнәсәбәттә ритмика да, интонация дә җәһәт кенә үзгәрә тора. Әлеге үзгәреш интонациянең музыкаль әсәрдәге сымак кабатланмас төрлелеген китереп чыгара, катлаулы, төзек гармониясен тудыра.

«Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасын язарга Илдарга халык судында утырышчы булып эшләү практикасы этәргеч бирде. Бу юлы шагыйрьнең поэма өстендә ничек эшләве турында сөйләве кызык. «Баяным булмаса, поэманы бәлки яза алмас идем,— дип сөйләде ул миңа бер вакытны, — әсәр язылмый башласа, тотам да уйный башлыйм. «Кәккүк» тә уйнала, «Кара урман» да уйнала, тагын күп-күп көйләрне уйныйм. Музыка сихерле бер көч сыман, язарга ярдәм итә. Әле генә яза алмый утырган өлеш я җиңел генә язылып китә, яки киресенчә, ничә көннәр буе язган өлеш юкка чыга, бөтенләй үзгәрә, башка мәгънә ала, башка интонацияләрдә яңгырый башлый. Шуңа да «Өчәү чыктык ерак юлга»ны мин ручка белән язуга караганда гармонем белән яздым дип әйтә алам...»

Көй, музыка шагыйрьдә төрле ассоциацияләр уята, ул шагыйрьнең хыялын хәрәкәткә китерә, я сүзнең үз яңгырашын, үз гармониясен табарга булыша.

Композитор Заһид Хәбибуллинның өендә була бу хәл. Хуҗа үзенең дус шагыйре Сибгат Хәкимне яңа иҗат иткән көе белән таныштыра һәм «көе бар, сүзе юк бит, Сибгат», — дип тә өсти. Казакъларга багышлап язган бу көй кайсы яклары беләндер шагыйрьгә охшый һәм ул, көй белән кызыксынып, аның моңы белән тәэсирләнеп, шунда ук бер строфа язып та ташлый. Сүзләрне композитор да ярата. Әмма «Казакъ дусларга» җыр текстының тулысынча язылып бетүе күп соңрак. Шагыйрь көйнең эчке рухына тирәнрәк төшенергә тырышып, музыка белән аерылгысыз бөтен төзегән сүзләр эзләп шактый баш вата.

Моңысы — композитор көе тәэсирендә язылган әсәргә бер мисал. Халык музыкасы да шагыйрьне яңа әсәрләр иҗат итәргә рухландыра, бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы булып хезмәт итә. Мәсәлән, С. Хәкимнең «Таң атканда», «Фазыл чишмәсе» шигырьләре халык музыкасына нигезләнеп, шул исемдәге халык көйләрен тыңлау тәэсирендә язылалар. Ул көйләрне 1947 елны артистка Оркыя Ибраһимова гастрольдә йөргәндә өйрәнеп, отып кайткан була. Шагыйрь, көйләрнең эчке агышына тирәнрәк төшенер өчен, аларны кат-кат тыңлый. «Фазыл чишмәсе», ни сәбәптәндер, җиңел языла, ә «Таң атканда» җыры авырдан бирелә. Бу җырны автор сигез вариантта эшли. Көйне тыңлаган саен нинди дә булса сүз, деталь үзгәрмичә калмый. Шагыйрь эшләгән саен көйнең рухын ныграк үзләштерә бара...

Музыка тәэсирендә язылган шигырьләргә татар поэзиясеннән тагын байтак мисаллар китерергә мөмкин булыр иде.

С. Хәким үзенә классик музыкадан опера сәнгатенең бик тә якын икәнлеген сөйли: «Миңа аеруча операларның «Борис Годунов» тибындагылары — халык язмышы турында уйландыра торган, халыкның зур тарихын ачкан әсәрләр охшый. Шундый операларны тыңлау үземдә дә зур сулышлы әсәрләр язарга дәрт уята. Опера сәнгатен өйрәнү тәҗрибәсе поэмаларымны иҗат иткәндә аларда ниндидер ассоциацияләр рәвешендә чагылмый калмаганнардыр».

Йогынтыны турыдан-туры гына түгел, ә аның катлаулы ассоциацияләр бәйләнешендә дә карау, хәтта төрле сәнгать төрләренең кануннарын үзара чагыштыру иҗат практикасы өчен әһәмиятле һәм кызыклы күп нәрсәләр ачар иде. Хемингуэйның композиторлардан гармония һәм контрапункт-

ны өйрәнүе, композиторның прозаикны баетуы турында язуы — ул бит шаяру түгел.

Төрле сәнгать төрләренең үзенчәлекләрен кыю рәвештә чагыштырып карау жанр чикләрен югалтуга китермәс, ә жанр осталыгын ныграк күтәрергә ярдәм итәр иде. Ә. Фәйзи әдипкә архитектура, скульптура кебек сәнгать төрләрен өйрәнүнең композицион осталыкка ирешүнең күп юлларын күрсәтүен әйтә. Чөнки сәнгатьнең ул төрләрендә композиция әдәбиятка караганда күзгә ныграк ташлана, әһәмияте ныграк сизелә: «Мин осталарыбыздан берсенең скульптурада композиция турындагы ун кагыйдәсен укып чыктым. Ул кагыйдәләр иҗат практикасыннан чыгып төзелгәннәр һәм шуңа күрә бик кыйммәтлеләр. Язучы ул кагыйдәләрдә үзенең сәнгате өчен сабак булырлык бик күп нәрсәне, чынлап уйлану бик файдалы булган бик күп нәрсәне күрер. Композицион үзәк, икенче нәрсәләрнең төп нәрсәгә буйсынуы, күләм, ритм, контрастның ярашулары, туры килүләрнең очраклылыгы һәм закончалыгы [ә без бу өлкәдә әле гаҗәп күп ялгышабыз бит!], масштабны билгели белү — менә болар барсы да билгеле дәрәҗәдә әдәбият әсәрләренә дә хас бит». [«Совет әдәбияты» журналы. 1963 ел. 3 сан. 109 бит].

Әйтик, шушы ук композицион бөтенлеккә ирешү безнең язучыларны, романистларны бүген дә нык борчыган актуаль мәсьәләләрнең берсе түгелмени!! Драма законнарын, драматургик хәрәкәтне үстерүне өйрәнү безнең шагыйрьләргә дә, прозаикларга да эпик әсәрләр иҗат иткәндә көпшәклектән, буш һава чоңгылларыннан котылырга никадәр ярдәм итәр иде! Югыйсә, безнең байтак әсәрләргә конфликтның дәвамлы үстерелүе җитми, конфликт әсәрнең ярты өлешендә чишелеп бетә.

Проза, бер караганда, музыкадан әллә кайда, еракта ята. Ә баксаң, аларның да туганлыклары бар. Аларның үзенчәлекләрен чагыштырып карарга мөмкин. Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Ә. Еники, М. Әмир, И. Гази хикәяләрен укыганда алардагы фразаларның музыкаль яңгырашына игътибар итегез. Интонация я түбән төшә, я күтәрелә. Эчтәлеккә бәйле туктаусыз хәрәкәт итә. Фразалардан катлаулы музыкаль бөтен бер аһәң туа. Шунда бер генә сүз, җөмлә урынында булмаса да фальшь туа, музыкальлек юкка чыга. Шуңа да Г. Бәширов, И. Гази, Ф. Хөснилрнең сүзне урынлы куллану турында матбугатта еш кына сүз күтәрүләре, әсәрләрнең һәм сүзләрнең аһәңнәре турында туктаусыз кайгыртулары бик тә табигый. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы яки аның «Алмачуар» хикәясе никадәр шигъриятле, музыкаль! Сүзләр ярдәмендә нинди катлаулы гармония хасыйл була! Янсә Г. Кутуйның «Сагыну» нәсерен хәтерләгез — хискә нинди бай, аһәңле ул!

Ә. Еникинең һәр сүз өстендә ныклап уйлавы, хәтта өтер-ноктаны да бик озак вакытлар уйлаганнан соң гына куюы оста стилист булуы турында гына сөйләми торгандыр. Ул сүз белән бергә җөмлә, фразаның музыкасын эзли, әсәрнең бердәнбер төгәл аһәңле яңгырашына ирешергә омтыла.

Прозаның да үз гармониясе, үз музыкасы бар. Чайковскийның Чехов хикәяләрендә үзенә — композиторга якын аһәңлелек ишетүе нәрсә турында булса да сөйли торгандыр.

* * *

Әдәбиятчыга һәм тәнкыйтьчегә, нинди дә булса язучының иҗатын өйрәнгәндә, «саф» әдәби жанрлар белән генә эш итәргә туры килми. Күп очракта без аны үзебез шулай тар әдәби кануннар рамкасында карыйбыз. Шуңа күнеккәнбез. Шулай җиңелрәк. Комедия икән, аның сәхнәдә яңгыраганда гына бөтен образ тудыруын искә алып бетермибез. Интонацион шигырь икән, аның ритмик-интонацион бизәкләре, рифмасы тик яңгыраган, сөйләгән вакытта гына хәрәкәткә килүен, беренче карашка график язмада вакытында кытыршырак, төзексезрәк булып күренгән нәрсәләрнең бөтенләй юкка чыгуын хәтергә алмыйбыз. Әгәр шигырьнең уку өчен генә түгел, сөйләүне дә күздә тотып язылуын искә алсак, мәсәлән, Х. Туфанның кайберәүләргә сәеррәк тоелган рифмалары һич тә шулай сәер яңгырамас иде. Әнвәр Давыдовның да язмада аерым төзексезлекләре яхшылап укыганда, күпчелек очракта, төзек булып ишетелүләрен инкяр итәргә туры килер иде.

С. Хәкимне югарыда без «саф» лирик дип атаган идек. Ә бит ул җырчы шагыйрь дә. Ә көйне дә искә алып язу ул инде шагыйрьнең иҗат процессында да эзсез калмый, шигырь структурасына да нинди дә булса үзгәрешләр кертә. Сибгат аганың студентлар белән бер очрашуда «җыр язганда минем күңелемдә шигырь белән бергә җырның үз көе дә туа», — дип сөйләгәне хәтердә калган.

Әдәбият практикасында исә еш кына без җырның көй белән генә бер бөтен образ төзүен искә алып бетермибез. Җырны шигырь кагыйдәләре белән генә тикшерәбез. Ә музыка белгечләре исә еш кына үз якларыннан шундый берьяклылык күрсәтәләр, музыкаль образ хәрәкәте турында гына сүз алып баралар. Әгәр шулай булмаганда, бездә байтак җырларда очрый торган сүз һәм көй аерымлыгы күптән ачылмас идеме икән!! Тәнкыйть итәлә торган җырлар азаймас идеме икән! Әлбәттә, әдәби материалның үз мөстәкыйльлеген дә онытырга һәм инкарь итәргә ярамый. Җыр шигыренең үз канунннары бар, аларны да игътибар белән өйрәнергә кирәк. Тикшеренүчеләр алдына җыр чишелергә тиешле байтак кызыклы мәсьәләләр куя. Әйтик, сүз һәм көй ниг ул кадәр үк аерылмас бердәмлек төзиләрме! Аларның мөстәкыйльлекләре ни дәрәҗәдә! Ни өчен кайчандыр бер бөтен образ төзегән җыр вакытлар үтү белән бу бөтенлеген югалта: я сүзе, я көе тарих киштәсенә менә! Кайчандыр эчтәлек һәм форма тәңгәллегенә ирешкән

образ, бөтенлеген югалтып, ни өчен яңа бәйләнешләргә керә, яңа бөтенлек төзи (мәсәлән, Тукайның «Зиләйлүк» көенә җырлана торган «Милли моңнар» шигыре, Җ. Фәйзинең «Умырзая» көе һ. б.). Көйне һәм сүзне берләштерә торган нинди уртак законнар бар!

Композиторлар җыр өчен нинди шигырьләрне һәм шагыйрьләрне сайлыйлар! Бу сайлау нәрсәгә нигезләнә! Ни өчен композиторлар талантлы һәр шагыйрьгә көй яза алмыйлар! Исәпләсәң, һ. Такташ яки Ә. Давыдовлар шигыре музыкада иң аз яңгыраганы түгелме соң! Русларда — Маяковский, Кирсанов шулай. Күрәсең, интонацияне күздә тотып язган әсәрне музыкага күчерүнең үз авырлыклары бардыр. Ә Роберт Рождественскийның «Реквием»е! Ул да бит декламация!! Маяковскийның аерым әсәрләре соңгы елларда музыкага уңышлы гына күчте түгелме соң!! Бәлки ирекле шигырь музыка өчен ул кадәр кыен барьер да түгелдер!! Бәлки ул композиторлар өчен күтәрелмәгән уңдырышлы чирәм булып ята торгандыр!!

Х. Туфанның байтак шигырьләре нәкъ менә композиторлар яраткан классик шигырь үлчәмендә иҗат ителгән, күп кенә шигырьләре җыр үлчәмендә язылган. Соңгы елларда Хәсән аганың нибары берничә шигыре көйгә салынды. Ә шул ук вакытта поэтик зәгыйфь җырлар эфирда күпме яңгырый! Нәрсә белән аңлатырга! Һәр яклап тикшерү, анализлау кирәк.

Күрәсез, җыр турында уйлану гына да практик яктан әһәмиятле никадәр күп сораулар һәм мәсьәләләр кузгата.

Әгәр опера шикелле катлаулырак структуралы формага игътибар итсәк, анда да хәзерге практика куйган сораулар аз булмас иде.

Бер жанрдагы образны икенче жанрга күчерү кайвакытта уңыш китерә. Шекспирның «Гамлет» трагедиясе кинода үз көчен югалтмады, заманча яңгыраш алды, эстетик байлыгы кино сәнгатендә дә тулы ачылды. Г. Тукай халык авыз иҗатында гасырлар буе килгән Шүрәле образына яңа әдәби гомер бирде. Шүрәле поэма-баллада белән генә чикләнмәде, музыкага күчте (Н. Җиһанов поэмасы), сәхнәгә менде (Ф. Яруллин балеты). Рәсем һәм һәйкәлчелек дөньясына да барып керде. Күрәсез, бер үк образ сәнгатьнең, әдәбиятның төрле формаларында яши ала икән. Ләкин Тукайның «Шүрәле»се нииндидер яклары белән Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, Б. Альменов шүрәлеләреннән аерыла. М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте сәхнәдә җанланганда да үз көчен югалтмады. Һәр сәнгать төре образны үз материалыннан, хасиятеннән һәм мөмкинлекләреннән чыгып тудыра. Бер очракта образның мәгънәсе адекват рәвештәрәк яңгыраса, икенче очракта әсәрнең дә, образның да тулылыгы төрле дәрәҗәдә, хәтта төрле интерпретациядә ачылырга мөмкин.

Ләкин иҗат практикасында образның бер төрдән икенче төргә, башка жанрга сәяхәте уңышка очрамау мисаллары да аз түгел. Г. Бәшировның «Намус» романы хаклы рәвештә дан казанды. Ә менә романдагы образларны операга күчерү уңышлы ук барып чыкмады. Ни өчен! Ә бит опера тәҗрибәле композитор Н. Җиһанов тарафыннан язылган иде. Либреттисты да тәҗрибәле шагыйрь — Ә. Исхак иде.

Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте — шулай ук татар совет классикасына кергән әсәрләрдән. Талантлы композиторыбыз Җәүдәт Фәйзи бу әсәрне изге теләктән чыгып музыка теленә күчерде — опера иҗат итте. Г. Минский шул ук әсәргә таянып пьеса язды. Әмма инде бу әсәрләр Г. Кутуй әсәре шикелле көч белән яңгырый алмадылар. Сәбәпләре нәрсәдә! Һәр образ, һәр талантлы әсәрне икенче жанрга күчерергә омтылу кирәкме икән! Үз жанрыннан күчәргә теләмәгән образлар да бар түгелме соң! Чайковский, мәсәлән, «Гамлет»ны музыкада биреп булмас иде дип юкка гына әйтмәгәндер. Димәк, бу мәсьәләне дә көн тәртибенә тормыш үзе куя. Образның бер жанрдан икенче жанрга сәяхәтен тикшерү (тарихи һәм теоретик планда да) һәр сәнгать төренең кабатланмас хасиятен һәм жанр төрләренең диалектик мөнәсәбәтен ачуны сорый.

Мондый катлаулы мәсьәләләрне чишүне, әлбәттә, әдәбият һәм сәнгать белгечләренең бердәм тырышлыклары белән генә җиңеп чыгарга мөмкин.

Әдәбият һәм сәнгатьнең баюы нигезендә кешенең рухи баюы ята. Сәнгать җәмгыять белән бергә үсә, баый. Халыкның рухи тормышы туктаусыз хәрәкәттә булуы, гади хезмәт кешесенең интеллекты үткән чорлар белән чагыштырганда нык үсүе, укучының матурлык хисләрен тәрбияләүдә бөтен сәнгать төрләренең актив катнашуы язучының шәхес буларак интеллектуаль югарылыгын, киң карашлы һәм культуралы булуын сорый. Бай рухи дөньялы бүгенге кешеләрне тирән тасвирлау үзеннән-үзе язучының да эрудициясен күтәрүне бөтен кискенлеге белән көн тәртибенә куя. Язучының эрудициясе мәсьәләсе шуңа күрә дә бүгенге чорның югары культуралы сәнгатен иҗат итү белән турыдан-туры бәйләнә. Язучы хәзерге заманның һәм үткәннең сәнгать казанышларын никадәр яхшы һәм тирән белсә, сәнгать төрләре белән дуслыгы нык булса, бу дуслык аның иҗатында, һичшиксез, уңай яктан күрсәтәчәк, аның фикер һәм хисләр дөньясын, сурәтләр палитрасын баетачак.

— — □ — —

**Әдәбият тарихыннан материаллар**

# МУСА ҖӘЛИЛ БИОГРАФИЯСЕНӘ ЯҢА ДОКУМЕНТЛАР

*Атаклы шагыйребез Муса Җәлилнең тормышына һәм иҗат эшчәнлегенә бәйләнешле һәр документ халык өчен дә, фән өчен дә зур кыйммәткә ия.*

*КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивында шагыйрьнең иҗади биографиясен һәм җәмәгатьчелек эшчәнлеген ачыкларга ярдәм итәрдәй төрле характердагы күп кенә документлар саклана. Ул материаллар бөек Ленин партиясендә тәрбияләнгән шагыйрьнең Ватан сугышы алды елларында ук чыныккан көрәшче булып җитлегүе, зур һәм күп төрле иҗтимагый-политик эш алып баруы турында сөйлиләр.*

*Журналның бу санында әнә шул документларның берничәсен укучыларга тәкъдим итәбез.*

А. П. Золина, КПССның
Татарстан өлкә комитеты партия
архивы инструкторы.
Т. М. Насыйров, тарих фәннәре
кандидаты.

## ТАТАР ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСТӘЛЕГЕН МӘҢГЕЛӘШТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА ТАССР СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ИДАРӘСЕНЕҢ ҖАВАПЛЫ СЕКРЕТАРЕ М. ҖӘЛИЛОВНЫҢ ЯЗМА ДОКЛАДЫ

*11 август, 1939 ел*

ВКП(б) өлкә комитеты секретаре
ип. Долотказинга
ТАССР Халык Комиссарлары Советы
председателе урынбасары
ип. Сөләйманга

**Татар халык шагыйре Габдулла Тукайның 25 еллык юбилеен бәйрәм итү уңае белән, 1938 елның апрелендә Татарстан хөкүмәте Г. Тукайның академик җыентыгын бастыру һәм шагыйрь истәлеген мәңгеләштерү турында карар чыгарган иде.**

**Ул карарны тормышка ашыру максаты белән, Язучылар идарәсе байтак конкрет чаралар билгеләде, шул чараларны тикшерүгезне һәм раславыгызны үтенәбез. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:**

### I. Г. Тукайның академик җыентыгын бастырып чыгару буенча

**1. Г. Тукайның академик җыентыгын әзерләү өчен, ТАССР Халык Комиссарлары Советы председателе урынбасары иптәш Сөләйманов председательлегендә хөкүмәт комиссиясе төзергә, аның составына Сөләйманов (ХКС), Тинчурин (Татгосиздат, ко-**

миссия председателе урынбасары), Рамазанов Ш. (фәнни хезмәткәр), М. Җәлил (Язучылар союзы), Ш. Маннур (орденлы шагыйрь), Г. Кашшаф (тәнкыйтьче), Хисмәтуллин (Тукай иҗатын тикшерүче) иптәшләрне кертергә. (Комиссиянең бурычлары һәм функциясе академик басма план проектында әйтелгән.)

2. Басманы әзерләү өчен кирәк булачак чыгымнарга без тәкъдим иткән 38700 сумлык сметаны расларга һәм аны Татгосиздат карамагына бирергә.

3. Г. Тукай әсәрләре академик басмасы планы проектын тикшерергә һәм расларга (проект теркәлә).

4. Оештыру эшләре өчен, комиссияне тиешле штат һәм техник аппарат (әдәби сотрудник, секретарь, машинистка, кулъязмаларны әзерләү һәм бастыру һ. б.) белән тәэмин итүне Татгосиздат идарәсенә йөкләргә.

5. Комиссиянең Г. Тукай материалларын әзерләү буенча фәнни-консультатив эшен яңадан оештырыла торган Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институтына тапшырырга.

## II. Г. Тукай музеен оештыру буенча

Г. Тукайның 25 еллык юбилеен үткәрү буенча Хөкүмәт комиссиясе 1938 елның мартында «Болгар» номерларында Г. Тукай торган квартираны реставрацияләү һәм ул бүлмәдә Г. Тукай музее оештыру турында карар чыгарган иде. Әмма Хөкүмәт комиссиясенең бу карары тормышка ашырылмаган. Төп кыенлык музей оештырырга средство булмауга бәйләнгән. Шул ук вакытта Г. Тукай тормышына һәм иҗатына бәйле күп кенә кыйммәтле материаллар, билгеле бер саклау урыны булмаганлыктан, акрынлап югала бара. Г. Тукай тормышын һәм иҗатын характерлый торган экспонатларны (кыйммәтле кулъязмалар, хатлар, көндәлекләр, әһәмиятле басмалар һ. б.) эзләү һәм җыю буенча бернинди дә эш алып барылмый. Менә шушы күңелсез фактлар безнең алга, һич кичектермичә, тизрәк Г. Тукай музеен оештыру бурычын куя. Г. Тукай музее оештырылса, анда әдәби мирасны җыю һәм өйрәнү эшен тупларга һәм әдәби архивны тәртипкә китерергә мөмкинлек булыр иде.

Шунлыктан үтенәбез:

а) Шәһәр советына элекке Г. Тукай бүлмәсен реставрацияләүне, шулай ук күрше бүлмәләрне бушатуны һәм «Болгар» номерларында Г. Тукай әдәби музеен оештыруны йөкләргә.

б) Казан крайны өйрәнү музее җитәкчелегенә әдәби музейны үз аппаратына кушуны һәм, Г. Тукай музеен җитәкләү өчен, махсус штат билгеләүне йөкләргә. Крайны өйрәнү музее дирекциясенә Язучылар союзыннан һәм барлык башка оешмалардан Г. Тукай тормышына һәм иҗатына караган материал-экспонатларны һәм башка әдәби архив һәм әдәби мирас материалларын кабул итеп алырга һәм Г. Тукай музеен оештырырга тәкъдим итәргә.

в) Шул максат белән, музей сметасы нигезендә, крайны өйрәнү музее карамагына средстволар бирергә.

## III. Г. Тукай истәлеген мәңгеләштерү буенча

Г. Тукайның 25 еллык юбилее уңае белән, Татарстан хөкүмәте шагыйрьгә, үлүенә 30 ел тулу көненә, һәйкәл куярга карар чыгарган иде. Әмма ул карарны җиренә җиткерү буенча да бернинди конкрет эш эшләнми.

Без үтенәбез:

1) Иң яхшы һәйкәл проектына (эскиз) хөкүмәт конкурсы игълан итәргә.

2) ТАССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы Сәнгать эшләре идарәсенә конкурс проектын, аның вакытын һәм шартларын әзерләүне тапшырырга.

3) Аннары Сәнгать эшләре идарәсенә һәйкәлне булдыруга бәйләнгән бөтен конкрет чараларны билгеләүне һәм аларны тормышка ашыруны тәэмин итүне йөкләргә.

4) Хөкүмәт юбилей комиссиясенең ТАССРның Этнә районына һәм «Болгар» номерларына халык шагыйре Г. Тукай исемен бирү турындагы 1938 ел 29 март карарын тамәлгә ашырырга.

5) Г. Тукай юбилеен үткәрү буенча Хөкүмәт комиссиясенең Казан дәүләт педагогия институтының әдәби факультетында укучы отличниклары өчен Г. Тукай исемендәге даими стипендия булдыру турындагы 1938 ел 29 март карарын үтәүгә ирешергә.

6) Сталин район советына шагыйрь Г. Тукай каберен тәртипкә китерергә һәм үзгәртеп корырга тәкъдим итәргә.

Без ТАССР Халык Комиссарлары Советына шушы бөтен конкрет тәкъдимнәрне тикшерүне һәм, шулай итеп, хөкүмәтебезнең бөек шагыйрь Г. Тукай истәлеген мәңгеләштерү турындагы политик яктан бик мөһим карарын тормышка ашыруны тәэмин итүне үтенеп мөрәҗәгать итәбез[1].

ТАССР совет язучылары союзы
идарәсенең җаваплы секретаре —
М. Җәлилов[2].

## ТАТАРСТАН СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ИДАРӘСЕНЕҢ ҖАВАПЛЫ СЕКРЕТАРЕ М. ҖӘЛИЛОВНЫҢ МАТУР ӘДӘБИЯТ ӨЧЕН КӘГАЗЬ ФОНДЫ БИРҮ ТУРЫНДА ҮТЕНЕЧ ЯЗУЫ

*19 декабрь, 1939 ел*

СССР СЯС идарәсенә, Президиумның җаваплы секретаре
ип. Фадеевка
Күчермәсе: ВКП(б)ның Тат. өлкә комитетына
ип. Алемасовка
ип. Мөхәмәтовка

Хөрмәтле ип. Фадеев!

...1940 елда Татарстан хезмәт ияләре үз милли республикасының XX еллыгын бәйрәм итәчәкләр. Хәзер барлык Татарстан язучылары, шул шатлыклы юбилейга багышлап, житди һәм зур әсәрләр язу өстендә эшлиләр. Татарстанның XX еллыгына әзерлек уңае белән, ТАССР СЯС идарәсе язучылар арасында зур иҗади-оештыру эше башлап җибәрде: язучыларга иҗади ял һәм командировкалар бирде, тематик план төзеде һәм аны тикшерде, аерым китапларны уку һәм алар турында фикер алышулар оештырды h. б. Шунлыктан татар язучылары иҗатында зур күтәрелеш һәм күп кенә яңа житди китаплар дөньяга чыгуы көтелә.

Әмма әгәр кәгазь юклык аркасында хезмәтләре басыла алмый калса, язучыларның хәле ничек булачагын аңлау читен түгел.

...1940 елда Татреспублика тулысынча рус графикасы нигезендә яңа алфавитка күчәчәк. Димәк, 1940 елда нәшрият алдына татар классикларының һәм дөнья әдәбияты классикларының, шулай ук совет язучыларының иң әйбәт әсәрләрен кабат бастыру мәсьәләсе дә килеп басачак. Яңа алфавитка күчү безнең китапханәләрне һәм укучыларны классик һәм хәзерге заман әдәбиятының иң яхшы әсәрләреннән мәхрүм итәргә тиеш түгел.

...Соңгы вакытта Татарстан язучыларының иҗади активлыгы һәм татар матур әдәбиятының бик нык күтәрелеше сизелә. Моның шулай икәнлеге Татарстан язучылар союзы члennары артудан да күренә: 1938 елда 25 булса, 1939 елда аларның саны 45 житте.

...Бу фактларның барысы да нәшрият эшен киңәйтү кирәклеге турында сөйлиләр. 1940 елның тематик планына караганда, Татгосиздат матур әдәбият секторы буенча 775 басма табак күләмендә 113 исемдә, ...яшьләр-балалар әдәбияты секторы буенча 278,5 басма табак күләмендә 58 исемдә китап чыгарырга ниятли. Гадәттәге планнан тыш, Татарстанның XX еллыгына юбилей басмалары чыгару өчен, 182 басма табак күләмле 35 исемне эченә алган аерым план төзелгән.

---

[1] М. Җәлилнең бу язмасына түбәндәге резолюция салынган: «Архивка. Г. Тукай әсәрләренең академик басмасы тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институтына тапшырылды һәм бөтен материал шунда эшкәртелә. Зимуров. 10 февраль, 1940 ел».

[2] Рус телендә язылган бу докладның төп нөсхәсе КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивында (15 фонд. 20 опись. 575 эш. 81—84 битләр) саклана. Доклад язмасына Г. Тукай материалларын җыю өчен тотылырга тиешле чыгымнар сметасы һәм шагыйрь әсәрләре академик басмасының план проекты да теркәлгән (85—90 битләр).

Мина шушыларны искә алып, югарыда күрсәтелгән тематик планны гамәлгә ашыру өчен, ип. Фадеев, Татгосиздатка, махсус рәвештә матур әдәбиятка дип, кирәк кадәрле кәгазь фонды бирүләрен сорап, ВКП(б) Үзәк Комитетына һәм РСФСР дәүләт планына ходатайство белән керүегезне үтенәбез[1].

Сәлам белән,
Татарстан СЯС идарәсенең җаваплы
секретаре — М. Җәлилов.

## МӘСКӘҮДӘ БУЛАЧАК ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ ДЕКАДАСЫНА ӘЗЕРЛЕК ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ ИДАРӘСЕНЕҢ ҖАВАПЛЫ СЕКРЕТАРЕ М. ҖӘЛИЛОВНЫҢ ЯЗМА ДОКЛАДЫ

*19 декабрь, 1939 ел*

ВКП(б) өлкә комитетына
ип. Мөхәмәтовка
ТАССР Халык Комиссарлары
Советына ип. Тынчеровка
ип. Сөләйманoвка

СССР совет язучылары союзы идарәсе һәм Мәскәү язучылар йорты ел саен Мәскәүдә милли әдәбият һәм фольклор декадалары үткәреп киләләр. Милли әдәбиятлар ирешкән уңышлар белән СССРның киң катлам хезмәт ияләрен таныштыру, аларны популярлаштыру эшендә, милли республикаларның язучылары һәм сәнгать эшлеклеләре белән башкала язучылары һәм сәнгать эшчеләре арасындагы элемтәне ныгытуда һәм милли әдәбиятларны тагын да үстерүдә бу декадалар бик зур культура-политик әһәмияткә ия булып тора.

Безнең үтенечебезне канәгатьләндереп, СССР совет язучылары идарәсе һәм Мәскәү язучылары йорты 1940 елның февраль ахырларында Мәскәүдә татар совет әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрергә карар кылдылар һәм безгә ул декаданы үткәрү өчен әзерләнергә тәкъдим иттеләр.

СССР язучылар союзы идарәсе һәм Мәскәү язучылар йорты декада мәсьәләсен уңай хәл итүгә канәгатьләнеп һәм канатланып, без, Татарстан язучылары, үзебездә декадага әзерлек эшен киң итеп башлап җибәрдек. Татарстан СЯС идарәсе тарафыннан Җәлил (Җәлилов) — председатель, Таҗи Гыйззәт (орденлы драматург), Ш. Маннур (орденлы шагыйрь) иптәшләрдән декадага әзерләнү буенча комиссия төзелде. Хәзерге вакытта бу эшнең конкрет планы төзелә.

Без декадага 1940 елның март башында, Казан шәһәрендә язучы Шәриф Камалның 30 еллык юбилей тантанасы тәмамланганнан соң, китәргә ниятләп торабыз. Ш. Камал юбилеен үткәрү буенча хөкүмәт комиссиясе планына караганда, Язучылар союзының юбилей пленумының йомгаклау утырышы һәм кичәсе 1940 елның 28 февралендә булырга тиеш. Беренче мартта без Мәскәүгә чыгып китә һәм Мәскәүдә декаданың беренче көннәрен Ш. Камал юбилеена багышлый алабыз. СССР совет язучылары союзы идарәсе президиумы ул көнне, Ш. Камал юбилеена багышлап, үзенең киңәйтелгән тантаналы утырышын үткәрергә уйлый.

Декаданы үткәрү планы якынча түбәндәгеләрдән гыйбарәт булачак:

а) Танылган шагыйрьләребезнең үз әсәрләрен укуы. Аларның ул шигырьләре алдан ук танылган Мәскәү шагыйрьләре тарафыннан русчага тәрҗемә ителәчәк һәм декада вакытында укылачак.

б) Танылган артистларның һәм сүз осталарының татарча һәм рус телендә әйбәт хикәяләр һәм проза әсәрләреннән өзекләр укуы.

в) Татар дәүләт академия театры артистлары һәм Мәскәү театрлары артистлары башкаруында татар драматурглары пьесаларыннан татарча һәм русчага тәрҗемә итеп, аерым актлар, өзекләр һәм сценалар күрсәтү.

[1] Төп нөсхәсе КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивында (15 фонд. 20 опись. 575 эш. 338—342 битләр) саклана.

г) Җырчыларның татар композиторларының татар шагыйрьләре текстына язган массовый һәм лирик җырларын башкаруы.

д) Халык җырчылары, биючеләре, сүз осталары чыгышы.

е) Татар художниклары, скульпторлары әсәрләреннән һәм халык талантлары чиккән әйберләрдән күргәзмә оештыру.

Бу чыгышлар алты көн дәвамында Мәскәү язучылар йортында, Союзлар йортының колонналы залында, зур предприятиеләрнең клубларында һ. б. урыннарда күрсәтеләчәк.

Мәскәүдә үткәрелгән казакъ, үзбәк, калмык, каракалпак әдәбияты һәм сәнгате декадалары тәҗрибәсе шуны күрсәтте: декаданың уңышы нигездә чыгышларның бик ныклап әзерләнгән булуы, тема һәм жанрлар төрлелеге белән тәэмин ителә. Моңарчы үткәрелгән декадалар бик иркен оештырылган һәм киң масштабта куелган иделәр. Бу эштә ул республикаларның хөкүмәтләре аларга зур ярдәм күрсәтте. Мәсәлән, кайбер республикалар декадага халык инструментлары ансамбльләрен, бөтен бер артистлар группаларын һәм 100 кешелек хорлар җибәрделәр.

Без дә Мәскәүдә татар әдәбиятын, фольклорын һәм сәнгатен аның бөтен байлыгы белән һәм төрле формаларында күрсәтергә теләр идек. Моның өчен, әлбәттә, материаллар әзерләүгә дә, декадада катнашачак коллективны Мәскәүгә алып барырга да шактый күп средство кирәк булачак.

Әзерлек буенча эшлисе эшләр: әсәрләрне русчага тәрҗемә итү, машинкада бастыру, декорацияләр әзерләү, постановкаларга репетицияләр ясау, музыкаль әсәрләр әзерләү, художество күргәзмәсе өчен материаллар җыйнау, фольклор материаллары җыю һәм сүз осталарын чыгышларга әзерләү.

Катнашучыларны Мәскәүгә алып баруны оештыру буенча эшлисе эшләр: 50 кешене 6 көн буена тәэмин итү (15 шагыйрь һәм драматург, 15 артист-башкаручы, 5 җырчы, 8 сүз остасы, халык җырчылары һәм фольклорчылары, 2 концертмейстер, 2 композитор, 2 художник, 1 скульптор). Ике генә көнгә булса да, фольклор репертуары белән Казан дәүләт филармониясе ансамблен Мәскәүгә алып килүне теләр идек.

Шушы эшләрне башкару өчен кимендә 25000—30000 сумлык средство кирәк булачак (смета СССР совет язучылары идарәсе белән килешенгәннән соң китереләчәк).

Декаданы уздыру мәсьәләсен тикшерүне һәм аны оештыруны принципиаль хәл итүне үтенәбез[1].

ТАССР совет язучылары союзының
җаваплы секретаре — М. Җәлилов.

## ТАТАР СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ТОРЫШЫ ҺӘМ АНЫ КИЛӘЧӘКТӘ ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ҖАВАПЛЫ СЕКРЕТАРЕ М. ҖӘЛИЛНЕҢ ЯЗМА ДОКЛАДЫ

*4 февраль, 1941 ел*

ВКП(б) өлкә комитетына ип. Алемасовка
ип. Мөхәмәтовка
ТАССР Халык Комиссарлары Советына
ип. Тынчеровка

Соңгы елларда татар совет әдәбияты Татарстан язучыларының иҗат активлыгы шактый күтәрелүе һәм матур әдәбият продукциясенең үсүе белән характерлы. Матбугатта һәм театр сәхнәләрендә күп кенә әһәмиятле сәнгать әсәрләре барлыкка килде («Сиваш», «Тукай», «Гөлəндәм», «Хуҗа Насретдин», «Кыю кызлар», «Матур туганда», «Агыйдел», «Ныклы адымнар», «Хат ташучы», «Ялкынлы яшьлек» һ. б.). Талантлы яшь язучылар һәм активлашып килүче «картлар» хисабына Язучылар союзы членнарының саны да артты (Язучылар союзы составы 46 кешегә җитте). Зур әдәби стажлары булган, әмма шактый вакыт әдәби эштән читләштерелеп торган язучылар актив иҗат эшенә һәм Совет язучылары союзының җәмәгать эшенә тартылдылар (Н. Исән-

[1] Төп нөсхәсе КПСС Татарстан өлкә комитеты партия архивында (15 фонд, 20 опись, 575 эш, 335—337 битләр) саклана.

бэт, Г. Кутуй, М. Гали һ. б.). Классикларга һәм, гомумән, революциягә кадәрге татар әдәбияты вәкилләренә тарихи һәм фәнни яктан дөрес караш булдырылды; нәкъ менә соңгы ике ел эчендә аларның иҗатлары аеруча тулы һәм тирән тикшерелде. Әдәбият тарихын һәм борынгы әдәби мирасны өйрәнү мәсьәләсендә җитди борылыш ясалды; тугандаш республикалар язучылары белән бәйләнеш ныгыды һәм, ул халыкларның классиклары, бүгенге язучылары юбилейларын үткәрүдә катнашу, иң яхшы әсәрләрне үзара тәрҗемә итешү юлы белән, туганлык тагын да киңәя төште (Руставели, Шевченко, Хетагуров, Рыльский, «Давид Сасунский», Иванов һ. б.).

Ләкин партиянең һәм хөкүмәтнең һәр көн җитәкчелек итеп һәм кайгыртып торуы нәтиҗәсендә ирешкән шушы шиксез уңышларына да карамастан, безнең әдәбият илебездәге социалистик төзелеш бурычлары темпыннан бик нык артка кала. Татар әдәбияты һәм татар совет язучылары илебез халыклары алдындагы «кешеләр рухы инженерлары» дигән исемне аклау белән бәйләнгән изге бурычларын үтәү дәрәҗәсенә ирешә алмадылар әле.

Тематик яктан артка калу, художество продукциясенең тиешле дәрәҗәдә югары сыйфатлы булмавы, көн кадагына сугучы һәм актуаль темаларга аз мөрәҗәгать итү, оборона темасының әдәбиятта йомшак яктыртылуы, совет эпохасы проблемаларының сай һәм өстән-өстән генә чагылдырылуы, идея сыйфатының тиешле югарылыкта булмавы, ә кайчакта әсәрләрдә партия күрсәтмәләрен бозу очраклары һәм башка шундыйлар — болар барысы да безнең әдәбиятның җитешсез яклары.

Хәзерге әдәбиятның бу барлык кимчелекләре т ү б ә н д ә г е с ә б ә п л ә р г ә кайтып кала: безнең язучыларның гомумкультура дәрәҗәсе һәм политик әзерлекләре тиешле югарылыкта түгел әле; язучылар арасында тәрбия эше һәм марксизм-ленинизм нигезләрен өйрәнү йомшак куелган, язучылар производство һәм колхоз тормышы белән тиешенчә нык бәйләнеш тотмыйлар, аларның кайберләре тормыштан аерылган; язучыларны политик тәрбияләү буенча мөһим чаралар үткәрүдә һәм татар совет әдәбиятының югары сыйфатлы булуы өчен көрәштә Язучылар союзы аппараты сүлпән эш итә.

Әдәбият фронтындагы соңгы фактлардан чыгып һәм партия күрсәтмәләреннән тиешле практик нәтиҗә ясап, Татарстан совет язучылары союзы үз эшен үзгәртеп кора һәм язучыларны коммунистик тәрбияләүне, аларның культура-политик дәрәҗәсен күтәрү өчен көрәшне, халык белән, производство һәм колхозлар белән тыгыз элемтә булдыруны һәм татар совет әдәбиятының югары сыйфатлылыгы өчен көрәшне үзенең төп бурычы итеп куя.

Ләкин билгеләнгән чараларны уңышлы үтәү кайбер кыенлыклар белән бәйләнгән. Ул кыенлыкларны җиңеп чыгу язучыларның иҗади уңышларын арттыруга һәм татар совет әдәбиятының идея-художество үсешен тагын да үстерүгә тиешле шартлар тудыруга китерер иде.

Язучылар союзына һәм Татарстан совет язучыларына үз алларына куелган яңа һәм мөһим бурычларны үтәүне җиңеләйтү максатыннан чыгып, без ВКП(б) өлкә комитетына һәм ТАССР хөкүмәтенә булган объектив кыенлыкларны бетерү, уңай шартлар тудыру буенча байтак чаралар үткәрүләрен үтенеп мөрәҗәгать итәбез. Алар түбәндәгеләргә кайтып кала:

1. Татарстан язучыларының һәм гомумән сәнгать работникларының, системалы рәвештә политик тәрбия һәм культура эшләре алып бару һәм үзара иҗади элемтә булдыру өчен, Казанда билгеле бер урыннары (клублары) юк. Матбугат йортындагы Г. Тукай исемендәге бердәнбер язучы кабинеты бу таләпне канәгатьләндерә алмый: беренчедән, ул «—» кв. м. бер кабинеттан гына гыйбарәт һәм башка бүлмәләре дә, фойесы да һ. б. юк, икенчедән, Г. Тукай исемендәге ул кабинетның берниндн финанс базасы да һәм кирәкле җиһазлары да юк. Кабинетның регуляр рәвештә лекцияләр оештырырга, кичәләр, очрашулар үткәрергә, кабинет мөдире һәм китапханәче штатларын тотарга, китапханәгә китаплар сатып алырга, бәйрәм көннәрендә кабинетны бизәргә, язучылар өчен курслар-семинарлар үткәрергә, экскурсияләр оештырырга һ. б. да средствосы юк.

...Шуңлыктан без ВКП(б) өлкә комитетына һәм ТАССР Халык Комиссарлары Советына әдәбият һәм сәнгать хезмәткәрләре клубын оештыру мәсьәләсен хәл итүләрен үтенеп мөрәҗәгать итәбез, чөнки бик кечкенә язучы кабинеты клуб хезмәтен үти

алмый һәм, шуның өстенә, үсеп баручы Казан сәнгать кадрларының да (артистлар, композиторлар, художниклар, скульпторлар һ. б.) шундый культура учаклары юк. Зур тәрбияви һәм иҗади эш җәелдереп җибәрү өчен, әдәбият һәм сәнгать осталарына, һичшиксез, үзәк клуб кирәк, аны оештыру мәсьәләсе хәзер куелырга тиеш.

Ләкин, моннан тыш та, без язучылар кабинетының финанс-материал базасын булдыру мәсьәләсен хәл итүне үтенәбез. Без аны финанслауны билгеле бер оешмага йөкләүне үтенәбез. Ул оешма әлеге кабинетны тиешле штатлары, китапханәсе, башка төр кирәк-яраклары һәм культура чаралары фонды булган чын-чынлап язучылар кабинетына әверелдерер иде.

2. Татарстанда берниндн дә әдәби газета басылмый. Бу хәл Язучылар союзы эшенә һәм әдәби хәрәкәт белән өзлексез җитәкчелек итеп баруга җитди зыян китерә. Төп проблемаларны язучылар җәмәгатьчелегенә үз вакытында җиткереп бару, укучылар белән ныклы элемтә урнаштыру, тәнкыйтьне җайга салу, язучылар эшчәнлеген актуаль бурычларга дөрес юнәлтү һ. б. Әгәр басыла башласа, бу эшләрнең барысын да әдәби газета башкара алыр иде. Совет әдәбиятын зур бурычлар югарылыгына күтәрүдә, язучыларны һәм укучыларны тәрбияләү эшендә әдәби газета бик җитди корал була ала. Шунлыктан без әдәби газета оештыру мәсьәләсен карауны үтенәбез (сәнгать мәсьәләләрен дә кертеп).

Алда күрсәтелгән бурычларны үтәү өчен, без, ахыр чиктә, республикада басыла торган газеталарда даими рәвештә «әдәби бит»ләр оештырып баруны үтенәбез. Әдәбиятыбызның идея-художество дәрәҗәсен күтәрү ноктасыннан караганда, бу бик мөһим һәм җитди чара булып тора.

3. Безнең әдәбиятыбызның җитди кимчелеге — эчтәлеге һәм күләме буенча зур, мөһим әсәрләр булмау. Җитди тарихи проблемаларны һәм безнең чынбарлыкны чагылдырган тирән эчтәлекле калын романнар янсә тагын да зуррак әсәрләр язылмый. Безнең тормышта һәм безнең данлы партиябез тарихында, халкыбыз тарихында әле әдәбиятта чагылышларын тапмаган җитди темалар бик күп (мәсәлән, татарларның Пугачев восстаниесендә катнашуы, Казан губернасында революциягә кадәрге зур крестьян хәрәкәтләре, Казандагы большевистик оешмаларның матур сәхифәләре, партиябез җитәкчеләренең Казан тарихы белән бәйләнгән биографияләре, Владимир Ильич Ленинның яшьлеге һ. б., татар революционерлары Ямашев, Мулланур Вахитов, Якупов һ. б., Казанны ак чехлардан саклау, Казандагы зур предприятиеләрнең биографияләре — М. Вахитов исемендәге завод һ. б.; зур колхозларның биографияләре, «Икенче Баку» проблемасы, «Казан — Бөгелмә тимер юлы төзелеше», «Зур Казан» һ. б.). Бу темаларның барысы да җитди, тирәнтен өйрәнүне һәм дәвамлы, киеренке иҗади хезмәт сорый.

Зур әсәрләр җиңел генә туа алмый. Зур әдәби тәҗрибәле һәм бу бурычны үтәп чыгарлык талантлы татар язучылары булуын инкарь итәргә ярамый. Ләкин Татарстан нәшрияты авторлар белән бары тик алар кулъязмаларын китереп тапшырганнан һәм ул кулъязмаларга уңай бәя бирелгәннән соң гына договор төзи һәм акча бирә алганлыктан, һәм гонорар бик түбән булганлыктан, язучыларның озакка сузылган иҗади эшкә керешергә мөмкинлекләре юк. Яшәрлек акча табу өчен, язучыга ярдәмче эшләр белән шөгыльләнергә туры килә. Бу хәл аның төп иҗат эшенә комачаулый.

Шунлыктан без, һич югында, өч-дүрт иң яхшы язучыга, мөһим кирәкле темага зур полотнолы әсәрләр иҗат итү өчен, вакытлы күренеш буларак, тиешле шартлар тудырып булмасмы икән дигән мәсьәләне күтәрәбез (автор гаризасы буенча). Бу — я иҗат командировкасы бирү, я хөкүмәт хисабына Казандагы иҗат йортында (яки ял йортында) эшләргә җибәрү, я предприятиеләргә һәм колхозларга нииндидер бер эш белән һәм шул вакытта язучының теләге буенча аңа иҗади эш тә тапшырып, аны озак вакытлы командировкага җибәрү дигән сүз. Менә шушылай тәэмин ителсә, билгеле бер вакыт эчендә язучы зур әсәр иҗат итүгә тулысынча бирелеп эшли алыр иде.

4. Матур әдәбият бастыруның канәгатьләнерлек куелмавы һәм гонорарның бик түбән түләнүе — язучының иҗат эшендәге иң җитди кыенлыкларның берсе. Таттосиздатта матур әдәбият чик дәрәҗәдә аз басыла. Тыйнак кына төзелгән тематик планнар да, кәгазь аркасында, бик кискен кыскартылуларга дучар була һәм язучыларның күбесе үз хезмәтләрен вакытында бастырып чыгара алмый (Н. Исәнбәт, М. Әмир, К. Нәҗми һ. б. әсәрләре).

Кулъязмалар өстендә эшләрен тәмамлагач, кайбер язучылар договор төзи алмыйлар, чөнки Татгосиздат, кәгазь булмыйча торып, договор төземи. Бу хәл язучының алдагы иҗат эшенә тәэсир итә. Татгосиздатның язучы белән бары тик кулъязмасы уңай бәя алганнан соң гына договор төзүе дә аның эшен читенләштерә. Материаль гарантиясе булмаса һәм билгеле бер вакытка материаль яктан үзен тәэмин итмәсә, язучы кулъязма өстендә уңышлы эшли алмый...

...Шуңа күрә без бу мәсьәләләрне тәртипкә китерүдә булышуыгызны үтенәбез: 1) бөтен яхшы әсәрләрне бастырып чыгаруны тәэмин итү өчен, Татгосиздатның матур әдәбият басу базасын киңәйтергә, аның басма планнарын киңәйтергә; 2) авторлык гонорарын шактый арттыруга ирешергә; 3) авторлык гонорарын тәртипле, регуляр рәвештә түләп баруны тәэмин итәргә.

5...[1]

6. Татар совет әдәбияты үсеше өчен, әдәби мирасны җыю, саклау һәм өйрәнү мәсьәләләре җитди әһәмият ала бара. Классикларыбыз хезмәтләрен һәм гомумән татар әдәбияты тарихы материалларын фәнни өйрәнү һәм тәнкыйтьләү буенча безнең тәнкыйтьчеләребез һәм тел-әдәбият фәнни тикшеренү институтлары хезмәткәрләре тарафыннан хәзер шактый зур эш алып барыла (Халитов, Кашшаф, Хәйри, М. Гали, Агишев, Ярми, Фәйзуллина һ. б.). Институт архив материалларын җыю буенча да эш алып бара. Әмма шулай да бу эш буенча иң мөһим һәм күп кенә тиешле нәрсәләр эшләнмәгән. Әдәби музей оештыру бу эштә беренче мәсьәлә булып тора. Г. Тукай юбилее уңае белән хөкүмәт Г. Тукай исемендәге әдәби музей оештырырга һәм Г. Тукайга һәйкәл салдырырга карар кылган иде. Әмма бу карарлар тормышка ашмады. Әдәби музей оештыру мәсьәләсе буенча Язучылар союзы Мәгариф Халык Комиссариатына, Халык Комиссарлары Советына берничә мәртәбә конкрет практик тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итеп карады. Әмма болар барысы да әлегә һаман бер урында кала килә. Ләкин, культура мирасын саклау һәм өйрәнү җәһәтеннән караганда, бу бик кирәкле чара. Югыйсә күп кенә язучылар һәм әдәби фактлар, үткән чор документлары югалачак, игътибардан читтә калачак.

Тукайга һәйкәл кую — бик зур культура-политик эш. Хөкүмәтнең бу карарын тормышка ашырасы иде (бу турыда да Язучылар союзы практик тәкъдим белән мөрәҗәгать иткән иде).

Әдәбият классиклары Г. Камал, Г. Тукай каберләре, атаклы революционер Х. Ямашевныкы кебек үк, кызганыч хәлдә. Элек Г. Камал яшәгән йортларда мемориаль такталар юк. Без боларның барысы турында да шәһәр идарә органнарының кайгыртуын үтенәбез һәм аларга тәэсир ясалуын телибез.

Әдәби мирас мәсьәләләре җитди кайгыртучанлык, культуралы мөгамәлә күрергә һәм тирәнтен өйрәнелергә тиешләр. Бу эшләрне тормышка ашыру өчен Сезнең ярдәмегез кирәк.

Татар совет әдәбиятын тагын да интенсиврак үстерүне тәэмин итү өчен, җитәкче органнар тарафыннан хәл ителүгә мохтаҗ булган мәсьәләләр, безнең фикеребезчә, менә шушылар.

Боларның барысыннан тыш, әлбәттә, Язучылар союзының үзенә һәм язучылар активына сезнең һәр көн җитәкчелек итеп һәм, конкрет мәсьәләләр буенча язучылар активы киңәшмәләрен уздыру (шәһәр Комитетында тәнкыйтьчеләр киңәшмәсе мисалында), әһәмиятлерәк әсәрләрне Өлкә Комитетында яки Халык Комиссарлары Советында уку һәм тикшерү (Өлкә Комитетында «Наемщик» сценарием уку мисалында), курс-семинарлар, курс-конференцияләр үткәрү, республика газетасында әдәбият буенча күрсәтмә — җитәкче мәкаләләр урнаштыру рәвешендә, ярдәм итеп торуыгыз һ. б. кирәк.

Бу конкрет мәсьәләләрне алдыгызга куеп, без аларны уңай хәл итү буенча чаралар күрүегезне үтенәбез.

Сәлам белән,

ТАССР СЯС идарәсенең җаваплы секретаре — М. Җәлил[2].

---

[1] Монда М. Җәлил квартиралары бик кысан булган талантлы язучыларны әйбәтрәк квартиралар белән тәэмин итү мәсьәләсен куя.

[2] Төп нөсхәсе КПССның Татарстан өлкә комитеты архивында (15 фонд. 22 опись. 384 эш. 20—29 битләр) саклана.

## ТАТАРСТАН СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ КАРШЫНДАГЫ БАШЛАНГЫЧ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫ ТАРАФЫННАН ЯЗУЧЫ МУСА ҖӘЛИЛГӘ (ҖӘЛИЛОВКА) БИРЕЛГӘН ХАРАКТЕРИСТИКА

*16 май, 1940 ел*

Муса Җәлил (Җәлилов) — татар совет поэзиясенең күренекле вәкилләреннән берсе.

Аның әсәрләре 1919 елда Төркстан фронты газетасында басыла башлады һәм ул үзенең ак бандалар һәм интервентлар белән көрәш темасына багышланган беренче шигырьләрендә үк халыкта совет патриотизмы һәм илне саклау хисләре тәрбияләде.

1922—23 еллардан алып, аның әсәрләре журнал һәм альманахларда системалы рәвештә басыла башлады һәм югары художестволы лирик шигырьләре белән ул халык арасында киң танылды. Аның әсәрләрендә төп урынны комсомол тормышы һәм көрәше, гражданнар сугышы эпизодлары, совет патриотизмы һәм илне саклау, авыл хуҗалыгын социалистик реконструкцияләү, ударниклар һәм стахановчылар хәрәкәте темалары алып тора. Тирән идеялелек, тыгыз эмоциональлек һәм югары художество осталыгы — аның иҗади йөзен менә шул сыйфатлар билгели.

Ип. Җәлилов (Җәлил) комсомол белән аеруча нык элемтәдә тора. Аның «Үтелгән юллар», «Сәрвәр», «Комсомоллар» һ. б. шигырьләре һәм поэмалары бик киң таралган һәм яшьләребезне тирән дулкынландыралар.

Ип. Җәлилов әдәбият теориясе һәм тәнкыйть өлкәсендә күп эшләде. М. Гафури, Г. Коләхметов, Ш. Камал, М. Әмир, Ә. Фәйзи иҗатлары турында мәкаләләр язды.

Ип. Җәлилов соңгы елларда иҗади яктан аеруча активлашты һәм күп кенә кыйммәтле әсәрләр язды. Мәсәлән, «Зәйнәп», «Пожар», «Яшьлек», «Колхоз кызы», «Джим», «Алмагач» һ. б. шигырь һәм поэмалар. Колхоз төзелешендә стахановчылык хәрәкәте һәм акыл хезмәте белән физик хезмәт арасында аерма бетә башлау темасына «Хат ташучы» исемле яңа поэма язды.

Татар операсын үстерү эшендә ип. Җәлиловның билгеле бер дәрәҗәдә казанышы бар. Ул татар героик эпосы темасына «Алтын чәч» либреттосын (операсын Н. Җиһанов яза) һәм «Беренче яз» исемле либретто язды.

ТАССР СЯС башлангыч оешмасы
секретаре — Н. Баян [1].

## ШАГЫЙРЬНЕ МАКТАУ КӘГАЗЕ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮНЕ СОРАУ УҢАЕ БЕЛӘН ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕ ТАРАФЫННАН МУСА ҖӘЛИЛОВКА БИРЕЛГӘН ХАРАКТЕРИСТИКА

*1939 ел*

Ип. Муса Җәлилов (Җәлил) — хәзерге татар әдәбиятының күренекле вәкилләреннән берсе. Аның егерме еллык әдәби-иҗат стажы бар (әсәрләре 1919 елдан бирле басыла). Совет поэзиясенең үрнәк әсәрләре аның каләме белән язылган һәм, атаклы язучы буларак, М. Җәлилов татар совет әдәбияты үсешендә үзенә аерым урын алып тора. Болардан тыш, Ленин комсомолының җитәкче урыннарында эшләп, ип. Җәлилов күп еллар буенча зур һәм җаваплы иҗтимагый-комсомол эшләрен дә башкарып килде (ВЛКСМның ҮК һәм ШК, ВЛКСМ ҮКның Тат. Баш. бюросында инструктор).

Ип. Җәлилов художестволы-әдәби журналлар редакторы, газеталарның әдәбият бүлеге мөдире булып күп еллар эшләде һәм, ниһаять, хәзер Язучылар союзы эше белән җитәкчелек итә.

Ип. Җәлилов 1935 елдан, язучылардан беренче булып, опера өлкәсендә эшли башлады, музыка культурасын үстерүгә бик зур хезмәт кертте. Ип. Җәлиловның каза-

[1] КПССның Татарстан өлкә комитеты архивы. 15 фонд. 30 оп., 61 эш. 174 бит.

нышлары бик зур. Композиторлар белән тыгыз элемтәдә булып, ул аларны җырлар язу өчен әдәби текстлар, романслар һәм музыкаль иҗатның башка төрле жанрлары белән тәэмин итеп торды. Музыкага салу өчен күп кенә бик матур җырлар язды. Классик опера текстларын тәрҗемә итү буенча беренче тәҗрибәләрне ип. Җәлилов ясады.

Татарстан опера студиясендә әдәби бүлек мөдире булып эшләгәндә ип. Җәлилов студиягә язучыларны туплады һәм, даими консультацияләр биреп, аларны либреттолар язуга юнәлтте.

Үзенең тырыш иҗади-редакторлык эше белән ип. Җәлилов либретто язучы беренче кадрлар үстерде. Аның рецензияләре, тирән анализлы һәм югары культуралы консультацияләре авторларга яхшы либретто һәм тәрҗемәләр тудырырга ярдәм итте. Опера репертуарын булдыру баштанаяк ип. Җәлилов тарафыннан гамәлгә ашырылды.

Боларның барысыннан тыш, ип. Җәлилов иң яхшы югары художестволы «Алтын чәч» либреттосын язып театрга тапшырды һәм «Фигароның туе» исемле операны бик яхшы тәрҗемә итте.

Ип. Җәлиловның опера сәнгате өлкәсендә күп еллык редактор-консультантлык, әдәби-иҗади эше бик зур игътибарга лаек. Шунлыктан ип. Җәлиловның беренче Татар опера театрын барлыкка китерү өчен куйган зур оештыру, редакторлык һәм иҗади хезмәтләре бернинди дә шик тудырмый.

Шуннан чыгып, без ип. Җәлиловның милли операны үстерү эшендә күрсәткән хезмәтен билгеләп үтү кирәк дип саныйбыз, һәм аны Мактау кәгазе һәм акчалата бүләк белән бүләкләүне үтенәбез.

ТДОТ директоры — Бермилеев.
Башлангыч партия оешмасы
секретаре — Рәхимов.
ТДОТ месткомы председателе — Пустоветов[1].

## Ип. ҖӘЛИЛОВ (ҖӘЛИЛ) М. М. ИҖАТЫНА КЫСКАЧА ХАРАКТЕРИСТИКА

*15 февраль, 1940 ел*

Ип. Җәлилов Муса — күренекле татар шагыйре. 1919 елдан басыла башлады. Аның иҗатының характерлы сызыгы — лирик әсәрләр. Ип. Җәлилов үзе алган теманы, барыннан да элек, лирик шигырь чаралары аша җылы йөрәк хисе белән сугарып бирә белә.

Аның әсәрләренең темасы — комсомол тормышы, совет яшьләренең патриотлыгы, гражданнар сугышы эпизодлары. Илне саклау һәм колхоз төзелеше.

Үз эшендә идеялелек һәм гаделлек — аның иҗади йөзенә менә шул сыйфатлар хас.

Ип. Җәлилов соңгы елларда татар совет операсын булдыру өчен дә системалы эшли: ул татар фольклоры — «Алтын чәч» экияте темасына опера театры өчен кызыклы либретто язды, «Хат ташучы» һәм «Җиһан» поэмаларын иҗат итте.

Ип. Җәлилов поэзия һәм тәнкыйть өлкәсендә зур теоретик әзерлекле, культуралы шагыйрь.

**Язды: Ш. Маннур[2].**

[1] КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы. 1954 фонд. 1 опись. 55 эш. 1 бит.

[2] КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы, 30 ф., 10 оп., 56 эш. 11 бит. Төп нөсхә.

# *Шагыйрьнең күен дәфтәреннән*

*Зәки Нури*

## Чәчәкле этюд

Таң калдым мин урман юлында
Май башының якты кичендә:
Яз кабынды минем кулымда
Нәп-нәни бер бөре эчендә.

Мин елмаеп куйдым күрүгә:
Күз алдымда туды бер чәчәк!
Әйттем: чыктың тере бөредән,
Күңелләргә инде кер, чәчәк!

...Зур яз туа нәни бөредән,
Язның аның җиңел йөреше.
Талма, аяк, туйма йөрүдән,
Син яз тудыр, күңел бөресе.

## Белсәм әгәр

Сызылыр идем күктә якты яшен булып,
Шаулар идем булып диңгез дулкыннары,
Ятар идем олы юллар ташы булып,
Белсәм әгәр ул күрәсен, ул тыңларын!

## Гыйшык уты

Яндырса да, күмер-көл итсә дә,
Сөйләмиләр утны яманлап!
Мин дә янам... Аңа синдер сәбәп!..
Һәм аңлатып булмый, һәм аңлап.

## Кәләпүш

Ташкентка баргач бер егет
Тапшырды миңа аны.
Бизәкләре — тамыр кебек,
Тамырда — дуслык каны.

Төннәрен салмыйча хәтта,
Көн дә киясем килә.

Бигрәк матур, бигрәк кәттә
Бүләк! — диясем килә.

Хәтерлим аны кигәндә
Берәүнең кара күзен:
Әллә шул чикте микән дә
Шул текте микән үзен?!

Мин аны «Кәләпүш» дидем,
«Тәлпәк» дисәң дә матур.
Мин шундый бер бүләк кидем —
Кайчан кисәң дә матур!

## Ике башак

— Син ник туксың — әйтче сәбәбен?
Ник бөртек юк миндә һаман да?
— «Үс, башак!» ди минем сабагым,
Ә синеке үсә саламга.

## Бер кәрләгә

Булмас үсү, булмас артуың...
Син үзеңне зурдан үлчәмә.
Кемнең, кайчан, күпме тартуы
Сүздә түгел, эштә үлчәнә.

## Ашыгуга каршы

«Ярытырмын һәм тиз ташламамын,
Ташлар булма син дә тиз», — дисең,
Мин гыйшкымны әле башламадым,
Син азагын аның әзлисең.

## Сүздә һәм эштә

Келт-келт кенә итеп сөрән салды:
Мин сәгать! Ә гер ул — гер түгел!..
Күтәрмәгәч герен туктап калды...
Сүзе белән эше бер түгел!

## Оптимист ялкау

Куллар таза-сау. Башкаем уйлый.
Тотынсам эшкә — башкарып булмый...
Йомырка атып таш ярып булмый,
Таш ярам диеп баш бәреп булмый.

## Борчак белән ногыт

Үз-үзләрен шашып мактыйлар —
Ике сүзнең бере: «Мин» дә «Мин»...
Суга салсаң бүртеп шартлыйлар —
Икесен дә яхшы беләм мин!

## Актарыла урам...

Казыдылар: «Монысы газ!» — диделәр, —
«Ә бу юлдан менә су килә!»
Кабельчеләр хәзер казый диләр...
Актарыла урам, ду килә...

## Шагыйрь шунда иде

Шагыйрь өенә бер төнне
Тәнкыйтьче килеп керде,
Эзләнде дә: «Күрмим, тапмыйм,
Юк бит монда», диде.
Эзләде. Талант тапмады...
Чыкканда ишек япмады...
Шагыйрь шунда иде.

## Авызын бикләде

Уйлый йозак: — И, мескен ачкыч!
Бәп-бәләкәй... Ә мин, ичмасам...
Әйтә ачкыч: — Андамыни эш?
Мин биклим бит сине, мин ачам!

## Эре белән вак

Фил сыртына нәни Черки килеп куна.
Һәм куана, һәм аптырый үзе шуңа.
Уйлый: мин бик авыр түгел микән? диеп,
Авыр булсам, әйт, Фил, очып китәм! диеп.
Хыяллана Черки шулай бик биектә.
Ә Фил аны белми хәтта бар диеп тә.
...Вак кешеләр бездә әле булгалыйлар,
Киң җилкәгә шулай менеп кунгалыйлар.

## Масаю

Борынын чөйде Итек юештә:
«Күтәреләм! Ярыйм зур эшкә!»
Хуҗа әйтте: «Ташлыйм утка!» диде.
Бу масаю, димәк, юкка иде.

## Сүз остасы

Сүз сораган. һәм сүз биргәннәр.
Шулай булган ләкин күп вакыт:
Инде нәрсә бирик, дигәннәр,
Булсын өчен сүздән туктатып?!

## Уңай тип

Эштә утыра, җыелышка килә,
Эчсә — күрсәтми, тартса — ешламый,
Кирәк санаса — елмая белә...
Ә җыеп әйтсәң — берни эшләми.

## Яла ягучы

Бик күп эшли. Тырышлыгы өчен
Заман аңа һәйкәл куяр микән?
Кешеләргә зур-зур баз казыды,
Үз базына үзе сыяр микән?

## Тасма тел

— Ник соң сиңа ярап булмый?
Нинди соң синең күңел?
— Әйләндереп карап булмый,
Күңел тун җиңе түгел!..

## Акыллы зат

Җыелышларда дәшми — имеш, тыңлый,
Сөйләшергә эштә иренә.
Мәҗлесләрдә утыра дәшми-тынмый...
һәм... акыллы булып күренә.

—●—

# ЮЛ ӨСТЕНДӘ КОЯШ

Гаҗәеп катлаулы бу дөнья. Социаль давыллар канатына бер үк вакытта кешенең изге өметләре һәм шомланулары кунаклый, гасырыбызның олы идеяләре, бөек ачышлары белән янәшәдә үк кешенең тырнак очы кадәрле генә, шулай да көчле шәхси мәшәкатьләре урын даулый. Бу дөньяны аңлау, аны шагыйрьләрчә йөрәккә сыйдыру һәм күңелгә сеңдерү — гаять дәрәҗәдә авыр эш. Шуңа күрә дә Җир, Кеше, Ил язмышын беркадәр тулырак сыйдырган һәм чагылдырган шигырь китаплары ел саен туып тормый.

1966 елда Татарстан китап нәшрияты Шамил Мәхмүдовның «Юл өстендә кояш» дигән китабын бастырып чыгарды. Шунысын да әйтергә кирәк: бу китапның аерым өлешләре рус телендә 1962 елда ук чыгып, «Дружба народов», «Литература и жизнь» журналларында, «Советская Башкирия», «Комсомолец Татарии» һәм башка газеталарда матур-матур рецензияләр дә алып өлгерде. Шуның өчен дә бу китап шигырь сөючеләргә көтелмәгән күчтәнәч булмады. Шулай итеп, татар укучылары алдында яңа китап, таныш исем.

* * *

«Юл өстендә кояш» — сүзнең туры мәгънәсендә китап, шигырьләр җыентыгы гына түгел. Роман яки повестьны арттан алга таба укып булмаган кебек, бу китапны да теләсә кайсы битеннән, теләсә кайсы шигыреннән башлап укып булмый — аңлашылмаучылык килеп чыга. Китапның һәр шигырен бүлек дип атап була. Ләкин проза әсәрләрендәге, поэмалардагы бүлекләрдән бу китаптагы һәр бүлек үзенең мөстәкыйльлеге, төгәллеге белән аерылып тора. Шул ук вакытта һәр бүлек үзеннән алда килгәненең увертюрасы да. Менә «Гади әйберләр» дип исемләнгән беренче цикл.

**Җирдә һәркем өчен бар:**
**яктылык, җылылык, эш һәм аш,**
**юллар өстендә — кояш, —**
дип башланып китә ул.

Бу увертюра циклның, хәтта китапның гына да башы түгел. Ул — авторның образлы фикерләр йомгагының җеп очы да. Шушы юллар Җир, Кеше, табигать, тормыш турындагы образлар дөньясына алып керә. Әйе, бу тормышның нигезендә гадидән гади әйберләр ята.

Аларның гадилеге, билгеле, чагыштырмача гына. Иң гади әйбер, мәсәлән, Җир. Чөнки ул кешенең иң күптәнге танышы, кеше аны бик яхшы белә һәм аңлый. «Җир» шигыренең циклның башында булуы да очраклы түгел. Ул авторның образлы фикерләү диалектикасына бәйле. Кеше өчен Җир — беренчел: кеше үзе дә, аның барлык шатлык-кайгылары да, өмет-хыяллары да, «бөтен гүзәл нәрсәләр дә» җирдән башлана.

Шул ук Җирдә кеше үзенә оя кора, оясында гаилә булдыра: чөнки «ике яр яшәгән өйләр — иң гүзәл оя Җирдә».

Кеше уяу булырга тиеш. Ул бит белә: бу тормышның гади, ак әйберләрен кайчаклар да кара эшләр пычрата.

**Кеше килә ак дөньяга,**
**татый аналарның ак сөтен...**

һәм ул барлык кара нәрсәләрне ләгънәтли, ә аннары — барлык пакь әйберләрне имгәтүче кара эшләргә каршы көрәшкә күтәрелә. Кеше йөрәге, табигате белән «түбәнлектән котылу, кояшка омтылу» ягында. Көрәш аны аңның югары баскычларына күтәрә.

**Менә-менә биеккә,**
**әйләнәләр кешеләр**
**үзләре дә**
**бөеккә!**

Менә шуңа күрә дә:

**тормышның**
**киң ачылган күз бәбәгендә**
**күренә шундый бөек булып**
**тик кешенең генә горур сыны!**

Картларныкымы, яшьләрнекеме — аныцы барыбер: ул сын гүзәл, ул сын бөек. Чөнки кеше — тормышны матурлаучы, чөнки кеше — яшәүне дәвам итүче, җир язмышын хәл итүче!

«Гади әйберләр» дигән циклның логик төзелеше әнә шундый. Китапның калган биш циклы да нәкъ шулай төз логикага корылган һәм һәр цикл берсе берсеннән үсеп чыга. Циклларның мондый төзелеше үзенә бертөрле сурәтләү чарасына әверелә, һәм бу чараның, сүз, рифма, ритм, аллетерация һәм башка әдәби чаралар кебек үк, мөһим, тормышчан иканлеге күренеп тора. Бу Шамил Мәхмүдовның китабын башка шигырь җыентыкларыннан аермалы ясый.

Шулай итеп, беренче цикл дөньяның, аны тәшкил иткән гади әйберләрнең, кешенең гомуми контурларын, бәйләнешләрен, фәлсәфи халәтләрен күрсәтә. «Гади әйберләр»нең дәвамы булып «Йөрәк хатере» дигән цикл үсеп чыга.

Бу цикл инде дөньяның, яшәешнең драматизмын һәм трагик хәлләрен конкрет сурәтләр аша ачып бирә. Ул — сугыш турындагы сюжетсыз поэма. Цикл:

**Җиргә**
**яшәр өчен килгәннәр**
**үлем эзләми җирдә... —**

дип башлана да, бер-бер артлы авыр, куркыныч сугыш картиналарын күз алдына китереп бастыра.

Әнә:

**өскә төшәргә тора**
**тимер баскыч өзеге;**
**агы купкан стена**
**чеп-чи ит төсле —**
**күренеп тора кызарып**
**канлы үзәге...**

Менә егерме ел инде исән улын үлгәненең исеме белән атап йөргән ана сурәте, дога кылган анага охшаган җимерек стена. Ул:

**Гүя,**
**хәлсез кирпеч кулларын**
**куеп күкрәк өстенә,**
**кайгыдан башын иеп,**
**пышылдый да пышылдый —**
**дога укый ул,**
**дога укый үлгәннәргә:**
**кешеләргә,**
**агачларга,**
**үләннәргә...**

Шулай итеп, безнең күз алдына сугышның коточкыч сурәтләре җанлы булып килеп баса. Үле стенаның ләгънәтен укыгач, бөек табигатьнең җан тавышын ишеткән кебек буласың. Табигать тынычлык яклы, чөнки аның гүзәллеген бары тынычлык кына саклый ала, ул гына яклый ала.

**Алтын тавыннан да**
**кыйммәтрәк**
**тынычлыкның хәтта бөртеге.**
**Еллар буе төзгән, күтәргәнне**
**юк итә сугышның бер көне.**
**Түгел сугыш сөяр башлыклар,**
**идарә итсен дөнья белән**
**акыл иялəре һәм гашыйклар.**

(«Тынычлыкның бөртеге».)

Бу юллар кешеләрнең өметен чагылдырган фикер булып кына түгел, ә табигатьнең катгый боерыгы булып яңгырый. Һәм моннан соң килгән «Җәйге көннәр» дигән цикл турыдан-туры табигать әмеренә буйсына. Моның шулай булуында Ш. Мәхмүдов тудырган лирик геройның да өлеше зур.

Бу циклдагы шигырьләрне бер-бер артлы укып чыккач, табигатьнең: «Менә мин нинди бит! Ә сез, кешеләр, кайчакта...», дигәнен ишетәсең һәм кабат «Йөрәк хәтере» циклы күз алдында җанлана. Аннары «Гади әйберләр»нең асылы, фәлсәфи халәте, кеше тормышындагы тоткан урыны турында уйлана башлыйсың. Һәм син: «...идарә итсен дөнья белән акыл ияләре һәм гашыйклар», дип, табигатьнең теләктәшенә әвереләсең, күңелдә олы гуманизм хисләре туа.

Автор тормыш фәлсәфәсен өйрәнүдә укучыны һаман тирәнгәрәк — мавыктыргычрак һәм катлаулырак дөньяга алып керә бара. Укып үткән һәр шигырь үзенең ассоциатив җебен укучының күңеленә суза. Ул җепләрдән бер үк вакытта гади һәм катлаулы чигеш барлыкка килә.

«Җәйге көннәр» циклы кешедә, аның нинди генә катлаулы, кыен, куркыныч вакыйгалар кичерүенә карамастан, гүзәл сыйфатларның мәңгелек булуы турында сөйли. Кеше күңеле, асылы белән беркайчан да төшенкелеккә бирелми. Ул — мәңгелек якты өмет иясе, мәңгелек оптимист, чөнки:

**Кешеләрнең күңеле —**
**шул ук туфрак.**
**Шул ук туфракта**
**яра яфрак**
**яхшылык, гаделлек үсентеләре...**

Чөнки ул белә:

**килү**
**китүдән күбрәк һәрвакыт:**
**көннән-көн**
**арта җирдә байлык, акыл...,**
**тамыр җәя, тармаклана**
**җирдә кешелек агачы!**

Юк, бу хакыйкатьне белү генә кешене бөек оптимист итә алмый. Эш циклның тулаем фәлсәфәсендә. Аны укып чыккач, табигатьнең гомуми халәте аңга кереп урнаша. Табигатьнең дә төп теләге тынычлык икән (хәрәкәтсезлек түгел!), ул теләкне эшкә ашыра алучы бердәнбер көч кеше икән. Кеше аңына үзеннән-үзе менә шушы хакыйкать сеңә һәм аны бөек оптимист итә.

Үзебез дә сизмәстән без «Кешеләрнең күңеле» дигән циклның берничә шигырен укып куйганбыз һәм алар (бу китап өчен гадәти хәл) «Җәйге көннәр» дигән циклны кабат искә төшергәннәр. «Кешеләрнең күңеле» дигән цикл беренче карашка ук «Гади әйберләр» циклын искә төшерә. Беренче циклны Ш. Мәхмүдов «Бөтен гүзәл нәрсәләр башлана җирдән» дип башласа, бу циклның иң беренче юллары — «Кешеләрнең күңеле — шул ук туфрак». «Барысы алда» шигыре — «Оя»ны, «Төзү дәрте» «Биеклек»не хәтерләтә.

Ләкин Ш. Мәхмүдов үзен-үзе кабатламый. Ул «Кешеләрнең күңеле» циклында кешегә тагын да якынрак килә, аның табигатьтәге ролен тагын да тирәнрәк күрсәтә.

**Кешеләрнең күңеле —**
**яхшылык яши торган урын, —**

дигән юлларны укыгач, кеше белән табигать арасында тигезлек барлыкка килә сыман. Кеше — барлык сыйфатлары, мөмкинчелекләре, көче белән үзе бер табигать! Табигать үлемсез әйберләр тудырган кебек, кеше дә үлемсезлек тудыра.

**Кешене мөмкин үтерергә,**
**елмаюны —**
**мөмкин түгел...**

Бу циклдан соң «Мәхәббәт» дигәне килә. Андагы шигырьләр, бер карашка, бик гадиләр. Ләкин алар алдагы циклларда башланган кайбер фикерләрне яңа баскычка күтәрәләр. Әгәр дә «Оя» исемле шигырьдә: «Ике яр яшәгән өйләр — иң гүзәл оя җирдә» диелсә, шагыйрь бу циклда:

**Без икәү бергә чакта,**
**үтәбез мәңгелек сызыгын,**
**безнең кайнар иреннәргә**
**үлемсезлек кагыла... —**

ди. Циклның төп фикере — кеше үлемсезлегенә, аның фәкать ак эшләр өчен яралганына ышану.

Ә соңгы цикл («Бөек үзгәреш») — шагыйрьнең дөньяга гомуми карашы. Ул дөньяның бөек үзгәрешләр, ачышлар алдында торуын күрә һәм шул үзгәрешләргә, ачышларга мәдхия җырлый. Бу циклда шагыйрьнең үз кредосы да ачыграк бирелә. Ул циклны һәм китапны тәгәлли торган түбәндәге шигырьдә:

**Мин ялгышмыйм. Килде шундый**
**мәгънәле чак:**
**Без аңладык, кара кара ул, ак ул ак.**
**Бу шулай. Ләкин кырыс чынлык**
**дөньясы**
**үзе турында үзе сөйләп кенә**
**буяуларны, сүзләрне дөрес,**
**чын ясый.**
**Шигърияттнең бар тагын бер**
**кануны:**
**һәрвакыт, бигрәк тә кара көннәрдә,**
**шагыйрь тиеш яктылыкка өндәргә.**

Бу юлларда бүгенге тормышның иң актуаль проблемалары (сугыш, тынычлык, атом психозы, өмет, космоска чыгу...) тагын да ачыграк күренә.

Бу китап яшәүгә, тормышка мәдхия җырлый. Шагыйрь заман, яшәү, үлем, яхшылык-яманлык кебек зур категорияләргә мөрәҗәгать итә һәм кешенең яңа дөнья тудыручы икәненә, бөеклегенә ышана һәм, коммунистик позициядән торып, кешелек дөньясының олы казанышларын раслый. Китапның гражданлык пафосы шуннан гыйбарәт тә һәм бу, коры декларация булмыйча, шагыйрьнең йөрәгеннән чыга.

«Юл өстендә кояш» — кешенең бүгенгесе, бигрәк тә аның киләчәге турындагы поэма. Аның төзелеше турында сөйләгәндә, без бу төзелүнең үзенә бертөрле әдәби сурәтләү чарасы икәнен әйтеп үткән идек. Мондый әдәби чараның матур үрнәкләре безнең шигъриятебездә очрыйлар иде инде (Х. Туфан, С. Хәким, Ә. Давыдов), ләкин ул цикл чикләреннән чыкмый иде. Ә Ш. Мәхмүдов аны, цикл эчендә генә калдырмыйча, китапның буеннан буена барырлык әдәби чара итү дәрәҗәсенә ирешкән.

Әдәби образ тудыруда да Ш. Мәхмүдовның игътибарны җәлеп итәрлек үзенчәлекләре бар. Ихтимал, укучылар «Юл өстендә кояш»та бер зур «житешсезлек» күрерләр. Кайбер детальләрнең, образларның, фикерләрнең шигырьдән шигырьгә, циклдан циклга күчүен очратырлар. Бәлки,

моның өчен авторны тарлыкта, үз-үзен кабатлауда гаепләрләр. Ләкин бу «гөнаһлар» Ш. Мәхмүдовның образ тудырудагы, аны тулы итүдәге казанышы, һәм бу очракта авторны гаепләү мөмкин түгел. Образның фәлсәфи халәтен тулырак, тирәнрәк ачарга теләп, автор үз образларын, детальләрен икенче, өченче, унынчы шигырендә үстерә икән — бу тарлык билгесе түгел.

Кыскасы, Ш. Мәхмүдовның «үз-үзен кабатлавы» — образ тудыру чарасы, ул образны гомумиләштерү, тирәнәйтү, аны бу китап өчен бер итү чарасы. Мәсәлән, берничә циклга, берничә шигырьгә сибелгән «оя» образы укыган саен анда, күз алдында конкретлаша, тулылана, тирәнәя бара. Менә «оя» — кешене тугач ук каршы алучы нәни дөнья, менә ул имгәтелгән әйберләр арасында, менә ул ике яшь кешегә бәхетле сәгатьләр бирә, анда кайгы, анда сугышны каргаучы мич, анда бердәнбер әни... һәм ул тора-бара Җир-оя образына әверелә һәм яшәү символы булган Кояш образына барып тоташа.

Ш. Мәхмүдов шигырьләренең тагын бер үзенчәлекле ягы бар. Ул — метафораларның бик сирәк кулланылуы. Шигырьләр «шәрә», ләкин аларның «күлмәксез» булулары һич сизелми. Күпчелек сүзләр үзләренең туры мәгънәләрендә генә кулланылсалар да, алар артындагы мәгънәнең тулылыгын татыр өчен я микроскоп, я телескоп-күнел кирәк. Мәсәлән, «Янгырый элек ишетелмәгән гүзәл сүзләр...», «Шагыйрьгә башкача мөмкин дә түгел...» дип башлана торган шигырьләрне тулаем аңлар өчен, телескоп-күңелнең объективын, һәрхәлдә, бер егерме еллык үткәнгә төбәп, андагы һәр детальне зурайтыбрак, ачыграк итеп күрергә кирәк.

Ш. Мәхмүдовның шигырьләре, метафорасыз булсалар да, күз алдына гаҗәеп төсләр дөньясын, кайвакыт хыялый, ә кайвакыт турыдан-туры тормышның үзеннән алынган кырыс һәм реаль күренешләрне бик ачык китереп бастыралар. Ә сәбәп нидә? Шигырьләрнең укучылар аңында зур ассоциацияләр тудыра алу сәләтендә. Алда ук әйтеп киткән идек: китапның уртасындагы, я иң соңындагы шигырьләрне укыганда, безнең хәтеребезгә китапның моңа кадәр укылган образлары, фикерләре искә төшә бара. Шул ук вакытта яңа гына укып чыгылган шигырьнең фикерләре объектив дөнья хәлләре белән бәйләнешкә керәләр. Алар китапның образын тагын да тулыландыралар һәм үзләре дә, шигырь йогынтысы астында, башкарак яктан, яңарыбрак күренәләр. Ассоциация — Ш. Мәхмүдов шигъриятен билгеләүче иң беренче чара. «Юл өстендә кояш»ның да, «Европа уртасыннан репортаж»ның да, «Прага дәфтәре»нең дә, «Солнце на дороге»ның да — методик нигезе шул. Әмма шагыйрь образ метафоралары урынына мәгънә — сүз метафораларын куллана, хәтта аерым шигырьләрне аерым бер сүзнең күп кырлылыгына, бай төсмерләренә, күп мәгънәлелегенә һәм колоритына кора. Мәсәлән, «Кара нәрсәләргә ләгънәт» шигырендә «кара» сүзе 17—18 мәртәбә кулланылып, һәр очракта аның яңа төсмере ачыла. Өченчедән, параллель фикер-образлар (аерым юллар санау юлы белән) бер җепкә тезелеп, тулы бер картинаны бөтен детальләре белән күз алдына китереп бастыралар һәм шигырьнең төп идеясен ачалар («Яшәеш асылы»).

Ш. Мәхмүдовның шигырь төзелеше — поэзия сөючеләр өчен дә, әдәбият белгечләре өчен дә, шагыйрьләр өчен дә игътибарга лаеклы күренеш. Ш. Мәхмүдов иректе шигырьне соңгы елларда татар шигъриятенә беренче булып алып керүче генә түгел, бу форманы кабул итәрлек хәлгә китерүче шагыйрь дә. Аның иректе шигыре көнбатыш шигъриятенең татар теле нигезендәге варианты гына да түгел. Ул күбрәк Назыйм Хикмәт шигъриятенә якын. Бу аңлашыла да: Ш. Мәхмүдов — ун ел дәвамында Н. Хикмәт белән якын элемтәдә булган кеше (татар һәм башкорт телләрендә чыккан Н. Хикмәт шигырьләренең тәрҗемәчесе Ш. Мәхмүдов). Шуның өстенә ул көнчыгыш телләре белгече (МГУның көнчыгыш телләре бүлеген һәм аспирантурасын бетергән, М. Горький исемендәге әдәбият институтында укыткан). Монда шунысын да әйтергә кирәк — автор үзенең иң беренче укытучылары итеп Н. Хикмәтне һәм татар халык җырларын саный.

Ш. Мәхмүдовны соңгы елларда татар ирекле шигырен кабул итәрлек хәлгә житкерүче дип әйткәнбез икән — дәлилләргә дә кирәктер.

Ирекле шигырь — хаостан гыйбарәт канунсыз форма түгел. Ул без белгән «шакмаклы» шигырьдән нәзберегрәк, катлаулырак, чөнки форма монда беренчелекне мәгънәгә, образга бирергә тиеш. Моңа ирешү өчен исә шигырьнең һәр юлы, һәр фикере укучыны ничектер сихерләргә тиеш. Сихерли торган образлар бирү — шигъриятнең иң катлаулы һәм мактаулы эше.

Сүз монда форманың образ-фикер белән тәңгәлләшүе турында бара.

Ш. Мәхмүдовның һәрбер шигыре — үзенә бертөрле кабатланмаган форма. Бу формаларны ул «күктән тартып төшерми». Ул безнең традицион формаларның элементларын башкача тезә һәм форманың нигезе булган ритмнарны яңарта. «Оя» шигырен алыйк. Аның нигезендә — татар халык җырларыннан күчкән 8 — 7 ле үлчәү. Ләкин ул үлчәү, ритмик буыны 8 — 7 гә туры килгән башка буыннар белән аралаша: 7 — 7 — 8 — 7, 8 — 7 — 8 — 7, 8 — 7 — 4 — 7, 8 — 5 — 8 — 8, 7 — 8 — 8 — 7, 7 — 8 — 7, 8 — 7 — 5, 7 — 8 — 8 — 7 — 4 — 5.
«Кара нәрсәләргә ләгънәт»нең ритмикасы тагын да кызыклырак: 4 — 10 — 10 — 3, 4 — 10 — 3, 2 — 8 — 9, 8 — 5 — 7 — 7 — 7, 2 — 9 — 9 — 8 — 7...
Иҗек саннары шундый төрле булган юллар бик кытыршы яңгырарга тиешләр кебек, ләкин алар, ни сәбәптәндер, бик табигый, яңача яңгырыйлар, хәтта үзләренең «кытыршы» икәнлекләрен дә сиздермиләр.

Эш нәрсәдә соң? Ә эш, күңелне җәлеп иткән мәгънәдән тыш, барыбызга да билгеле булган ритмик буыннарда. Әгәр дә «Кара нәрсәләргә ләгънәт»не ритмик буыннарга бүлеп чыксак, без менә мондый күренешкә тап булыр идек: 4 — 4 — 6 — 6 — 4 — 3, 4 — 4 — 6 — 3, 2 — 4 — 4 — 6 — 3, 4 — 4 — 5 — 4 — 3 — 4 — 3 — 4 — 3...
Ягъни, нигездә 4, 6, 3 иҗекле ритмик буыннарның башка ритмик буыннар белән аралашуын күрер идек. Бу ритмнар — шигырьләрнең фикерләре тудырган ритмнар һәм алар үзләренә бер музыкальлек алып киләләр. Гомумән, Ш. Мәхмүдовның шигырьләре бик музыкальләр. Аларның төзелеше дә музыка әсәрләрен хәтерләтә: иң алдан прелюдия-афоризм, аннан 2, 3, 4 кисәк һәм тәмамлаучы өлеш килә. Алар, музыка әсәрендәге кебек, квадрат яки квадрат булмаган (так яки җеп иҗекләр) нигездә корылалар. Мәсәлән, традицион 10 — 9, 8 — 7 квадрат төзелеш булса, ритмик буыннары 6 — 4, 4 — 5 һәм 4 — 4, 4 — 3 — 5 һәм 3 иҗекле буыннар музыкаль яктан пауза хисабына 6 һәм 4 иҗекле буынга тигезләр. Шулай итеп традицион шигырь тик җөп иҗекле буыннардан тора. Мәхмүдов исә, югарыда күрелгәнчә, иҗек саннары төрле булган так иҗекләрдән кора, ягъни квадрат булмаган төзелеш барлыкка килә. Бу — сөйләү теле интонациясен тудыручы төп нәрсә. Музыкальлек ягыннан килгәндә басым роленең дә көчле булуын әйтергә кирәк: бу шигырьләргә тоник басым хас, ягъни аерым юлларда билгеле сандагы басымнар кулланыла (һәр синтагма — бер басым). Мәсәлән, «Урамнар» шигыре болай корыла: беренче юл — бер басым, икенче юл — 3, өченче — 3, дүртенче — 1... Музыка әсәрләрендә беренчел тема әсәрнең буеннан буена барган һәм үз тирәсенә башка темаларны туплаган кебек, Ш. Мәхмүдовның шигырьләрендә беренчел ритмик буын әсәрнең буеннан буена төрле вариацияләрдә үсеп бара һәм бөтен шигырьгә хас булган гомум ритмик рәсем («сквозная интонация») тудыра.

Ритмик буыннар нигезендә синтагмалар ята, шигырь кирәкмәгән урында бүгәләнми: юл — тулы фикер-образ. Ш. Мәхмүдовның шигырьләре — строфасыз шигырьләр, ләкин алар паузалар белән строфа кебегрәк өлешләргә бүленәләр. Бу өлешләрдә фикер башланырга да, тәгәлләнергә дә өлгерә. Ә калган өлешләр шушы фикергә логик ассоциация белән бәйләнәләр. Әгәр җөмләләрдәге синтагмаларны күз алдына китерсәк — нәкъ шундый күренешкә тап булабыз: фикернең тәгәлләнгән буыннары да бер-берсе белән нәкъ шулай бәйләнәләр һәм тагы да зуррак, камилрәк фикер хасил итәләр. Бу параллельдән соң Ш. Мәхмүдов шигырьләренең эчке төзелешен (әгәр дә шулай атап булса) синтагматик төзелеш дип атарга мөмкиндер. Шигырьнең бер зур паузадан алып икенче зур паузага кадәр өлеше «синтагма» дип аталса, шул «синтагма»лар, бер-берсе белән логик бәйләнешкә кереп, бер зур образ-фикерне «җөмлә»гә (шигырьгә) әвереләдерәләр. Параллель образ-юллар үзенчәлекле шигырь корылышын — синтаксик корылышны тудыра: аерым фикерләр бер үк синтаксик конструкцияләр аркылы бирелә (хәтта рифмалар). Мәсәлән, «Яшәеш асылы» һ. б. Бу да бер шигъри алым.

Кайбер укучылар рифмасыз шигырь күрсәләр: «Ах, бу ирекле шигырь икән!» диләр. Ләкин ирекле шигырь рифмалы да була ала, тик анда рифма фәкать иң кирәкле урында гына кулланыла. Ш. Мәхмүдовның кайбер шигырьләрендә («Әльшан зиратында», «Әниемнең йөзе» һ. б.) рифма традицион шигырьләрдәгегә караганда күбрәк тә. Алар юлның башында да, уртасында да, ахырында да.

Йоклагыз,
җинел булсын бу туфрак,
бу авыр ташлар,
җинел булсын ватандашлар,

якташлар, йокыгыз...
Сирәк киләсез дип тотмагыз
безгә үпкә,
ерак бит, булмый бит килеп ешрак
һәм күпкә...

Күрәсез, һәрбер сүз диярлек рифмалашкан. Ш. Мәхмүдов шигырьләрендә рифманың төрләре бик бай: яңгырашка корылган рифмалар (барыбер — бәрабәр, агачы — апачык, төзү дәрте — үзгәртү), кәнчыгыш шигъриятенә хас ике, өч сүздән гыйбарәт рифмалар да, тәңгәл рифмалар... Тәңгәл (бер, ике хәрефе белән генә аерылган рифма) рифмаларны Ш. Мәхмүдов рифмалашкан сүзләргә зур мәгънә бирмәгәндә ешрак куллана. Үзе белән зур мәгънә алып килгән сүзне юлның ахырында ул я бөтенләй рифмалаштырмый, я аңарга яңгыраш нигезендә корылган рифмалар таба һәм бу рифма укучының игътибарын җәлеп итәрлек була. Ә мәгънәле сүз рифмалашмаганда, ул сүзгә кадәр укыла торганнары рифмалашалар һәм мәгънә алып килүче сүзне, йөз күк күгәрчен арасында бер ак күгәрчен кебек, аерылып торырлык итәләр.

Кыскасы, шигырьләр техника ягыннан камилләр, үзенчәлеклеләр, фикер ягыннан тирәннәр һәм тыгызлар. Күренүенчә, Ш. Мәхмүдов шигырь техникасы белән заманча коралланган зур культуралы, киң диапазонлы шагыйрь.

Ләкин бу китапта, аның уңышлары белән беррәттән, күңелгә ятып бетмәгән моментлар да юк түгел. Әйтик, «Гади әйберләр» циклындагы «Кызыл розалар» шигырен укыганда, ниндидер логик пауза барлыкка килә. Бу шигырь ни өчен бирегә килеп керде икән, дип уйлый башлыйсың. Әгәр дә бу шигырьне гомумән китаптан алып ташласаң, «Имгәтелгән әйберләр» һәм «Икмәк» дигән шигырьләр арасында («Кызыл розалар» шушы ике шигырь уртасында) бушлык кала. Бәлки, «Имгәтелгән әйберләр» белән «Кызыл розалар» арасында логик күпер вазифасын үтәгән башка шигырьләр булгандыр да, бәлки, төрле редакцион сәбәпләр аркасында, алар төшеп калгандыр... Ләкин бусы инде укучы өчен билгеле түгел, ул хәтле үк мөһим дә түгел. Бәлки, «Кызыл розалар»ның композицион урыны «Икмәк» шигыреннән соң ук булгандыр. Бәлки, бу шигырьнең эпиграфы «Икмәк»кә дә карыйдыр. Бу очракта инде логик бәйләнеш саклана кебек.

Йомгаклап шунысын да әйтергә кирәк, китапның иң уңышлы циклы — «Йөрәк хәтере» һәм аның уңышлы ягы сюжетлылыкта. Бу очракта сюжетлылыкны прозага хас әдәби термин белән бутамаска кирәк. Шигырь үзе абстракт, ярым абстракт конструкцияләрдән торуы мөмкин. Ләкин алар ассоциатив рәвештә тормышның төгәл бер картинасын, вакыйгасын фабулалы рәвештә күз алдына китереп бастыралар, аларда вакыйга була.

«Йөрәк хәтере»нең картиналары гаять дәрәҗәдә драматиклар, экспрессивлар, бетмәс-төкәнмәс хәрәкәткә ияләр. Картиналарның һәр детале, кинодагыча итеп, зур планда бирелгән.

«Гади әйберләр» циклы да уңышлы. Бигрәк тә «Ак әйберләр», «Кара нәрсәләргә ләгънәт», «Биеклек», «Оя», «Ишекләр», «Җир», «Икмәк» кебек шигырьләр. Бу шигырьләр башкача эшләнгәннәр һәм алардан вакыйга-картина сюжетлылыгы таләп итү мөмкин түгел кебек. Без белгән сюжет — вакыт агышын, вакыйгаларның үсешен, алмашынуын художестволы итеп, объектив һәм табигый итеп чагылдырырга тиеш. Ләкин шигырь ассоциацияләр потенциалында булып, бу ассоциацияләр укучыга табигый барып җитә торган логик бәйләнештә була икән, монда ниндидер сюжетлылык бар дигән сүз.

«Гади әйберләр» циклына кергән шигырьләр нәкъ шундый сюжетлылыкка — фикер сюжетлылыгына корылганнар да. Монда без белгән сюжет ролен әйберләрнең фәлсәфи халәтен, эчке сыйфатларын ачу процессы, шушы ачу процессындагы образ-фикерләрнең логик үсеше үти. Шуңа күрә дә бу шигырьләр бераз абстрактрак булып күренәләр һәм алар шулай булырга тиеш тә, чөнки бу шигырьләр гади әйберләргә мәдхияләр, ә мәдхияләрдә вакыйга сюжетлылыгы була алмый.

* * *

Соңгы сүз итеп шуны әйтәсе килә: кайбер укучылар бу мәкаләне бер яклы дип кабул итәрләр. Алар хаклы, чөнки бу — китапның яхшы, начар якларын тикшереп, китапка ниндидер бәя биргән рецензия дә, тәнкыйть мәкаләсе дә түгел. Мәкаләдә фәкать китапның үзенчәлекле төзелеше, шигырьләрнең корылышы һәм шулар белән бәйле рәвештә генә шигырьләрнең эчтәлеге каралды.

**Ренат ХАРИСОВ**

# *Истәлекләр*

*Локман Аитов*

# АРТИСТНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ

### ТАТАР ДӘҮЛӘТ ТЕАТРЫНДА[1]

Татар дәүләт театрының 1924/25 елгы сезоны бик күп эшсез артистлар өчен зур мөмкинлекләр вәгъдә итә иде. Чөнки яңа куелган директор Зәки Баязитский театрны аякка бастыру максаты белән танылган артистларның барысына да эш тапты. Бу сезонда Сара Байкина, Нәгыймә Таждарова, Нәфига Арапова, Рокыя Кушловская, Өммегөлсем Камская, Ситдыйк Айдаров, Нури Сакаев, Мохтар Мутин, Мифтах Әпсәләмов, Касыйм Шамил, Хөсәен Уразиков һәм Мөхәммәт Вәлишин кебек артист-артисткалар сәхнәнең күрке булдылар. Галиәсгар абзый Камал да бу сезонда үзенең артистлык талантын күрсәтергә мөмкинлек алды. Елга аръягы эшчеләр театрыннан да дүрт-биш артистны профессиональ сәхнәгә тарттылар. Фатыйма Ильская белән Фатих Бәкерне дә Ташкенттән чакырып кайтардылар. Баш режиссер итеп Шакир Шамильский билгеләнде, нәүбәттәге режиссерлар арасында Мәскәүдә Вахтангов театр студиясен тәмамлаган, югары белемле Гомәр Девишев та бар иде. Җырчы Фәттах Латыйповны, Зәйнәп Хөсәенованы да читтә калдырмадылар. Шундый зур көчләрдән 40 кешелек коллектив төзелде һәм яңа сезон Нәкый Исәнбәтнең «Һиҗрәт» комедиясе белән ачылды.

Бу сезонда репертуар күп төрле һәм кызыклы булды. Озак та үтмәде, авторның үзе катнашында Һади Такташның «Җир уллары» трагедиясе сәхнәгә куелды. Аннан соң Гадел Кутуйның яңа әсәрләреннән «Балдызкай» комедиясе уйналды. Хәсән исемле мишәр образын уйнап, Хөсәен Уразиков тамашачыларның мәхәббәтен казанды. Аның «саксун», «кәбәм», «зачим» кебек сүзләрен, урамда йөргәндә, халык арасында еш ишетергә туры килә иде.

Шул елны артистларга бенефисләр үткәрү башланды. Мифтах Әпсәләмовның сәхнә бәйрәменә «Иван Грозныйның үлеме» исемле трагедия уйналды. Иван Грозный образын Әпсәләмов башкарды. Ул монархны үзен көлке рольләрдә танытканан иде, бу юлы трагик жанрда да оста булуын күрсәтте. Ул заманда тәрҗемә әсәрләргә халык йөрергә яратмый иде. Шулай да бу әсәр сезонда берничә тапкыр кабатланды.

Минем бенефисне дә үткәрергә әзерләнә башладылар. Ләкин минем бенефиска куелачак «Печән базары» комедиясен Кәрим Әмир өлгертеп җиткермәгән иде әле. Кәрим Әмирнең өенә бардым да, әсәрнең өлгергән ике пәрдәсен алып кайтып, репетицияләр башладык. Язучы авыру хәлендә булса да, берничә көн утырып, калган ике пәрдәне дә язып бетерде. Мартның 22 сендә бенефисем үткәрелде. Комедиянең баш герое итче Гыймади ролен мин башкардым. Гыймадиның дусты Гайнетдинне — Мөхәммәт Вәлишин, итченең хатынын Нәфига Арапова уйнады. Спектакльгә атаклы итче Гыймади үзе дә килгән иде. «Арттагы рәттән генә карап утырды», — диделәр.

Печән базарының бу әһлен сәхнәдә гәүдәләндерү өчен миңа күп эзләнергә туры килде. Аның кыяфәтен һәм хәрәкәтләрен күзәтеп, мин аның кибетенә бардым, рестораннарга йөрдем. Гыймадиның чын үзе итеп грим салдым. Беренче пәрдәдә ул заманда атаклы булган «Амур» рестораны күрсәтелә иде — бу ресторан залын нәкъ шундагыча итеп кордык. Хәтта шундый детальләргә кадәр онытмадык: ресторанда пианинода уйнаучы кызның ни төсле киенгәнен һәм кыяфәтен карап кайттык та

[1] Ахыры. Башы 11 санда.

Салих Сәйдәшевне нәкъ шул кызныкы шикелле күлмәкләр һәм хатын-кыз паригы киертеп, сәхнәгә чыгардык. Эстрада да кавказ биюләре белән ниндидер бер артист чыгышлар ясый иде, аны да онытмадык: Гали Ильясовны черкесларча киендереп, сәхнәдә биеттек. Галиәсгар абый белән Җ. Байкин: «Амур» икән, «Амур» булсын! Без дә чыгып утырыйк», — дип, бер өстәлгә утырып сыра эчәргә тотындылар. Пәрдәне ачып җибәргәч, халык хәйран калды — сәхнәдә чын мәгънәсендәге «Амур» иде. Анда мин — Гыймади да килеп кергәч, халык гөр килеп кул чабарга тотынды. Бик озак әйтәсе сүземне әйтергә ирек бирмәделәр. Бу комедияне дә сезонда берничә тапкырлар кабатларга туры килде.

Мохтар Мутин бенефисенә Гали Рәхим тарафыннан тәрҗемә ителгән «Гамлет» трагедиясе куелды. Гамлет — М. Мутин, Офелия ролендә Фатыйма Ильская уйнады. Әсәрне тамашачы яратып карады. Герой белән героиняның чын мәгънәсендә оста уйнаулары Казан тамашачыларын Европа һәм рус классикларын да карарга өйрәтә башлады. Бу сезонда зур хәзерлек белән «Ревизор» һәм «Отелло» да куелып, Мохтар Мутин бу постановкаларда баш рольләрне уйнады, үзенең көчле артист булуын чын-чынлап танытуга ирешә. Мондый классик әсәрләр татар артистларының сәхнә тәҗрибәләрен үстерүгә дә зур мөмкинлек тудырды.

Фатыйма Ильскаяның да сәхнә культурасы бу елларда гаҗәп дәрәҗәдә үсте. Аның «Хан кызы»нда, «Гамлет»та, «Таһир-Зөһрә» һәм башка спектакльләрдә гәүдәләндерелгән образларын күреп сокланмаска мөмкин түгел иде.

Бу әсәрләрнең барысын да диярлек сәхнәгә куючылар Шакир Шамильский белән Гомәр Девишевлар булды. Аларның бу хезмәтләре татар театрында беренче күренгән, чын мәгънәсендә художество ягыннан эшләнгән постановкалар иде. 30 апрельдә сезон ябылды һәм бу сезон татар театрында моңарчы күрелмәгән уңышлар белән тәмамланды. Артистлар театр белән исәп-хисапны өзеп, янадан кайсысы кая таралышырга мәҗбүр булдылар.

Габдулла Уральский белән Камал III, аларга ияреп берничә артист һәм артистка Астраханьга киттеләр. Без исә, бу тирә кешеләре, иялэнгән җиргә, әлеге дә баягы хезмәт биржасына барып учетка язылдык.

Көннәрнең берендә Фәттах Латыйпов квартирасында — Шакир Шамильский да анда иде — өчәү киңәштек тә, кечкенәрәк бригада төзеп, Татарстан районнарына чыгарга, берәр ай булса да йөреп кайтырга булдык. Бу бригадага Шакир Шамильский (режиссер), Маһирә Мирвәлиева, Зәйнәп Хөсәенова, Өммегөлсем Камская, Фәттах Латыйпов, Гали Ильясов, Мөхәммәтхан Вахитовлар керде. Мине бригаданың җитәкчесе итеп билгеләделәр.

Май уртасында чыгып китеп, башта Әгерҗегә туктадык. Аннан Ижевскида, тагын Әгерҗедә, Сарапулда, Чаллыда, Бондюгта булдык, аннары Алабугага киттек. Чистайга да кердек.

Бер айлык гастрольдә без унбишләп спектакль күрсәттек. Сәфәребез ярыйсы уңышлы чыкты. Һәркайсыбызның бераз ял итәрлек чамабыз да калды.

Казанга кайтып берәр атна чамасы торгач, Шакир Шамильский, иптәше Маһирә ханым белән, туган авылларына кайтып ял итәргә уйлады. Иптәшем белән мине дә үзләре белән барырга чакырдылар. «Бераз ял итәрбез дә аннан Уфага да барып килербез», — диде Шакир. Без риза булдык.

Нури Сакаев белән Нәгыймә Таҗдарова без барганда Уфада иде. Алар белән киңәшеп, Уфадагы һәвәскәрләр катнашында Кәрим Әмиринең «Печән базары» комедиясен куеп җибәрдек. Сборны күп алдык. Өчдүрт көннән шул ук язучының «Казан кызы» комедиясен әзерләп өлгерттек. Бу спектакль дә ярыйсы үтте. Безнең спектакльләрне Мәҗит ага Гафури да карады. Башкортстанның хөкүмәт җитәкчеләре дә килгән иде. Алар безнең постановкаларга әйбәт бәя бирделәр, Мәгариф Халык Комиссариатына чакырып, Уфада калырга кыстый башладылар. «Гыйлаҗ Казанскийны, Әмин Зөбәеровларны чакырып кайтарырбыз, өстәвенә, үзегезгә кирәкле артистартисткаларыгызны чакыртырсыз. Уфада татар-башкорт труппасы оештырырга кирәк», — диделәр.

Дөрес, алар безгә хезмәт хакын тәэмин итә алмыйлар, ләкин театр бинасын бушлай бирү, театрдагы костюм, декорацияләрдән бушлай файдалану мәсьәләләрен хәл итәргә сүз бирделәр. Кыскасы, без алардан, алар бездән акча сорамаска тиеш идек. Комиссар: «Спектакльләрдән җыелган сборларыгыз артистларның үз бәхетләре», — диде.

Шуннан Нури Сакаев елмайды да: «Бу инде ашау байдан, үлем ходайдан дигән кебек була икән!» — диде. Без барыбыз да көлешеп алдык. Шулай да бу шартларга

риза булдык. «Тәмам уйлашкач, Казаннан телеграмма сугарбыз», — дип саубуллаштык. Бер-ике көннән Уфадагы дуслар безне озатып калдылар.

## УФАДА ТАТАР-БАШКОРТ ТРУППАСЫ

*(1925—26 еллар)*

Казанда безгә озак яшәргә туры килмәде. Уфада бер сезон эшләргә теләгебез барлыгын әйтеп, Башкортстан Мәгариф Комиссариатына телеграмма суктык. Озак та үтмәде, җавап алдык, оештыру расходларына, юлга дип, ике мең сум акча да җибәргәннәр иде.

Шуннан Урал, Себер якларында булган иптәшләрдән Казанскийга, Зөбәеровка, Сәмитоваларга телеграмма сугып, аларны Уфага чакырдык. Мәҗит Илдар белән Рокыя Кушловская Оренбургта иде, аларны да чакырттык. номер әзерләнеп куелган Уфада аерым номер әзерләнеп куелган иде. Шунда яши башладык һәм эшкә тотындык. Уфаның үз артист-артисткаларыннан: Мәрфуга Иманская, Һаҗәр Һилалова, Гыймал Минһаҗов, Хажи Бохарский һәм башкалар белән сөйләштек. Районнардан яшь артистлар һәм курайчылар китерттек. Ул арада Фәхернисә Сәмитова, Гыйлаж Казанский һәм Әмин Зөбәеровлар да кайтып җиттеләр. Мәҗит Илдар белән Рокыя Кушловскаялар да килеп төште. Шулай итеп составында 25 ләп кеше булган «Татар-башкорт драма һәм музыкаль комедия труппасы» оештырылды.

Баш режиссер итеп Шакир Шамильский билгеләнде, мине труппаның җаваплы җитәкчесе итеп куйдылар.

24 октябрь көнне Мәҗит ага Гафуриның яңа әсәре — «Кызыл йолдыз» пьесасы белән сезоныбызны ачып җибәрдек. Театр бинасына җәйдән үк ремонт ясалганлыктан, бик чиста, бик җылы иде. Антракт вакытларында фойеда оркестр уйнап торды. Постановка бик уңышлы чыкты, авторны да, уйнаучыларны да сәхнә алдына кабат-кабат чыгарып алкышладылар.

Бер-ике көннән соң ук «Галиябану»ны куеп җибәрдек. Галиябану — Кушловская, Хәлил — Казанский, Исмәгыйл — Шамильский, Бәдри — Зөбәеров, Галимә — Сәмитова, яучы — Таҗдарова булды. Кыллы оркестр музыка уйнап торды. «Уфада мондый «Галиябану»ны күргәнебез юк иде әле!» — дигән югары бәяне ишеттек.

Көннәрнең берендә Башкортстан сәнгать эшчеләре союзының 5 нче съезды уздырылды. Мортазин белән мине делегат итеп җибәрделәр. Мине идарә составына да сай-



*Татар-башкорт труппасы, 1925—1926 ел. Уфа.*

ладылар. Идарәнең тапшыруы буенча, кызлармеецлар арасында культура-шефлык эшләрен алып бардым.

Тора-бара башкортча әсәрләр дә куя башладык. Х. Габидинең «Энҗекәй белән Юлдыкай» дигән әсәре Мортазин постановкасында бик уңышлы чыкты һәм сезонда берничә тапкыр уйналды. Буранголның «Ашказар» драмасы да халык яратып карый торган әсәр булып китте. Кушловскаяның матур җырлары бу спектакльләрдә аеруча тәэсирле яңгырап, Уфа халкы ул катнашкан спектакльләргә килергә атлыгып тора иде.

1926 елның январенда татар театрының тууына 20 еллык юбилей үткәрү өчен Шәриф Сүнчәләй, Әмин Зөбәеров, Мансуров, Мортазин, Шамильский, Казанский, Амантай һәм минем катнашымда комиссия оештырылды. Театрның үсешен күрсәткән әсәрләрдән төрле өземтәләр алып киң программа төзелде. Театр фойесына театр тарихына кагылышлы зур күргәзмә куелды. Алтын хәрефләр белән язылган афишалар чыгардык, чакыру билетлары өләштек. 30 январьда, шимбә көнне Уфаның сәнәгыйнәфисә сараенда тантаналы юбилей кичәсе үткәрелде. Мәгариф Халык Комиссариаты вәкиле Вәлиулла Мортазинның «Татар театрының 20 еллыгы» хакында зур докладлы булды. Соңыннан татар театры төзелгәннән бирле эшләп килгән артистларны котлаулар, бүләкләүләр башланып китте. Бик күп тәбрикләү телеграммалары укылды. Төрле пьесалардан өзекләр күрсәтелеп, зур концерт үткәрелгәннән соң, фойеда төнге сәгать икегә кадәр танецлар, биюләр, күңел ачулар булды. Ике якта ике оркестр алмашлап, өзлексез уйнап торды.

Бу елны без югарыда әйтелгән спектакльләрдән тыш Кәрим Әмиринең «Пайтәхет җәлләдләре», Буранголның «Ялан яркәй», Ибраһимовның «Башмагым» һәм Хаҗибековның «Аршин мал алан» әсәрләрен куйдык. Эш белән мавыгып, атнасына икеөч постановка куя-куя, яз якынлашканын сизми дә калдык.

Бер көнне профсоюзның өлкә комитетында рус опереттосының һәм безнең труппаның отчет докладлары булды. Безнең труппаның килере рус труппасыннан өстен булып чыкты. Без үз расходларыбызны каплау белән генә калмыйча, артистларыбызга да артыграк түләгәнбез. Бу хәлне күргәч, профсоюз Мәгариф Халык Комиссариатына безнең труппаны үз карамагына алырга тәкъдим ясады. Мәгариф Халык Комиссариатының приказы озак көттермәде. Анда: «Татар-башкорт труппасы беренче апрельдән Мәгариф Халык Комиссариаты карамагына күчә һәм Башкортстан дәүләт труппасы исемендә йөртелә», дип язылган иде. Яңадан «Печән базары»н, «Казан кызы»н, «Башмагым» һәм «Тәфтиләү» әсәрләрен куйдык. Апрельнең ахыры килеп җитте дә 30 апрельдә сезонны яптык.

Безнең бу кышкы сезоныбыз асылда Башкорт дәүләт театрына нигез салу булды. Шул көннән башлап башкорт театры даими эшли башлады. 1928 елда әсәрләрен Мәскәү сәхнәләрендә күрсәтүгә иреште. Елдан-ел үсә барып, «Башкортстан Дәүләт Академия театры» исемен алды. Соңыннан Мәскәүдә башкорт әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнашуга лаек булды.

## АСТРАХАНЬДА

*(1926—27 еллар)*

Казанга кайткач, бу җәйне дә бушка уздырмадык: Ш. Шамильский, Камал II, Х. Уразиков, М. Вәлишин, Б. Ибәтуллин, Өммегөлсем Болгарская, Хәдичә Арская һәм Рауза Ямангуловалар җыелып, тугыз кешедән торган бригада төзедек тә, үзебезгә таныш булган якларга гастрольгә чыгып киттек.

Гастрольдән кайтып кына җиткән идек, Астрахань шәһәреннән Габдулла Уральский килде. Анда кышкы сезонга татар труппасы төзәргә уйлаганнар икән. Уральский Казаннан артистлар җыярга кайткан булып чыкты. Мин анда барырга ризалык бирдем. Шуннан театр техникумында укучылардан Әминә Мөхәммәдиеваны, Зыя Сабитовны һәм типография эшчеләре клубы түгәрәгеннән Камилә Нигъмәтуллинаны алып — барлыгыбыз бишәү — Астраханьга киттек. Астрахань шәһәр Советы безгә — читтән килгән артистларга — берничә номер да әзерләп куйган иде. Уналты кешелек коллектив белән «Вулкан» кинотеатры бинасында эшкә башладык. Бу бинада без атнага ике көн уйнарга тиеш идек. Габдулла Уральский театрның режиссеры, мине җитәкче итеп билгеләделәр. Ноябрь башында Г. Кутуйның «Балдызкае» белән кышкы сезонны ачып җибәрдек. Балдызкай ролендә Камилә Нигъмәтуллина уйнады. Мин — Хәсән мишәр ролендә идем. Уразиков алымнарын хәтеремә төшерергә тырышып уйнадым. Халыкның алкышларына карaганда, спектакль җанлы үтте кебек, Әсәр-



*Астрахань труппасы. 1926—27 елгы сезон.*

нең музыкаль ягы кыллы оркестр белән башкарылды. Ананьев җитәкчелегендәге бу оркестр барлык музыкаль әсәрләрдә кыш буенча уйнап чыкты.

Озакламый Габдулла Гатауллин-Апушның «Ачы хакыйкать» драмасын, Габдулла Уральский әсәрләреннән «Бал куаслы туй» комедиясен куеп җибәрдек. Бу соңгысы астраханьлылар тормышыннан алып язылганлыктан, халык гадәттән тыш күп килгән иде. Галиәсгар абзыйның «Алтын кармак» әсәре дә уңышлы барды. Паулюсь ролендә Уральский, кызы Лукия ролендә Нигъматуллина, офицер Рауль ролендә Зыя Сабитовлар уйнады, Альберт ролен мин башкардым. Габдулла Уральскийның «Камчылы ишан», «Малик ширкан», «Туктамыш хан» һәм «Балыкчы кызы» кебек әсәрләре дә күп куелды һәм уңыш казанды. Астрахань һәвәскәрләреннән Дибердиева Маһруй, Садретдинова Хәят, Вәльшина Вазифа, Хәйруллин, Гумеров, Байкиннар да бу спектакльләргә катнаштылар. Астраханьда оешкан коллектив язга кадәр шулай бердәм эшләп килде дә апрель ахырларында сезонны тәмамлады.

Бозлар китеп, Иделгә пароход төшү белән Казанга кайттым. Бу елгы җәйдә, Казаннан чыгып китмәскә, бераз ял итеп алырга исәп иде. Кайтып бер ай чамасы торуга, минем семьямда бер ир бала артты. Шатлыгымны уртаклашырга Галиәсгар абзый янына ашыктым. Мин аңа алдан ук: «Галиәсгар абзый, ир бала булса да, кыз бала булса да берәр исем әзерләп куй әле. Балама исемне син кушсаң иде», дип үтенгән идем. Ул килде һәм: «Нәүфәл кушыгыз», диде. Бу исем миңа да, иптәшемә дә бик ошады.

Галиәсгар абзый бу бала турында беренчә еллар буена, очраган саен: «Ничек, Локман, теге мин исем кушкан малаең ни хәлдә? Исән-сау гына үсәме?» — дип сораштыра иде...

Бу җәйне гастрольгә беркая чыкмадым.

## ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫНДА

*(1927—28 еллар)*

Көзен театр дөньясында зур үзгәрешләр булды. Театрыбызга «Татар Дәүләт Академия театры» дигән мактаулы исем би-

релде. Ул елны театр техникумын да унике яшь артист тәмамлап чыкты. Татар сәхнәсендә моңарчы эшләп танылган артистларның берсен дә Академия театрыннан читтә калдырмаска карар кылдылар. Театрның директоры итеп Фәтхи Бурнаш, баш режиссер — Гомәр Девишев, нәүбәттәге режиссер итеп Шакир Шамильский билгеләнде. Мин администратор булып эшкә кердем.

Бу елгы сезонда миңа бик җаваплы һәм кыен бурыч йөкләтелде: тамашачыларны оештырырга тиеш идем. Бөтенләй яңа эш иде әле бу.

Сезон төрек язучысы Нәмыйк Кәмалнең (Г. Камал тәрҗемәсендә) «Һинд кызы» әсәре белән ачылырга тиеш иде. Татпрофсоветта культура бүлеге мөдирләрен чакырып киңәшмә уткәрдек. Татар академия театрының киләчәктәге репертуары белән аларны таныштырдык. Киңәшмә «Сәнгать һәм производство эшчеләре арасында бәйләнешне ныгытыйк!» дигән лозунг астында узды. Профсоюзлар ярдәмендә, эшче-хезмәткәрләр, студентларны оешкан рәвештә театрга якынайту эшенә керештек.

1927 елның 28 октябрендә, Казан зур театры бинасында Татар дәүләт академия театрының пәрдәсе кутәрелде. Беренче сүзне һинд кызы Сөружи ролендәге татар артисткасы Фатыйма Ильская башлап җибәрде.

Сөружи, инглиз офицеры Томсонга (артист Шакир Шамильский): «Күр, Томсон, бу еланнар яткан елгада купме чәчәкләр бар. Алар синең йөзең шикелле матурлар. Мин шул чәчәкләргә карап, синең күңелеңдәге гүзәллекне күрергә телим. Бу чәчәкләргә елан агуы сеңмәде микән?» — дип сөйли.

Романтика, сәхнәдәге Һиндстан күренешләре тамашачыларны сихерли иде. Менә сәхнәгә һинд халкының аксакалы Турумтур (артист Бари Тарханов) керә. Ул Сөружины инглиз офицеры белән бергә очраткач:— «Син уйла, Сөружи, гыйшык адәмнең күзен сукырайта. Нишләгәнеңне дә сизми калырсың. Гыйффәтенә кул сузган дуңгыз, гомерең буена күз-яшь түксәң дә, сине кызгана белмәс...» — дип кисәтә. Мондый шомлы сүзләр сәхнәдәге серлелекне тагын да көчәйтә... Сәхнәдә саф мәхәббәт янулары белән бергә әшәке мәкер, ирек даулаучы халык һәм хәйләкәр колонизаторларның провокацияләре — көчле бәрелешләр гәүдәләнә.

Халык тын да алмыйча бирелеп карый һәм күз алларында шушындый билгесез дөньяларны ачкан артистларга, режиссер Гомәр Девишевка рәхмәт алкышларын яудыра.

Берничә көннән соң, бу спектакль оешкан тамашачылар өчен уткәрелде. Ачык әйтергә кирәк, моңарчы театрга теләр-теләмәс кенә йөргән Казан тамашачылары театрны якын күрә башладылар.

Озак та утмәде, Әхмәт Тажетдин Рахманкуловның «Тигәнәк» исемле комедиясе куелды. Бу спектакльдә гел яшь артистлар гына катнашты. Җилкуар Мифтах ролендә Хәким Сәлимҗанов, Бәдерниса ролендә Фәрхия Тарханова, Шәйхелисламны Хәсән Катиев, староста ролендә Каюм Бариев һәм Хәлил ролендә Нәҗип Касыймовлар уйнады.

Сәхнәгә бер-бер артлы яңа әсәрләр менә торды. Шакир Шамильский постановкасында драматург Веналинның «Канлы чәчәкләр»исемле мелодрамасы (С. Җәләл тәрҗемәсе) куелды. Маркетанка кызны Фатыйма Ильская башкарды, тамашачылар алдында яңадан бер тапкыр дан казанды. Ильскаяның уйнавын Казандагы рус артистлары да килеп карыйлар һәм бик югары бәя бирәләр иде.

Фәтхи Бурнаш «Камали карт» комедиясен өлгертте. Баш рольдә — Камали карт булып — Бари Тарханов уйнады. Бари Тарханов бу рольдә зур уңыш казанды, әйтерсең, әсәр Бари Тарханов өчен махсус язылган диярсең иде.

Шулай ук «Трильби», Фәтхи Бурнашның «Камали карт», Н. В. Гогольнең «Ревизор» әсәрләрен дә халык яратты.

- Бу сезонда театр «Тамашачы» исемле айлык журнал чыгара башлады. Аның битләрендә постановкаларга рецензияләр, аерым артистлар турында иҗат портретлары, куелачак әсәрләр турында аңлатмалар, постановкалардан күренешләр һәм башкалар басыла иде. Бу журнал халыкны театрга якынайтуда бик зур роль уйнады. Яшь язучылардан Гадел Кутуй журналны чыгарышуда зур тырышлык курсәтте.

Сезон ахырына таба Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» әсәре куелды, художник Беньков аңа гаҗәеп декорацияләр, Салих Сәйдәшев өстәмә балет музыкалары («Шәрык балеты») язды, балетмейстер Юлий Муко һәм Зинаида Чарушиналар гүзәл биюләр әзерләделәр. Матур яңа киемнәр тегелде. Рольләр дә иң оста башкаручыларга бирелде. Таһир — Ситдыйк Айдаров, Зөһрә — Фатыйма Ильская, Гарәп — Камал II,

Хан — Зәйни Солтанов, ханча — Рауза Урмансовалар иде.

Бу сезонда тагын Һ. Такташның «Күмелгән кораллар», Г. Минскийның «Мансуровлар гаиләсе», К. Әмиринең «Тимер ага», Г. Кутуйның «Нәнкә жан», Ә. Рахманкуловның «Килмешәк», «Упкын» һәм «Боз астында дулкын», Г. Ильясовның «Сөембикә», С. Җәләлнең «Дим буе», Ф. Бурнашның «Адашкан кыз» һәм «Хөсәен мирза» исемле пьесалары куелды. Кыскасы, бу сезон бик бай репертуар белән һәм оешкан тамашачыларның театрга күп йөрүе белән билгеләнде.

## 1928—29 ЕЛГЫ СЕЗОН

Бу елгы сезонда Шакир Шамильский артист булып кына эшләргә теләде. Ә Гомәр Девишевны баш режиссер итеп билгеләделәр. Безне Галактионов урамындагы хәзерге Академия театры бинасына күчерделәр. Художник П. Беньков Урта Азиягә китте, аның урынына Г. Т. Сперанский эшли башлады. Тагын бер яңалык шул булды: артистлар белән тулы бер елга договор төзеделәр. Хәзер инде җәй көннәрендә дә артистлар тик ятмаска, гастрольләргә чыгарга тиешләр иде. Моңарчы даими хезмәт хакы күрмәгән артистлар өчен бу зур шатлык булды.

Фатыйма Ильская Мәскәүдә, Бари Тарханов та читтә булганлыктан, дирекция алар урынына Кырымнан Сара Байкина белән Җ. Байкинны чакыртып кайтарды. Хәлил Әбҗәлилов та Казанга килде. Нәүбәттәге режиссер итеп Сөләйман Вәлиев-Сульваны билгеләделәр. Ильяс Кудашев-Ашказарскийны, Фәхрия Кудашеваны һәм яшь артистлардан Әминә Милюшеваларны да театрга алдылар. Барлыгы 50 кешегә якын җыйналдык.

Беренче спектаклебез Шәриф Камалның «Ут» исемле драмасы булды. Әсәрнең баш герое Рәүф Моратовны Шакир Шамильский башкарды. Гомәр Саттаров ролендә Хәким Сәлимҗанов, Габдрахман Туйбековны Хәлил Әбҗәлилов, Искәндәр Туйбековны Габдрахман Камал II, Сәләхи Моратовны Касыйм Шамил, Галия Туйбекованы Рокыя Кушловская һәм Зәйнәп ролендә яшь артисткалардан Хәдичә Ихсанова уйнады. Спектакль алкышлар белән үтте.

Икенче спектаклебез итеп «Урман кызы» әсәре куелды. Яшь язучы Р. Яхин иҗат иткән бу әсәрдә Сәлим ролендәге Камал III дән калган башка рольләрне яшь артистлар башкарды. Хәсән Катиев, Зариф Закиров, Нәҗип Касыймов, Каюм Бариев, Гай Таһиров, Гомәр Исмәгыйлов, Газиз Зыятдинов, Бәкер Йосыпов, Закир Сафин, Нурия Кальметева, Хәдичә Ихсанова, Луиза Салигаскарова, Галимә Ибраһимова һәм Фатыйма Янбарисовалар уйнавында спектакль берничә тапкыр кабатланды.

Ул арада Тажи Гыйззәтнең «Наемщик» музыкаль драмасы өлгерде. Салих Сәйдәшев бу әсәр өчен искиткеч көйләр язды. Әсәрне сәхнәгә Вәлиев-Сульва куйды. Халыкның бу спектакльне карар өчен театрга ничек агылуын санап та, сөйләп тә бетерерлек түгел иде.

Батыржанны Ситдыйк Айдаров, Гөлйөземне Кушловская, Иманкул мулланы Зәйни Солтанов, Бикташны Габдулла Уральский, Әскәрне Габдрахман Камал II, Булат картны Хәлил Әбҗәлилов, Шәрифә бикәне Мәрьям Кугушева һәм Айсылуны Нәгыймә Таҗдаровалар аеруча яхшы башкардылар. Бу артистларның җырларын ишетеп, уйнауларын карап туймаслык иде. Әсәрне бер караган кешеләр дә кабат-кабат карамыйча булдыра алмадылар. «Наемщик» Тажи Гыйззәтнең ул заманда язган беренче музыкаль драмасы һәм иң яхшы әсәрләреннән булды.

Ә инде Салих Сәйдәшевнең ул драмада язган көйләре, нур өстенә нур булып, татар музыкасының алтын фондына кереп калды.

Салих Сәйдәшев турында сүз чыккач, аның тарафыннан шул ук елны язылган «Кызыл Армия маршы» турында да әйтмичә үтә алмыйм.

Салих Сәйдәшевнең театрда эшли торган урыны касса артында, минем администратор бүлмәсе белән янәшә, зур, шыксыз гына караңгы бер бүлмәдә иде. Ул анда, көндезләрен дә ут яндырган хәлдә, пианиносы артына утырып иҗат итә иде. Мин месткомнардан йөреп кайткач, бүлмәгә кереп эшкә тотынам, ул да клавишлар өстендә бармакларын уйната. Әледән-әле тынып тора... Уйлана булса кирәк. Шуннан ул минем кайтканны сизеп ала да стенаны кагып үз янына чакыра. Мин керәм. Тәмәке тартабыз, эшләр турында сөйләшәбез. Шунда ул миңа:

— Менә, Локман абый, тыңлап кара әле! — дип, яңа язган көенең бер өзеген уйнап күрсәтә. — Я, ничегрәк? — дип сорый. Мин үзем төшенгән кадәр бәя бирәм.

— Рәхмәт, — ди ул.

Бу маршның миңа аеруча ошаган бер урыны бар иде. «Менә бу җире бигрәк тә

көчле, йөрәкнең әллә кайсы урыннарына үтеп, тәэсирләндерә...» — дигәч, «Кайсы җире, кайсы? Бусымы?» — дип, кат-кат уйнап күрсәтеп, төпчи-төпчи, җентекләп сорый иде. Кайсыбер көннәрне исә, ул минем кайтканны сизеп ала да, маршның мин яраткан урынын юри уйнарга тотына. Нихәл итмәк кирәк, ихтыярымны җуеп, көйгә сихерләнеп, янына керергә мәҗбүр булам. Шуннан ул мине бүлмә буенча әле кызу, әле җай белән генә маршка атлатып йөртә. Шуның буенча көйнең ритмын билгели. Ачык әйтергә кирәк, мин бу маршка көне буенча атлап торырга да риза идем.

Композитор аны Кызыл Армиянең унбер еллыгына багышлап яза иде. Ниһаять, марш язылып бетте.

25 февральдә Академия театрында кызылармеецлар өчен тантаналы юбилей кичәсе уздырылды. Шул кичәдә ике гаскәри частьның 60—70 кешедән торган тынлы оркестры чыгыш ясады. Оркестр Кызыл Армиянең унбер еллыгына багышланган яңа маршны башкарганда, Салих Сәйдәшев үзе дирижерлык итте. Әсәр уйналып бетүгә, залдагы кызылармеецлар, аягүрә басып, композиторны бик озак алкышладылар. Салих Сәйдәшев тантаналы рәвештә бу маршын Кызыл Армиягә бүләк итте. Соңра, Казан гарнизонының приказы укылып, Салих Сәйдәшевкә «Почетлы кызылармеец» исеме бирелде һәм хәрби кием бүләк ителде.

Халык маршны яңадан кабатлауны сорап кул чапты. Бу юлы пульт янына хәрби оркестрның үз дирижеры басты. Музыкаль культурабызның алтын фондына кереп калган бу марш беренче тапкыр әнә шулай башкарылды.

Шушы ук елда Академия театрының зур гына бүлмәсендә татар театры музее ачылды. Артистлар кулларында булган афишаларны, фоторәсемнәрне, татар театры тарихына кагылышлы башка материалларны шушы музейга китереп тапшырдылар. Художниклар куелган постановкалардагы декорация макетларын, төрле эскизларны да куеп җибәргәч, бу бүлмә хәйран матур, тамашачыларны үзенә тартырлык күргәзмәгә әйләнеп китте. Антракт вакытларында бу музейга кереп, күзәтеп йөрү тамашачыларга гадәт булып керде.

Көннәрнең берендә Гомәр Девишев, Лавреневның Зәйни Солтанов тәрҗемә иткән «Разлом» пьесасын әзерләргә кереште. Татар театрында беренче мәртәбә әйләнмәле



*«Разлом» әсәрендә Ш. Шамильский — Годун.*

сәхнә эшләтелде. Художник Сперанский сәхнәдә диңгез корабле «Заря»ны күрсәтте. Бу постановкада рольләрдә генә утызга якын артист булу белән бергә, масса күренешләрендә 30—40 кеше катнашты. Матрослар булып театр техникумы укучылары уйнадылар. Спектакль искиткеч уңышлы чыкты. Матрос Годун ролендәге Шакир Шамильскийны танып хәл дә юк иде. Ул үз ролен шулкадәр көчле темперамент белән башкарды, аның ныклыгына, каһарманлыгына хәйран калырлык иде. Без чын мәгънәсендәге большевик образын сәхнәдә беренче тапкыр күрдек. Татар театры, гомумән, мондый героик пьесаны үз сәхнәсендә беренче тапкыр күрсәтә иде. Шул ук әсәр Зур театрда, рус сәхнәсендә дә булуга карамастан, безнең театрга да халык күп йөрде. Спектакльләргә тамашачылар, кызыл байраклар күтәреп, оркестрлар белән килгән көннәр дә булды. Әсәр беркөнне елга аръягы эшчеләренә күрсәтелсә, икенче көнне елга эшчеләре — грузчиклар, матрослар— өчен куелды. Алар да, шәһәрнең зур урамнары буйлап, кызыл байраклар күтәреп һәм музыкалар уйнап килделәр. Без, театр эшчеләре, аларны театр ишек төбенә чыгып, үз оркестрларыбыз белән, митинглар

ясап, речьләр сөйләп каршы ала торган булдык.

Мондый революцион-героик пьесаларның уңышы безнең яшь драматургларыбызны да рухландырып җибәрде. Гализв «Казан өчен көрәш» исемле героик пьесасын язып театрга китерде. Әсәр сәхнәгә куяр өчен бик кыен язылганлыктан, театрга зур әзләнүләр ясарга туры килде. Бу эшкә режиссер Вәлиев-Сульва алынды һәм бик уңышлы башкарып чыкты. Бу постановкада сәхнә белән тамаша залы бергә кушылды. Чөнки әсәр тамашачы халыкның да катнашы белән барырга тиеш иде. Тамаша залыннан сәхнәгә гаскәр үтү дисеңме, карап утыручыларның сәхнәгә менеп сөйләүләре дисеңме — моңарчы күренмәгән яңалыкларның барысы да эшләнде. Бу постановкада хәтта Мулланур Вахитов образын башкаручы артист Габдрахман Камал II нче, мотоциклга утырып, тамаша залыннан сәхнәгә килеп керде.

Бу спектакльгә дә культпоходлар оештырылды. Мондый героик пьесаларны сәхнәгә куюда, ихтимал, беркадәр сәхнә кануннарыннан читкә чыгулар да булгандыр. Ни генә булмасын, алар үзләрен акладылар. Революцион героика белән массаның да кызыксынуын ачык күрсәттеләр.

Бу сезонда «Галиябану»да Гомәр Девишев тарафыннан яңача куелды. Әсәр өчен Салих Сәйдәшев яңа увертюра язды. Шуның өстенә композитор музыка дөньясында беренче мәртәбә симфоник оркестрга гади гармонь катнаштырып уйнатты. Бу яңа иҗади тәҗрибә зур алкышлар белән каршы алынды. «Зәңгәр шәл», «Аршин мал алан», «Энҗекәй белән Юлдыкай» кебек музыкаль әсәрләр дә кабатланды.

Кышкы сезон уңышлы тәмамланса да, театр дирекциясе артистларны җәйгә үзендә эшләтү мөмкинлегенә ирешә алмады. Артистлар белән договор сентябрьгә кадәр төзелгән булса да, җәйге гастрольләр мәсьәләсе хәл ителмәгән, районнар, чит шәһәрләр белән договорлар төзелмәгән иде. Театрның сәхнәгә куйган әсәрләре барысы да зур күләмле булып, аларны районнарга яки башка шәһәрләргә алып чыгу мөмкин түгел иде. Шуннан Мәгариф Халык Комиссары, академцентр вәкиле, профсоюз җитәкчеләре белән берлектә, театрның зур җыелышы үткәрелде. Артистларны я гастрольгә алып чыгарга яки, эшләмәсәләр дә, аларга биш айга хезмәт хакы түләргә кирәк иде. Кайнар бәхәсләрдән соң, артистлар коллективы исеменнән Ш. Шамильский һәм З. Солтановлар чыгыш ясадылар. «Безгә апрель аена һәм май аена хезмәт хакын тулысынча түләсәгез, калган дүрт ай өчен бернәрсә дә таләп итмибез. Договорны өзелгән дип хисаплап, шуңа риза булабыз», дигән тәкъдим керттеләр. Театр дирекциясе дә, хөкүмәт кешеләре дә, артистларның мондый олы җанлылык күрсәтүләрен көтмәгән иде. Алар коллективның бу тәкъдимен яхшы дип таптылар.

Без Өммегөлсем Болгарская, Рокыя Кушловская, Мәрьям Кугушева, Салих Сәйдәшев, Ситдыйк Айдаров, Хәлил Әбҗәлилов, Мәҗит Илдар, Исмәгыйль Кугушев, Габдулла Сәгыйтов һәм Гомәр Девишев (режиссер)лар составында бригада төзеп, Астраханьга төшеп менәргә уйладык.

Мин алдан китеп, Астраханьның «Вулкан» театрын ике көнгә, шәһәр театрын бер көнгә килешеп, афишалар чыгарып, әзерләнеп куйдым. Берничә көннән билгеләнгән артистларның барысы да Астраханьга килеп төштеләр. Салих Сәйдәшев шәһәрдәге симфоник оркестр белән репетицияләр башлады. Майның 20 нче числосында «Вулкан» театры халык белән шыгрым тулды. «Зәңгәр шәл» мелодрамасын куйдык. Берничә көннән тагы шул ук постановканы кабатлап, «Энҗекәй белән Юлдыкай» әсәренә әзерләк башладык. Бәйрәм вакыты иде, безнең артистларны халык бик зур кунак итте. Өч кенә спектакль бирсәк тә, бу шәһәрдә ике атна яшәргә туры килде.

## ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ГАСТРОЛЬЛӘРЕ

Мин берничә ел Казан зур драма театрында эшләгәннән соң, 1933 елның январенда яңадан татар театрына кайттым. Репертуар бик чуарланган иде. Тамашачыларны оештыру мәсьәләсе дә шактый кактыгшаган булып чыкты.

Бу эшне җайга салу өчен, профсоюзларга таяндым. Көн-төн чаба торгач, февраль аеның беренче яртысына тамашачылар ярыйсы йөри башлады. Шәриф ага Камалның «Козгыннар оясында» премьерасында халык агруча күп булды. Аннан соң куелган «Отелло» постановкасы да, шулай ук, берничә тапкыр уйналды. Отелло ролен Мохтар Мутин белән Шакир Шамильский нәүбәтләшеп уйнадылар. Минем карашымча, Ш. Шамильский Мутиннан калышмады.

Озак та үтмәде, «Наемщик» куела башлады, М. Горькийның «Тормыш төбендә»сен әзерләп өлгерттеләр. Минем эшләр тиешле эзгә төште. Иркенләп тын ала башладык.

Ул арада булмады. «Ил», «Кандыр буе» өлгерде, «Зәңгәр шәл» кабатланды. Шулай итеп апрельнең яртысына килеп җиттек тә, сезонны уңышлы гына тәмамлап, Бакуга, Ташкентка гастрольгә китәргә әзерләнә башладык. Бу — Татар дәүләт академия театрының беренче гастрольләре иде. Гастрольгә «Отелло», «Тормыш төбендә», «Наемщик», «Зәңгәр шәл», «Кандыр буе», «Ил» һәм «Козгыннар оясында» спектакльләрен алып барырга булдык. Гастрольләрнең җаваплы җитәкчесе Сөләйман Вәлиев-Сульва, режиссер Риза Ишморатов иде.

Бакуга, Астрахань аша, составны өч төркемгә бүлеп, пароходларда алып барырга булдык. Беренче май көнне беренче төркемне үзем белән алып киттем. Сигезенче май көнне Бакуга барып төштек. Әзербәйҗан җәмәгатьчелеге безне бик зурлап каршы алды. Эшләребез өчен төп база итеп, Әзербәйҗан драма театры бинасын бирделәр. Безнең группа белән килгән Салих Сәйдәшев симфоник оркестр белән репетицияләр башлады. Башта берничә спектакльне шушы драма театры бинасында куеп, аннан нефть районнарындагы культура сарайларында уйный башладык. Тамашачыларны профсоюзлар аша оештырганлыктан, спектакльләребез һәркайчан зал тулы халык белән үтте. Бакуда ай ярым торып, барлыгы кырык спектакль үткәрдек. Шуларның утызы оешкан тамашачы өчен булды. Калган унысы гына театрларда, бакчаларда билет сату юлы белән узды. Алары да аншлаг белән үтте. Бакуда татар эшчеләре дә бик күп яши икән. Урыннарда үзешчән драма түгәрәкләре дә шактый күп иде. Алар һәркайчан диярлек безнең янда булдылар, бездән сәхнә әсәрләре сорадылар, сәхнә белеме буенча киңәшләр алдылар. Бигрәк тә Салих Сәйдәшевне күрергә теләүчеләр гадәттән тыш күп булды. Спектакль алдыннан булсын, соңыннан булсын, аны һәркайда сырып алалар, чәчәкләр бүләк итәләр, автографын сорыйлар иде.

Эшләребез шулай гөрләп барганда, күңелебезгә бик авыр һәм зур кайгы китергән хәбәр ишеттек. Татар театрының атасы, классик драматург Галиәсгар Камалның кисәк үлүе турында хәбәр алдык. Шул көнне үк, Әзербәйҗан язучылары белән берлектә, театрда олы драматургны искә алу митингысы уздырылды. Казанга кайгы белдереп телеграммалар сугылды. Әзербәйҗанда да Галиәсгар Камалны бик яхшы беләләр икән. Атаклы трагик Араблинскийның «Бәхетсез егет» драмасын үзе тәрҗемә итеп, Закир ролен үзе башкаруын сөйләделәр. Бу әсәр Әзербәйҗан сәхнәсендә бик күп тапкырлар уйналган. Кызганычка каршы, без бу гастрольләргә Галиәсгар ага Камалның бер генә булса да әсәрен алып чыкмаган идек. Бу бик зур үкенеч булды...

Китәр көннәр якынлаша башлады. Бер кичне Әзербәйҗан хөкүмәте җитәкчеләре, татар һәм әзербәйҗан артистларының, язучыларының зур очрашу мәҗлесен үткәрделәр. Һәр яктан матур-матур чыгышлар ясалды. Безнең коллективка котлау язулары һәм бүләкләр тапшырылды. Дуслык мәҗлесе таң атканчы дәвам итте. Шуннан безне Ташкентка озаттылар. Озатырга пристаньга төшүчеләрнең исәбе дә, хисабы да юк иде. Каюталарыбыз чәчәкләргә күмелде. Дебаркадерда музыка уйнап торды. Ниһаять, диңгез корабленә кузгалырга сигнал бирелде. Барлык артистлар палубага чыгып, Салих Сәйдәшевнең «Без кабызган утлар»ын җырлап җибәрделәр. Корабль кузгала башлау белән, дебаркадердагы оркестр «Кызыл Армия маршы»н уйнады. Эшләпәләр, яулыклар болгау, саубуллашу, музыка тавышлары астында корабль Красноводскига таба юл тотты...

Мин, аякларым сызлап авыру сәбәпле, Казанга кайтып китәргә мәҗбүр булдым.

Казанга кайтып дәваланганнан соң, яңа гына оештырылган эстрада-концерт оешмасына директор итеп билгеләделәр.

...1935 елның август башы иде. Академия театрының яңа директоры Абдуллин миңа сәхнәләрне, фойеларны күрсәтеп чыкты да:

— Сезонны ачарга бер ай вакыт калган, ничек итсәң ит, барысын да рәткә керт күр, — дип, мине кабат Академия театрына чакырды. Мин ремонтка акча һәм материаллар сорый башладым. Складта акбур белән алебастрдан башка берни дә юк иде. Смета күптән төзелеп бирелгән булса да, шушы көнгә кадәр каралмаган икән! Нишләмәк кирәк, кирәкле җирләргә чабарга тотындык. Буяучылар, штукатурчылар табып эшкә куштык. Театрга даими йөри торган абонемент билетлар эшләтеп, аларны профсоюзлар аша сатарга керештек (болар «Ударниклар билеты» дип атала иде). Алардан җыелган беркадәр акчаны ремонт расходларына тота башладык. Театрның буфетын ашханәләр трестына арендага биреп, театрда артистлар өчен ашханә булдырырга договор төзедек. Отпускадан кайткан артистлар, хезмәт хакы исәбенә, талон белән, театрның үзендә туклана башладылар. Күп тырыша торгач, ре-

монт тәмамланды, театр эш башларга әзер булды.

15 сентябрьдә сезонны ачып җибәрдек. Ләкин бу елгы сезон репертуарында әллә ни яңа әсәрләр юк иде. Шулай да, «Ударниклар билеты»ның алдан сатылган булуы, аның өстенә, профсоюзлар аркылы оешкан тамашачыларга ябык спектакльләр куюю театрны материаль кытлыктан коткарды.

Зәйни Солтанов атаклы немец язучысы Вольфның «Профессор Мамлюк» исемле әсәрен тәрҗемә итте. Бу әсәр режиссер Гомәр Исмәгыйлов тарафыннан сәхнәгә куелды. Нәкъ менә шушы вакытта әсәрнең авторы Вольф та Казанда иде. Спектакль халыкка бик ошады. Профессор Мамлюк ролен Хәлил Әбҗәлилов башкарды. Фридрих Вольф баш рольне башкаручыга һәм башка артистларга үзенең рәхмәтләрен белдерде. Немец халкының прогрессив язучысы Вольфны сәхнә алдына чыгарып, көчле алкышларга күмделәр. Икенче көнне, авторның үзен чакырып, постановканы тикшерү үткәрелде. Автор артистларның уеннарына зур бәя бирде.

Бу сезонда Кәрим Тинчурин үзенең «Казан сөлгесе»нә бик күп яңалыклар өстәп сәхнәгә куйды. Комедиянең бер күренеше ат абзарында бара иде. Арткы планда атларның арт саннары һәм койрыклары биепселкенеп торды. «Балет»та ат караучы дүрт егет агач атларга атланып биеделәр. Ләкин мондый ясалма эффектлар әсәрнең идеяэчтәлеген баета алмады. Кыскасы, Татар дәүләт академия театрының бу елгы сезоны зур кыенлыклар эчендә узды. Шакир Шамильскийны да Бакуга чакыртып алдылар. Ул шул китүеннән 1937 елның көзенә кадәр Казанга кайтмады. Танылган артистлардан Бари Тарханов, Камал I, Камал II һәм Рокыя Кушловскаялар да бу елларда төп йортта күренмәделәр. Директорлар да, режиссерлар да әледән-әле алмашынып кына торды.

Ә тамашачылар үзләренә якын торган, чын мәгънәсендә халык сорауларына җавап бирә алган театрны күрергә теләделәр. Дөрес, бу елларда пролеткультчылар һәм сәнгать өлкәсендәге «Сулфчылар», «Сәнгать — массага!» дигән лозунг астында, әдәбиятка һәм сәнгатькә үзләренчә реформа кертергә маташып йөрделәр. Алар артык «суллашып» китеп, пролетариатның «үз культурасын» өр-яңадан тудырмакчы булдылар. Иске культура мирасыннан файдаланмаска, аны җимерергә теләделәр. Ләкин мондый «өр-яңа формалар» чыкылдап торган формализмга гына китерде — алар халыктан ераклашты — киң масса мондый «формаларны» аңларга да теләмәде, кабул да итмәде.

## ТАТАР ДӘҮЛӘТ КҮЧМӘ ТЕАТРЫ

Бу елларда Әсгат Мәҗитов җитәкчелегендә театр техникумын тәмамлаган яшьләрдән төзелгән «Татар дәүләт эшче художество театры» эшли иде. Аның төп бинасы элекэге «Печән базары» чатында, атаклы «Көфер почмагы» өстендә — мәчеттә иде. Мине шул театрга директор урынбасары итеп билгеләделәр.

Театрны күчмә итәргә, районнарда эшләтергә кирәк дигән тәкъдим керттек. Коллективта да, театр идарәсендә дә, тәкъдимне хуплап каршы алдылар. Шуннан театрга «Татар күчмә эшче театры» дигән исем бирелде. Озак та үтми, Зеленодольскига барып, «Париж коммунасы» исемендәге клуб белән 15 көнгә килешү ясадык. Шәһәрдәге заводларның завкомнары белән сөйләшеп, фәкать шул заводларның эшчеләре өчен генә ябык спектакльләр бирергә договор төзелде. Июнь аеның башында беренче спектаклебез «Шатлык җыры»н (Гадел Кутуй әсәре) куеп җибәрдек. Халыкка ошады. Икенче спектакль Әсгат Мәҗитнең «Гармонь сөйләр» пьесасы иде. Аны да яхшы каршы алдылар. Аннары Лопатинога (хәзерге Волжск шәһәре) барып, ике спектакль куеп кайттык. Безне һаман да Зеленодольскидан җибәрмәделәр. Бу шәһәрдә бер ай торып, 25 спектакль күрсәтеп, театрның материаль ягын шактый ныгыттык. Аннан Казанга кайттык та Кукмарага юл тоттык. Кукмарада ике генә атна торырга исәп иткән идек, күрше-тирә авыллардан да халык күп килә башлагач, озаграк калырга һәм 14—15 спектакль күрсәтергә туры килде. Әгерҗе ягындагы авылларда, Ижевск шәһәрендә куелган спектакльләргә дә тамашачылар күп йөрде. Спектакльләребезнең уңышлы үтүе турында «Ленин юлы» газетасында (1936 ел, 15 нче июль, № 65) мәкалә дә басылып чыкты.

## ТЕАТРНЫҢ БЕРНИЧӘ КОНЦЕРТ БИРҮЕН СОРЫЙБЫЗ

*Без, стахановчы эшчеләр, алдынгы актив яшьләр, Татар дәүләт эшче художество театрының постановкаларын карадык. Театрның барлык постановкалары да безгә бик яхшы, онытылмаслык тәэсир калдырды.*

*Шуның белән бергә, театрның берничә көнгә Ижевскида калуын һәм тагы берничә концерт бирүен сорыйбыз.*

М. Гарифуллин, Габдюков, Балтачев, Абитов һәм башкалар.

Менә икенче бер мәкалә:

### РӘХМӘТ ЭШЧЕ ТЕАТРЫНА

*Татарстан республикасының сәнгать эшләре комитеты заданиесе буенча татар эшчеләренә культура-художество хезмәте күрсәтү өчен Удмурдстанга килгән Татар дәүләт эшче художество театры Ува урман пунктында булды.*

*Кыска гына вакыт эчендә театр мең дә ике йөздән артык кешегә хезмәт күрсәтте. Урман эшчеләре театрның өч постановкасын: Әсгат Мәҗитовның «Гармочь сөйләр»ен һәм ике спектакль-концертын карадылар.*

*Артистлар җәмәгать эше тәртибендә радио аша 2 радиоконцерт бирделәр.*

*Театрның постановкалары уңыш белән үттеләр. Артистлар, онытылмаслык образлар тудырып, үзләренең рольләрен яхшы башкардылар. Бигрәк тә артисткалар: Позднякова, Карамышова, Зарипова, Гобәйдуллина иптәшләр һәм артист Халитов, Гафуров, Салихов, Гыйльманов, Сәгыйтов һәм гармунчы Җәмлиханов иптәшләр аеруча яхшы тәэсир калдырдылар.*

*Без, эшче-стахановчылар, Ува урман пунктындагы барлык татар эшчеләре исеменнән, югары художестволы постановкалар күрсәткәннәре өчен театрның бөтен коллективына матбугат аша үзебезнең пролетар рәхмәтебезне белдерәбез.*

*Урман пунктларында театрның гастрольләрен оештыруда конкрет булышлык күрсәтүләре өчен Татарстан республикасының сәнгать эшләре комитетына һәм Удмурдстан республикасының урман һәм сал агызу эшчеләре союзының Өлкә комитетына рәхмәт әйтәбез.*

Эшче-стахановчылар: З. Әхмәтҗанов, Ә. Гыйльманов, Дини, Шәрәфетдинов, Г. Гыйлаҗетдинов.

Бу чыгуда без 100 гә якын спектакль-концертлар үткәрдек, 30 меңнән артык халыкка хезмәт күрсәтеп кайттык.

Казанга кайтып артистларга отпуск биргәч, «мәчет»не театр хәленә китерү эшенә, ремонтка керештек. Мәчет күршесендәге ике магазинны безгә бирделәр. Аларга стеналар тишеп, аскы катта фойелар һәм баш-



*«Каюм Насыйри» әсәрендә мөфти ролендә Таҗи Гыйззәт.*

ка урыннар эшләттек. Театр тәмам матурланып, ял итү урынына әйләнеп китте.

Октябрь аеның ахырында «Дәвамы булачак...» исемле тәрҗемә әсәр белән кышкы сезоныбызны ачтык. Халык театрны үз итә башлады. Аннан соң Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» драмасы куелды. Кручининаны Нурия Кальметева, Низамовны Фоат Халитов, Шмаганы Габдрахман Мамай аеруча яхшы башкардылар.

Гадел Кутуйның «Шатлык җыры» аеруча күп уйналган әсәр булды һәм бу пьеса театрның сәхнәдән төшми торган капиталь әсәре булып китте...

...1937 елны Татар дәүләт филармониясе эшли башлады. Мине шул филармония каршында татар җыр һәм бию ансамбленең администраторы итеп эшкә чакырдылар. Анда мин Бөек Ватан сугышы тәмамланганчы диярлек эшләдем. Аннан инде Татар дәүләт академия театрында артист булып эшкә керештем. Сәхнәдән озак еллар аерылып торганнан соң, минем беренче башкарган ролем «Банкрот» комедиясендә Камали бай булды. Аннары «Чаткылар»да пристав ролен, «Хуҗа Насретдин»да Ахунны, «Изге аманәт»тә Панас карт, «Каюм Насыйри»да

Йосыф мулла рольләрен уйнадым. Сүз уңаенда шунысын да әйтергә кирәк: М. Гали һәм Х. Уразиковларның «Каюм Насыйри» драмасында мөфти мирза ролен атаклы драматург Таҗи Гыйззәт башкарды.

Татар дәүләт академия театрының бу чордагы торышы: репертуары да, уйнаган артистлар да, куелган әсәрләрнең авторлары да — хәзерге буын кешеләренә яхшы таныш. Шуңа күрә мин аларга тукталып тормыйм. Артистлар да, режиссерлар да, язучылар да күбесе арабызда яшиләр, иҗат итәләр.

Әмма югалтулар да булмады түгел. Җиденче май көнне, инде менә сугыш бетте, Берлин безнең гаскәрләр тарафыннан алынды, дигән көнне генә халкыбызның иң талантлы улларыннан берсе Шакир Шамильский арабыздан китте... Җиңү көннәрендә шатлыкка чумган күңелләребезнең бер чите кителде. Кече яшьтән бергә укып, бергә уйнап үскән, иң якын дустымнан аерылу минем өчен бигрәк тә аянычлы иде. Мин берничә көннәр үземне-үзем белешмичә йөрдем...

Минем өчен бик тә якын булган икенче бер кешенең — Салих Сәйдәшевнең үлеме бөтен культура җәмәгатьчелеге, бөтен татар халкы өчен зур югалту булды. Аның белән бергә эшләгән вакытларны, бергәләп гастрольгә йөрүләрне һич тә онытасым юк...

Кырыгынчы елларның ахырында миңа кабат Татар җыр һәм бию ансамблендә эшләргә туры килде.

Салих Сәйдәшевне Урал, Урта Азия якларына алып чыгу, андагы тугандаш халыкларга популяр композиторны күрсәтеп кайту — күптәнге хыялым иде. 1948 елның җәендә, ансамбль белән Советлар Союзының 33 шәһәрендә йөздән артык концерт биреп кайткач, Салих дускайны, аның гомер юлдашы Асия ханымны күрергә ашыктым. Салихка да, Асия ханымга да минем фикер бик ошады. Шунда ук филармония директорына шалтыраттык. Ул да безнең фикерне хуплап каршы алды. Шуннан җиде кешедән торган бригада төзәргә карар бирелде. Составка Салих Сәйдәшевнең үзе, иптәше Асия ханым (бригаданың җаваплы кассиры һәм хисапчысы), программаны алып баручы — нәфис сүз остасы артист Мәҗит Илдар, җырчылардан — Әсма ханым Шаһиморатова белән Рәшит Ваһапов һәм атаклы гармоньчы Фәйзи Биккининнар кертелде. Язучыбыз Нәкый Исәнбәт концерт алдыннан сөйләү өчен «Татарстаннан сәлам» исемле шигырь язып бирүне өстенә алды. Репертуар сайланды, маршрут билгеләнде, зур әзерлек башланды. Барасы шәһәрләрдәге оркестрларны әзерләү өчен мине алдан җибәрделәр. Уфага киттем. Анда опера театры эшләми — отпускада, театр бинасына ремонт бара иде. Ләкин, Салих Сәйдәшевнең Уфага килү теләген ишетү белән, бөтен Уфа халкы гөр килде, оркестрантларның да күбесе шәһәрдә иделәр һәм алар, отпускада булуларына да карамастан, җыелырга, Салих Сәйдәшевнең үз дирижерлыгында уйнарга ризалыкларын белдерделәр. Шулай итеп кырык кешедән торган симфоник оркестр оешты. Дүрт-биш көннән Салих Сәйдәшев белән артистлар да Уфага килеп төштеләр. Аларны каршы алыр өчен Уфа вокзалына Башкортстанның композиторлары, язучылары, артистлары һәм журналистлары төште. Салих Сәйдәшевнең һәм башка артистларның вагоннан чыгулары булды, аларны чәчәкләргә күмделәр. Күрешү, исәнләшү китте.

Ике көн оркестр белән репетиция үткәреп, өченче көнне Уфаның рус театры бинасында Салих Сәйдәшев иҗатына багышланган концертларны башлап җибәрдек. Сәхнә алдына Мәҗит Илдар чыгып «Татарстаннан сәлам!» әсәрен укыды. Шигырь халыкка бик ошады. Шуннан пәрдә ачылып китте. Музыкантлар алдына Салих Сәйдәшев чыгып басты һәм халыкка баш иде. Тамашачылар, аны күрү белән, дәррәү күтәрелеп кул чаба башладылар. Салих Сәйдәшевне хөрмәтләү берничә минутка сузылды. Шуннан композиторның «Кантата»сы уйналды. Илдар икенче номерны игълан итмәкче, ләкин халык «Кантата»ны икенче тапкыр кабатлауны сорый. Башка номерларның да шулай кабатланулары бик күп булды. «Галиябану» драмасына язылган увертюра халыкка аеруча ошады. Яшь җырчы Рәшит Ваһаповның да беренче тапкыр оркестрга кушылып җырлавы иде. Шуңа күрә ул, сәхнәгә чыгар алдыннан, бераз борчылып алды. Сәйдәшев аны: «Син анда минем таякка гына карап тор!» — дип тынычландырды. Салих Сәйдәшевнең тылсымлы таягы яшь җырчыга көч, ихтыяр бирде: ул гаҗәеп көчле һәм матур җырлады. Рәшит Ваһапов белән Әсма Шаһиморатованың парлап җырлаулары да бик уңышлы чыкты. Аларны халык кат-кат сәхнәгә чыгарып алкышлады. Концертның ахыры композиторның «Кызыл Армия маршы» белән тәмамланды. Салих Сәйдәшевне, гомумән сәхнәне, чәчәкләргә күмделәр. Икенче көнне

безнең барыбызны да редакциягә чакырдылар. Анда язучылар белән композиторларның очрашу мәҗлесе уздырылды. Рәсемнәргә төшерделәр. Назар Нәҗминең «Кызыл Башкортстан» газетасында чыккан мәкаләсендә шундый җөмләләр бар иде: «Бу көннәрдә Салих Сәйдәшев Казаннан Уфага килде. Ләкин аның җырлары моннан күп еллар элек үк Уфага килгәннәр иде инде. Бәлки, Салих Сәйдәшев Башкортстанның бер генә авылында да һәм башка калаларында да булмагандыр, ләкин Сәйдәш җыр булып бөтен авылда да, калада да яши...»

Икенче концерт та шул ук Рус драма театрында үткәрелде.

Өченче концертыбыз, Черниковск эшчеләр районында, кечкенә генә сәхнәдә, оркестрдан башка гына үткәрелде. Салих Сәйдәшевкә рояльдә күп уйнарга туры килде. Композиторның маңгаеннан кара тир акканчы уйнаттылар. Әмма ул иренмәде, халык ни сорады — барысын да уйнады. Җырчылар да программага кермәгән әсәрләрне дә җырладылар.

Уфада биш көн торып, өч концерт биргәч, Оренбургка киттек.

Мин Оренбургка бер көн алдан килгән идем. Яшь вакытында Салих Сәйдәшев шушы шәһәрдә укыган, үзе музыка мәктәбендә укыткан кеше булганлыктан, аның даны биредә бик югары иде. Ләкин биредә дә оркестр мәсьәләсе кыен булып чыкты: музыкантларның күбесе ялда, калганнары җиде-сигез генә кеше иде. С. Сәйдәшев оркестр юк дип, таныш шәһәрдә концертын күрсәтмичә китәргә уңайсызланды. Филармониянең концерт залында рояльдә генә башкарып ике концерт бирергә туры килде. Концертлар биредә дә бик яхшы үтте. Халыкның кат-кат соравы нәтиҗәсендә, композитор хәзинәдә бар көйләрен барсын да уйнады.

Ташкентка киттек. Анда филармония бинасында ике, иске шәһәрдәге яшь тамашачылар театрында ике концерт үткәрергә договорлар төзегәннән соң, алтмыш кешелек оркестр белән репетицияләр башланды. Концертларга халык гаҗәп дәрәҗәдә күп җыелды. Мондый зур оркестр башкаруында шундый популяр композиторның көйләрен ишетү Ташкент халкы өчен зур вакыйга булды. «Галиябану» увертюрасын, «Кызыл Армия маршын», гадәттәгечә, кат-кат уйнарга мәҗбүр иттеләр. Фәйзи Биккининның гармоньда уйнавы, Рәшит Ваһапов, Әсма Шаһиморатоваларның җырлары тамашачыларга зур тәэсир ясады. Салих Сәйдәшев үзе дә Ташкент оркестрындагы уйнаучылардан бик канәгать калды. «Мондый оркестрантлар белән эш итү — ул үзе бер гомер!» — дип аларны күккә күтәреп мактады.

Алма-Атада безне композиторлар Латыйф Хәмиди һәм Жубанов иптәшләр каршы алырга төштеләр. Бу вакытта опера театры үзе эш башлаган иде, аның оркестры белән тулысынча файдаланып булмады. Радиокомитетның утыз кешелек оркестрына опера̀дан берничә кеше өстәп, кырык кешелек состав белән, Сәйдәшев репетицияләргә тотынды. Концерт гадәттән тыш күтәренкелек белән узды. Беренче бүлек программасына Салих Сәйдәшевнең симфоник оркестр өчен язган әсәрләре кергән иде. Икенче бүлектә җырчыларыбыз, музыкантларыбыз чыкты. Һәр номер тәлгән саен, аларны кабатлаттылар. Алкышларга, антракт араларында сәхнә артына кереп котлауларга, тәбрикләүләргә чик булмады.

Икенче концертыбызны радио аша трансляция ясадылар. Икенче көнне Казагыстан консерваториясенең директоры Жубанов һәм композитор Латыйф Хәмиди безне мәҗлескә чакырдылар. Биредә бездән башка тагы унлап кунак, язучылар, композиторлар җыелган иде. Салих Сәйдәшев һәм казакъ композиторлары рояльдә үз әсәрләрен уйнап күрсәттеләр. Артистлар, артисткалар үз телләрендә җырлар җырладылар.

Өстәлдә алмалар бик күп иде. Салих Сәйдәшев бу алмаларны мактый-мактый ашады. «Карасана, бу алмаларны! Чыннан да, Алма-Атада алмаларның аталары үсә икән!» — диде.

Профессор Жубанов: «Әйе, Алма-Ата алмалары Мәскәүдә дә зур дан алдылар. Мәскәүнең 800 еллык бәйрәменә безнең Алма-Ата бүләк итеп алма илтте. Әмма алар гади алмалар түгел иде! Ул алмалар сигез йөз данә һәм һәркайсы берәр килолы булырга тиеш иде. Һәм безнең оста бакчачыларыбыз шундый алмаларны үстерделәр», — диде.

Бу алмалар хакында сөйләшү бушка китмәде.

Шулай Салихның гостиницадагы бүлмәсендә сөйләшеп утыра идек, рөхсәт сорап, бер таза гына кеше килеп керде. Күрешкәннән соң, көлемсерәп кенә: «Совхоздан сезгә күчтәнәчләр җибәргәннәр иде. Шуларны кайда бушатыйк икән?» — диде. Без беркадәр аптырап калдык. «Нинди күчтә-



*Салих Сәйдәшев һәм Локман Аитов. 1954 ел, 1 нче Май.*

нәч?» — дип сорадык. Теге кеше: «Сез безне яхшы, матур концертлар белән сыйладыгыз, шуның өчен совхоз эшчеләре сезне тәмле алмалар белән сыйларга уйлады», — дип җавап бирде.

Без бу алмаларның шактыен Казанга да күчтәнәч итеп алып кайттык.

Бу көннәрдә Алма-Атада профсоюзларның өлкә конференциясе үткәрелде. Безне делегатлар алдында чыгыш ясарга чакырдылар. Шул ук филармония залында, казакъ артистларының да катнашлары белән, делегатлар өчен зур концерт үткәрдек. Халык шулкадәр күп булды, хәтта залда басып караучылар да бар иде.

Салих Сәйдәшев бу йөрүләрдән бик канәгать булды.

Безнең гастрольләр турында Алма-Ата газеталарында мактаулы мәкаләләр басылып чыкты.

### ЙОМГАК

Шушы рәвештә, төрле шәһәрләрдә, төрле театрларда, төрле клубларда 55 ел буена эшләп килеп, яшемнең 70 тән ашып киткәнен сизми дә калганмын. Хәер, искә төшерделәр: 1961 елның 7 апрелендә — туган көнемдә — Бөтен Россия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге, Казан театр җәмәгатьчелеге Артистлар йортында минем юбилеемне билгеләп үттеләр. Бу кичәгә мине хөрмәт итүче якын иптәшләрем, дусларым һәм туганнарым бик күп җыелган иде. Театрлардан, төрле оешмалардан адреслар, бүләкләр дә бик күп булды. Төрле шәһәрләрдәге иптәшләремнән, туганнарымнан котлау телеграммалары алдым. Кичәнең художество бүлегендә үзем дә катнашып, моннан 40—50 ел элек уйнаган образларны хәтерәмә төшердем. Моннан 55 ел элек, укытучымның: «Мөгаен, син артист булырсың!» дигән сүзе, әтиемнең: «Гомерегез кәмитче булып үтсен!» дигән теләге дә дөреска чыкты. Ләкин гомеремнең «кәмитчелектә» үтүенә мин аз гына да үкенмим. Культурабызның көннән-көн чәчәк атуын, халкыбызның сәхнәгә булган мәхәббәте үсүен күреп куанам. Үз халкыңа, үз илеңә, партиягә ярты гасыр хезмәт итә алудан да куанычлырак нәрсә булуы мөмкин! Советлар хөкүмәте минем бу хезмәтләремне тәкъдир итеп, картлыгымдагы тормышымны бәхет белән урады — персональ пенсия белән тәэмин итте, Октябрьның 50 еллыгына «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале белән бүләкләде. Миңа карата булган ихтирам өчен, Советлар хөкүмәтенә, Коммунистлар партиясенә чын күңелемнән рәхмәтләремне белдерәм.

# Яңа китаплар

### Нурихан Фәттах

## ЯШЬ ЧАКЛАРДА

Бәясе 25 тиен

«Сезнеңчә ничек?», «Бала күңеле далада» романнары һәм күп санлы матур-матур хикәяләр авторы Нурихан Фәттахның «Яшь чакларда» исемле бу җыентыгында «Әттә», «Сәйдәш маршы», «Гарифҗан абзый», «Бер тамчы күз яше», «Мәдинә», «Ләйлә», «Дачада» дип аталган хикәяләре һәм




«Серле капчык», «Тәнкыйтьче», «Тамак шеште», «Бала хәсрәте», «Бухгалтер мәхәббәте», «Шифалы дару», «Яшь чакларда» исемле юмористик парчалары тупланган.

### Нури Арсланов

## НУРИЯ

*Шигырьләр җыентыгы*

Бәясе 11 тиен

Бу җыентыкка авторның кече яшьтәге мәктәп балаларына багышланган шигырьләре тупланган. Шигырьләрдә нәни дусларыбызның укулары, ял вакытларын күңелле итеп уздырулары, үзара мөнәсәбәтләре тасвирланган. Бу китапка шагыйрьнең төрле милләт халыклары әкиятләренә нигезләнеп язылган шигырьләре дә кертелгән.







### Нәби Дәүли

## МИНЕМ ТАНЫШЛАРЫМ

*Хикәяләр, памфлетлар*

Бәясе 32 тиен

Шагыйрь һәм прозаик Нәби Дәүлинең бу җыентыгында «Сихерле утлар», «Тол хатын мәхәббәте», «Үч алу», «Минем кадерле әбием», «Мин дә гаепле», «Нинди бал тәмле була», «Бозбаш», «Ревизор шәүләсе», «Итекче», «Исемсез кеше», «Төлке тиресе», «Җир астында калган машина», «Кемне кунакка чакырырга?», «Кайда яши кысла?», «Хатын сүзен тыңлап», «Өч кирпеч», «Кешене көләргә өйрәтегез» исемле мавыктыргыч хикәяләре һәм «Тимер дивизия» солдаты сөйли», «Мистер Умыржанның соңгы сәгате» исемле үткен сатира белән сугарылган памфлетлары басылган.

### Шамил Бикчурин

## ТАЛЬЯН МОҢЫ

Бәясе 13 тиен

Шамил Бикчуринның әле шушы араларда гына аерым китап булып басылып чыккан «Тальян моңы» исемле бу дүрт пәрдәле



комедиясе тамашачыларга таныш инде. «Тальян моңы» моннан берничә ел элек Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында һәм Әлмәт театрында зур уңыш белән барган иде. Партиянең XXII съезды хөрмәтенә Мәскәүдә үткәрелгән дәүләт театрлары конкурсында да зур уңыш казанып, беренче дәрәҗәле диплом алды ул. «Тальян моңы»н үзешчән сәнгать коллективлары да хуплап каршы алырлар дип ышанабыз.

Рәисә Ишморатова

## ТОРМЫШ ЮЛЫНДА

*Пьесалар*

Бәясе 46 тиен

Драма әсәрләре, хикәяләре һәм очерклары белән укучыларга инде күптән таныш язучы Рәисә Ишморатованың бу пьесалар җыентыгында «Әйтер идем йөрәк




серемне» исемле өч пәрдәле лирик комедиясе, «Тормыш юлында» исемле дүрт пәрдәле драмасы һәм «Бай кияү» исемле ике пәрдәле комедиясе басылган.

## ДУСЛЫК БУКЕТЫ

*Шигырьләр җыентыгы*

Бәясе 8 тиен

«Дуслык букеты» дип аталган бу китапта әзербайҗан шагыйрьләреннән Хагани, Низами, Нәсими,




Физули, Вагиф, Закир, Кодси Бакиханов, Мирза-Фатали Ахундов, Сабир, Сәмәт Вургун, Сөләйман Рөстәм, Мәмәт Рагим, Рәсул Рза, Талеэт Эюбов, Нәби Бабаев, Алиага Кюрчайлы, Нәби Хәзри, Зәйнал Хәлил шигырьләре урнаштырылган. Ул шигырьләрнең барысын да татарчага Зәки Нури тәрҗемә иткән.

Мәдинә Маликова

## ЮЛДАШЛАР

Бәясе 6 тиен

«Юлдашлар» — Мәдинә Маликованың беренче китабы. «Чаллы баскычлары», «Юлдашлар», «Алтын читлек» һәм «Кыр ягы» исемле хикәяләрне эченә алган бу җыентыгында автор хатын-кызларның тормышын, омтылышын, күңел күркәмлеген һәм якты уй-хисләрен сурәтли.




## ЯҢА ҖЫРЛАР

Бәясе 18 тиен

Редакциянең китаплар да, җырлар да җибәрү белән шөгыльләнмәвен әйтеп, журнал битләрендә әледән-әле искәртеп барылуга да карамастан, теге яки бу язучының китабын, яисә теге яки бу җырның текстын җибәрүне үтенеп, укучылардан бик күп хатлар килә. Китапларны ничек алдырырга икәнен аңлату ансат булса да, җыр текстлары мәсьәләсендә эш моңарчы шактый четрекле иде. Чөнки хәзерге заман җыр текстларын туп-




лаган телгә алып әйтерлек китап юк иде әле. Инде ул бушлык тутырылды: Татарстан китап нәшрияты йөздән артык җыр текстларын җыйнап, 50 000 данә тираж белән аерым китап итеп бастырып чыгарды.

*Хөрмәтле укучылар!*

Югарыда исемнәре аталган китапларны һәм, гомумән, үзегезне кызыксындырган барлык татар язучыларының китапларын түбәндәге адрес белән хат язып, почта аша алдырырга мөмкин: г. Казань, ул. Баумана, 19, Таткниготорг, отдел «книга-почтой».

Редакция китаплар җибәрү белән шөгыльләнми.

# *Укучы сүзе*

Кадерле редакция!

Мин «Казан утлары» журналын бик күп еллардан бирле алам, һәр санын игътибар белән укып барам. Шулай итми мөмкин дә түгел, чөнки безгә, әдәбият укытучыларына, әдәбияттагы яңалыклар белән танышу өчен журнал бердәнбер чыганак дияргә мөмкин. Журналның күләме дә шактый зур, төрле материаллар да күп басыла. Монысы яхшы. Ләкин, минем фикеремчә, журналда проза әсәрләренә урын аз бирелә. Ничек дисәң дә, бу бит татар телендә бердәнбер әдәби журнал, язучыларның яңа әсәрләрен без шушы журнал аша беләбез. Менә соңгы 8 нче санны алыйк. 158 биттән торган әдәби журналда проза әсәрләренә нибары 35 бит урын бирелгән, ә поэзиягә тагын да азрак. Бу бүлекләргә урын күбрәк бирелсә, яхшырак булыр иде.

8 нче санда басылган материаллардан миңа «Журнал турында сөйләшү» бик ошады. Язучыларның бер-берсен исемнәре белән атап, чын күңелдән сөйләшүләре, без укыган әсәрләр турында ачыктан-ачык үз фикерләрен әйтүләре безнең өчен дә бик кирәк. Журналдагы әсәрләр турында бездә дә күп төрле фикерләр туа бит. Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» исемле повестен нык кына тәнкыйть астына алганнар анда. Бәлки, язучылар күзе белән караганда уңышсыз яклары күптер. Ләкин, минем фикеремчә, ул тормыш дөреслегенә бик якын килгән. Фатих Хөсни иптәш авторны «кызларны йөгәнсез итеп бирүдә» гаепли. Ләкин азмыни әле бездә андый кызлар! Андый кызларны да, гыйбрәт өчен, сәхнә түренә менгереп утыртырга кирәк.

Журналда драма әсәрләренә дә урын күбрәк бирелсә яхшы булыр иде. Драматургларга да үпкәбез зур. Укырга ярарлык, ләкин сәхнәдә куярга ярамаслык пьесаларны күбрәк язалар. Халык, сәхнәдә пьесаның яртысы уйналгач та, ахыры нәрсә белән бетәсен белеп, кайта башлый. Тирән эчтәлекле, яхшы пьесалар кирәк.

Яшь шагыйрьләр турнирында Фәнис Яруллинның беренче урынны алуына бик шатмын. Без аның шигырьләрен бик яратып укыйбыз.

Тагын бер сорау.

Укучылар бик яратып укый торган язучыбыз Габдрахман Әпсәләмовның исеме әдәбият битләрендә бер дә күренми башлады. Аның сәламәтлеге ничек! Яңа әсәрләр өстендә эшли аламы! Укучылар бездән моны сорыйлар.

ЗӘЙТҮНӘ ӘХМЕРОВА,
Башкортстанның Тәтешле районы Аксөет урта мәктәбе тел һәм әдәбият укытучысы.

**РЕДАКЦИЯДӘН:**

*Габдрахман Әпсәләмовның сәламәтлеге һәм иҗаты белән бер З. Әхмерова гына түгел, башка күп кенә журнал укучылары да кызыксына. Шуны искә алып, редакция язучыдан укучыларга җавап бирүен үтенгән иде. Түбәндә Габдрахман Әпсәләмовның җавабын урнаштырабыз.*

Укучылардан килгән кечкенә генә сәлам-хат та язучының күңелен дулкынландырырга җитә кала. Бу — язучы бик беркатлы икән, ул җылы сүзләргә эри дә төшә икән дигән сүз түгел. Кайчак бик бизәклә язган зур-зур хатлар да сине тыныч калдыруы мөмкин, киресенчә, кайчак берничә юллык хат та синең тән йокыларыңны качыруы мөмкин. Хикмәт ул юллардагы эчкерсезлектә, сафлыкта, тойгылар тирәнлегендә.

Укучылар журнал битләрендә минем байтак вакыт тавышым-тыным ишетелмәүгә борчылалар икән. Бу хәл минем үземне дә бик газаплый. Ләкин ни хәл итәсең, түзмәс җирдән түзәсең. Менә бу юлларны да больница палатасында язам. Больница — иҗат урыны түгел, моны һәркем белә. Без барыбыз киләчәккә өмет белән яшибез, бу авыру бер үтеп китәр әле, дип ышанасы килә.

Минем укытучылар тормышыннан уйлаган бер әсәрем бар иде. Шуның каралмасын яздым да, тәмамлауны киләчәккә калдырып, читкә куйдым. Инде нишләргә! Тик тормассың бит. Сугыш елларында фронтта язган көндәлекләрем бар иде. Шуларны кулыма алдым. Төрле шартларда, төрле урыннарда карандаш белән генә сызгаланган язулар. Үземнән башка аларда казынырга теләүче дә табылмас бугай. Көндәлекләрнең кечкенә бер өлеше «Совет әдәбияты» [«Казан утлары»] журналында моннан нәкъ 25 ел элек, 1942 елда, басылган. Чиксез шатландым. Бу — Бөек Ватан сугышында катнашкан бер совет солдатының уйлары, тойгылары. Еллар аларга үзенә күрә бер объектив документ төсен биргән. Теләсә кем аларны укый, чагыштыра, нәтиҗә ясый ала. Тагын бер мөһим ягы шунда: Ватан сугышы тәмамлануга чирек гасыр үтте инде, ә кайберәүләр бу сугышның дөнья күләм нәтиҗәсен күрмәмешкә тырышалар, янәсе, совет халкы, шул халыкның аерылмас бер өлеше — татар халкы көнбатышка бары тик дәһшәт кенә илткәннәр, алар — көнбатыш цивилизациясен җимерүче варварлар гына булганнар. Менә шундый коточкыч яла ягучыларга да җавап бирәсем килде. Менә күрсеннәр: нинди уйлар белән гади бер совет солдаты сугыш утларына кергән, ничек сугышкан, нинди тойгылар белән сугыштан чыккан.

Әлбәттә, яза торгач, көндәлекләр белән генә чикләнмәдем. Аларга ниндидер бер төзек форма бирер өчен гамьсез бала чакларыма да, яшьлек елларыма да тукталырга кирәк булды. Бигрәк тә әдәбиятка килү юлларымны яктыртасым килде. Бу турыда материаллар юк диярлек, аннары укучылардан да бик күп сораулар бар иде.

Ватан сугышы тәмамлану белән минем язмалар да бетә. Нәрсә килеп чыккандыр — әйтә алмыйм. Язмаларның исемен «Гомер сәхифәләрен ачканда» дип куйдым.

Менә нибары шул. Кулымнан килгән кадәрле вакытлы матбугатта да катнашырга тырышкан булам.

Хатында минем хәлне сораган Зәйтүнә Әхмерова һәм башка бик күп иптәшләргә чын күңелдән рәхмәт.

17. X. 1967 ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВ.

# „КАЗАН УТЛАРЫ“ ЖУРНАЛЫ БИТЛӘРЕНДӘ 1967 ЕЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

## ПРОЗА ӘСӘРЛӘРЕ

Абдуллин И. **Мин ничек ир кешегә әйләндем.** Хикәя. № 6.
Баянов Ә. **Яшьлегемне эзлим.** Повесть. № 1, 2, 3.
Бәширов Г. **Туган ягым — яшел бишек.** Автобиографик повесть. № 5, 6, 7, 8, 11.
Бикчәнтәев Ә. **Койрыклы тел.** Хикәя. № 6.
Воскресенская З. **Йокысыз төн.** Хикәя. № 4.
Гази И. **Малайлыкта кунакта.** Автобиографик повесть. № 2.
Гази И. **Кызыл томаннар артында.** Хикәя. № 10.
Еники Ә. **Мәчет җылый.** Хикәя. № 8.
Исәнгулов Ф. **Балаларым, газизләрем.** Хикәя. № 6.
Исхаков В. **Базар тавыгы.** Хикәя. № 6.
Ихсанова Л. **Мин әле бу.** Хикәя. № 3.
Мин Тхюи. **Вакытлы килешү көнендә атышлар.** Хикәя. № 1.
Минский Г. **Мылтыклы кеше.** Хикәя. № 8.
Мәһдиев М. **Сабантуй көнендә. Кеше күңеле. Тормыш дулкыннары. Галиябану. Алла бармы! Ахири.** Этюдлар. № 5.
Мөхәммәтшин Г. **Тәмәкене ничек ташларга.** Хикәя. № 2.
Расих А. **Ямашев.** Роман. № 9, 10, 11, 12.
Төхфәтуллин Р. **Пыяла ватыгы һәм асылташ. Ике көймә. Яшьлек сере.** Парчалар. № 2.
Фан Ты. **Ике бертуган.** Хикәя. № 1.
Фазылҗанов Ә. **Бәхәс. Буш баш.** Юморескалар. № 4.
Фәизов Р. **Гафур.** Хикәя. № 3.
Фәттах Н. **Улым турында хикәяләр.** № 5.
Фәттах Н. **Мөдир Саҗидә.** Повесть. № 10, 11, 12.
Хөсни Ф. **Язмыш шуклыгы.** Повесть. № 4.
Хөсни Ф. **Бар иде Балтачта бер әтәч.** Хикәя. № 7.
Хөсни Ф. **Яз галәмәте.** Хикәя. № 9.
Шолохов М. **Күтәрелгән чирәм.** Романнан өзек. № 6.

## ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Вахит Х. **Соңгы хат.** Пьеса. № 6, 7.
Катиев И. **Ялкын.** Драма. № 9.
Миңнуллин Т. **Бәхетле кияү.** Пьеса. № 4.
Монасыйпов В. **Суйдылар. Нәкъ үзе.** Скетчлар. № 5.
Нәбиуллин Г. **Урак өсте.** Сценарий. № 6.
Шәкүров С. **Ана.** Драма. № 3.

## ШИГЫРЬЛӘР һӘМ ПОЭМАЛАР

Арсланов Н. **Моңсар.** Поэма. № 2.
Арсланов Н. **Тиен. Тукран. Икмәк валчыгы. Өч дус.** Шигырьләр. № 5.
Арсланов Н. **Диңгез ярында.** Шигырь. № 11.

Атнабаев Ә. Эш. Мирас. Кешегә нәрсә җитми. Юлда. Кирәк икән. Бер генә. Үлем килгәч. Шигырьләр. № 4.

Атнабаев Ә. Ышаныч. Шигырь. № 6.

Афзал Г. Җанга якын урыннар. Китабым. Кичке моң. Туган телем. Гөлҗимеш. Шигырьләр. № 5.

Афзал Г. Кызыл йолдыз. Поэзия. Бер елмаю. Мине картайткан. Борылам да карыйм. Берәү. Шигырьләр. № 9.

Баянов Ә. Тыйнак кеше турында баллада. Шигырь. № 10.

Беляев И. Иманнәрең илтеп утырт шунда. Шигырь. № 11.

Биишева З. Җырларым. Башкорт теле. Шигырьләр. № 6.

Биккол Ш. Нигә, иркәм. Соңгы трамвай. Җырлар. № 6.

Булатова К. Яратаммы сине! Ялгыз каен. Вакыт үтә. Яшьлек эзем калган. Шигырьләр. № 1.

Велюгин А. Иделдән искән җилләр. Поэмадан ике өзек. № 4.

Галиев Ш. Пәрәмәч. Тилгән килгән шәһәргә. Табын янында. Хәйләкәр курчак. «Сәгать йоткансың!» Кайнар шугалак. Борау-сорау. Шигырьләр. № 2.

Галиев Ш. Шигъри рецензияләр. № 3.

Галиев Ш. Испемай. Актүш һәм велосипед. Басмалар саный Әсма. Шакир һәм шикәр. Колмак. Кыяр-кыймас. Багана. Шигырьләр. № 4.

Галиев Ш. Шигъри рецензияләр. № 6.

Галиев Ш. Юаттылар. Бари. Шигырьчегә. Дөнья — куласа. Чамала. Чират күпере. Шигырьләр. № 8.

Галиев Ш. Җир баласы идем. Яшьләр, яшьләр. Тормышымда азмы күрелгән. Ашыкма, каләм. Яшьрәк чакта. Сабыр диеп. Унөченче елга чагыштырып. Исемеңне алып җырга куштым. Хәтерлим. Сөйгән ярым минем тылсымчы. Белеп булмый. Шигырьләр. № 9.

Гатауллин Рәдиф. Лениза. Идеал. Кадерлем, кояш кызы син. Мин элекке һаман. Әгәр. Шигырьләр. № 6.

Гатауллин Рәшит. Барысы да әле ярты юлда. Әллә нигә уйландыра. Шигырьләр. № 9.

Гайнанов Э. Майсыз тәгәрмәч. Палас язмышы. Термометр. Шигырьләр. № 9.

Гафури М. Кызыл байрак. Шигырь. № 10.

Гафури М. Бир кулыңны. Шигырь. № 11.

Гәрәева С. Әй, бер заман. Юлларга чыгам. Ул көнче. Карлы юллар. Кайтып киләм. Син еракта. Шигырьләр. № 3.

Гәрәй Р. Уйланган минутларда. Шигырь. № 2.

Гәрәй Р. Яратам мин Ленин районын. Шигырь. № 11.

Давыдов Ә. Мин — партизан. Татар китабына. Сынчы турында баллада. Була диләр. Башны тагын минем кыса. Нигә башың салдың әле, туган! Юлның тигезе юк. Тыныч караучылар юк миңа. Дус кеше ул. Шигырьләр. № 5.

Давыдов Ә. Октябрь кояшы. Шигырь. № 10.

Ерикәй Ә. Минем өчен Казан — әткәм йорты. Шигырь. № 11.

Закиров Р. Яшьлек эзләре. Юл буенда. Шигырьләр. № 7.

Зәйнашева Г. Уз илемдә. Ник чәчәгең сары. Тәрәз төбемдә. Шигырьләр. № 3.

Йосфи И. Байларга. Шигырь. № 10.

Камалов Х. Күңелдәге язулар. Эскизлар. № 8.

Киньябулатова К. Язмыш. Бик күп кирәк. Шигырьләр. № 6.

Кәрим М. Әнием чирләгәндә. Айсылуның күз яшьләре. Шигырьләр. № 6.

Кудаш С. Әйдә, тамсын. Кайгырам. Бик чәнчешеп. Карт бөркет. Ак сакалын селкә-селкә. Юлда барганда. Кала икән. Шигырьләр. № 5.

Маннапов Ш. Ышандыр. Хис. Хатирә. Шигырьләр. № 11.

Мингалимов Р. Сөенечем. Очрашу. Әрсезләр. Шигырьләр. № 7.

Мин Ле. Үлем килсә әгәр. Шигырь. № 3.

Мостафин К. Йолдыз. Тынычсызлык. Шулай була икән. Дезертир. Һәр кешенең үз йолдызы була, диләр. Шигырьләр. № 1.

Мөэминова Э. Аңлармы ул. Туган җиргә мәхәббәтем. Шелтә сүзе ишеткәлим. Сәер мәхәббәт. Кыз язны ашыктыра. Шигырьләр. № 1.

Нгуен Дин Тхи. Дөге. Шигырь. № 3.

Нури З. Яз көнендә туган кешегә. Шигырь. № 10.

Нури З. Чәчәкле этюд. Белсәм әгәр. Гыйшык уты. Кәләпүш. Ике башак. Бер кәрләгә. Ашыгуга каршы. Сүздә һәм эштә. Оптимист ялкау. Борчак һәм ногыт. Актарыла урам. Шагыйрь шунда иде. Авызын бикләде. Эре белән вак. Масаю. Сүз остасы. Уңай тип. Яла ягучы. Тасма тел. Акыллы зат. Шигырьләр. № 12.

Рафиков Б. Хәтер саклый. Кай арада. Таш кыяны. Төнге утлар. Төн күзәтә. Бәхет колы. Картлыгыма нәсихәт. Урманчы истәлегенә. Шигырьләр. № 5.

Рәхим Г. Сагыш һәм шатлык. Сугышта югалган солдатлар. Вәгъдә. Сабыйларга. Шигырьләр. № 7.

Садри М. Булган икән көч тә үзеңдә. Шигырь. № 2.

Садри М. Пушкин Одессада. Данко. Крейсерда сандугач. Шигырьләр. № 5.

Салахов И. Мин даланы сөям. Юлда. Иҗат газабы. Барыннан да син сылу. Шигырьләр. № 3.

Сирай Д. Яшьлек кебек. Наратлар талпына. Әй, сары яфрагым. Шифа бирә. Үз елгам бар. Алып кайтмас. Шигырьләр. № 12.

Сөләйманова С. Көз. Серләремне сиңа сөйлим. Шигырьләр. № 3.

Сөләйманова С. Балкыды да сүнде. Бу диңгезгә төшеп югалмыйсың. Таулар кичтем. Мәхәббәт фонтаны. Шигырьләр. № 8.

Сөләйманова С. Җир-су. Поэма. № 10.

Такташ Һ. Алтын сарайларга. Шигырь. № 10.

То Хыу. Кешелек язы. Шигырь. № 3.

Туфан Х. Кояш. Уралда. Завод ябылгач. Каспий яры. Уйланулардан. Татарстан бу. Шигырьләр. № 10.

Туфан Х. Бәйрәмгә килгәндә. Шигырь. № 11.

Фәйзуллина М. Тапшырылмаган хатлар. Шигырь. № 3.

Фәйзуллин Р. Туган якка. Читтә. Яшь беткәнче елыйлармыни. Көн шыксыз дип карадым. Ярлар күчәр. Куеп тереклек итүнең. Шатлыгы киләме. Мескен. Кайгы чәчеп. Минем турыда. Көз. Катлаулы икән. Тышка чыксам. Башны салларга салып. Шигырьләр. № 9.

Хуҗиев Г. Рөхсәт ит син миңа. Яшәү дәвамы. Учак. Каеннар. Аның рәсеме. Тормыш корабында. Гомер китабы. Без — кичәге фронт кешеләре. Бер уч туфрак. Шигырьләр. № 3.

Хуҗиев Г. Тәрәзәләр таңга карый. Поэма. № 12.

Хәким С. Яшьлегем искә төшереп. Шигырь. № 10.

Хәлим А. Колмак җыя кызлар. Тальян моңы. Шигырьләр. № 9.

Шамуков Г. Елан кырмыска оясында. Тәэсирле хат. Аптыраш. Мәсәлләр. № 2.

Шәрәпов Ш. Чебен. Шигырь. № 9.

Чанг-Хыу Тхунг. Бишек җыры. Шигырь. № 3.

Яруллин Ф. Якташлар. Яши алмыйм шунсыз. Җилкәмдәге авырлыкны. Башыңны күтәр әле. Туган авылым. Шигырьләр. № 6.

Җәлил М. Кошчык. Шигырь. № 10.

Юзеев И. Тынлык белән сөйләшү. Поэма. № 1.

## ҖЫРЛАР

Арсланов Н. Табын җыры. Ключарев музыкасы. № 10.

Вахит Х. «Соңгы хат» драмасыннан. Х. Вәлиуллин музыкасы. № 3.

Дәүли Н. Вьетнам солдатына. А. Ключарев музыкасы. № 5.

Туфан Х. Киек казлар. М. Макаров музыкасы. № 1.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Идиятуллин Р. Үз йолдызым. Белмим, кеше нидән яралгандыр. Нанлэгә. Кызлар күлә. 9 нчы Май шигыре. Безнең авылны күреп ярата алмаса да. Музыка. Шигырьләр. № 4.

Фазлыев Р. **Уйлану. Дүрт солдаты туган илемнең. Вьетнамга. Көтеп яшәү бигрәк авыр икән.** Шигырьләр. № 4.

Харисов Р. **Китү, кәтү, кайту. Уйнамагыз. Авыл карты. Бөртек-бөртек. Салкын яз.** Шигырьләр. № 4.

Шәфигуллин Ф. **Эшче горурлыгы. Унҗидедә. Туып үскән нигез ташларына. Сиксән яшьлек Тукай. Алтын эзләүчеләр.** Шигырьләр. № 8.

Х. Әюпов. **Күләгәләр. Танышу. Вәгъдә. Горур дисең. Киләчәген сагына. Белгесезлек. Мәхәббәт алланнарында. Хыял. Ышанып та бетмим.** Шигырьләр. № 4.

## ДУСЛАР ҖЫРЫ

Аманква Опоку. **Елга.** Шигырь. № 11.

Бекхожин Х. **Җырчыга.** Шигырь. № 3.

Бәхтия И. **Бакчачы. Бәлки бәхетле итү кулымнан да килмәс.** Шигырьләр. № 9.

Госманов М. **Уйгур әдәбияты сәхифәләре.** Мәкалә. № 9.

Дагстан халык җырлары. № 1.

Деннис Осадебей. **Тәвәккәллек.** Шигырь. № 11.

Искәндәров Һ. **Ак каеннар. Китмәнем.** Шигырьләр. № 9.

Молдагалиев Ж. **Кырык кыз. Мәңге биесәче. Сагынам.** Шигырьләр. № 3.

Моллаудов С., Г. Сәгъдеваккасов. **Татар һәм уйгурлар арасында культура мөнәсәбәтләре тарихыннан.** Мәкалә. № 9.

Нәхид Әбү Зәһра. **Өченче бомба ташланмас.** Шигырь. № 11.

Тажибаев А. **Моң турында. Борчылма ярлы чагыңда. Кайнар булсын. Сөенечемнең чиге юк. Ак нурлар.** Шигырьләр. № 7.

**Уйгур халык мәкальләре һәм мәзәкләре.** № 9.

Флавиен Ранаиво. **Бер гашыйкның җыры.** Шигырь. № 11.

Хәсән Н. **Үз анамсың.** Шигырь. № 9.

Һәмраев Х. **Көтүче кыз. Мәхәббәт һәм җырларым.** Шигырьләр. № 9.

## СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Гайнуллин Н. **Ерактагы якташларыбыз янында.** Очерк. № 10.

Гарәфетдинов Р. **Татар яшьләренең демократик хәрәкәте тарихыннан.** Мәкалә. № 5.

Гыйбадуллин М. **Революционер, хәрби җитәкче.** Очерк. № 9.

Данильченко С. **Чапаев Казанда.** Истәлек. № 10.

Ибраһимов Ф. **Без түбәннән күтәрелдек.** Мәкалә. № 6, 7.

Кадыйров Г. **Машиналар гөрләгәндә.** Очерк. № 10.

Камал Ш. **Тын таулар җилкәсендә.** Очерк. № 10.

Курчаков Г., Насыйров Г. **Кем идек һәм кем булдык.** Мәкалә. № 4.

Миңнуллин Ф. **Якты юллар сызып.** Мәкалә. № 10.

Мөхәррәмов М., Әхмәдуллин А. **«Эш» газетасы битләрендә әдәбият-сәнгать мәсьәләләре.** Мәкалә. № 5.

Госманов М. **Тарих һәм тарихчылар.** Интервью. № 11.

Римаренко Ю. **Дуслыкның матур үрнәге.** Мәкалә. № 1.

Сабиров С. **Дулкыннар ни сөйли.** Очерк. № 10.

Такташ Һ. **Тыңла, ТАПП!** Мәкалә. № 10.

Таҗетдинов Ә. **Бөек Октябрь һәм Татарстанда культура революциясе.** Мәкалә. № 9.

Ульянова-Елизарова А. И. **Казандагы тормыш.** № 10.

Усманова З. **Татар мәдәниятенең көндәлек дәфтәреннән.** Хроника. № 10, 11.

Госман Х. **Кабатланмас документ.** № 10.

Хәмитов М. **Солдат даны.** Очерк. № 10.

Хәйруллин Х. **Алмаз ихтыяр.** Очерк. № 8.

Әхмеров З., Касыймов Э. **Н. К. Крупская Идел-Кама буйларында.** Мәкалә. № 7.

Әхмәдуллин А. **Татар совет мәдәниятенең көндәлек дәфтәреннән.** Хроника. № 7, 8, 9.

Әхмәтҗанов З. **Октябрь яшьтәше.** Очерк. № 11.

Һидиятуллин Р. **Ялкынлы елларда.** Истәлек. № 10.

## ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Бикчурин Ш. **Могҗиза тудыручылар.** Очерк. № 6.

Вагыйзов Д. **Принцип.** Очерк. № 4.

Вагыйзов Д. **Балыкчылар.** Очерк. № 9.

Касыймов Э. **Карт рәссам белән очрашу.** Очерк. № 4.

Насыйров Ф. **Хезмәтенә карап хөрмәте. Гөлләр чәчәк ата.** Очерклар. № 5.

Хәсәнов М. **Таныш булыгыз, Сәет Сәлимгәрәев.** Очерк. № 1.

Хәсәнов М. **Эш сөйгәнне ил сөя.** Очерк. № 7.

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БАТЫР УЛЛАРЫ

Алишев С. **Пугачев полковнигы.** Мәкалә. № 1.

Кизя Л. **Партизан Морат.** Очерк. № 1.

Әпсәләмов Г. **Унсигез яшь.** Очерк. № 5.

## ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Госман Х. **Халыкның үзеннән.** № 11.

Халит Г. **Романтизмны һәм реализмны яклап.** № 8.

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Алишев С. **Яңа сәхифәләр ачылганда.** Мәкалә. № 2.

Гобәйдуллин Х. **Габделрәуф Ниязбаев.** Мәкалә. № 4.

Золина А. П., Насыйров Т. Н. **Муса Җәлил биографиясенә яңа документлар.** № 12.

Исәнбәт Н. **Бу шигырьнең шагыйрәсе кем!** Мәкалә. № 1.

Исәнбәт Н. **Шәйхзадә Бабич.** Истәлек. № 6.

Кәримуллин Ә. **Беренче татар китаплары.** Мәкалә. № 5.

Миңнуллин Р. **Тукай Астраханьда.** Истәлек. № 4.

Скворцов В. **Архив киштәләреннән.** Мәкалә. № 4.

Фәтхи А. **Азатлык өчен көрәшләрнең яңа бер әдәби документы.** Мәкалә. № 5.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ахунов Г. **Язучы һәм заман.** № 5.

Башкуров Р. **Үткән елның шигъри тавышы.** № 9.

Госманов М., Мәһдиев М. **XX йөз башы татар әдәбияты һәм матбугат тарихының кайбер мәсьәләләре.** № 7.

Мәҗитов З. **Фәнни тирән һәм туры сүзле тәнкыйть өчен.** № 5.

Харисов Р. **Юл өстендә кояш.** Мәкалә. № 12.

Юзеев И. **Кайбер уйланулар.** № 3.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

Ахунов Г. **Җир һәм күңел җылысы.** № 4.

Сафуанов С. **Бакчачы турында хикәя.** № 8.

## ЯҢА ДОКУМЕНТЛАР

Габәши С. **Татар һәм башкорт көйләре турында.** № 7.

ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ

Батуллин Р. Бүген концерт була. № 8.
Әмир М. Укучы өчен язабыз. № 6.

СССР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IV СЪЕЗДЫ

Делегатлар сөйли. Мәкаләләр. № 8.

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ

Вәлиев Ф. Чуптарлы һәм асалы тукымалар. № 8.
Рәхимов М. Рәссам һәм тормыш. № 11.
Юзиев Н. Музалар туганлыгы № 9, 12.

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

Бейлькин Ю. Җырым булсын бүләгем. Иҗат портреты. № 1.
Бейлькин Ю. Скрипка моңнары. Иҗат портреты. № 8.
Воронов В. Мәңгелек яшьлек. Иҗат портреты. № 6.
Саликова З. Галия Гафиятуллина җырлый. Мәкалә. № 2.

ТЕАТР

Бәйрәм белән. Мәкалә. № 1.
Гобәйдуллин Х. Эшчеләр бистәсендә спектакль. Истәлек. № 1.
Гыйззәтуллин Б. Сәнгатьтә яңа үрләргә. Мәкалә. № 2.
Илялова И. Үрнәк булырлык иҗат. Мәкалә. № 1.

ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕННӘН

Хәсни Ф. Урыннарындамы сүзләр-солдатлар. Мәкалә. № 1.

ЯЗУЧЫНЫҢ КУЕН ДӘФТӘРЕННӘН

Ерикәй Ә. Шигырьләр. № 3.
Әпсәләмов Г. Яфраклар коела. № 9.

БЕЗНЕҢ САФКА

Гыйләҗев А. Төкле аягың белән. № 5.
Туфан Х. Сокландыра да, шатландыра да. № 2.
Хәким С. Поэзиябезгә яңа шагыйрь килә. № 2.

ИСТӘЛЕКЛӘР

Аитов Л. Артистның тормыш юлы. Истәлек. № 11, 12.
Сафиуллин Г. Днепрны кичү. Мемуар. № 2, 3, 4.

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Бәширов Г. Әдәбиятыбызның аксакалы. Анкетага җавап. № 3.
Гомәров Л. Ул зур җәмәгать эшлеклесе иде. Истәлек. № 2.
Ибраһимов Г. Автобиография. № 2.
Ибраһимов Г. турында галимнәр һәм әдипләр. № 3.
Кадыйров О. Романтизмнан реализмга. Мәкалә. № 3.
Кәримова З. Ул безнең якын дустыбыз иде. Истәлек. № 3.
Маннурова М. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романында рус образлары. Мәкалә. № 2.
Минский Г. Бай мәктәп. Анкетага җавап. № 3.
Рафиков С. Беренче йолдызлар. Анкетага җавап. № 3.

Расих А. Килер буыннарга да остаз ул. Анкетага җавап. № 3.
Фасеев К. Бөек Октябрь һәм интернациональ культура. Мәкалә. № 3.
Фәттах Н. Мондый кешеләр сирәк туа. Анкетага җавап. № 3.
Хаҗиәхмәтов Т. «Безнең көннәр» романына иллюстрацияләр. № 1, 2.
Хәсәнов М. Революция байрагы астында. Мәкалә. № 1.
Хәсәнов М. Г. Ибраһимов һәм татар әдәбиятында социалистик реализм формалашуының кайбер мәсьәләләре. Мәкалә. № 3.
Хөсни Ф. Баскычлы юл юк. Анкетага җавап. № 3.
Шәрипова Г. Көндәлек битләреннән. Истәлек. № 4.
Әдипнең телеграммалары, яңа хатлары. № 3.
Әдһәмова Г. Киң дала — чал тарихның шаһите. Мәкалә. № 3.
Әмир М. Гүзәл тойгылар уятучы әдип. Анкетага җавап. № 3.

МИРСӘЙ ӘМИРГӘ 60 ЯШЬ

Расих А. Әйтәсе сүзләр күп әле. Мәкалә. № 1.
Әмир М. Мәхәббәт хаты. Яңа әсәрдән өзек. № 1.

ХӨСӘЕН ЯМАШЕВНЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби. № 1.

ИБРАҺИМ ГАЗИГА 60 ЯШЬ

Нуруллин И. Юк, тургай картаймый. № 2.

ГАЗИ КАШШАФКА 60 ЯШЬ

Минский Г. Халыкка хезмәт. № 4.

БАРИ РӘХМӘТНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Тәрҗеманов Җ. Мәңге яшь талант. № 5.

КАНДАЛЫЙНЫҢ ТУУЫНА 170 ЕЛ

Госманов М. Кандалыйның билгесез поэмалары. № 6.

ГАЛИМҖАН НИГЪМӘТИНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Исхаков М. Безнең сафта. Истәлек. № 7.
Нуруллин И. Киң карашлы галим. Мәкалә. № 7.
Фәйзуллина М. Тәнкыйтьче, педагог һәм фән эшлеклесе. Исәлек. № 7.

ГАРИФ ГОБӘЙГӘ 60 ЯШЬ

Ибраһимова Ф. Кайгыртучан дус. Мәкалә. № 8.

КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Кумысников Х. «Җилкәнсезләр» һәм аның сәхнә тарихы. Мәкалә. № 9.

УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА

Вәлиев Ф. Борынгы бабаларыбыз кемнәр. № 2.
Дубин А. Тормыш көзгесендә. № 4.
Мәҗитов З. Хәерләре белән үссеннәр. Мәкалә. № 1.
Фәхретдинов Р. Болгар тарихына яңа истәлекләр. № 7.

## БӘХӘСЛӘШӘБЕЗ, ФИКЕР АЛЫШАБЫЗ

Гыйләҗев А. Ә син үзең кем, укучы! Мәкалә. № 11.
Маликова М. Кем ул Әнис Бадигин. № 8.
Нәҗметдинов Г. Мин үкенмим. № 9.
Әхмәдиева Л. Әсәр хакында берничә сүз. № 9.

## ЯЗУЧЫЛАР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА

Вуап-Мокану Ш. Җәлил Румыниядә. № 8.
Голәм Г. Шагыйрьнең мәңгелеге. № 7.
Камалетдин Җ. Җәлил турында сүз. № 2.
Камалетдин Җ. Казан турында кайбер тәэсирләр. № 11.
Небенцаль Л. Шагыйрь-көрәшче. № 2.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Бакиров Г. Җимерелгән бастион. № 3.
Гөрәй Р. Җырлап үтик еллар аркылы. № 3.
Нигъмәтуллин Ә. Безнең Ильич. № 4.
Фәйзуллин С. Халыклар дуслыгы турында сөйләүче китап. № 1.
Фәттах Н. Беренче китап һәм балалар әдәбияты. № 9.
Харисов Р. «Аҗаган». № 1.
Харисов Р. Юл өстендә кояш. № 12.
Хисмәтуллин Х. Г. Тукай альбомы. № 1.
Әдһәмова С. Күкчәтау далаларында. № 4.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Госманов М. Тагын Ибраһим хан ярлыгы турында. Мәкалә. № 6.
Мәхмүтов Х. Садовников җыентыгындагы татар табышмаклары. Мәкалә. № 6.
Сатторов Г. Казан урамнарының исемнәре. Мәкалә. № 8.
Сүнчәләй Сорур. Каргалыда татар түе. Мәкалә. № 5.
Фәттах Н. Археология докторы А. Халиков белән әңгәмә. Интервью. № 6.
Фәйзи Җ. Чәчкап альбомы. Истәлек. № 4.
Хәйретдинов Р. Татарстан тарихы буенча чит илдә чыккан бер китап турында. Мәкалә. № 7.

## ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Курган татарларының авыз иҗаты. № 9.

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Гобәйдуллин Х. Халык артисты. № 8.
Шәрәфиев Ф. Сәнгатькә багышланган гомер. № 8.

## ӘДӘБИ КОНСУЛЬТАЦИЯ

Арсланов Н. Хатлар актарганда. № 4.

## ФОТОРЕПОРТАЖ

Хәкимуллин Н. Фотообъективта — Непал. № 7.

## ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА

Таҗетдинов С. Укучыларга җавап. № 9.
Укучылар сүзе. № 1, 2, 4, 7, 12.
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—11.
Кроссворд. № 6.
Яңа китаплар. 2, 5, 6, 12.

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 13/X-1967 ел. Басарга кул куелды 22/XI-1967 ел. ПФ 09046. Кәгазь форматы $70 \times 108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 56346 экз. Заказ М-1695. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

„Казан утлары“ журналының алдагы саннарында сез *Ә. Еникинең „Җиз кыңгырау“ дигән хикәясен, Э. Касыймовның „Бир кулыңны, дустым“ дигән повестен, Н. Дәүлинең „Кеше турында монолог“, Ә. Маликовның „Салкын-Алан“ дигән поэмаларын, С. Хәким, Ш. Галиев, Г. Латыйп, К. Мостафин һ. б.* шагыйрьләрнен шигырьләрен укый аласыз.

Алдагы ел өчен журналга теләсә кайсы айдан язылу дәвам итә.

Язылу бәясе бер елга 4 сум 80 тиен
ярты елга 2 сум 40 тиен
бер айга — 40 тиен.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

# Казан утлары

## (ОГНИ КАЗАНИ)

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210